ISSN 0206–4189 12+
Индекс 73210

# Казан утлары

11.2015



# БУ САНДА:



**Без тарихта эзлеме?**

*«Түгәрәк өстәл»*

«Казан ханлыгында Сәет дәрәҗәсендәге шәхес ил-көн күзендә. Аның хатынының иреннән яшертен эшләре барыбер дә инкарь ителер иде. Сәет кадәр Сәетнең үз йортында тәртип сала алмавына ишарә түгелме бу: үз йортында тәртип сала алмаган, ил-йортында ничек тәртип салсын, янәсе?.. Казанның алынуы, тарих күзлегеннән караганда, кичәге көн генә, дидек. Халык хәтерендә һәм тарих фәнендә Казанның алынуы Сәетнең гаиләсендә тәртип булмаудан түгел, ә татарның чуарлыгыннан, бер-берсенә терәк-туган булмаудан, ханнары-морзаларының сәяси сукырлыгыннан...»

136

# КИЛӘСЕ САНДА:

**Зөлфәт ХӘКИМ**
**«Газап»**

*Бәян*



«Мин аермачык хәтерлим: беркөнне көнләшеп сиңа бәйләнә башлагач, син миңа: «Җүләрләнәсең бит инде көнләшеп», – дидең. «Әйе, мин инде авырыйм бугай», – дип килештем. «Дәваланырга кирәк», – дидең син. «Мин риза. Минем үземнең дә көнләшәсем килми», – дидем мин.
Шуннан соң син, сөенеп, мине назлый башладың һәм без караватка яттык. Бер-беребезне сөеп, күңелләребезне күргәннән соң, ятып йокладык. Йокыга киткәндә, һәр икебез бу тотрыклылыкның вакытлыча гына икәнен һәм барыбер безнең арага тиздән көнләшү дигән кара мәченең тырнакларын тырпайтып килеп керәсен онытмадык.
Икенче көнне өебезгә мәчеләр түгел, ике табиб килеп керде. Тыныч, ягымлы әңгәмәдән соң алар мине, машинага утыртып, психушкага алып килделәр».

www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рашат НИЗАМИ. «Әйе!» һәм «Юк!». *Публицистик цикл.* ..... 3
Вахит ИМАМОВ. Сөләйман солтан. *Тарихи роман.* ..... 8
Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. Кояш чыга һәркөн саен иртән... *Робагыйлар.* ..... 54
Рәшит БӘШӘР. Ачык күңел ишегем. *Шигырьләр.* ..... 60
Алмаз ХӘМЗИН. Шамкай. *Бәян.* ..... 64
Сания ӘХМӘТҖАНОВА. Арча сулары. *Лиро-эпик цикл.* ..... 132

*100нче бит:* Вахит ИМАМОВ. Яңа байларыбыз татармы? ..... 100

Без тарихта эзлеме? *(Г.Арсланов, И.Заһидуллин, И.Ибраһимов, И.Рамиева, Р.Ханнанов, З.Хәким, Ф.Хуҗин катнашында «түгәрәк өстәл»).* ..... 136

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фәридә ХӘСӘНОВА. «Бар гаебең ихласлык булган, шагыйрь!»: яки мулла мәхәббәте турында уйланулар. ..... 148
Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Бер китап тудырган күп уйлар. ..... 154
Рабит БАТУЛЛА. Бер кәлимә, ике сүз. ..... 157

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Фәнзаман БАТТАЛ. «Күләгәдәге» Баттал *(Салих Батталның тууына 110 ел).* ..... 160
Камил КӘРИМОВ. Арча кыры *(Гариф Ахуновның тууына 90 ел).* ..... 170

**ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ**

Рифә РАХМАН. «Нинди дәрт берлә каләм сызсам да...» ..... 175

**СӘНГАТЬ**

Яшәвенең гаме дә, яме дә — театр *(Нәилә ГӘРӘЕВА белән Гүзәл СӘГЫЙТОВА әңгәмәсе).* ..... 178

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ..... 185

Мәкаль өмәсе. ..... 188
«Казан утлары» архивыннан. ..... 58
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 190

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (өст. 1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст. 1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст. 1268).*
✆: **Факс** — (843) *222-09-83 (өст. 1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.10.2015, график буенча 30.10.2015.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-3097. Тираж 4010.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2015 ел



Рашат
Низами

## «ӘЙЕ!» ҺӘМ «ЮК!»

ПУБЛИЦИСТИК ЦИКЛ

*Сугышны бер сүз белән башлап та,*
*бер сүз белән туктатып та була.*

R.N.

### Әйтче, кояш!

Кояш, Кояш! Әйтеп бирче:
Галәми яшен күпме?
Кемнәр сине элеп куйган
Бизәкләп зәңгәр күкне...

Жирдә барган орышларны
Күзәткәнсең «Аh!» итеп.
Миллион елларны кичкәнсең,
Син — шаһитләр шаһите.

Кыйтгаларда сугыш бара,
Елга булып кан ага.
Бу тарихта булгандыр бит
Сугышларсыз замана?

Бикфорд очындагы ялкын
Кая таба үрмәли?..
Шартламасмы? Чорналган ул
Жир күчәре тирәли.

Кулга — мылтык-кылыч түгел,
Вакыт каләм алырга;
Солых дигән шартнамәгә
Асыл тамга салырга.

Орден кадау нигә кирәк
Жанкыярлар түшенә?
Ходай биргән бер гомере
Насыйп булсын кешегә.

Без бит атом гасырының
Уллары һәм ... коллары.
«Кол булмаска!» диеп тетри
Гитарамның кыллары.

Хиросима, Нагасаки —
Көлгә очкан шәһәрләр...
Бомба ижат итүчене
Аллаһ үзе каһәрләр.

Рашат НИЗАМИ (1950) – *шагыйрь, прозаик; «Кызыл җәй», «Яшьлеккә хат», «Яшәүгә гимн» һ.б. китаплар авторы. Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

«Сугыш-сугыш» уйнаулардан
Жирдә кан һәм яшь арта.
...Трибунада чал Сахаров —
Атом бомбасы «әхлагын»
Чәеп ташлый башаркан!

Баш тартты ул дәрәҗәле
Титуллар, орденнардан.
Кирәкмиләр! Җан түрендә
Нибары тәүбә калган.

Хөрмәтли, алкышлый дөнья
Шушы Тәүбә иясен, —
Чәчәк итеп сузды аңа
Нобель премиясен!

Тукаебыз дөрес әйткән:
Яшәү фарыз аңлашып, —
Халыкара мәйданнарда
«Тел вә лөгать алмашып».

Бер хакыйкать вәхи булып
Уелган дивар-ташка:
Тарихларны язып булмый
Илен, халкыннан башка.

Вакыт — сугыш-албастыны
Цементлап катырырга;
Тын океан төпләренә
Мәңгегә батырырга!

Туганлыкка — яшел урам,
Ә тынычлыкка — «ӘЙЕ!»
Сугышларга: «ЮК!» — диябез,
Бетсеннәр алар мәңге!

## Чуардан да чуар замана

*Җир шары да нәкъ безнеңчә итеп*
*Уралгандыр төрле моңнарга.*
*Кайсы полюсларда нинди халәт —*
*Җирнең пульсын вакыт тыңларга.*

Тормыш гүя — төсле калейдоскоп:
Төсләрнең бар алы, карасы.
Безгә шушы чуар дөньялыкның
Уртасыннан атлап барасы.

Ил чигендә — бетон баганалар,
Буй-буй сызык... Аклы-каралы...
Кемгә — ак төс, кемгә — кара сызык:
Ачыклыйсы хәлләр бар әле.

Ипекәйдән кала, әй, Тынычлык,
Һава сыман кирәк син безгә!
Кайчан, кайчан барып ирешербез
Дуслык дигән олуг диңгезгә?

«Туганнарча гына яшәгез...» дип
Моң агыла күкләр багыннан.
Сугыш дигән афәт кешелеккә,
Ни әйтсәң дә, көчләп тагылган.

Килде исә атом һәлакәте —
Кара җилләр бары исәчәк;
Кара шәлен ябып, космик бушлык
Җиргә кайтарылып төшәчәк...

Безгә, безгә — вулканнарны түгел,
Сугышларны кирәк йөгәнләү.
Ана кеше фәкать балкып торсын
Сабыйларын сыйпап сөйгәндә.

...Чуардан да чуар бу заманда
Яшьләр өчен — кыйбла, юл башка:
Утлар-сулар кичкән комсомолга
Наркоманнар килде алмашка!

Фәхешлек һәм ришвәт чәчәк ата,
Җимешләре аның — фарисей[1].
Саф алтынга баткан бай түрәләр,
Сазаганнар нәрсә карый соң?

Күптән вакыт — коррупционерны
«Таш капчыклар»ына ябарга;
Яманаты чыккан ришвәтләрнең
Тамырына балта чабарга!

«Милиция» дигән бишмәтләрне
Алыштырдык «полиция»гә.
Алар ләкин һаман, һаман да бит
Гади кеше —
«Гражданин»га килеп сөялә.

[1] Фарисей — икейөзлелек, монафикъ

Үзгәрешләр — бар да, юк та кебек,
Мин тарихка карыйм борылып:
Чиратларның беткәне юк илдә,
Илдә әле — һаман сорылык...

Ин яманы: син яшәгән Илдә
Җимерелсә ирек һәм намус, —
Шушы вазгыятьләр эргәсендә
Мәңгегә кол булып калырбыз.

Бардыр бит ул галәм киңлегендә
Җирнең энергетик хәтере.
Кешелекнең миен тузан басса —
Менә шулдыр иң-иң хәтәре...

## Уян, хәтер!

*Империя упкан халыкларның*
*Күз яшьләре — милли хәзинә.*

Ялгамакчы булып Хәтер җебен,
Уятмакчы булып татарны,
Казансуда ятим җилләр йөри —
Их, саклыйсы иде Ватанны!

Хәтер көне... диеп җыйналабыз,
Җыенабыз нигә аз санлы?
Кирәк иде юкса яд итәргә
Кол Шәрифне, иске Казанны.

Нигә килсен — чыпчык борны хәтле
Патриотик хисен күр әнә:
Мәскәүләрнең йонын кабартмаска
Әй, тырыша безнең түрәләр!

Ләббәйкәгә биеп торуларны
Туктатырга вакыт, фаразан.
Колак салчы, кардәш: сагыш белән
Тукылган бит безнең һәр азан...

Казан уртасында — соры һәйкәл:
Илбасарга урын табылган.
Безнең хәтер, әнә, әле дә булса
Үткер кылыч белән чабылган.

Казан-йортны саклаучыларга без
Лаек һәйкәл куя белмибез.
Солтан түгел, олтан өммәтенә
Төшеп баттык бугай инде без.

— Көрәшчеләр кирәк! — диде шагыйрь.
Марат Мөлековлар, кайда сез?..
Әгәр милләт мәрткә киткән икән,
Чыбыркылап куу файдасыз.

Уян, Хәтер — аягүрә килеш!
Уян, татар — гафләт йокыннан!
Онытмагыз, безнең азаныбыз
Ачы хәсрәт белән тукылган...

## Аңлау мөмкин...

*Умом Россию не понять...*
Ф.И.Тютчев

Коммунизмга дип барган шәпкә,
Өзелеп тә китсен әле лепкә!
Корыч фундамент дип лаф орулар
Уратылган булган черек җепкә!

Кара халык эшкә карышмады,
Үстерде ул бодай, арыш, тары.
Шигарәләр чөеп җилгә очты
Россиянең күпме алтыннары!

Тирән тамырларда сут калырмы,
Илнең амбарында кот калырмы?
Батып бара торган албастыны
Иганәләр генә коткарырмы?

Белем кыяларын кимерсәк тә,
«Тимер диварлар»ны җимерсәк тә,
Шовинизм дигән кара чуан
Гел кычытып тора бу терсәктә...

«Үткәннәр»не тоташ сагыну бар,
«Яңа чор» дип дөрләп кабыну бар.
Халыкларны кая таба илтер
Демократик битлек ябынулар?

Космосларга, әйе, менгән чакта,
Завод-фабрикаларны бүлгән чакта,
Ни дәүләт бу — эзсез, бихәбәрсез
Бер кешесе хәтта үлгән чакта?

Кече парламентлар хокук сорый,
Башларына суксаң — йокымсырый.
Берни аңламыйча яшәп ята
Йә Машенька шунда, йә Шәмсурый.

Киллерларга ирек биргән чакта,
«Держава!» дип күкрәк төйгән чакта,
Халыкларга татлы Азатлыкны
Тамчы-тамчы итеп бүлгән чакта,

Империяне...
Әйе, аңлау мөмкин
Фәкать кан һәм күз яшьләре аша...

## Канатлы җыр

Әфганстан, Чечня кырларыннан
Әрдәнәләп кайтты табутлар.
Кайтмый калган солдат улларына
Гудок бирде ятим заводлар.

Генсекларны, президентларны
Газаплыймы икән вөҗданы?
Ышанмыймын! Әлмисактан бирле
Тынычлыкның алар — дошманы...

Сугыш уты кабызучыларга
Дөнья нигә шулай тар икән?
Бу кавемнең шәһәр төзегәне,
Агач утыртканы бар микән...

Сабантуйда арттан килгән атка
Яулык элгән безнең әбиләр.
Артта калган илләр-халыкларның
Кол булуын тели хәрбиләр.

Америка — контрастлар иле,
Президентлар анда сулагай.
Нигә әле үзен бүтәннәрдән
Һәрчак өстен куя Сэм агай?

Доллар исе, өсе — ориентир,
Милли низаг — бары жим генә.
Бәбәкләрен кыйтгаларга төбәп,
Канлы сугышларга жилкенә...

Нигә әле тәкәббер Сэм агай
Борын чөеп кенә сөйләшә?
Гуманитар ярдәм урынына —
Бомбалар һәм үлем «өләшә»...

Демократик дөнья төзибез дип,
Америка, женең котырган!
Илләр инде тәмам гаҗиз булды
«Янки» дигән кара кутырдан.

Юлбасарлар алтынынны талый,
Илбасарлар талый Ватаның.
Кемнең әле, кемнең күргәне бар
Явызлыкның чәчәк атканын?

«Әйе!» дигән безнең сүзләребез
Чәчәк атсын, бирсен жимешен.
Хыялымда... сугыш кырларыннан
Солдат булып кайтып килешем.

Солдат нәрсә? Ул бит жиңүгә дә,
Үлемгә дә әзер һәрвакыт.
Күпме язмышларын сыный дөнья
Сугыш казанында кайнатып.

Хәрбиләр дә, яна «патша»лар да
Үзен-үзе тота бик текә, —
Шулкадәрле көчле микәнни соң
Хакимият дигән вертикаль?

Сугышларга киртә куяр өчен
Тик бер нәрсә кирәк — батырлык!
Даһи акыл әйткән: бу дөньяны
Коткарачак бары матурлык[2].

Күптән вакыт — корыч танкларны
Аударырга домна мичәнә...
Тимер-томыр авазлары түгел,
Канатлы жыр кирәк кешегә!

Туганлыкка — яшел урам,
Ә тынычлыкка — «ӘЙЕ!»
Сугышларга: «ЮК!» — диябез,
Бетсеннәр алар мәңге!

---

[2] Ф.М.Достоевский

Вахит
Имамов

# СӨЛӘЙМАН СОЛТАН

ТАРИХИ РОМАН

## 7

«Сәлим солтан вафат!» дигән көтелмәгән хәбәр харәм сараендагыларның һәммәсен учак өстенә эләккән күбәләк урынына яндырып-чәнчеп узды. Остабикәләр «солтанга агу биргәннәр», дип сөйли, ә хадимнәр «эчеп үлгән», дигән гайбәт ирештерде. Солтан туфан-гарасатлар кузгалса да сыну-күгәрүне белмәс мәрмәр таш йә Шам кылычы кебек сау-сәламәт иде бит, югыйсә. Ул әле генә Баһдад хәтле Баһдад дигән пайтәхетне буйсындырып кайтты, Каһирә дә аның алдында күптәннән тез чүкте. Дунай буендагы Янош белән Лайош атлы падишаһлар да байтак ясак түли, аның белән алман-рум каһанлыгының короле Карл Бишенче дә нык санлаша, дип сөйлиләр иде. Саный китсәң, ярты җиһанга хуҗа булып алган, ә үзе кырык яшьне генә узган иде ләбаса. Шундый хакимнәр дә үз сәгате житмичә вафат була икән. Ничек инде, нишләп, ни сәбәптән?

Шикләнергә бер генә кеше бар, ул — Сөләйман. Явыз Сәлимнең бердәнбер малае, солтан тәхетен күтәп торучы бердәнбер шаһзадә дә. Өстәвенә, ул тәхеткә ия булмаган көенчә дә «хан» исемен йөртә. Чөнки Сөләйман — Кырымнан килеп, Сәлим солтанга кияүгә чыккан Гайшә ханым улы. Ә Гайшәгә ата кеше булган Миңлегәрәй әле үзе исән чагында ук яраткан оныгына «хан» дәрәҗәсе дә бирергә өлгерде бит. Ягъни мәсәлән, Сөләйманга Истамбулдагы солтан тәхете эләкми-нитми калса, ул ике дә уйлап тормыйча, рәхәтләнеп, Кырым ханлыгына да ия була ала. Ләкин ул Кырымга атлыкмый, аннары Сөләйман турында «соңгы сигез елда Истамбулга сирәк кайткан», диләр. Явыз Сәлим улы Сөләйманны унсигез яше тулуга ук пайтәхеттән бик еракка сөргән. Үзенең вөҗданында бик зур гөнаһы бар, ул тәхеткә әтисе Баязит солтанның һәм җиде энекәшенең гомерләрен кыеп үрмәләгән чөнки. Хәер, аларның бабасы Морад хаким дә керсез-тапсыз түгел. Тәхет өчен көрәшкән елларда анысы үзенең унтугыз туганын үтертеп бетергән. Кайсының башын кылыч белән чабып өзгәннәр, кайсыларын ефәк җепләр белән буып үтергәннәр. Явыз Сәлим мондый галәмәтләрнең һәрберсен истә тоткан бугай. Шунадыр, ахрысы, Сөләйманын әүвәл Кырым ярында иң олы порт булып саналган Каффа каласында, аннары Измир күршесендәге Манисса җирлегендә бәйләрбәге итеп утырткан бит.

Француз Жан төрле биюләр һәм түшәк мөгаллиме булып саналса да, зур гыйлемле тагын.

— Тәхет тирәсендәге чуалыш-үтерешләр чүл бүреләренең өер эчендәге көрәшеннән һич тә аерылмый, — дип һич тә курыкмыйча, теттерепме-тетә. — Тегеләренә дә, боларына да ит тулы тагарактан иң майлы калҗаны эләктереп

---

*Дәвамы. Башы узган санда.*

калу мөһим. Ач калмас йә әрәм булмас өчен бер-берсенең бугазларын чәйнәп өзешәләр. Морад солтанның — унтугыз туганын, ә Сәлим солтанның Баязитны үтереп тәхеткә менүе — тарих өчен беренче генә гыйбрәтле хәл түгел. Моннан йөз илле еллар элек татарларның Алтын Урдасында ук кабатланган инде мондый канлы мисаллар. Әүвәл Бирдебәк атлы хан үзенең әтисен үтергән, аннары Бирдебәкнең гомерен бертуган энекәше Җанибәк кыеп салган. Шуннан ары егерме ел эчендә егерме бер татар ханы алышынган, әмма ил дигәнең саклый алмаганнар. Төрек солтаннарының менә бу көрәше дә ниләр белән бетәр микән әле?..

Сөләйман Истамбулга һаман кайтмый да кайтмый, шуңа шомландыра. Харәм сараенда хәтта сабак бирүләрне дә бөтенләй оныттылар. Жарияләр үзара зарланыша.

— Сөләйман шаһзадәгә егерме биш кенә тулып киткән диләр. Ул тәхеткә менсә, сарайдагы иске жарияләрне алыштырыр инде. Әтисе өчен тотылган иске жарияләр өр-яңа солтанга ни пычагыма кирәк? Безнең һәммәбезне дә шул көенчә тотса, аның әтисе белән бажай булып куюы да бар бит.

— Әй, әтисе белән малае бажай булган солтаннар да бик аз түгел инде. Әнә, Мәхмүт солтан Нурбикә атлы жария белән башта үзе йоклап йөргән диләр, ә аннары шуңа малае Морадны көчли-көчли өйләндергән, имеш. Хак булса, шул Нурбикә Морадны әле унбиш яшендә чакта ук түшәк серләренә өйрәткән дә диләр. Алай икән, Мәхмүт солтан белән Морад шаһзадә Нурбикә янына алмаш-тилмәш килгән булып чыга.

— Алар үткән-киткән, безгә ниләр язган?..

Беркөнне, кичке эңгер-меңгер тәмам төшеп беткәч, Хүррәм бүлмәсенең ишеген шакыдылар. Чит-ят белән жарияләр чыбылдык аша гына сөйләшергә тиеш, өстәвенә Хүррәм битенә дә яулык ябып барды. Чыбылдыкны күтәрсә, ишек артында баш хадим үзе тора, йөзе-кыяфәте бәс саргандай салкын.

— Үзеңне бик тә олы түрә эзләп килде, киен дә чык.

Күкрәк каплавычларын, күлмәкләрен янарта-янарта тиргә батып бетте, ә башында гел уй. Нинди түрә тагын? Аны кемнәр белә? Динен, илен, исемен алыштырган жария кемгә генә кирәк?

Бакчага чыгуга ук хадим ипкә салды.

— Беркая да читкә китеп йөрмисең, сине түрәң әнә теге буш сарайда көтә.

Хүррәм өр-яңадан тагын әсәренде. Бу сарайны күргәне бар аның, элеккерәк айларда анда янычарларның сыбайлары кунып чыга иде. Бер ай чамасы анда ут кабызган кеше юк, бүген ана кемнәр генә хуҗа булып алган?

Ишекне ачып керүгә, зал түрендә алтын жепле җиләнгә төренгән Ибраһимны күреп, Хүррәм бер ягына авып китә язды. Кичә әле шаһзадәнең генә шәхси гаскәрбашы булып йөргән Ибраһим паша иртәгә инде тәхеткә менеп алган яңа солтанның иң беренче ярдәмчесенә әвереләчәк, моңа шик юк. Тик иртәгә каһанатның икенче түрәсенә әйләнәчәк бу пашага гап-гади жария янында ни калган соң? Бизмәннәргә салсаң, паша белән жария хәтта бер басуда да йөрергә лаек булмаган, төрле баскычтагы ике әрвах лабаса!

— Сине һич танырлык түгел, шушы бер-ике ел эчендә кәнизәкләр ханиясенә әйләнгәнсең икән, — дип әллә нигә сүзне салпы якка салам кыстырыбрак башлады ул. — Мин шаккатам. Син һич кенә дә элеккеге, Подолиядән сөйрәп китерелгән хохол кызы түгел. Син хәзер — алтыннарга алыштырмас байлык, син — асылташ!..

«Кая сукалый бу? — дип аптырады кичә генә беркемгә дә кирәкмәгән, мескен жария кыз. — Өйләнгән кеше түгел, мина кармак салып каравымы әллә?»

— Син ничек мине исеңә төшерәсе иттең әле? — дип телгә килгән булды үзе, күңелендәге уен сиздермичә генә. — Суга төшкән балта шикелле юкка чыккан идең.

Ибраһим, җил уйнаткан күмер кузы сыман кабына-кабына, тагын тезде.

— Ир белән ат башын ничек кенә сынамый бу язмыш дигәннәре! Сөләйман солтан белән бергә кай якларда гына михнәт чикмәдек без?!.

— Сөләйман — солтан? — дип урыныннан сикереп кабатлады Хүррәм. — Сөләйман шаһзадә инде солтан да булып алдымыни?

Ибраһим баш чайкады.

— Бүгенгә юк, ә бер атнадан Сөләйманны солтан тәхетенә мендереп утыртабыз. Чит мәмләкәтләрдәге падишаһ-корольләргә чакыру озаттылар. Төрек солтанына буйсынган пашалыклар һәм вилаятьләр дә үз вәкилләрен сайлап җибәрәчәк. Бүләкләр мул агар. Надир шаһның хәтта алтын бишек коеп юллавын да беләм. Иллә мәгәр аларның берсе дә мин әзерләгән бүләктән кадерлерәк һәм кыйммәтрәк була алмас төсле.

— Шаһларныкыннан да кыйммәтлерәк бүләк буламыни?

— Була, Хүррәм. Сөләйман солтан сөенәчәк бүләк — ул син генә!

— Йә, күпертмә инде, — дип Ибраһимның кылын тарткалавын дәвам итте Хүррәм. — Солтаннарның хатыннары гына да никадәрле.

— Сөләйманныкы өчәү, ләкин берсе дә аның өчен кадерле була алганы юк. Өчесе тиң — газап.

— Арттырасың бугай.

— Юк, арттырмыйм. Сөләйман алар белән бер түшәккә аяк та атлый алмый.

— Йә, алайса, иркенләбрәк сөйлә. Сөләйман солтанның хатыннары кемнәр?

Ибраһим җайлап утырды, йөзе уйчанланды.

— Сөләйман беренче һәм икенче хатыннарыннан бөтенләй уңмады. Икесе тиң, аны сөендереп, малай тапкан иде, икесенең дә балалары ярты ел дигәндә үлеп китте. Сөләйман башкача алар ягына әйләнеп тә карамады, чиркәсләрнең кенәзеннән Маһидәүрән дигән кызын алып кайтты. Никах укытканнан соң аны Гөлбаһар дип яңача атадылар, язгы лалә, имеш. Ходайның рәхмәте, Гөлбаһары да Сөләйманга малай алып кайтты. Син аны беләсең, багучысы булдың. Сөенечтән, Сөләйман Мостафа атлы ул малаен үзенең алмашчысы, дип игълан иткән иде. Ашыгырга ярамаган, Ходай мона нык рәнҗегән бугай. Мостафасы исән-сау үзе, әмма Гөлбаһары шуннан ары нинди генә бәбәй ташымасын, Ходай Тәгалә һәрберсен атна-ун көн эчендә үз янына ала да куя. Сөләйман шуңа хәзер өченче хатыныннан да йөз чөерде инде.

— Сөләйман солтанны берәр кешенең каргышы-фәлән эзәрлекләп йөдәтмидер инде? — дип сүз кыстырды Хүррәм.

— Бәлки, каргышы да бардыр. Әмма барыбер дә Сөләйман солтанга да бәхет тою кирәк.

Берникадәр дәшми утырдылар. Ибраһим ул тынлыкны янә үзе бүлде.

— Син Сөләйман солтан өчен иң зур бүләк һәм иң зур куаныч була аласың бит. Аңа җан җылытучы кирәк, сердәш, терәк кирәк. Ул сиңа игътибар итсен һәм сине генә сайлап алсын өчен, әйдә, болай итик...

## 8

Сөләйман солтанны Истанбул урамнарында әле берәүнең дә ныклап күргәне юк, ә хәбәрләр тау чишмәседәй кайный-кайный агып кына тора.

— Яңа солтан зинданнардан меңгә якын гарәпне азат иткән. Аларны Мисырдан Явыз Сәлим төяп кайткан иде бит. Сөләйманы ислам динен яклаучы, мөселман дөньясын берләштерүче булып күренергә җыенадыр инде.

Имәндә икән чикләвек, дигән төсле, миһербанлы битлек киеп алуының сәбәпләре бик тиз ачыкланды. Истанбулда солтан юклыгын ишетеп алуга ук Каһирәдә элек илне биетеп торган мәмлүк әмирләре фетнә кузгатканнар. Сәлим солтан калдырып киткән төрек пашасын дарга асканнар, нәүкәрләрен кылыч белән турап чыкканнар,

ди. Гарәпләр мәмлүкләр арасыннан кабат үз солтаннарын сайлап куярга, Мисырны төрек солтанының үги малае булып йөрүдән коткарырга маташалар, имеш.

Сөләйман солтан Мисыр тарафына шундук сиксән-туксан карабтан торган олы флот куды. Һәр карабта дүрт йөз-биш йөз чамасы нәүкәр[1] бардыр. Аерым кәрвандагы чуен һәм бакыр туплары, яу атларын-арбаларын санап бетергесез. Сөләйман яу башлыгы итеп Ибраһимны билгеләгән булган. Ә ул эшне коры тоткан, ахры, әйләнеп кайтканчы ук хәбәр юллаган, ди.

— Безгә дарыларга очкын элдерергә туры килмәде. Мин гаскәрне яр өстенә бушата башлауга ук Каһирәнең үзендә фетнә купкан. Кара гавәм әмирләрне дарга тотып аскан. Кала синең илчеләрне тезләнеп каршылады. Мин Каһирә вилаяте урынына төрек солтанлыгының аерым пашалыгын төзеп куйдым...

Сөләйман солтан харәм сараена шушы сөенечне алганнан соң килде. Тик йөзе барыбер кара көйгән, кәефе юк иде. «Мадьяр корольләре, аның солтан булуын котлап, ясак җибәрмәгән. Ул гына да түгел, солтан юллаган чапкынны дарга асканнар, ди, шуңа нык ярсулы», дигән хәбәр тараттылар, аңа карап кына бер жариянең дә йөзе яктырмады. Яна хуҗа үзенең әтисеннән калган биләмәләрне йә абзардагы малларын барларга дип юлга чыккан икән, ул булган нигъмәтләрне җиз иләккә мендереп җилгәрмичә һәм аксак-туксак җан иясен сугым базарына озатмыйча калмый. Сөләйман солтан да үзенең барлау сәфәрен бик тә коры тотты, иң беренче чиратта, ислам диненә күчмәгән христиан кызларын сараеннан куды. Соломия белән Хүррәм ике әшнә иде, елап хушлаштылар.

Сөләйман солтанга, әлбәттә, һәммәсе дә куркынып һәм сынап текәлделәр. Һич бәхәссез, аның турында килбәтсез йә мәхәббәтсез, дип әйтерлек бер нигез юк. Буйга әзмәвердәй озын, инбашлары, беләкләре таза. Гайрәт-кодрәт, дәрт-дәрман дигәннәре кайнап, ташып тора. Үзе барча төрек ирләре шикелле үк каратут тәнле, җил-кояшта янган. Әмма борыны карчыга томшыгы шикелле дугаланып тора, ятаган йөздәй нечкә. Сакал-мыеклары сагыз төсле кара, мүк шикелле куе. Ә күзләре, йә Ходаем, аның очкын сипкән карашларын күтәрермен, димә. Елмаюны онытып бетергәндер, сине ялкын белән чорнарга җыенган шикелле, гел бораулый сыман. Бу асылзат куркуны һәм чигенүне белмәс, үҗәт җандыр инде.

Сөләйман Хүррәм тарафына күз дә ташламады, хәтта яныннан да карачкы йә шәүлә турыннан узгандай сүзсез үтеп китте. Хүррәм гарьләнүдән ирен очларын тешләде, күңеленнән Ибраһимны сүкте. «Сөләйман солтанга бүләк итеп бирәм, син — асылташ һәм фәрештә, имеш. Беркатлы сабый бала урынына алдады бу мине. Йөзенә дә төкерә алмыйм бит, ичмаса. Шуның кулында һаман курчак төсле уенчык кына булып калырмын микәнни соң?»

Бер атнадан янә «солтан килә», дигән хәбәр кайнап узды. Бу юлы инде жарияләрнең берсе дә чәчен көдрәләтергә онытмаган иде, иннек-кершәнне дә кызганып тормадылар. Жарияләргә йөз каплау тыелган, шуны үзләренчә бозып, кайбер азгыннары муеннарын, күкрәк өсләрен дә томалап маташмады. Тик бер Хүррәм генә зал түренә иң таушалган күлмәгенә төренеп чыгып басты. Дөрес, йөзе ачык һәм мөлаем иде.

Менә, ниһаять, солтан. Шул ук тәкәббер йөз, элеккедәй очкын сипкән караш. Дивар буена тезелешеп баскан жарияләргә караш ташлый-ташлый, иренеп кенә атлый. Теге юлы өстендә имән яфраклары сыман сурәт төшерелгән алтынсу җилән иде, бүген тезләрен дә каплап бетермәгән кыска гына камзул. Сөләйманны ияр өстендә йөрергә бик ярата, диләр. Бәлки, шәһәр буенча сәяхәттән кайтып килешедер.

Сөләйман, әкренәеп, кайбер жарияләр каршында тукталгандай итә. Ул караш ташлауга ук жарияләр сафыннан пышылдап кына дәшкән тавыш ишетелә.

— Мин Фирдәүсә булам, Тәбриз каласыннан.

[1] Нәүкәр — сугышчы, яугир.

— Мин Олеся атлы, Новгородтан.

Менә, солтан Хүррәм турысына да якынаеп килә. Ул Хүррәмгә текәлгән дә сыман, күрмәгән дә төсле. Янә бер-ике адымнан соң узып китәчәк бит. Әле янадан аны күрәчәкме Хүррәм, әллә бөтенләй юкмы? Язмыш уены бишалтышар тапкыр сынамый бит, ашыгырга кирәк.

Хүррәм башын түбән иеп, сафтан бер адым чамасы алга чыгып басты. Мондый әрсезлек күрелмәгән бер хәл, һәммәсе дә мәет озаткандай тынып калган иде. Шул тынлыкта ялгыз жариянең үлчәп кенә тезгән сүзләре ишетелде.

— Мине бер теләк эзәрлекли, бөек солтаныбыз, шуны синең хозурына житкерергә батырчылык итәм. Мин — ислам динен бар күңелем белән кабул иткән, тугры бер бәндәмен. Хисләремнең ихласлыгын исбат итү өчен, Хак Тәгаләгә багышлап, аерым мәчет калкытасым килә. Ләкин Коръән-Шәриф кануннары буенча, Аллаһ йортын ирекле һәм азат кешеләр генә төзи ала. Мин кол көе, жария көе мәчет төзүгә алынсам, Ходай Тәгалә бүләгемне кабул итмәячәк. Шуңа күрә изге ниятем һәм Ходай Тәгаләгә бүләгем хакына мине жариялегемнән азат итсәң иде.

Кемнәрдер аһ итте, күпчелек тын калды. Жария кызый сират күперенә кереп баскан, хәзер һәркем солтан хөкемен генә көтеп тора иде. Сөләйман да моны төптән чамалады, сакал-мыегын сыпыргалап, бераз гына уйга батып торды. Шуннан ары тезгән жавабы һичбер жанда икеләнү шиге калдырмады.

— Бик тә изге ният, хуп, машалла. Аллаһ өчен синдәй ихлас диндарлар бик тә кыйммәт. Мөхәммәд галәйһиссәламнең нәзер итеп әйткән мондый сүзе бардыр. «Колын ирекка жибәргән һәр мөселман жәһәннәм газапларыннан азат ителәчәк». Шуны истә тотып, мин сине шушы мизгелдә үк харәм сараеннан азат итәм, моннан ары син Ходай Тәгаләнең генә колы булачаксың. Казначылар сиңа азат инсанга тиешле зиннәтләрне, асылташ вә парча-ефәк бирер, изге ниятләрең өчен мин дә өстәми калмам. Мәчетеңнең изге аен тизрәк күрергә насыйп булса иде, иншә Аллаһ вә амин!..

Хүррәм әүвәл үзенең колакларына ышана алмый торды, аннары Баязит бакчасыннан чыгарып жибәрәчәкләрен, урам уртасында япа-ялгыз калачагын уйлап зур хафага төште. Әмма адәм баласының бәхете бер ачылса, кулга алган туфрагы да алтынга әверелә дигәннәре хак икән бит. Хүррәм үзенең жария киемнәрен төенчеккә төреп тә өлгермәде, аның бүлмәсенә хәзер инде чыбылдык дигәннәрен санга да сугып тормыйча, баш хадим үзе килеп керде. Әйтер сүзе ихлас түгел бугай, карашын гел яшерә.

— Сине Баязит бакчасыннан читкә чыгармыйбыз. Сәлим солтан хатыннарының берсен Бурса атлы калага жибәрделәр. Шуннан бушаган бүлмәгә күченерсең...

Истамбул өстенә куе караңгылык төшкәч, инде яңа бүлмә ишеген килеп шакыдылар. Ачса, ишек артында шул ук хадим. Бу юлы күңел күтәренкелеге йөзенә бәреп чыккан.

— Киен дә чык, тышта сине ябык көймәле арба көтә. Кунак итеп нинди асылзат көткәнен алдан әйтә алмыйм. Һич курыкма, мәңге үкенмәссең.

Бик озак сәяхәттән соң гына гажәеп зур таш капка аркылы үтеп, агачлар күләгәсе астына туктадылар. Монда Хүррәмне нindidер яңа ир шәүләсе каршылады, кулларыннан тотып, мәрмәр баскычлар буенча таш сарай эченә алып керде. Сарайның кунаклар кабул итү залы даладай киң, колонналар өстендә йөзләгән шәм яна, олы урам булып сузылган озын коридорда ишекләр санап бетергесез.

Хүррәмне, һаман да шул сүзсез шәүлә көенчә, бүлмәләрнең берсенә үткәрделәр. Тупса аша атлап керүгә үк туктап калды. Олы гына залның уртасында иркен, йомшак ятак. Өстенә бәрхет белән парчаларга төренгән ястык түшәгәннәр. Ятакның дүрт почмагына әзмәвердәй дәү гәүдәле дүрт зәнҗи ир баскан. Кулларында тавис каурыйларыннан ясалган жилпәзәләр, як-якларда

болан мөгезе кебек тармакланган шәмнәр. Зәнҗи ирләре балавыздан ясап куйган кебек, шылт иткән һичбер авазлары чыкмый.

Хүррәмнен яктылыкка күзләре тәмам ияләнгәнче, дүртесе дә чыгып югалдылар. Хүррәм ни кылырга белми басып калды, тик бераздан гына ишек шыгырдаган тавыш ишетелде. Шәүлә сыман кереп баскан зат иясе, әлбәттә инде, Сөләйман солтан шәхсән үзе иде.

## 9

Ил буенча «яу сәфәре», дигән хәбәр тараттылар, егерме вилаятьнен һәрберсенә аерым чапкын очты. Сөләйман солтан яу сөңгесен кай тарафка корган, кайдагы халыкны канга батырмакчы — ул турыда ләм-мим. Әмер тик бертөрле:

— Хәрби алайлар язнын уртасына Истамбул янәшәсендәге кин далага тупланырга тиеш!

Төртмә телле ташбашлар күп уйланып тормый, төрле-төрле усал сүзләр ата.

— Оясында ни күрсә, очканында шул булыр. Мәхмүт Фатыйхтан соң бабасы Баязит Икенче дә яудан кайтып керүне белмәде, атасы Явыз Сәлим дә бертуктамый орышларда йөрде. Монысына да байлык кирәккәндер. Солтан тәгаме нәфес дигән тыюны беләме соң?!

Яшь көчекләр капка астында шыңшый, ә бүре өере һаман йөри бирә. Апрель ахырында пайтәхет янындагы яшел ялан җайдак белән тулды. Алмаш атлар, арба-чатыр, ияр-тезген, сөңге-кылыч, җәя-аркан, дары-туп шикелле кирәк-яракның һәммәсен дә барлап чыкканнан соң солтан тарафына чапкын күпты.

— Йөз мең җайдак зур сәфәргә әзер!

Солтанны шакмак-шакмак булып тезелешкән сафлар барабаннар һәм сорнайлар шавы белән каршылады. Шул чагында гына солтан үзе сәфәрнең максатын биек үр өстеннән ярып салды.

— Буда каласына бикләнгән бавар бәге Лайош-Людвик тарафына илче юлладык без. Мәмләкәтебездә яңа солтан пәйда булгач, бәйләнешләребезне янартмакчы, дустанә яшәргә сүз куймакчы идек. Бавар бәге безнең илчебезне дарга тотып асты. Далаларның борын-борынгыдан Коръән-Шәриф сүрәләре кебек үк газиз саналырдай изге йоласы бар. Илчегә үлем юк, илчеләргә кусәк күтәрмиләр. Шушы дала канунын бозган дошманнарны безнең бабабыз Чыңгыз хан да гафу итмәгән. Илчеләргә кул күтәргән мәкерле еланнардан Бату бабабыз да һәрчак үч кайтарган. Без куркак җан түгел, без галеллек яклы. Шуна күрә үзебезнең илчеләрне һәм барча мәмләкәтебезнең данын яклау өчен яуга юнәләбез. Кабих илә соран җаннарга — үлем, безгә галәбә-җиңүләр генә насыйп булсын!..

Икенче таңда ук юлга кузгалдылар. Өлкән яшьтәге, тәҗрибә туплаган сәрдәр-пашалар байтак кына да бит, тик Сөләйманның беренче мәртәбә шундый олы гаскәр җитәкләве, ул анын дилбегәсен һәм кымырҗый-кымырҗый көтелгән шөһрәт-данны кара гавам кулына бирәме соң!

Буар еланнар чылбырыдай сузылган алайлар көнбатышка төбәп купкан иде. Берәр атнадан соң ялга тукталуга, тәүге сәрдәрләр дә пәйда булды.

— Беренче дүрт төмән карабларга күчә, алар мангаенда үзем барам. Калган алты төмән икегә бүленә, берсен — Ибраһим паша кулына, икенчесен өлкән агам Яхья эргәсенә бирәм. Ибраһим паша төмәннәрне яр буенча Дунай тамагына чаклы алып барачак, Яхья агайга Дубрава аша үтәсе таулы юллар кала. Барча көчләр июнь уртасында Дунай тамагындагы Камка каласы янында очрашачак. Аннары Белград, безнең мәсләк шулдыр...

Юлда төмәннәрне бертуктаусыз койган яңгырлар тоткарлады, аеруча Кара дингез яры буенча сузылган олаулар газап чикте. Буар еланга тоткарлыксыз гына шуышулар читен. Елга-инешләрне кичкән чакта әле яр өстенә килеп тыгыла ул,

әле меңбашларның чыбыркылап-камчылап кууларына буйсынып, тегәрҗептәй сузылып кына бара. Чиләкләп койган яңгыр давылыннан аткайларның муеннары һәм сыртлары гел чиләнеп чыкты, ташлы тау сыртларын үткән чакта меңәрләгән арбаларны ватып бетерделәр. Ачлык-сусаулардан атлар гына түгел, җайдаклар да өрәкләргә охшап, кибеп калды.

Дунай тамагына июнь азагында, көч-хәл белән килеп туплandылар. Сөләйман солтан үзенең мин-минлеген кайгыртып котырына.

— Чех-мадьярлар бәге Янош мине менә шушы төшкә килеп, олы гаскәр белән каршыларга тиеш иде, ә ул һаман ярты юлда гына. Гаскәр урынына да алты меңләп җәяүлене генә туплаган, ди. Бүләкләр юк. Мин аны Лайош атлы икейөзле көндәшеннән коткарыйм, тәхеткә юл арчыйм, дип ун төмән нәүкәр кузгаттым, мең чакрымлык араларны үттем, ә аның алты мең чебеше ни пычагыма кирәк?

Яубашларның, әлбәттә, үз кайгысы, алар күбесенчә мохтаҗлыктан дулый.

— Авыр тупларны, солтан фәрманы буенча, Дубрава каласы янында ташлап калдырдык. Дары мичкәләренең һәммәсе дә лычма-юеш, хәтта җиңел тупларны да кулланырлык түгел. Кирмән диварларын ташка башны орып кына җимереп ташлап булмый. Алда Белградны нинди туплар белән утка тотарбыз соң?..

Кая монда жиде тау сырты артында ятучы Белград турында баш ватулар? Дунай яры буйлап күтәрелә башлагач та, Шабас кирмәне янында ике-өч атна буе тоткарланырга туры килде. Будапешт каласында утырган Лайош-хаким бу кирмәнгә иллегә якын бакыр туп һәм өч меңләгән алпар[2] җибәргән, Шабас диварлары Сөләйман җайдакларын тоташ ут көлтәсе белән каршылады.

Сөләйман җайдакларны, диңгез дулкыннары кебек, катлы-катлы һөҗүмнәргә дә ыргытып карады, әйләнә буенча бертуктаусыз чаптырып, диварлар өстенә ук яңгыры да койды, ләкин юк кына бит, туп утлары төрекләрне манара һәм капкаларга якын җибәрмәде. Ә күктән, шайтан котырган шикелле, һаман яңгыр ява, томан болытыннан котылмалы түгел. Ләкин, Ходайның рәхмәте, «күршегә дә ява, шөкер», дигән төсле, яңгыр давылы Шабас кирмәне өстендә дә яман уйный бит ул. Кирмән сакчылары кулындагы дары белән филтәләр дә юешләнде бугай, берзаманны дивар тәрәзәләреннән төбәлгән туплар ата алмас булды. Тубык-тез тинентен пычрак ера-ера, тимер капкаларга ябырылдылар, күз ачып йомган арада төрек нәүкәрләре манаралар өстенә үрмәләде. Ә дивардагы мәйданчыкларга сикереп күчендеме, аеруча кансыз янычарларны тотып тыям, димә. Йөзәрләгән алпар кылычлардан ауды, тагын йөзәрләрен дивар өстеннән жиргә очырдылар. Үзәк манара түбәсендә ике койрыклы әләм җилферди башлады, Шабас кирмәне Сөләйман солтанның тез астына ауды. Биш мең чамасы бияне корбан итеп чалдылар, тәүге җиңү шатлыгы касәләрдән күбек булып акты...

Белградны август ахырында гына барып камадылар. Дары капчыклары кипкән иде инде, җиңел туплардан мең-мең ядрә очты. Алар кирмән диварларын әтәч булып чукый, әмма таш-кантарын һич кымшата алмый. Туплар тынган арада нәүкәр-янычарлар кирмән эченә башакларына очкынлы сүс уралган сәрпи ук очырды, аннан янә ядрә яңгырлары диварларны мунчадагы кайнар миллек кебек пешекләде. Унжиде көн буе шулай чәбәкләгәч, кирмән капкалары ачылды, ак җәймә күтәргән арадашчы ирләр пәйда булды.

— Никадәрле сугышчыгыз исән калды әле? — дип, борынын күккә чөеп сорау бирде Сөләйман шәхсән үзе.

— Дүрт йөз, әмма алар ахыргача кан коярга әзер.

— Кирәкмәс, тиктомалдан корбан булып, газап чикмәсеннәр. Без камалышта сезгә юл ачабыз, дүрт ягыгыз да кыйбла.

Капкалардан дүрт йөз яугир агылып чыккан иде, шул минутта алар өстенә

[2] Алпар — тоташ тимер көбәгә төренгән сугышчы, рыцарь.

янычарлар аранны җимереп качкан үгез шикелле котырып ябырылды. Дала уртасында берничә мизгел буена әҗәл биеде дә, гарасат югалган шикелле, бары да тынып калды...

Икенче таңда ук янә яңгыр давылы башланды, аның артыннан, чирле карчык сыман ухылдап, көзге салкыннарның килеп житүе бар. Лайош-Людвиг Буда каласында, тегермәндәге он чоланына кереп качкан күсе шикелле, тын алырга куркып, посып ята. Ходай Тәгалә мәрхәмәтеннән ирәеп китү гөнаһ, аның төрекләргә артык куюы бар. Җинәрдәй җинүләр яуланган, Сөләйман солтанның йөзе чиста. Хүррәм сылукай да күптән сагындыра, кайту юлын чамаларга кирәк.

## 10

Хүррәм элеккечә Баязит бакчасында, Явыз Сәлим хатыннары белән янәшәдә яшәп калган иде. Колак салып йөргәч, хәйран булды: Сөләйманның әнисе исән-сау һәм ул гөлләр кебек гел хөрмәттә яши, хәтта вәзирләр дә, мәмләкәт башындагы икенче кешегә куеп, ана «солтанбикә әфәнди», дип эндәшәләр икән.

Беркөнне Хүррәм, мәчет төзелешен карарга дип, Истамбул урамнарына чыккан иде. Бу юлы да ана баш хадим иярде. Хүррәм аның күләгәдәй тагылып йөрүенә күптән ияләште, ә исемен белеп алгач, «әфәндем, бәй» шикелле сүзләр дә онытылды. «Якуб, Якуб» — кыска гына, ансат. Мәчет диварларын капшап чыкканнан соң, базарны да бергә урадылар. Хүррәмнең җир җиләгенә күзе төшкән иде, Якуб каршы килеп, тыеп маташмады.

— Синең шундый көннәр инде хәзер, ни телисең, аша гына, ханым.

— Син дә үзеңә кирәк ниггьмәтләрне сайла, — дип Хүррәм Якубка ике-өч дукат та сузган иде, тиң алтын тәңкәләр аның бармаклары арасында шайтандай юк булды.

Аның каравы, Баязит бакчасына кайтып кергәч, Якуб башы белән генә түргә, куе сәрби агачлары ышыгына поскан затлы чатыр тарафына ымлады. Чатыр саф көмештән койган матур челтәр белән уратылган, түбәсе дә мәчет гөмбәзеннән бик калышмый. Чатыр эчендә япа-ялгыз хатын, ул дивар буендагы кечкенә генә фонтанга текәлгән дә тынган.

— Солтанбикә әфәнди, Гайшә ханум, — дип пышылдады Якуб.

«Ә-ә, әстәгъфирулла, Сөләйман солтанның анасы бу, димәк», — дип гаҗәпләнде Хүррәм, тик зиһене аша, ә авыз ачып Якубка сүз кушарга теле әйләнмәде. Баш хадим мондый халәтләрне аңлый иде бугай, баш какты да, өермә бөтереп алгандай, тын гына юкка чыкты.

Хүррәм әүвәл берникадәр вакыт читтән күзәтеп торды, аннары, тәвәккәлләп, солтанбикә тарафына атлады. Чатыр челтәрләре янына килеп баскач, ничек сүз башларга аптырап тора иде, яртылаш кына борылып, солтанбикә үзе тавыш бирде.

— Нигә туктап калдың? Әйдә, кер дә утыр.

— Ә сез мине ничек шәйләдегез? — дип сорады Хүррәм, сабыйларча аптыравын яшереп кала алмыйча.

Солтанбикә йөзе белән борылып, кет-кет кеткелдәде.

— Сарай тирәсендә калырга насыйп булса, син дә песи атлауларын ишетергә өйрәнерсең әле.

Хүррәм асылзат йөзенә текәлде. Бик мөлаем ханым, ачык йөзле, чибәр. Дугаланган нечкә кашлар астыннан төбәлгән коңгырт күзләрендә елмаю бар сыман. Борыны озын, текә. Иреннәре юка, янак сөякләре тәртеп тора. Аның йөзендә таныш чалымнар да бар шикелле, кайсы яктан икән?

— Сине Акмәчет базарына да чыгарып караганнар икән, — дип тынлыкны, әлбәттә инде, солтанбикә бүлде. — Нишләп бер татар да сиңа йөгән кидерә алмаган, шунысы гаҗәп. Гадәттә, безнең халык кулга кереп торган малны бер дә ычкындырмый торган иде.

Хүррәм гаҗәпләнүдән кулларын чәпелдәтте.

— Бәрәкалла, сез Кырымнанмыни?

— Кырымныкы мин, без якташлар. — Солтанбикә ияген өскә табарак күрәрде. — Мин Минлегәрәй ханның кызы булам. Ул Казаннан Нурсолтан атлы яңа хатын алып кайтты да, котылыр өчен, мине тизрәк монда олактырды. Нурсолтаны элек Казандагы Хәлил вә Ибраһим атлы абыйлы-энеле ханнарның хатыны булып торган. Соңгысын урыслар үтергәч, минем әткәй аны үзенә яучылаган. Менә шулай фәлән иргә ярый торган хатыннар да була.

Үз фикерен белдерергә кыймагач, Хүррәмнең дә мактанасы килеп китте.

— Ә мин Акмәчеттә чакта ханның Хаҗиәхмәт атлы вәзире белән танышырга өлгердем.

— Нindирәк кыяфәттә ул хәзер, нindирәк ир? — дип солтанбикәнең күкерттәй кабынып китүе сискәндерде.

Хүррәм коела-коела гына җавап тотты.

— Ир кебек ир инде. Озын гына буйлы, бик таләпчән, усал. Бераз гына корсагы бар, таза.

— И-и, әкәмәт! Ә яшь чагында бик тә ябык иде. Тал чыбыгы сыман. — Солтанбикә хәтер дингезенә чумды. — Буй җиткән вакытта ул гел минем тирәдә бөтерелә иде. Ике-өч мәртәбә мәктүбләр дә алышкан чак булды. Аның әтисе дә вәзир иде. Мине үзенең улына сорап карады, әткәй каршы торды. Хан кызлары падишаһ вә солтан шаһзадәләре өчен үсә, янәмәсе.

Бераз тынлыктан соң Гайшә-солтанбикә янә сүз башлады.

— Түгәрәкләнә дә башлагансың икән, бик хуп. Минем килennәрне әллә нишләп чәчәк түләмәсе әзәрлекли, тапкан бер балалары шуннан китә тора. Чиркәс Гөлбаһардан туган бер Мостафа гына исән-имин үсә, алты яше тулды, ярхәмкалла. Малай тапсаң, улым сөенәчәк. Ә килennәр үзенә талпан урынына ябышмыйча калмас, бигрәк тә Гөлбаһары. Итәгеңне җыеп йөрергә өйрән, сак була бел...

Хүррәм ике-өч көн буена шушы көтелмәгән танышудан, сөйләшүдән иләсләнеп йөргән иде, бер караңгы кичтә Якуб ишек какты.

— Сиңа хат бар, ханым. Базарга чыккан идем, шунда кемдер минем җилән кесәсенә салган. Базарда башта ук мине бик тә сәер киенгән сәүдәгәр күзәтеп йөрде. Шуның гына эшедер дип беләм.

«Алтын тәңкәләр эше бу, зиннәт эше», — дип фикер йөртте Хүррәм, ә хатның юлларына күз йөгертүгә үк, иске елан кабыгыдай куырылып, артка ава язды. Газиз анасының кулыдай таныш хәрефләр, назлы сүзләр:

«Аккошкаем минем, Роксоланам! Синең Николаң бу. Мин исән-сау, мин иректә. Синең эзләреңнән Истанбулга чаклы килеп җиттем. Инде таптым. Харәм йортына бикләнеп яшәвеңне беләм. Коткармыйча калмам. Мин — синеке, син минеке генә. Бүтән аерылмабыз».

Хүррәм үкси-үкси күз яшьләренә бирелде, ахыр чиктә аңын җуеп ауды.

**11**

Сөләйманның үзеннән дә иртәрәк Истанбулга яңа хәбәр кайтты:

— Солтан уң кулы саналган Ибраһим пашага үзенең сеңлесе Хәдичәне биргән. Янычарлар Синоп култыгына тукталып туй итә, ди. Җил уңайга иссә, Ибраһимга вәзир булулар да ерак йөрмәс...

Хүррәмнең үз кайгысы — кайгы. Сөләйман аның янына кайтып төшмәсә йә баш тартса? Хүррәм әле көмән генә йөртә, исән-сау көенә котылырмы? Кызый тапса, Сөләйманның исе китмәс инде. Малай туса, бераз өметлерәк. Солтаннар андый җарияне хатын итеп ала, күккә чөймәсә дә, читкә какмый, диләр. Әнә, Сөләйманның беренче, икенче хатыннары Сәйлән белән Гөлсем — элекке

жарияләр. Икесе дә малай табып биргән, шуның өчен харәм йортыннан чыгып котылганнар. Дөрес, икесенең дә малайлары үлгәч, Сөләйман алар янына керүдән гел туктаган инде. Кызый тапса, аның Хүррәмнән дә баш тартуы мөмкин. Ир-атка, хәтта ул солтан булса да, ышанырлык түгел. Сөләйманга һәр тарафтан көтү-көтү жария китерәләр. Ир-ат нәфесе бирән, яна калжа, яңа сылуларга үрелмичә калмый. Хүррәмне алыштырса, яшәү бетте. Син аннары — читкә типкән күмер, туздырылган учак...

Эчтәге ут ялкынсыз талагандыр, Хүррәм баласын вакытыннан иртә тапты. Сабый малай булып туды-туууын, әмма озын һәм искитмәле ябык, йончу иде. Ник туганына нык үкенгән сыман, ашамый да, еламый да үзе. Кендек әбиләре ике-өч атна дигәндә генә юньгә китерделәр. Жанга жылы биреп, имчәккә ябыша башлады, тибенде, елады да.

Сөләйман нәкъ шундый чагын көткән шикелле кайтып керде, авызы колакта тегенең, сөенечен һич яшерә алмый.

— Малай туды, малай! Бәлкем, шаһзадәдер.

Аннан бөтен әйләнәсендәге яраннарына төбәлеп әмер бирде.

— Хүррәмне минем хатыннар яши торган сарайга күчерегез! Ул жария түгел, минем улымның анасы, ана да шунда яшәү тиеш!..

Хүррәм солтанның элекке хатыннары яшәгән сарайга күчеп килгәч, билгеле инде, барыннан да элек Гөлбаһар күтәрелеп бәрелде.

— Мин чиркәс кенәзе Чилук бәк кызы буламын, ә жария түгел. Солтан минем Мостафамны инде әллә кайчан шаһзадә, дип игълан итте. Бер күк йөзендә ике кояш булмый, йолкыш жариядән туган чирле чәүкәне тагын бер шаһзадә итеп күтәрергә хәтта солтанның да хокукы юк!

Сөләйман солтан «карт» хатыннары янына гел керми башлагач, Хүррәм, тегеләрне үртәгән шикелле, сабые Мәхмүтне кулда уйнаткан булып, аны «койма ярыклары» өчен юри иң кадаулы сүзләр белән үсендергән булды.

— «Бәлкем, булачак шаһзадәдер», диде бит солтаныбыз синең хакта, балам. Иплe генә үсик, сина да, атаң шикелле, тәхет капусларын[3] күрергә насыйп булсын.

Боларны да ишетеп алгач, Гөлбаһар, чынлап та, чыгырыннан чыкты. Хүррәм сизмәгәндә генә арт яклап килде дә көндәшенең чәч толымнарыннан эләктереп алды. Тегене утын пүләне урынына уңга-сулга тотып болгады, Хүррәм тибенә-сугына башлагач, аның муены белән яңакларына тикле тырнап бетерде, өстендәге күлмәген умыргалап атты. Үзе үгез тавышлары белән үкерә дә әле.

— Мин ул чын шаһзадә анасы, мин ул, мин ул! Солтан үзенең иң олы малаен тәхетенә утыртып калдырырга тиеш. Мин солтанның баш хатыны булып исәпләнәм. Себерке жарияләр миңа һичбер сүзсез буйсынырга тиеш!

Гөлбаһарның әлеге женләнүен һәм сүзләрен Сөләйманның колагына житкергәннәр иде, солтан баш хатынны төпкә утыртырдай жавапны тиз тапты:

— Хүррәм — минем иң яраткан хатыным, ул беренче! Мин ана «нәзакәт хатын» һәм «хатын әфәнди» дигән дәрәжәләр дә бирәм!

## 12

Сөләйман солтан өчен Кырым ханлыгы — меңәр чакрымнарга жәелгән төрек солтанатының сыңар олысы, бер бәйлеге генә, аннан тоткарлыксыз рәвештә Истамбул казнасына алтын-көмеш инеше агылып тора. Сөләйман үзенең игезәкләрдәй якын һәм иң ышанычлы утары дип санаган атавында ниндидер хәвефле вә зәһәр учак кабынуны уена да кертеп карамады. Әмма бу вакытта Бакчасарайда инде муенчак-тышау белмәс арыслан үсеп житкән һәм читлек ишекләрен жимереп чыккан иде.

Әтисе Миңлегәрәйнең вафатын көтә-көтә сакал-мыегына чал йөгергән һәм

[3] Күк йөзе, гөмбәз.

илле яшен тутырганнан соң гына, ниһаять, тәхеткә менеп алган Мөхәммәтгәрәй хан, балигъ булырга га өлгермәгән кыз кыенчә кияү төшәгенә ингән килен сыман, тәүге айларда шылт иткән тавыш та чыгармыйча, ипле-басынкы гына яши белде. Беренче елда Явыз Сәлим солтан тарафыннан катгый фәрман килгәч, дин вә кан дошманы булган урыс кенәзләре белән «кочаклашып», ләһләргә каршы яу сәфәренә дә барып кайтты, хәтта. Аннан соң бер-ике ел вакыт Истамбулдагы үзгәрешләр кайтавазын көтеп үткән иде, ул көннәрдән бер көнне Мәскәү белән ике арадагы юлны такырлатып бетергән илчесе Аппак морзаны янына дәшеп алды.

— Без җыйган байлыкның яртысын диярлек солтанга озатабыз, үз казнабыз, ел да, ел да язгы су ташкыны килеп юган төсле, һич кенә дә калынаю-симерүне белми, — дип башлады ул, хәтта фәрештәләр колагы өчен дә хыйлаф тоелырдай сәер сүзләр белән.

Аппак морза — урыс кенәзләре генә түгел, төрек яки татар вәзирләре каршында да авызын үлчәп ачуны гадәт иткән түрә, эт каешыдай шомарып беткән илче, бу юлы да һичбер төрле тойгы күрсәтмәде. Ә Мөхәммәтгәрәй моны хуплау сыман кабул итте бугай, бөеренә таянып тезә бирде.

— Бату хан заманыннан бирле безгә урысы белән казагы да, чиркәс белән аланы[4] да ясак ташып торган, монысы һәр татарга бишектән үк мәгълүм. Сарайдагы Әхмәт ханны чәнчелдерим, диеп, минем атай Мәскәүдәге Иван кенәз белән солых төзеп куйды да, аны Сарайга гына түгел, Бакчасарайга да ясак түләүдән азат итеп хаталанды, мәрхүм.

Аппак морза сагая башларга мәҗбүр булды. Кара гавам арасында әтиләре белән бабаларын такыр кесәлек, тар маңгайлык өчен чүбек чәйнәп искә төшерүче гыйбад табыла ул, әмма үзенә тәхет вә мәмләкәт калдырып киткән хан чаклы хан бакчасына таш ыргытучы таждарлар да була микәнни соң?

— Әйе, әйе, кабат-кабат, торып-торып бизмәннәргә салам. Ярар, Сарайдагы ул Әхмәткә бил бөгеп вә ясак ташып яшәүләрдән котылырга кирәк иде инде, монысы чишмә төбе кебек ачык, үтә күренмәле. Егерме ел чамасы элегрәк Әхмәт ханга каршы яу белән барган вакытта аркасына пычак кадауны көтеп йөрмәс өчен Иван кенәз белән солых төзеп кую да атай өчен отышлы вә кулай бер гамәлдер. Монысы да бик хуп. Иллә мәгәр минем атай Сарай тәхетенә дә хуҗа була алмады, урысны да бәйдән ычкындырды, менә монысы олы хата, гаҗәеп зур хыйлафлык.

Мөхәммәтгәрәй тәхетеннән төшеп Аппак морзаның каршына килеп басты. Ул өреп чыгарган кайнар һава морзаны да көйдереп алды сыман.

— Атай вафат булды, ике кулым да азат. Мәскәүдә дә хәзер яңа кенәз. Мин ул Василий белән ике арада һичнинди дә солых төземәдем. Атай төзегән солых аның вафаты көнне үк юкка чыкты. Мәскәүнең уҗымга чыгарылган үгез сыман гайрәтләнеп йә симереп китүе бар, вакытында башына сугып миңгерәтү вә тез чүктерү хаер. Әнә, Василий кенәз Касыйм каласына Әүлиярдән соң аның унөч яшьлек улы Шаһгалине хан итеп утырткан бит, йөзе кара тәре! Касыйм каласының Василий өчен үз кесәсендәге уенчык икәнен дә, андагы ханның һичбер хокуксыз курчак кына икәнен дә беләм. Әмма аларның икесе дә Гәрәйләрнең кан дошманы булган Әхмәт хан нәселеннән, ә Шаһгали атлы тышаудагы бозау — Әхмәт ханның энекәше булган Бәхтияр оныгы бит. Әгәр Василий атасы Иван шикелле Кырым белән тату яшәүне отышлырак һәм хәвефсез дип санаса, ул безнең рөхсәттән башка Касыймдагы тәхет хуҗаларын тәртә арасындагы ат урынына алыштырмас иде. Гәрәйләргә дошман булган Әхмәт нәселен өстен күрә икән, димәк, Кырым тәхетен таяк ыргытып куылган эт шикелле түбәнсетә бит бу!

Мөхәммәтгәрәй эссе мунча ләүкәсенә менеп алган сыман кызарынды, маңгае белән муенында кан тамырларына чаклы бүртеп чыкты.

[4] Алан — чукынгач, осетиннарга әверелгән милләт.

— Син Мәскәүгә юнәл. Алдан ук чамалыйм, Василий кенәз минем тәкәббер һәм һавалы таләпләремне ишетүдән генә үзенен тәхетеннән һич егылып төшмәс. Ә син, барыбер дә, әүвәл минем атай белән анын атасы арасындагы дуслык солыхын озынайтуны тәкъдим иткән бул, аннары шундук шәхси хатымны һәм таләбемне дә житкер. Исән-имин һәм яу-җәберләрсез генә яшәүне муафыйграк күрсә, Касыймдагы манкасы да кипмәгән, унөч яшьлек Шаһгалине куып җибәрсен дә минем угылым Нурдәүләтне чакырып китерсен ул. Тәкәбберләнә һәм гозеребезне кире кага икән, димәк, ана каршы яу чабарга үзе үк нигез бирә.

«Һе, Касыймныкыннан бигрәк үз тәхетеннен иминлеге турында кайгырасын түгелме сон, хаким? — дип уйлап куйды Аппак. — Нурдәүләтне Касыймга аткарсан, үзенне суярдай бер хәвефтән тирә-юнен, тәхетен чистара бит.»

...Аппак морза Мәскәүдәге олуг кенәз сараена үтеп кергәнче үк, төрле имеш-мимеш хәбәрләргә югылып, баш түбәсенә кар ташкыны ишелеп төшкәндәй, пошаманга калды.

— Казандагы Мөхәммәдәмин гөбедәй шешенеп, хаста булып ауган. Анын урынына хан итеп утыртырдай алмаш эзлиләр, ди. Әминнен үзенен уллары да, Казанда Чынгыз нәселеннән булган һичбер гаһед[5] тә юк. Әминнен бертуган энекәше Габделлатыйф бар-барын да, илләмәгәр ул бер мәртәбә Казан тәхетендә утырды бит инде. Хан булыр алдыннан биргән антын бозган өчен Василий кенәз аны, Казандагы морзалар шикаятен тынлап, тәхетеннән йолкып алып кайтты. Безнен кенәзнен бер мәртәбә авызы яман пешкәч, анын Белозёрдагы зинданга илтеп бикләгән әрвахны өр-яңадан Казанга кайтаруы бик икеле. Олуг кенәз Касыймдагы Шаһгалине Казанга күчереп куярга ният корган, диләр, шул хорафат хакыйкать сүз булып чыкмагае...

Аппак морза олуг кенәз хозурына бер атна чамасы утлы табада биегәннән сон гына үтеп керә алды. Югыйсә, Истамбулдагы солтан янәшәсенә куярлык яисә Бакчасарайдагы хан белән чагыштырырлык та түгел инде үзе. Монын өстендә, тегеләрнеке шикелле, алтын белән укаланган җиләннәр дә, якут ташлар белән бизәлгән чалмалар да, энҗе-мәрҗән тезелеп киткән кынлы хәнҗәр аскан алтын аеллы каешлары да юк. Иннәрендә ит чабарга җыенган гыйбадныкы кебек гади кафтан, кендегенә төшкән җирән сакал, эренләнеп беткән күз төпләре, кавын сыман түм-түгәрәк итеп кыркылган чәч. Мәгәр, кара, үзен Ходай Тәгалә фатыйхасын алып кайткан пәйгамбәр шикелле ничек эре тота!

— Мөхәммәдәмин, асылда да, хаста, — дип илче-морза шиген шундук таратты ул. — Габделлатыйфны Мәскәүгә кайтарырга әмер биргән идем, анысы да хасталанган, дигән хәбәр кайтты. Ханлык тәхетенә мәшһүр Казан каласына лаек нинди генә варис табаргадыр, шунын өчен утлар йотып хафаланмыш инде сонгы көннәрдә.

Аппак морза, кайнар шулпа йотарга әзерләнгән кебек, бик сак кына итеп авыз ачты.

— Мөхәммәтгәрәй хан галиҗәнапләре Казанга үзенен бертуган энекәше Сәхибгәрәй шаһзадәне китереп утыртуны бик муафыйк саный. Хаста Мөхәммәдәмин хан да, алай-болай булса, үзе урынына Сәхибгәрәй шаһзадәне чакыруны васыять иткән икән.

— Әйе, әйе, Сәхибгәрәй шаһзадә Казан тәхетенә утырса, ошбу гамәл Кырым белән Мәскәү арасындагы дуслык-туганлыкны ныгытуга ярдәм итәр иде, — дип Василий кенәз капылт эләп алгач, Аппак морза хәтта утлы күмер йоткандай куырылып калды. Ләкин кенәзнен алдагы фикер сөреше морзанын күнелен кылчыклы билчән урынына тырнап-ертып узды.

— Тик ни бит, ни бит, илче Аппак морза. Казандагы морза-сәүдәгәрләр Кырым шаһзадәсен Казан тәхетенә мәгъкуль күрер микән? Мондый гамәл хәтта булачак әби-бабай күзенә дә барып күренмичә килен ятагына үткән

[5] Гаһед — тәхет варисы.

кияү шикеллерәк. Сәхибгәрәй шаһзадәне тәкъдим итүгә Казандагы аксөяк-байчуранын каршы чыгуы да бар, дип кисәтүем. Казаннар — бик тәкәббер.

— Кырым белән Казан — бер ананың ике угылыдыр, без үзебез ничек тә килешер һәм уртак телне таба алыр идек, — дип Аппак морзаның чигенмәвен күргәч, Василий кенәз тиз-тиз очлап куйды.

— Кырымыңа оч та Мөхәммәтгәрәй туганыма тапшыр. Әгәр ул Мәскәү белән ике арадагы дуслык-бердәмлекне мәрхүм аталарыбыз Минлегәрәй хан һәм бөек кенәзебез Иван Өченче заманнарындагы кебек саклый икән, без дә, үз тарафыбыздан, Сәхибгәрәй тәкъдимен якларга ризаларбыз...

«Сәхибгәрәй энекәшен Кырым тәхетеннән читкә аткарган өчен Мөхәммәтгәрәй галиҗәнапләре мин фәкыйрьне алтын көшеленә күмәр әле», — дигән хыяллар эчендә канатланып очкан Аппак морзаны, Мәскәүдән чыгып биш тәүлеклек юлны узуга ук, арттан яшен кебек үтәли көйдергән хәбәр куып житте.

— Казанның элеккеге ханы Габделлатыйфны Белозёр кирмәнендә буып үтергәннәр. Казан морзалары шуны сорый, дигән хәйлә белән Василий кенәз Мөхәммәтәмин урынына Шаһгалине озатып җибәргән, ди...

Бакчасарайга кайтып керүгә үк Мөхәммәтгәрәй хан, аяк табаннарына кайнар энә кертеп газаплагандай, чыгырыннан-чыгып котырынды.

— Аһ, икейөзле соран! Аһ, мәкерле көзән! Син кайтып җиткәнче Казандагы Сәйди, Садыйр, Түләк морзалардан хат килде бит. Алар да миннән ашыгыч рәвештә Сәхиб энекәшемне хан итеп җибәрүне сорап ялваралар. Ә Василий кенәз, эче кара тәре, Гәрәй нәселенең кан дошманы булган Шаһгалине юллап, мине мыскыл иткән. Ачыктан-ачык, лачкылдатып биткә төкерү бу! Моны гафу итү юк, Мәскәү өстенә яу белән бармый калмыйм, яу, яу!

Аппак морза курка-йолка гына сүз кыстырды.

— Казан күптән икегә бүленгән. Бер як — Нугай Урдасы белән туганлыкны өстен күрә, икенче як, көн-таң атса, Мәскәү җырын җырлый. Агиш белән Түләк морзаларның Нугай һәм Кырым сәүдәгәрләре белән эше пешә, ә Эчек, Булат Ширин, Исмәгыйль шикелле морзалар Мәскәү, Сүздәл, Рәзән калалары белән сәүдәгәрлек итә. Василий кенәзнең «Казан морзалары унөч яшьлек Шаһгалине үзләре сорады бит», дигән сүзләрендә дә, мөгаен, хаклык бардыр. Казанның элеккеге Ибраһим вә Илһам ханнары ук Мәскәүгә тугрылык вә буйсыну белдергәч, алар урынына алмашка менгән яшь таждарлар нишли алсын инде? Аның тегеләре үк «Мәскәү рөхсәтеннән башка ханнар утыртмаска», дигән шартнамәне үбеп калдырган бит.

— Мәскәү җырын җырлыйсың, син үзең дә кенәз акчасына сатылган соран түгелме икән? — дип үкерде Мөхәммәтгәрәй. — Сатылгансың икән, сина да дар!

Мөхәммәтгәрәй икенче таңда ук Аккирмән, Акмәчет, Садак, Аккала, Алып, Жанкай калаларына, хәтта еракгагы Көбә үзән[6], Каф тавындагы татарлар тарафына да житез чапкын куды.

— Урыс кенәзе бөек Гәрәйләр нәселен мыскыл итеп, Касыймга да, Казан каласына да безнең кан дошманнарыбыз булган Әхмәт хан сөләләсыннан чыккан карачура шаһзадәләрне хан итеп утыртты. Мөселман йортында кафер урыс итеге биюгә ирек куеп булмас, Мәскәү өстенә яуга кузгалабыз. Хан галиҗәнапләре үзенә тиеш булган ганимәттән бер өлеш тә алмый, барча табыш сезгә, үзегезгә!..

Алтмыш меңләп җайдак маңгаенда Мөхәммәтгәрәй үзе юлга чыкты. Тула каласына хәтле юлны җитез элдерттеләр. Василий кенәз дә дошман якынлашуын тиз арада белеп өлгергән шул, ул да алтмыш менлек чамасы гаскәр туплап, Мөхәммәтгәрәйнең юлын бүлде. Тын[7] елга ярында йөзгә-йөз килделәр. Татар алайлары[8] җиңел туплар гына алып чыккан, әле аларның да күбесен, көзге пыскак

[6] Көбә үзән — Кубань.
[7] Тын — Дон.
[8] Алай — полк.

янгырлар башлану, юл жепшүгә сылтап, ханлык чигендә үк ташлап киткән иде. Василий кенәз татар ташкынын биек ярга тезгән авыр туплардан туктаусыз ут ачып каршылады. Лифляндия белән Ливон олысларына ясалган яулардан әсирлеккә алып кайткан алман тупчылары, алны-ялны белмичә, бер филтәдән икенчесенә колын шикелле уйнап йөгерделәр. Нәтиҗәдә татар алайлары буталышып бетте, тәшвиш чире йоккан йөзәрләгән җайдак сафны бозып качты. Кылыч орышында татар алайлары русның чалгы-балта тотып килгән сала ирләрен пыр туздырып атса да, елга аръягына күчеп өзәрлекләүдән тукталып калды. Шул төндә үк күк йөзеннән тоташ кар да яварга тотынгач, Мөхәммәтгәрәй үзенең тәүге сәфәрен оттырышсыз тәмамларга карар кылды. Юл өстендәге барча кала-салаларны тоташ талый-талый, меңәрләгән әсир-саугат җыеп, ханлык чигенә кайтып егылдылар.

Мөхәммәтгәрәй Бакчасарай түренә кайтып керсә, анда — Истамбулдан килеп төшкән чапкын.

— Мәскәү белән Истамбул үзара яу йөрешми, берсен-берсе туган итеп таный. Ике арадагы дуслык солыхын хаксыз бозган өчен Сөләйман солтан галиҗәнапләре сине нык гаепли. Василий кенәз, илче юллап, үзен Кырым ханы мәрхәмәтсезлегеннән ярлыкау һәм хәтта урыс җирләренә китерелгән зыян-зәүрәт өчен түләү дә сораган. Мондый башбаштаклыгың өчен солтан галиҗәнапләре синнән аның фәрманнарына сүзсез буйсыну, урыс кенәзенә карата миһербанлык һәм башкача яу йөрмәүне таләп итә.

Мөхәммәтгәрәй, ярсуыннан тирләп пешә-пешә, солтанга хат сырлады, махсус илче билгеләп, эчтәлеген аңа бәян итте.

— Мәскәү кенәзлеге тышаулыгын өзеп качкан бозау төсле көннәр узган саен көрәя-тазарадыр. Ул үзе басып алган һәрбер яңа җирдә ислам динен аяк астына мунчала чыпта урынына салып таптый. Кеферләр әле кичә генә кукраеп утырган безнең мәчетләребездән чиркәү ясап бетерде, аларның манарасын җимереп, чатак тәре мендереп бастырды. Әгәр урыс кенәзләренең мондый зобанилыгына ирек куеп торсак, муенчагын салган Василий иртәгә үгез сыман көрәеп җитәчәк һәм бөтен мөселман олысларын вә мәмләкәтләрен җимереп ташлаячак. Безне фәкать уяулык, саклану һәм бердәмлек кенә ул зобанилар коллыгыннан коткарып калачактыр.

Василий кенәз Истамбулга хат кына түгел, янчык-янчык алтын-көмешен дә юлларга онытмаган. Шул янчыкларга ия булып алган мулла һәм пашалар, солтан хозурына кереп, яңа төрле «дога» пышылдаган. Тилмерергә ара калдырмыйча, җавап кайтып төште.

— Василий кенәз — хаклы, ә син — хаксыз. Минем мөһерем шулдыр.

— Тфү, калалгыры! — дип сүгенергә мәҗбүр булды Истамбулга кендеге белән бәйләп куелган Кырым ханы. — Син тәхеттән алып атмасын дип, мин дә моннан ары, булдыра алган кадәр, «ярхәмкә Аллаһ»ны гына укып утырырмын инде...

Юк, Мөхәммәтгәрәй борыны канаса да тәүбә итә торган бәндә түгел иде, басымчак кол битлеген кигәнгә дә озак түзә алмады. Җитмәсә, казандай кайнаган ярсуын яңартырга куыз өстәп торучылары да көннән-көн күбәя бара бит әле аның. Әнә, бүген тагын Казан тарафыннан Түләк морза юллаган чапкын зарын түгә.

— Хан урынына безгә шүрәлегә охшаш карачкыны китереп утырттылар, килеш-кыяфәте ташка үлчим. Буе карсак кына, корсагы туп чаклы. Ботларының озынлыгы өч карыштан артмый, аның каравы, табаннары ике карыш бардыр. Куллары маймылныкы төсле озын, кәкре. Буып үтерик дисәк, муены юк, башы кавын кадәр. Иң яманы — чыраенда пескәк белән эзләсәң дә сынар сакал бөртеген дә табып булмый, арт сандай шоп-шома. Ниндиер хатын-җәмәй, дияр идең дә, хатыннарның да андый шыксыз-гарипләре юк бит аның. Ходай Тәгалә нигә безне шундый албастыны җибәреп рәнҗетәдер?..

Түземлеген җуеп, Мөхәммәтгәрәй төпчек энекәшен чакырттырды. Сәхибгәрәй тәхет залына үтеп керүгә үк нотыкны бала итәге шикелле кыска гына тотты.

— Мин сиңа бер мең кадәре озатучы елгыр яугир бирәм. Син Казанга юнәл. Күз алдымда саруымны кайнатып йөрмәсен, үзең белән Аппак морзаны да ал. Ул бик шома таш, сарай тирәсендәге уеннарны биш бармагы төсле яттан белә. Казандагы Сәйди, Агиш, Түләк морзалар — барысы да бездән ханлык тәхетенә гаһед котә. Ә Мөхәммәтәмин әле үзе исән чагында ук тәхетне сиңа калдырачагын васыять итеп әйткән. Син — лаеклы һәм Чыңгыз атабыздан калган «Яса» вә шәригать буенча иң кануни гаһед, моңа һич шикләнмә. Казан капкасы каршына барып җитүгә үк, сиңа юл арчырлар, икеләнеп тормыйча тәхеткә үт тә утыр. Хәвеф туа калса, сине араларга гаскәр җибәрермен. Әмма әүвәл тавыш илә тәшвиш кузгатмыйча гына Казан тәхетенә менеп ояларга иде. Мәскәү яңадан соң безгә «Казан разый түгел, гаскәр белән генә китереп утырттылар», дигән гаеп ташламасын.

Сәхибгәрәй егерме яшен әле генә тутырган алкынчак шул, телен тешләп калырга күнекмәгән.

— Алай-болай, син монда энекәш мине суеп ташламасын, арткы яктан пычак кадамасын дип шөбһәләнмисеңдер лә инде, өлкән абый? Син — минем өчен газиз атам урынына калган иң кадерле кеше. Минем син утырган тәхеткә дәгъва иткәнем дә, үпкә-зар белдергәнем дә юк бит. Миннән котылу өчен генә читкә кумыйсыңмы, дип соравым бу. Аңлавымча, Казан үзенең колачын ачып каршылап та тормый, тәхеткә яу белән менәсе булса, шәһид китүем бар. Менә шуларның барысын да күздә тотмыйсыңмы?

— Аһ, син, егермесен тутырып та акыл туплый белмәгән буп-буш чүлмәк! — дип сүгенде Мөхәммәтгәрәй, чын күңеленнән әрнеп. — Әгәр үз туганнарымнан арынуны гына максат итсәм, сезне берәм-берәм яуга ташлап йә катыйллар җибәреп җаныгызны кыю авырмыни? Юк, энекәш, минем күңелемдә — син күз алдыңа да китерә алмаган олы, изге максат. Чыңгыз белән Бату җиһангирларны, Мүнкә белән Үзбәк ише бөек каһаннарны гына исеңә төшер дә шуннан инде минем эчтә нинди ут януын, бәлкем, син үзең дә бераз чамаларсың. Мин әлегә йөрәгемне ачып сала алмыйм, андый уйны йөрткән бер генә чурасын да Сөләйман солтан гафу итмәячәк. Ә хәзергә син шуны гына ятла. Мин — Кырымда, син Казанда утырсак, бу инде ике йодрык кебек алагаем зур көч. Безне урыс кенәзе дә, сугым малы сыман, табан астына сузып сала алмаячак. Килен-кәләш алышуны да күз чалымына китермичә, һаман-һаман дошманлык саклаучы Хаҗитархан ханнары да моннан ары безнең алда дер калтырап торудан башканы белмәячәк. Шушыны аңла һәм бер генә мизгелгә дә туганлыкны, бергәлекне онытмыйча яшә. Син — минем калканым, ә мин — сиңа канат!..

## 13

Абыйсы Мөхәммәтгәрәй хан күрәзәче түгелдер, әмма белеп әйткән. Сәхибгәрәй юлда сайлап алган өч йөз җайдагы белән Казан каршына килеп туктауга ук, дивар сакчылары кала капкаларын улын сагынып көткән ана кочагыдай ачып каршылады. Сәхибгәрәй өчен Казан дигән мәркәз күптән таныш, әле ун-унбер яшьлек малай чагында ук әнкәсе Нурсолтан белән аның биргә кунакка килгәне бар. Әнә хәзер дә ул һаман элеккечә. Казансу елгасы өстендә юан бүрәнәләрдән тезелгән агач кирмән, әнә аның Төмән, Алат, Ногай атлы биек капкалары. Кирмән каршындагы Ташаяк базары да, Болак суының ике яры буйлап тезелешкән бистәләр дә — һәммәсе шул көенчә.

Капкадан Сәхибгәрәйне каршыларга килгән Сәйди, Агиш, Түләк морзалар, меңбашлары, дистәләгән сәүдәгәрләр тезелешеп чыкты. Иң сөенечлесе — урталарында Коръән-Шәрифне күкрәгенә кыскан Боерган сәет белән ун-егерме имам. Мәмләкәтнең дин башлыгы синең килүенне хуплый икән, шәригатькә

хыйлаф адым ясамыйсын, син кадерле, димәк. Морзаларны, яубашларын, сәүдәгәрләрне ярлык биреп йә янчык белән сатып алып була, дин башлыгын орып-бәреп һәм юхаланып кына үз әләмен астына индерү бик кыен.

— Әссәламәгаләйкүм, Сәхибгәрәй туганыбыз һәм хан галиҗәнапләре! Сине Казан тезенә чүккән көе каршы ала, — дип сәет сәлам сүзен ыргыткач, морза белән сәүдәгәрләрнең һәрберсе, башларын тезләренә чаклы иеп, тугрылык белдерергә җөрьәт итте.

Иярennән төшеп Коръәнне үбүгә үк, Сәхибгәрәй эчен еландай тырнаган сорау белән кырыс сүз башлады.

— Хан сараен Мәскәү колы Шаһгали белән орышканнан соң гына яулап алырга туры киләчәкме?

— Юк, сарайга юл ачык, — дип бәлзәм төсле татлы җавап ташладылар. — Әмма Шаһгали шунда. Сабый бала сыман, нәрсәгәдер өметләнеп, сине көтә әле.

Сәхибгәрәй тәхет залына ак-караны күрми бәреп керде. Тупсаны атлап үткән чагында ук шәйләп өлгерде ул: аяклары яртылаш кисеп ташлангандай кыска, гәүдәсе кыршауларын алып ташлаган мичкә төсле чик-чамасыз юан бер албасты тәхет янындагы бер баскычта утыра, йөзе көл сипкән шикелле кара янган, карашлары төссез, чыраенда нур юк. Аңлашыла, ул үзенең өстенә басып килгән Сәхибгәрәйне тәхеткә утырган көенчә каршыларга да батырчылык кыла алмый инде.

— Син нишләп тагын Мәскәвенә, урыс кенәзенең табанын яларга чыгып качмадың соң әле? — дип таудагы шарлавык шикелле усал, вәкарь тавыш белән кычкырды Сәхибгәрәй, дошманының йөзенә карчыгалар төсле кырыс багып. — Сез, Казанныкылар, ихатада чынаяк ватсагыз да, Мәскәү кенәзенә барып әләкләргә вә көндәшләрне урыс кулы белән буып бетерергә күптән күнеккән монафыйклар, җебегәннәр ләбаса. Мин бит сине тотмыйм, бар, элеккечә Мәскәвенә, урысларның Василий кенәзеннән ярлыкау вә гаскәр сорарга дип чык та ычкын.

— Мин — хан бит, мине Мәскәү кенәзе раслады, аңа буйсынмыйча яшәсәм, алып ата, — дип меж-меж итеп телгә килде Шаһгали. — Ә син, шул ук урыс төсле, басымчаклык итеп басып кердең. Син кануни хан түгел. Сине Казан-йортның тануы да бик икеле.

Сәхибгәрәй төкерекләрен чәчеп, үгез шикелле ярсып җавап бирде.

— Тәхетне ялварып сорамыйлар, талап алалар ул, ахмак Гали! Теләсә кайсы ханлык — иярен вә йөгәннәрен җуйган айгыр төсле. Аңа иң беренче булып кем бугалак ташлый йә йөгән кидерә, тик шул җайдак кына аны авызлыклый, ияренә сикереп атлана, ахыр чиктә арткы аякларына күтәрелерлек итеп ярсыта да, биетә дә ала. Йөгәнне, менә, бүген мин эләктердем, ә син, әллүр моннан, аттыр!

Шаһгалинең һаман каккан казык кебек селкенмәвен күргәч, янә җиргә типте.

— Мин сине, әлбәттә, дар агачына озата йә, букәнгә салып, сатлыкҗан башыңны чаптыра алыр идем. Тик безнең үзара кан койганны күрсә, дошман сөенәчәк. Мин егерме мәртәбә миһербанлык күрсәтмәм. Бүген тәхеткә менәчәкмен, шуна кәефем шәп. Шуннан файдаланып кал да яхшы чакта күз алдымнан югал!..

Беркавем арадан соң каравыл йөзбашлары хисап тотты.

— Шаһгали мөртәтне, хатыны вә балалары белән балыкчылар көймәсенә тәяп, Зөя ягына агызып җибәрдек без.

— Ә аны татарларга каршы котыртып ятучы бәдбәхет Карпов кайда? — дип кычкырды Сәхибгәрәй, йокысыннан яңа уянгандай.

— Урыс илчесе Карпов әле син Казанга җиткәнче үк качып китәргә өлгерде шул, каһәр.

— Нигә качырдыгыз? — дип кабынды янә Сәхибгәрәй, тешләрен боз кисәге чәйнәгәндәй усал шыгырдатып.

Морза һәм меңбашларның ялкынсыз йә аумакай гына җавапларын ишеткәч, яңа таҗ иясе ярсуын йодрыгына төйнәп кала алмады.

— Ләбиб, Кәрим! — дип кычкырды ул үзенең йөзбашларына. — Мин Казанда Шаһгалине Мәскәүдән чакырып китерттергән Коләхмәт, Яуш, Жанкай атлы соран морзалар посып ятуын беләм. Ул монафыйк жаннарны таракан шикелле качкан ярыкларыннан көйдереп чыгарыгыз да кирмәндәге сарай мәйданына сөйрәп китерегез! Госман! — дип эндәште ул аннары бер-ике адым алгарак чыгып баскан пәһлевандай зур гәүдәле бер меңбашка. — Син үзеңне Сәхибгәрәй оныткан һәм танымый, дип уйлыйсыңмы әллә? Нурсолтан анам белән сәфәр килгән чакта син безне Нижгар каласыннан Казанга чаклы озата кайткан идең. Улчакта да анама һәм шаһзадә буларак үземә бигать[9] иткәнеңне һич онытмыйм. Әйдә, кабат расла. Сарай мәйданына дар агачлары тезеп кую хәзер синең өстә. Аннары Касыйм каласыннан карачкы Шаһгалигә ияреп килгән сатлык сәүдәгәрләрне дә дарга озатыгыз. Урыс илчесе Карповны качыргансыз икән, калагызда Василий кенәз Шаһгалигә тагып җибәргән баскын воевода Поджогин да бар иде бит әле. Ул шымчының да урыны дар агачында, тизрәк котылыгыз!..

Шуннан ары атна-ун көн буена дар агачлары мәет-корбаннардан бушамады. Тынган берсен соңыннан, салларга тутырып, Идел буйлап түбәнгә озаттылар. Кирмән эчендә яңа ханга ант китерүләр дә, мәҗлес, күңел ачу кебек тантанасы да булды, әмма Казан, эченә корт төшкән яфрак-үлән сыман шомланып, саргаеп һәм тынып калган иде. Искә-аңга килерлек, яңа тәртипләргә ияләшерлек тә ара бирмәделәр, Кырым тарафыннан гаярь чапкын килде.

— Мөхәммәтгәрәй хан Мәскәү өстенә зур яу белән бара. Нугай белән ләһ яугирләре дә аңа кушылганнар. Мөхәммәтгәрәй хан хозурында энекәше Сәхибгәрәй вә Казан яубашлары өчен дә аерым чатыр әзер.

Абыйсының «энекәш», дип кенә кимсеткеч оран ташлавы Сәхибгәрәй ханның мин-минлеген итәгенә төшкән күмер кебек яндырып таласа да, яңа хаким кем алдында бурычлы булуын бер генә мизгелгә дә исеннән чыгармады. Өстәвенә, абыйсының хушлашканда әйткән сүзләре дә аның җанын тукран сыман гел-гел талый иде.

— «Элек Чыңгыз белән Бату җиһангирлар, Мункә белән Үзбәк кебек бөек каһаннарыбыз булганын мәңге онытма син. Йөрәгемне нинди ут талавын шуннан чамаларсың.»

— Мин аңладым, хәзер аңлыйм инде, — дип пышылдады Сәхибгәрәй үзалдына гына. — Олыгайгач, акылың да, чәч-сакалың төсле, коела бара бугай. Син үзеңне төшеңдә Чыңгыз яисә Бату хан итеп күрәсеңдер. Мәгәр кайсы хаким генә андый хыял диңгезендә йөзми калгандыр да, аның ише шөһрәт вә шәүкәткә ирешү синең генә хәлеңнән килер микән, туган абыкаем? Хәер, син мине — үзеңнең калканың, ә үзеңне минем канатым, дип атадың бит әле. Калкан икәнмен, синең янәшәңә бармыйча булмый инде.

— Яуга, Мәскәү өстенә кичекмәстән яуга! — дип оран салды Казан тәхетендә калкып чыккан өр-яңа хан.

Әллә яңа таҗдарның күп дошманны кансыз юк итүен күреп шомландылар, әллә яу сәфәреннән баеп кайту атлы яман корт талады — бер атна дигәндә Сәхибгәрәй хан әләме астына кырык меңнән артык җайдак тезелешеп басты. Нижгар каласына барып җиткәнче һичбер төрле дошман очрамагач, чынлап сагайдылар. Сәбәбе баз төбенә күмгән чүлмәк түгел икән, бер-бер артлы агылышып торган чапкыннар көн дә хәбәр итте.

— Мөхәммәтгәрәй хан явы турында белеп алуга ук Василий кенәз Кырым чирүенә каршы олы гаскәр куган. Кырым татарларының Ука елгасын турсыкларда[10] кичүләрен күреп, урыс алайлары, бүре талый башлаган эт өере сыман, төрле якка качкан. Владимир Курбский белән Ширәмәт атлы чукынган бер татар туктатырга тырышып каршыларына баскач, теге котырганнар ике кенәзне дә таптап үтергәннәр.

[9] Бигать — тугрылык, басымчаклык турында ант.
[10] Турсык — бурдюк.

Федор Оболенский атлы тагын бер кенәзләрен Мөхәммәтгәрәй ханның сәрбазлары әсирлеккә алган. Хан ул кенәзне тәртә арасына җигеп, арбалар тарттырып чиләтә-черетә, ди. Яллап китерелгән Ливон алманнары биргән әмерләрне тыңлаучы юк, татар җайдаклары колакларына ут элгән ук яңгыры очыра башласа, урыс алайлары «шайтан, шайтан», дип оран сала-сала качып китә икән...

Кырым белән Казан чирүләре Коломна шәһәре янында бергә кушылдылар. Вәгъдә итүенчә, Мөхәммәтгәрәй яубашлары өчен дистәләгән чатыр корып куйган, сый табыны әзер, ике як та шап-шоп килеп, кысып кочыштылар. Мөхәммәтгәрәй, баш сәргаскәр сыйфатында, энекәшен үзенең ефәк-парча чатырына дәште. Тыштан бик җинелчә генә булып күренсә дә, чатыр эчендә бәрхет белән киезгә төргән аулак бүлмәләр дә яшерелгән икән. Шундагы ястыклар өстенә иңүгә үк, абзый кеше, мышный-мышный үзе сүз башлады.

— Моннан егерме ел чамасы элегрәк әткәй Сарай ханы Әхмәтне тар-мар итеп кайткач, и-и, сөенгән идем! Әхмәт ханны Нугай бәге Ибәк мирза суеп үтерсә дә, төп гаскәрне атай-мәрхүм җыеп барган Кырым татарлары тәшкил итте һәм иң төп яуларда аның җайдаклары Сарай сәрбазларын пыран-заран китереп бетерде ләбаса. Шуннан ары җанда өмет туды. Менә, Алтын Урда мәмләкәтеннән бушаган бар җиргә, һәмишә байлыкка алга табан атай берүзе хуҗа булып ала, Ходай Тәгалә Гәрәйләр нәселенә бетмәс-төкәнмәс хакимият, күк капусына таба олы баскыч бүләк итте, имеш. Иллә мәгәр, Сәхиб туганкаем, барча хыяллар да томан гына булган. Әхмәт вафатыннан соң Җаек аръягында, Җидесу буйларында кайсак татарлары, Каф тау татарлары арасыннан Әбелмәмбәт, Низам, Шәйбан, Насретдин, Борак, Булат атлы дистәләгән ялган шаһзадәләр, яңа ач-әрвахлар калкып чыкты. Шулар, кан исеннән котырган чүл бүреләре сыман, Алтын Урданы үгез үләксәсе урынына төрле якка тарткалый һәм өзгәли башладылар. Безнең атай өмет баглап торган бердәм каһанлык урынына, Алтын Урда җәсәде өстендә, Ак Урда, Күк Урда дигән намьнәр алган әр-яңа мәмләкәтләр хасил булды. Менә шулай итеп, Гәрәйләр нәселе үзе җиңү яулап ирешкән нигъмәт-байлыклардан коры калды. Без мондый кимсетелүгә һәм мәсхәрә калуларга лаек түгел идек, түгел идек, Сәхиб туганкаем!..

Мөхәммәтгәрәйнең ике күзеннән дә яшь тамчылары сытылып чыккан, ул усал итеп йомарлаган йодрыклары белән әле тез башларын, әле түшәк читен дөп-дөп төеп ала. Ачы яшь тамчыларын шәйләп өлгерүгә, Сәхибгәрәй аның йөзенә күтәрелеп карарга да кыймый.

— Ходай Тәгалә Сарайдан калган җирләрне бер учка җыярга унай форсат бирде, ә без атай заманында шуны ычкындырдык. Әмма аның нигъмәтләре, олыс-утарлары еракка таралмаган, аларны кабат Гәрәйләрнең түбә астына тупларга һич соң түгел әле. Безгә Чыңгыз хан илә Бату хан җиһангирлар җыеп калдырган татар каһанлыгын, татар солтанатын әр-яңадан торгызырга кирәк. Коллар сурәтендә зынҗыр-читлек киеп, тышауланган сыман бәйле булып, төрекләрнең Сәлим яки Сөләйман солтаннары каршында бил бөгүне туктатырга вакыт. Сөләйманының арт саны тәхеткә дә күнегеп өлгермәде, ә шул сәләгәй дә әнә «урыс белән бульшма, урыска таш атма», дип, инде алтынчы дистәсен кырлаган Кырым ханын маңкалы урам малаена санап, миңа күрсәтмәләр биреп, фәрман юллап ята. Юк, без, татарлар, үзебез аерым каһанлык төзи һәм, кирәк була калса, урысларның Василий кенәзенә дә, төрекләрнең Сөләйман солтанына да йөгән кидерә алырлык бөек халык. Безнең ата-баба Алтын Урда атлы шәүкәтле һәм олы дәүләт тоткан, бугазга-бугаз килеп җәдәләшә торгач, үзләре үк аның башын ашаган һәм каһанлык атлы бөек мәмләкәтне печән кибәнедәй таркатып бетергән. Хәтта бүген дә Чыңгыз туруннары Таш Билбау аръягында, Каф тавында, Кырымда, Казанда, Хаҗитархан илә Нугай даласында аерым-аерым ничә ханлык тота. Ил төкерсә, күл була, ди халык. Безгә менә шушы вак-вак ханлыкларны ерганаклар төсле, инеш төсле бер дәрьяга, бер әләм астына туплый белү кирәк.

Инешләрдән олы диңгез җыелмыйча калмас, ә диңгезне төрек җайдакларының ятаганнары белән дә, урысның сасы чабатасы белән дә түгеп бетереп вә корытып булмый. Мин шушы хакта сине Казан тәхетенә озаткан чакта ук орлык салган идем, инде күзгә-күз карашып сөйләшергә дә вакыт житте менә...

Мөхәммәтгәрәйнең күзләре төнге далада җил исеп уяткан учак күмерләре сыман, торган саен көчәя барып, очкынланып яна. Аның хәтта борын тишекләре дә беренче тапкыр сыртына җайдак сикереп менгән өчен ярсыган тайныкы шикелле киерелгән, үзе еш-еш сулый. Кулларына чаклы, очарга әзерләнгән кыр казлары, торналар канатыдай, вакыт-вакыт уйнаклап, күтәрелеп куя, Мөхәммәтгәрәй менә-менә күккә калкыныр да иң биек кыя түрендә урын алыр сыман.

Сәхибгәрәй үзе дә бәйгегә кузгалырга әзерләнгән чабышкы ат шикелле әсәренде. Аның да бит очлары учакка якын килеп кулларын җылыта башлаган сәйяхныкы кебек алсуланып чыкты, ә ялкын телләре күкрәгенә күчеп көйдерергә тотындылар сыман.

«Дөрес сөйлисең син, һәр сүзеңдә хаклык, — дип кабынып уйланды ул. — Татар — бөек, ул да, төрекләр шикелле, бер йодрыкка, күмәк түбә астына укмашып яши белсә, аны урыслар да, башкасы да сындыра алмас иде. Әмма һәр йорт-сарайның ишеге дә, тәхете дә берәү генә була. Атның тезгене — бер. Олауның да дилбегәсе фәкать сыңар кузла иясендә, арбакашта. Кабат аякка бастырырга җыенган Чыңгыз каһанлыгының тезгенен син үз кулыңа эләктерергә җыенасың инде, моңа шик юк. Ә мине, төпчек энекәшеңне, нигъмәт табынының кай турына утыртып куярга ниятлисең икән? Түрдә, синең янәшәңдәме миңа урын, әллә ишек катында, кара гавам, ит чабучы кассаплар белән бер рәттәме? Тик кая гына куйма, миңа син кимергән сөякне ялап утырудан башка тәкъдир елмаймый шикелләрәк...»

— ...Без бит — ике туган, әмма беребез — Мәскәү тарафына, икенчебез Истамбул эргәсенә карап каткан кара кол хәлендә. Әйдә, Василий кенәзне җиргә тезләндерик тә, аннан ары Хаҗитарханын-Нугаен, Себерен һәм хәтта Каф тауны, Җидесу буйларын, Ак вә Күк Урданы Гәрәйләр түбәсе астына туплап, бөек татар солтанатын кабат аякка бастырырга берүк ашыгыйк без. Ходай Тәгалә сынау-форсатларын гел җибәреп тормас. Безнең өчен, бәлки, бүген соңгы сынау, соңгы талпынудыр. Без йокласак, иртәгә ханлыкларыбызны, берәм-берәм, йә төрек солтаны, йә урыс кенәзләре үз итәкләре астына җыеп ала. Син минем ниятләремне хуплыйсыңмы, энем, туганкаем? Син минем янәшәмдәге калкан илә аркадашым икән, әйдә, бигать китер.

— Син искиткеч катлаулы, ләкин бөек юлда. Мин сиңа гомерем буе тугры калырга ант китерәм, олкән борадәрем! — дигән дулкынланган җавап ыргытты Сәхибгәрәй, эчендәге утны сиздермичә.

— Син ике арада сөйләшенгән барча сүзләрне гел сер итеп сакла, — дип йомгакларга ашыкты Мөхәммәтгәрәй хан. — Ә мин, күзләренә тәтен җибәрү өчен, Хаҗитархандагы Хөсәен ханны да, Нугайдагы олугбәк Мамай белән Агышый, Урак мирзаларны да Мәскәү өстенә яуга чакырып карыйм әле. Нугайныкылар күнәр, алар минем кулда. Ә Хөсәен хан баш тарта йә кәҗәләнә икән, соңыннан аның өстенә барырга да бик шәп сәбәп булыр...

Мөхәммәтгәрәй канәгать елмаеп урынынан купты, шап-шоп китереп энекәшен кочагына состы. Кияү-кәләшләрен башлы-күзле итәргә, никах укытырга вәгъдәләшкән ике кода сыман, ике төрле ут эчендә янган бертуганнар кыска арага янә хушлаштылар...

Берләштерелгән татар гаскәре барча тирә-юньне тимер ташкын сыман сытып-изеп барды. Василий кенәз камчылап юллаган дружиналар ул ташкынны буарга маташып юл өстенә чыгып караса да, кыяга бәрелгән диңгез дулкыннары урынына кире чәчелделәр. Ә берзаманны алар инде ут элдергән салам кибәне астына кереп качкан кыр тычканнарыдай ак-караны күрми качарга тотынды.

Мәскәү диварлары, капка алдындагы күперләр өстендә, алар елгадагы язгы боз ташкыны сыман бер-берсенең өстенә өелде. Бәрхет җилән киеп алган йөзбашлары, капкага юл арчымакчы булып, аяк астына эләккән качакларны кылыч белән чапкалый башлады. Күз ачып йомганчы күперләр һәм ерымнар каршында дистәләгән мәет өемнәре калкып чыкты.

Мондый башбаштаклык һәм тәшвишне күреп, Мөхәмммәтгәрәй хан һөҗүмне туктатып торырга әмер бирде. Кайбер тарафларда, барыбер дә, ермак алай[11] яугирләре дивар өсләренә дә менеп җиткән, шулар бер-бер артлы хәбәр яудырдылар.

— Олуг кенәзләре, Мәскәүне кияве — чукынган татар сатлыгы Ходай Бирде кулына калдырып, Волок каласына чыгып качкан.

«Әһә! — дип шаккатты Мөхәмммәтгәрәй, башын кат-кат чайкап. — Ходай Бирде — элек Казанда утырып бакыйлыкка күчкән Ибраһим хан угълы. «Ибраһим вафатыннан соң тәхеткә нугайлылар күтәргән Илһам утырырга тиеш түгел иде. Ибраһимның тол хатыны Кырымдагы Миңлегәрәйгә кияүгә чыкты, әлеге хан Мәскәү белән яу йөрмәскә солых төзеп куйды. Казанда Кырымга киткән Нурсолтанның малае Мөхәммәдәмин утырса, безгә дә хәвефсезрәк», — дигән сылтау белән, Иван кенәз Казан каласы өстенә зур яу белән килгән. Тәхеткә Мөхәммәдәминне утыртып куйганнан соң Ибраһимның беренче хатыны Фатыйма белән аның өч угылын да Мәскәүгә алып киткәннәр[12]. Илһам хан бераздан Вологда зинданындагы газап-михнәтләргә түзә алмыйча җан тәслим кылган. Чукынудан баш тарткач, Мәликтимерне Белозёр зинданында буып үтергәннәр. Ә Пётр дигән өр-яңа ат һәм тәре тагуга килешкән Ходайбирдене, Евдокия атлы картаеп беткән кызына өйләндереп, Иван кенәз үзенең кияве ясап куйган. Мәскәүне менә шул кияве кулына ташлап качкан, димәк. Әйдә, тугрылыгыңны күрсәт, дип сатлык татарны сынап карауы бу? Әллә татарны кала башлыгы итеп калдыргач, яу белән килгән туганнары мәрхәмәт күрсәтмәс, кызганмас микән, дигән яшерен бер өметме?»

Диварлардан хәбәр юллауларны бер дә сонартмыйлар.

— Мәскәү боярлары таш кирмән эченә кереп бикләнү өчен үзара сугышалар. Кирмән яны мәет белән тулы, бала-чагалары, хатын-кызлар кая кереп посарга белмичә, артларына ут капкандай йөгерешә һаман.

— Спас капкасы янында бер яубашларын әсирлеккә алдык. Мәскәү эчендә Василий кенәз акчага яллап китергән бер алман тупчысы бар, ләкин ул безнең өскә ут яудыра алмый, калада бер янчык та дары калмаган, ди...

Әмма Мөхәммәтгәрәйнең йөрәгенә пычак булып кадалачак хәбәр ханның үз иленнән сәмум җиле сыман килеп җиткән икән.

— Азак кирмәненнән чапкын килде, яшен төсле ашыгыч хәбәре бар, — диде бер түмәнбаш аңа, ханны тимер бождрадай саклаган каравыл сафларын камышларны ерган каек урынына аудара-сыта үткәч.

Түмәнбаш аңа мөһерләнгән төргәк сузуга ук Мөхәммәтгәрәй корбанының муенына ташланган көзән елгырлыгы белән хат эченә чумды. Укып бетерүгә йөзе агарынды, куллары утлы кисәү тоткан сыман дер-дер калтыранды.

— Азак кирмәнендә калдырып киткән Борһан паша яза, — дип телгә килде ул, суга төшкән чебеш сыман, канатлары сынып. — Хаҗитархандагы Хөсәен хан, хәсис, Мәскәүгә барырга дип җыйган чирүенә Кырым тарафына борылырга әмер биргән икән. Тәхетне ташлап китүемне генә көткән дә сыртка пычак кадарга чамалый бу соран. Аһ, мин ул сатлыкның эчен измәсәмме!..

Утлы таба сыман кыздырып торган кояш офык сызыгына таба авышкач, Мәскәү эченнән дә олы кәгазь төргәген калкан урынына алга сузып, әмма киез кәпәчле башларын билгә тикле бөгеп атлаучы арадашчы-илчеләр төркеме дә чыгып җитте.

---

[11] Ермак алай — авангард полклар.

[12] 1487 елгы вакыйгалар.

— Олуг кенәзебез Василий Иоан улы Өченче буйсыну вә түбәнчелек илә Мөхәммәтгәрәй хан һәм Сәхибгәрәй хан галиҗәнапләренә солых тәкъдим итә. Кенәзебез ике хан галиҗәнапләренә дә элек Сарай ханнарына түләгән микъдарда ясак озатып торырга ант китерә. Фәкать пайтәхетебезгә генә бәреп кермәгез дә, кенәз сараена зәүрәт китермәгез. Кенәзебез Казан йортын да, нәкъ Кырым-йорт шикелле үк, туганы дип саный. Моннан ары Мәскәү Казан-йорт эшләренә тыкшыначак түгел, андагы халык вә морзалар кемне теләсә шуны тәхеткә хан итеп күтәрергә хаклы.

Барча хәбәрләрне бизмәннән кичергәч, Мөхәммәтгәрәй энекәшен янә үз янына дәште. Ни галәмәт, Сәхибгәрәй Мәскәүне берьялгызы тезләндергән сыман,ияр өстеннән төшәргә дә ашыкмыйча утыра бит һаман. Абыйсының шәрә кыз күргәндәй акаюын шайләп алгач кына, җиләненең якаларын ачып, түшенә яшерелгән нәни төргәк суздры.

— Василий кенәз миңа аерым хат юллаган. «Син мең биш йөз дә унынчы ел кышында[13] әниең Нурсолтан ханбикә белән сараема килеп, айлар буе миһман булган идең. Мин ул чакта сине мыскал да рәнҗетмәдем. Ашка таш атмыйлар, минем илнең пайтәхетен кызган, вәйран итмә», имеш.

«Ишкән икән ишәк чумарын», — дип үзалдына гына уйланды да, Кырым ханы, йөзенә елмаю чыгарып, тантаналы, бик тә горур төстә тезде.

— Син бу көнне гомер буена да онытма, катибларына да кат-кат тукып яздыр, газиз туганкаем. Мең биш йөз дә егерме беренче елның егерме тугызынчы июнь көнедер бу[14]. Туктамыш вә Олуг Мөхәммәд ханнардан соң бер генә татар таҗдарының да Мәскәүне менә бу рәвештә тезгә куйганы юк. Без хәтта менә шушы җиңү бәрабәренә дә тарихта калачакбыз, синең белән минем исемемне сабыйлар ятлаячак. Шушы көннән башлап Казаның да ирекле, син үзең дә, һәр олуг гамәлеңне кылу алдыннан рөхсәт сорап яисә баш иеп Мәскәү эргәсенә табыначак ярымхан да, ярымкол да түгел. Син ирекле, син — мөстәкыйль хаким!

Илчеләрне солых кәгазьләренә мөһерләрен сугып озатуга, Мөхәммәтгәрәй хан энекәшен култыгыннан алды.

— Яшереп азапланмыйм, Хаҗитархандагы Хөсәен атлы этҗан, Кырымга барып, минем табан астына ут салырга әзерләнә икән, — дип нык ачулы кыяфәт белән сүзен башлады ул. — Гәрчә Мәскәүгә кереп, аны тулысынча вәйран китерергә бик уңайлы форсат булса да, гаскәремне җыеп, мин кичекмәстән үз йортыма юнәлергә мәҗбүр. Без бүген Мәскәүнең билен сындырдык, аны тулысынча аяк астына сузып салу да ерак качмас. Мин сиңа теге юлы да каткат тәкрарладым, татарның иң зур дошманы урыс кенәзе дә, төрек солтаны да түгел. Аның иң яман һәм иң беренче дошманы — татар үзе, аның каймак яисә май урынына оеша-укмаша белмәгән эчке көнчеләре, янәшәдә йөргән сатлыклары. Безгә, иң беренче нәүбәттә, үзебезнең дошманнардан, сатлык җаннар, сораннардан арынырга кирәк. Мин төбенә чаклы чокынып ачыкларга да өлгердем инде, туган. Икейөзле кабих Хөсәен хан, астан гына, еланнарча итеп, Василий кенәз белән сүз беркетеп куйган. Минем монда яу сәфәрендә йөрүдән файдаланып, ул Кырым-йортны кулына эләктерә дә минем тәхеткә менеп оялаячак, имеш. Ә соңыннан синең тарафка бергә-бергә яу чапмакчылар да, Казан-йортны урыс чабатасы астына сузып салмакчылар.

Сәхибгәрәйнең йөзе әрем капкан төсле кара янып чыкты, күзләрендә зәһәр ут кабынды, кашларына тикле усал бөгәрләнде.

— Юк, юк, Казан-йортны саклап калу фарыз.

— Мин, Хөсәенне дә яу сәфәренә чакырган булып, бик нык хаталандым, серне генә ачтым. Кайтуга ук Хаҗитархан өстенә зур яу белән чабам, аны үземнең олысыма әйләндермичә тукталачак түгел! — дип ярсыды

[13] Саннар Григориан календарена күчерелгән.
[14] Григориан календаре белән.

Мөхәммәтгәрәй, үз тезгенен үз көенә селкеп. — Ә син Коломна янында бигать китергән антларыннан кире танмыйсыңмы?

Сәхибгәрәй елан чаккандай куырылып калды.

— Юк, юк, танмыйм, танмыйм, абыйкаем, антым үз көчендә, — диде ул, утка пешкән сыман кабаланып-янып.

— Антыңны онытмас өчен син шуны исеңнән чыгара күрмә тагын, — дип ысылдады өлкән хаким. — Үзенне Казанга илтеп утыртсам да, синең улың Хәсәнгәрәй минем сараемда, минем кул астымда яшәп калды. Вәсвәсәгә бирелеп, урыс яки солтан ягына сатылсаң, мин малаеңның гомерен кыярга мәҗбүр булачакмын. Ул чагында мин түгел, ә син үзең аның башына җитәчәксең!

Сәхибгәрәй янә елан тиресеңдәй кисәк куырылды, тагын тәкрарлады.

— Мин синең яклы, һәр адымыңны хуплап кына гомер итәчәкмен, малаема тимә.

— Синең антың Ходай Тәгалә колагына күптән ирешкәндер, минем кисәтүемне генә түгел, ә сират күперендә очрашачагыбызны да онытмыйча яшә, — диде дә Мөхәммәтгәрәй хан меңбашлары ярдәмендә ияренә менде.

Татарларның кайтып китүен белгәч, Мәскәүдәге халык атна буе күз ачмыйча күңел ачты, шашты, канатланды. Шуннан ары еллар агышында әлеге ирек килгән һәм «чукынган Пётр җингән» көнне «Питрау бәйрәме» дип йөртә башладылар.

## 14

Истамбул вәзирләре Сөләйман солтанга Кырым белән Казан түнтәрешләре турында шактый соңлап һәм тәбикмәк-бәлеш урынына майлап җиткерделәр.

— Мөхәммәтгәрәй Казан тәхетенә үзенең тəпчек энекәше, Нурсолтаннан туган Сәхибгәрәйне кертеп утырткан. Сәхибне илткәнче Мөхәммәтгәрәй аннан, Коръәнне үптереп, Кырымга тугрылыкка бигать китерттергән. Шулай икән, моннан ары Казанны да төрек мәмләкәтенең аерылгысыз вилаяте дип санарга мөмкин. Казан да хәзер, бәйдәге эт сыман, Истанбулдан беркая да китә алмый инде. Сәхибне солтан галиҗәнапләренә бигать китерергә чакыртсак та була.

Ләкин ялагай вәзирләрдән тыш сарай тирәсендә алтын-көмешләрдән күзе томалана торган сәрдәр-паша белән сәетләр дә буа буарлык бит. Шулар арткы ишекләр аша гына Сөләйман хозурына урыс чапкыннарын да алып керә белде.

— Кырым белән Казан ханнары Мәскәү кенәзе өстенә тиктомалдан, бергәләп яу чапты. Тула, Коломна, Нижгар, Рәзән калаларын вәйран китерделәр. Василий кенәз Мөхәммәтгәрәй ханны, олау-олау алтын биреп кенә Кырымына кире куа алды, — дип җирән сакалбай тезгән сүзләрне ул әүвәл колак яныннан гына үткәреп тик утырды.

«Менә, картлач Мөхәммәтгәрәйгә биргән, бер дә Казанның төпсез базына түгеп әрәм итмәгән бит. Ә алтын-көмеш Кырымга кайта икән, иртәме-соңмы солтан казнасына күчәчәк ул», — дигән хыяллар белән күңелен дә юаткан иде, хәтта. Ләкин сакалбай чапкынның алдагы сүзләре сау тешне дә сызлатырдай булып тәэсир итте.

— Мөхәммәд үзенең төпчек энекәше Сәхибне аның сүзеннән чыкмаска, аның рөхсәтеннән башка берни дә кылмаска ант иттергән. Кырым белән Казан моннан ары — бер үк дәүләт, димәк. Бер көрәеп алса, араннарын җимереп качкан үгез сыман, алар хәтта төрек солтанының тәртә арасына да һич керәчәк түгел.

«Дөрес сукалый бит бу сакалбай, — дип пошынып һәм салкын тиргә батып уйланды ул. — Сарайдагы татар ханнарының һичберсе дә төрек солтаннарына мәңге буйсынмады. Йоклап калсаң, Кара диңгез белән Каф тау арьягында Алтын Урда шикелле үк өр-яңа бер татар каһанлыгы үсеп чыгуы бар. Әнә шулай, ялкау хатын сымак йоклаганга күрә, Баязит Елдырым да Җаек арьягында Аксак Тимер атлы яңа җиһангир симереп җитүен шәйләп өлгермәгән. Ә тегесе Җидесу ярыннан Каф тау аша безгә сикергән дә Баязит Елдырымның башын

чабып аткан. Мин бу сакалбайның да миннән бигрәк урыс иминлеге хакына житмеш дала кичеп, яна-пешә килеп житүен бик чамалыйм. Үзләренең ике татар ханын берьюлы тукмап кайтарырдай куәтләре юк бит. Әмма Василий кенәз мине дә урынлы кисәтә, бәйдән ычкындырсам, ул Мөхәммәтгәрәй соңыннан мине килеп сөзәргә дә рөхсәт сорап тормас. Татар — хәтәр. Аның даласында яңа Чыңгызхан үсеп чыгуга юл куярга ярамый, ярамый бит!»

Нугайлар да «Мөхәммәтгәрәй бездән гаскәр талый», дип тилмерә-зарлана чапкын куган иде, Сөләйман солтан Кырым ханын тез чүктерергә барыбер соңга калды. Мөхәммәднең Мәскәү сәфәреннән кайтуына җиде-сигез ай да вакыт үтмәгәндер, Идел дәрьясы буеннан таралган дәһшәтле яңалык ярты җиһанны гарасат урынына сискәндереп узды.

— Нугай мирзалары Мамай белән Уракны ияртеп, Мөхәммәтгәрәй Хаҗитархан өстенә зур яу белән барган. Андагы татарлар Кырым ханын кирмән капкаларын нигезенә яңа килен йә кодалар төшерүче бәхетле хуҗа шикелле ачып каршылаган. Хөсәен хан, сыртына таяк эләккән йолкыш эт урынына чиный-чиный, Мәскәү тарафына чыгып качкан. Мөхәммәтгәрәй нугай мирзаларын Әстерхан тәхетен вәгъдә итә-итә ияртеп барган булган, иллә мәгәр тегеләрнең берсенә дә таҗ кидереп рәхмәт кайтармаган. Ул Әстерхан тәхетенә үзенең өлкән малае Баһадирны утыртып куйган икән.

— Бәрәкалла! — дип, баш түбәсенә күсәк белән органдай, урыныннан сикереп торды Сөләйман солтан. — Болай булса, инде дүрт татар ханлыгын тез астына салып куйды бит бу картлач. Әгәр үзен дүрт ханлыкның да уртак бер таҗдары, дип игълан итсә, Мөхәммәтгәрәй хәтта өстенә йөз меңлек чирү белән килсәң дә, авызлык-йөгәннәрне таныячак түгел. Аның әле бу баскычта гына тукталмыйча, Җаек аръягына, Себер җирләренә дә сикерүе мөмкин.

Сөләйман солтан тынычлана алмыйча, читлеккә ябылган юлбарыстай ярсып, тәхет залы буйлап әрле-бирле чапты, үзе ни кылырга белми изаланды.

— Пәйгамбәр исемен йөртүче ханга каршы кылыч күтәреп баруы да оят, җанын кыйсаң, гомерлек кара тамга. Ничек тәртә арасына кертергә соң моны, йә, нишләргә? — Әрле-бирле байтак суккалангач, элеккечә сүгенеп һәм ярсып дәвам итте. — Элек Казан ханнары гына, куыш эзләп йә яклауларын сорап, Мәскәү кенәзләренең ышыгына бара һәм урыс чабатасын ач эт шикелле ялый торган иде. Башлап Касыйм хан, ялына-ялвара, кенәз Иванны Казандагы Ибраһим хан өстенә алып килгән. Ибраһим урынына менгән Илһам ханны Мөхәммәдәмин Мәскәү көче белән чәнчелдереп атты. Кырымнан соң Василий кенәзнең култык астына күчкән Габделлатыйфны да, ахыр чиктә татар үзе үк албасты һәм карачкы дип түбәнсетә торган Шаһгалине дә Мәскәү каласыннан илтеп утырттылар. Инде менә Хаҗитархандагы Хөсәен дә Казанның умырткасыз ханнары такырлатып бетергән юл буенча чапкан. Мөселман һәм тәхет ияләре була торып, нишләп кәфер урыс куенында сыену эзли болар? Нигә, нигә Казанның бер ханы да аннан ярдәм сорап, сыену эзләп килми? Нишләп боларның кыйблалары Мәккә ягында йә Истамбулда түгел, ниемә дип гаребтагы, котыптагы урыс кенәзенә табыналар икән? Мин-минлек, иман, горурлык атлы хисләр коргаксыган бит боларда, шунадыр, ахрысы, һичберсе кызганыч та түгел...

Читтән генә, гамьсез күзәтсә дә, Сөләйман солтан да дөрес чамалаган, кыш беткәндә яңа хәбәр килде.

— Мөхәммәтгәрәй Каф тау өстенә, андагы татарларны үз канаты астына җыю өчен яуга кузгалган, ди.

Монысы да суынып өлгермәде, кайнар күмер урынына көйдерердәй хәбәр:

— Нугай мирзалары Мамай белән Тиле Урак, Хаҗитархан тәхетенә утыртмаган өчен, Мөхәммәтгәрәй ханны суеп үтергәннәр!

— Мөселман дөньясының кайсы почмагында да бер үк төрле сырхау, — дип сыкрады Сөләйман. — Без бер-беребезнең башын ашаудан туктамабыз инде. Көферләргә ярдәм, көферләргә бәйрәм...

## 15

Сөләйман солтанның сүзен раслагандай, мең биш йөз дә егерме дүртенче елның язында Кырым ханының һәлакәте турындагы хәбәрне Василий кенәз түшәменә чаклы сикереп каршылады.

— Гәрәйләрнең иң гайрәтле ханын суеп үтергәннәр, әх, шул кирәк ана! Үзебез барып суярга өлгерә алмый калдык, менә шунысы җәл. Хәер, ана көчек кебек ияреп килгән Сәхибе исән бит. Ходайга мең шөкер, аны куенында иркәләп йөри торган абыйсын дөмектерделәр, хәзер Сәхибне яклап юлны бүлүче юк. Әйдә, Казанны талап булса да, Кырымга озатылган алтын-көмешләрне кире кайтарабыз. Барча рус калаларына чапкын җибәрегез. Бер атнадан Казан өстенә үч явына, яуга!..

Нижгар каласына житеп, андагы дружиналарны да өстәп кушкан чакта Василий кенәз кул астындагы сугышчылар саны йөз мең тирәсенә якынайган иде. Шушы чаклы көч туплаганнан соң да кенәз алайларын көтү урынына чыбыркылап алга куаларга һич тә ашыкмады. Сура елгасының Иделгә кушыла торган тамагына житкәч, бер ай чамасында биек яр өстенә имән белән нарат бүрәнәләрдән ныклы кирмән төзеп житкерделәр. Поплар һәм дьяклар чиләкләренә Иделдән тотырылган болганчык су белән бар почмакны «изгеләндереп вә рухландырып» чыкты, яңа каланы «даһи» кенәз хөрмәтенә Васильсурски дип атый башладылар. Василий үзе кирмән түрендәге сарай эченә кереп посты, алга таба яу башлыгы итеп Шаһгалине куйды.

Юньсез хәбәр канатлы кошлардан да житез һәм елгыррак оча, шымчылар аны көне-сәгатендә Казан каласына китереп иңдерделәр. Йөз меңлек зур чирү турында ишетүгә, Сәхибгәрәй зина юлында тотылган яшь килендәй дер калтырап төште.

— Әх, теге чакта акылдан ычкынган абыйның коткысына ник бирелдем икән? — дип, түбәсенә ут капкан йортның хуҗасы төсле, әле ишек, әле тәхет тарафына йөгерә-йөгерә, әрни башлады ул. — Менә хәзер мине яклап килергә сыңар иптәш тә юк. Бер ояга кушам, бер бәйләмгә төйним, дигән булып, абый бар татар дөньясын кырмыска оясы урынына чәчкәләп вә таркатып атты. Кырым тәхетенә кем менеп кунакласын гөманлап та булмый. Казанны якларга Хаҗитарханнныкылар, нугайлар да — берсе-бер килмәс инде.

Аптыраган үрдәк күлгә арты белән чумган дигәндәй, Сәхибгәрәй дә, үзен коткарып калырдай салам эзләп, Истанбулга ашыгыч чапкын куды.

— Менә сиңа алтын, менә якут, иллә мәгәр солтан галиҗәнапләренең хозурына үтеп керми калма. Сәхибгәрәй хан сиңа бигать китерә, Казан мәмләкәтен вилаять йә бәйлек итеп, үз каһанлыгын эченә кабул кыла күр, мәрхәмәтеннән ташлама, безне якла, зинһар, дип күз яшьләрең белән, каткат ялын. Йә үз канаты астына алып безне коткара ул, йә кол шикелле урыс чабатасы астына сузылып ятасы гына кала...

Урау юллар уза-уза, анда да әле Мәскәүдәге шымчылар аша гына Сәхигәрәй колагына Сөләйман солтанның җавап сүзе кайтты:

— Солтан галиҗәнапләре Мангуп каласыннан озатылган Искәндәр атлы илчесенә Мәскәү боярлары каршында шуны белдерергә әмер биргән. «Казан дистә еллар буе Мәскәү кенәзенең кул астында булды, Казан тәхетенә кемне хан итеп утыртуны да ул гына хәл итә. Солтан галиҗәнапләре Мәскәү кенәзе белән дуслык вә тигезлек саклый. Шушы сәбәпләр нәтиҗәсендә Сәхибгәрәйнең дә Казан-йортны төрек солтанына бүләк итәргә һичбер хокукы юк»...

Сәхибгәрәй шундый җавапны ишеткәннән соң, чәчен йолкый-йолкый, күккә ашардай булып теткәләнде, янды, котырынды.

— Мөхәммәтгәрәй абзыкаем белән өстенә барып җиңгәч, Мәскәү кенәзе Казан-йортны хали мәмләкәт дип таныды, аның эшләренә тыкшынудан бөтенләй баш тартты бит. Сөләйман солтан да моны биш бармагы кебек күптән белә, әмма нигә, ни сәбәпле безне мөстәкыйль йорт итеп танымый?! Аңа йөз меңлек олы чиру туплап, аны урыс өстенә җибәрү дә кыен түгел. Кырымны ул ничә мәртәбәләр шулай яклап калды. Ә нигә Казан ханлыгын якламый, нишләп безне үги итә сон ул!?.

Әле ярый, Мәскәү гаскәре ханлык үзәгенә үтеп керә алмый изалана. Чирмеш-мукшы олыслары аша узган чакта урыс сугышчыларына әллә нинди үләт чире йоккан, тегеләр елга-күл буйларын, сазлык өстен, күпер-сал урынына, тоташ мәет белән түшәгән, ди. Ходайның рәхмәтеме бу, әллә Сәхибгәрәйнең ялвару-өзгәләнүләре аның колагына барып ирешкәнме?

— Василий кенәз үзе, үләт чире эләгүдән шүрләп, кире Мәскәвенә кайтып киткән. Мәгәр, барыбер дә, чирле-хасталарны сау яугирләр белән алыштырырга фәрман тараткан ул. Яу сәфәре кирәк кадәр гаскәр туплануга янарачак икән.

Ни кылырга белмәгән Сәхибгәрәйгә бөтен дөнья тарайгандай булды, ул читлек эченә ябылган арыслан шикелле бәргәләнде, интекте дә, беркөн таңда туган иле тарафына яшерен илче куды.

— Мөхәммәт агамнан соң иң өлкәне булып калган Фатыйх абыем алдына барып тезлән. Ул минем урыныма үзенең бирәр малаенмы, яки аңа энекәш тиешле Мәхмүт абыйның улынмы наиб итеп җибәрсен. Мин хаҗ кылып, Ходай Тәгаләдән ярдәм вә ярлыкау сорарга чыгып китәм. Мин сәфәрдә чакта алар юллаган наиб минем исемемнән идарә итеп торыр.

Илче юлга чыгып киткән көннең иртәгәсендә үк Сәхибгәрәй Казан эчендәге аксөякләр арасына хәбәр таратты.

— Безнең ханыбыз хаҗга барырга әзерләнә, ә үзе югында Казан-йорт йөгәнен ул диванга йә Сәйди карачыбәккә түгел, ә Кырымнан килгән наиб-җигәненә[15] биреп калдырачак...

Тоташ ул эчендә байтак тилмертеп көттергәннән соң гына, илче Казанга унөч яшьлек малайны ияртеп кайтып керде. Сәхибгәрәй аны төсмерли дә сыман, тик аның кайсы җигән һәм нинди атлы булуын исенә төшерә алмый. Үзен арба үрәчәсенә менеп ат куганда эре тоткан малай, ярый әле, баш ватарга ара калдырмыйча ярып салды.

— Мин Сафагәрәй булам, гамужа[16] абыкаем, синең агаң Мәхмүтгәрәй углы. Без, атаем белән икәү, Бакчасарайдан Сарыхан[17] каласына чыгып качтык, шулай итеп кенә исән калдык. Төпчек абыең Сәгадәтгәрәй нугай мирзалары Муса белән Исмәгыйльне: «Сез мине Кырым тәхетенә кертеп утыртсагыз, мин сезне Хаҗитархан таждарлары итәм», — дип котыртып, Бакчасарай өстенә алып килгән. «Нәселдә мин синнән өлкәнрәк, Кырым тәхете, иң беренче чиратта, миңа тиеш», — дип Фатыйх гамуҗам аның юлына каршы баскан иде дә, Сәгадәтгәрәй туган агасының башын кыеп атты... — Сафагәрәй беркадәр тын алганнан соң гына өстәп куйды. — Синең хаҗ кылу ниятең чыннан да хак булса, Кырым тирәләрен урап узу хәер. Сәгадәт агайның кулы печән тырмасыдай бик тә озын, тешенә эләктерсә, аның сине дә алабута-билчән урынына харап итүе бар.

Боерган сәет, карачыбәк Сәйди, дистәләгән морза һәм сәрдәрләрне җыеп, Сәхибгәрәй үзенең хаҗ сәфәренә чыгачагы турында әйтеп салгач, билгеле ки, барчасы да таудан тәгәрәп төшкән буш мичкә тавышлары чыгарып тузындылар.

[15] Җигән — племянник.
[16] Гамужа — туган абый-агай, русча «дядя».
[17] Сарыхан — Харьков.

— Василий кенәз йөз илле меңлек яна чиру туплый, дигән хәбәрләр боз яңгыры сыман явып кына тора. Ул йөз илле мең урысның ханлык өстенә килеп авуы бар. Казан-йортны саклап калырдай көч-куәт юк. Урыс килсә, без Ибраһим хан вафатындагы сымак хурлыкка калачакбыз. Мондый хәвефле заманада ханның Казан-йортта булуы хәерлерәк. Хаҗга урысларны куып җибәргәннән соң сәфәр кылсаң, Ходай Тәгалә аны икеләтә һәм хәтта бишләтә савап шикелле кабул кылыр иде...

Тәхеттә мыекларын сыпыра-сыпыра тыңлап утырган Сәхибгәрәй барча гозерләрне илтифатсыз гына колаклары яныннан уздырды да, ил агаларыннан Сафагәрәй җигәненә тугры хезмәт турында антлар китерттергәч, Каф таулары ягына чыгып чапты. Казанныкылар колакларын ябалактай торгызып, көтә-көтә көтек булганчы шылт иткән авазны да тыңлап чиләнделәр, хаҗдагы хан галиҗәнапләре хакында сыңар гына җөмлә дә әйләнеп кайтмады. Дөрес, бик сирәк булса да, Кырым ягыннан сөенечле хәбәрләр үтеп керә, алар шуны ишетеп юаналар иде.

— Мәрхүм Мөхәммәтгәрәйнең энесе Сәгадәт хан урысларның Казан кул астындагы чирмеш илә мукшы җирләренә яу чапканы өчен Василий кенәздән алтмыш мең кадәре алтын тәңкә таләп иткән, түләмәсә, Мәскәүне янә яндырып китү белән усал янаган, ди.

Бәлки, асылда да, яу гаскәре белән юлга чыккандыр ул. Тәүге хәбәрдән соң атна-ун көн вакыт үтүгә, инде хәерсезе дә килеп иреште бит.

— Сәгадәтнең Сарыхан тирәсенә юнәлүен белгәч, Кырым җиренә нугайлылар чиръе бәреп кергән. Яубашлары — Муса белән Арыслан бәк, ул морзалар «Сәгадәт алдады, безне Хаҗитархан тәхетенә кертеп утырту хакына бармакка-бармак та сугып карамады», дип үпкә белдерә, ди. Алар Көбә үзәндәге барча татар авылларын талап чыккан. Сәгадәтгәрәй, бичара, үзенең чирүен нугай мирзаларына каршы борырга мәҗбүр булган...

## 16

Сараена кайтса, вәзирләре авызыннан аяз көнне уйнаклаган яшен төсле кыргый хәбәр ишетеп, Сөләйман солтан аптырашка калды.

— Сине Казан ханы Сәхибгәрәй галиҗәнапләре көтә. Урау юллар аша синең хозурыңа ул шәхсән үзе килеп җиткән. «Илчеләр аркылы йөрткән гамәл — иләктән иләккә күчергән он шикелле, яртысы юлда вакытта ук коелып бетә», дип ул синең кабул итүеңне көтеп тилмерәдер.

— Тәхет ташлап китү — кайнар кәләш түшәгеннән чыгып качкан пешмәс кияүгә тиңдер, меңә кәмит, — диде ул, кат-кат башын чайкап. — Кәләшенең нинди сырхау ягын эзләп тапты икән, тыңлап карыйк, әйдә, чакырыгыз.

Солтан хозурына кереп чүгәләгәч, Сәхибгәрәй барча чүпне инде мәрхүм булган абыйсы Мөхәммәтгәрәй өстенә генә түкте.

— Мине Василий кенәзгә каршы яуда катнаштырып, тик шул гына Мәскәү белән Казан арасындагы дуслык җебен өзде. Тиктомалдан зур яу белән барып, барча Мәскәү тирәсен талап киткән өчен Василий кенәз мине гафу кыла алмый. Үзем генә түгел, ә бар ханлыкның йөзе корымга буялды бит. Мин Казан тәхетен калдырып китүне хәерлерәк күрдем. Сафагәрәй бик яшь, әле малай гына, аның гөнаһы юк. Ул Казан тәхете өчен яңа кием төсле. Василий кенәзгә аны гаепләп таш ыргытырга һичбер нигез юктыр. Мин әле Казан тәхетен ташлап киткәнче үк, өч морзамны илче итеп юллап, Василий кенәзгә «син — минем өлкән агам, Казанда хан алыштырасыбыз килсә, синең рөхсәтеңне сорап барачакбыз, мондагы урыс сәүдәгәрләренә дә һичбер төсле җәбер булмаячак», дип дуслык тәкъдим иттем. Бу рәвешле күндәмлекне күргәч, Василий кенәз Казан ханлыгын тынычлыкта калдырыр, аның эшләренә тыкшынмас һәм яу чапмас, дип беләм.

— Ярый, бик хуп, мин дә шулай уйлап тынычланыйм, — дип җаваплады солтан, әмма бармакларына киелгән якут ташлы йөзекләрен кат-кат санап

чыккач, кабат кабынып киткән самавырдай, тагын сорау бирде. — Ә син үзең хәзер нинди дәрәҗә өмет итәсең соң?

— Кырым! Кырым ханлыгы! — дип күкерт шикелле шартлап купты качак. — Аның тәхете Сәгадәтгәрәйгә тиеш түгел иде! Өлкән агам Фатыйхны үтереп, ул үзен тоташ канга батырды. Бертуганына җәллад булган әрвах тәхетне яулап утыруга лаек түгел! Аны алып ат та Кырым тәхетенә мине кайтар.

Сөләйман солтан күзләрендә шайтан уты кабынгандай булды.

— Ә ни отам?

— Сафагәрәйне Казан тәхетенә мин чакырып утырттым, ул берчакта да минем сүземнән чыгачак фетнәче-гыйсъян түгел. Ул — миңа энекәш тиешле хан, шулай булгач, Казан-йорт та Кырым өчен энекәш саналачак. Кирәк икән, мин Сафагәрәйдән солтан галиҗәнапләренә тугрылык турында да бигать китерттерәм.

Сөләйман солтан озак сузып тормый вәзирләрен дәште.

— Фәрман калыплагыз. Кырым ханы соңгы ике елда миңа ясак юлламады, ә аның улы Дәүләтгәрәй, үз илендә туганнары суеп үтерүдән шүрләп, минем сарай кулагәсенә качып ята. Сәгадәтгәрәйне улың хаста, дигән сылтау белән Истанбулга чакырып китерегез дә Шайтан бугазына[18] илтеп ыргытыгыз. Сәгадәтгәрәй урынына Бакчасарайга кемне кайтарырга — анысын күз күрер дә, Ходай Тәгалә бер пышылдар әле. Ә хәзергә Кырым белән дивандагы Ширин, Аргыннар идарә итеп торса да, минем пайтәхетем һични югалтмастыр...

## 17

Казан иле — Сәхибгәрәй түгел, ул аргамакка атланып кына хәвеф-хафалардан чыгып кача алмый. Татарларның Сафагәрәйгә ант китерүен белеп алуга ук Шаһгали, Мәскәүдәге таш кирмән эченә атыла-бәрелә үтеп, Василий кенәз алдына баш орды.

— Сафа иң кулай очракта да тик Кырым шаһзадәсе генә була ала. Унөч яшьлек ул көчекнең Казан тәхетенә һичбер хокукы юк. Ул — килмешәк! Мин — Казанның тулы хокуклы ханы! Казан миңа тиеш!

Василий кенәзнең шаккатудан ике күзе маңгаена менде.

«Әттәгенәсе! — дип уңлы-суллы башын чайкады ул. — Моннан алты ел элек Казанга илтеп утырткан чагында син карачкыга да нәкъ унөч яшь иде, анысы гына җитешсезлек булса. Казанлылар өчен, Кырым шаһзадәсе шикелле үк, Касыймныкылар да — чын килмешәк. Казанга кем илтеп утыртканын валлаһидыр, инде оныткан бу. Ул — тулы хокуклы хан, имеш! Кемнең итек табанын яларга тиешлеген дә искә алып тормый, адәм тәганәсе!»

— Миңа гаскәр күндер, Казаныма кабат кайтарып куй? — дип Шаһгали аның җилән итәкләрен үбеп ялвара башлагач кына, Василий кенәз, ниһаять, телгә килде.

— Минем рөхсәтемнән башка Казан тәхетенә килмешәк Сафаны утыртып куюларына барыбер дә күнәсем юк иде. Ярар, гаскәр бирәм. Идел буйлап көймәләрдә агачак ермак чирүне син йөгәнләп китәрсең. Ә яр өстеннән барачак атлы гаскәргә кенәз Иван Палецкийны башлык итеп куям.

Шаһгали ишкәкчеләрне юлда камчысын ятагандай болгый-болгый куды. Июль башында ук Чулман белән Идел кушылган урыннан ерак урнашмаган Кунаклар утравына килеп туктадылар. Шаһгали көне-сәгате белән Казан тарафына илче чаптарлады.

— Казан миңа тиеш, монда мин генә хан! Казан тәхетенә һичбер хокукың юк, Кырымыңа олак!

Казаннан бик өметсез генә җавап кайтты.

— Яу белән килгәнсең бит, әйдә, орыш. Кайсы як җиңүгә ирешер, шул тәхеттә калыр.

[18] Шайтан бугазы — Истанбулдагы иң коточкыч зиндан.

Шаһгали чабатадай ямьсез-иләмсез аякларын тибеп сүгенергә мәҗбүр булды.

— Мин тәхеттә утырам, димәк, җинәчәкмен, дип мыскыллый бит бу мине, аһ, селәгәй! Ярар, күрсәтермен мин сина ничек җингәннәрен! Булат Ширин белән Чанышларга хәбәр салыйм әле!

Шул төндә үк Казан ягына яшерен чапкын очты. Икенче төн керүгә, Казан кирмәненең Казансу елгасына караган агач диварына ялкын элдерделәр. «Казан яна, анда тәшвиш купты, кичекмәстән яуга ябырыл син!» — дигән хәбәр житкерсәләр дә, Шаһгали, утраудан чыгып, яр өстенә сынар аягын да баса алмады. Көймәләрне кайсы якка гына куып карамасын, ике-өч дилбегә ара калуга ук, ярдагы сакчылар руслар өстенә боз янгыры төсле уклар яудыралар. Бер-ике урында баскыннар ат арбасын калкан итеп якынайган иде, татар яугирләре аларын да арба-көймәләре белән бергә су төбенә әйләндереп атты.

Көндезләрен яр өстенә тоташ көбә кигән менәр-менәр русларны да чыгарып карадылар, мондый ермак алайлар да баш түбәсенә сугылган песи баласы кебек еламсырап кайтты.

— Казанлылар яр буендагы барча иген басуларын яндырып бетергәннәр. Уч төбенә кырып жыярлык та ризык табып булмый.

Тагын ике атна буе Палецкий жайдакларын көткән арада йөзәрләгән ирләр эч китүдән йә ачлыктан интегеп суга сикерделәр, тик берсе дә яр читенә йөзеп житә алмады. Акылларын жуеп шашкан ирләрнең тагын йөзәрләбе ак-караны күрми ярга томырылды, алары да куак-камыш арасыннан очып чыккан укка тортелеп ауды. Мондый бәлаләре генә житмәгән, нинди дер хәерсезе тагын утлы кисәү сыман хәвеф жибәргән бит.

— Казанлылар Палецкий жайдакларын пыран-заран китереп ташлаганнар! Һаман ярдәм көтсәк, шушы утрау эчендә без дә ач күселәр төсле кырылып бетәчәкбез!

Шаһгали үзе һәм ул камчылап куалаган меңбаш вә йөзбашлар никадәрле генә ис-акылга килергә чакырып карамасын, рус сугышчылары бүре күреп котырган үгез көтүе урынына көймә-баркасларга ябырылды. Әле көймәдә урын эләктергәнче үк берсен-берсе кылыч белән кыеп суешалар иде, яр читенә житкәч, татар яугирләре кылычыннан йөзәрләп кенә ауды. Ахыр чиктә барыбер дә кабат утрау эченә кайтып бикләнделәр.

Шул читлектә егерме көн буе газап чиккәннән соң гына, ниһаять, сөенечле хәбәр ишеттеләр.

— Палецкий Казаннан егерме чакрымдагы Зөя елгасы тамагына житкән. Иделнең унъяк ярына жәелеп яткан мукшы вә чирмешләр, урыс баскыннары талауга түзмичә фетнә күтәреп, Палецкийның юлын бүлгән икән.

Шаһгали балагына котырган эт ябышкан төсле кабаланып-янып чакырса да, Зөя тамагындагы түбәтәйдәй түм-түгәрәк утрауга кереп поскан Палецкий Казан ягына таба август уртасында гына юлга чыкты. Казансу буенда Шаһгалинең калдык гаскәре белән бергә кушылдылар. Кирмәнне чолгап алуга ук баскыннар ягыннан яллы Ливон алманнары корган туплар кала өстенә, февраль бураннары уйнатып, ядрә артыннан ядрә очырдылар. Казанлыларның маһир тупчыларын катыйл затлар төнлә суеп чыккан, кирмән, теле киселгән бичара шикелле, гел жавапсыз торды. Моны тәшвиш кубу һәм хәтта тезгә чүгү, дип аңладылар, ахры, урыс баскыннары диварларга таба һөжүмгә күтәрелде. Әмма диварларга тәүге баскычларын сөяп куярга да өлгерә алмадылар, кирмән капкалары ачылды да, аннан карачыбәк Аталык ияр ткән жайдаклар ташкыны бәреп чыкты. Алар дошман белән орыша башлауга ук, арткы яктан Арча яланында калдырылган Көчлек Отуч баскыннарның сыртына ябырылды. Ике яктан да яу ирләре йөзләп-меңләп ава, ләкин казанлылар сафы һич кимеми, жепшек карда тәгәрәткән олы төргәк сыман, аларга кирмән эченнән йә Казансу буеннан килгән сугышчылар гел өсталеп тора. Түземлеген жуйган һәм хафага төшкән кенәз Палецкий кирмән тарафына махсус чапкын куды.

— Яуны туктатыгыз, без китәбез. Мәскәү ягы Сафагәрәйне тулы хокуклы ханга санап, баш иярга мәҗбүр...

Мәскәү эченә кайтып керүгә үк Василий кенәз җибәргән Палецкийны имән бүкән өстенә озаттырды.

— Бер Шаһгали генә чын дөресен әйтте. Мең төрле мөмкинлеген була торып та, син үз башыңны саклап калу өчен Зөя утравына кереп бикләнгәнсең, яуны соңарткансың. Син астыңа җибәреп, посып яткан чакта казанлылар Шаһгали яндырткан кирмән диварларын яңадан бастырганнар һәм олы гаскәр туплап өлгергәннәр. Шаһгали яллаган катыйллар Казан тупчыларын суеп чыккач, син атналар һәм айлар буена аларның кирмәнен бертуктамый утка тота ала идең, югыйсә. Син шушы уңай форсатны да кулдан ычкындырып, минем сугышчыларымны яуга ташлагансың, меңәрләгән колымны үтерткәнсең. Аннан да яманы — син Сафагәрәйне хан дип таныгансың, аны минем белән бер үк биеклеккә мендереп бастыргансың. Сиңа бер кеше дә андый хокук төяп җибәрмәде, син — сатлыкҗан! Андый җибәргәнне, әнә, имән бүкән өстенә! Бөтен Мәскәү боярлары каршында башын чаптырырга!..

Берникадәр түл-мая җыюга ук Мәскәү калалары буенча яңа әмер:

— Казан ханлыгы өстенә яуга кузгалабыз. Элеккеге хурлык табын юып кайту тиеш...

Шымчы итеп озатылган ирләр алып кайткан һәр яңалык казанлылар күңелендә тирән шом уятты.

— Василий кенәз әләме астына тупланган җайдакларның саны гына да алтмыш меңне үтеп киткән инде. Көймәләргә утыртып озатылачак ирләрнең дә саны шул чамада. Казан-йортның берчакта да бу кадәрле көчне күргәне юк.

Егерме яшен дә тутырмаган Сафагәрәй үзе дә эченә ут йоткандай пошаманга калды. Ә хәбәрләр язгы боз ташкыны төсле, һич тә туктап тормый.

— Олуг кенәз Бельский, Глинский, Горбатов шикелле мәшһүр биш боярны гаскәр башлыклары итеп билгеләгән. Касыйм җайдаклары белән Шаһгали дә шулар янәшәсенә килеп баскан. Җәяүлеләр Идел, Чулман, Нократ елгалары буйлап, көймәләргә утырып юлга чыккан. Җайдаклар чирүе аерым гына атлый, анысы Нижгар каласыннан кузгалырга тора.

Сафагәрәй әүвәл хатынын, олауга утыртып, Агыйдел белән Ык аръягына сузылган Нугай даласына озаттырды.

— Каенатам Мамай ханга сүзен-сүзгә, җеген-җеккә җиткереп тапшыра күр, — дип ялынды ул аңа. — Мине тәхеттән кусалар, Казан гына түгел, син дә, уртак улыбыз да, хәтта Нугай иле үзе дә яклаучысыз кала. Үз юлындагы төп бүрәнә һәм төп капканы җимерсә, кибәргә эленгән кер шикелле, җепсәләргә генә эләгеп калган койма вә киртәләр, усал җилне көтеп тормастан, үзләреннән-үзләре үк череп-какшап ава. Казан — Мәскәү өчен менә шул төп бүрәнә һәм төп капка хәлендә ул. Башын элмәккә үзе китереп тыгасы килмәсә, атаң миңа ярдәмгә олы гаскәр кусын. Безне бергәлек һәм бердәмлек кенә урыс коллыгыннан коткарып калачактыр. Мамай каенатам берүк йокламасын, улыбызны, сине, мине яклап, янәшәмә бассын.

Сафагәрәй аннары карачыбәк Аталыкны янына чакырттырды.

— Мин — Кырым шаһзадәсе, иң беренче нәүбәттә, ярдәмне дә аннан көтәргә, аларны чакырырга тиешмендер инде. Тик Бакчасарай безнең Гәрәйләр нәселен көндәш иткән Шириннәр, Аргыннар кулында, берни эшли алмыйм, мин канатлары каерылган кыр казыдай көчсез. Хаҗитархандагы морзаларга да чакыру ташлап булмый. Аңа гамуҗа агам Мөхәммәтгәрәй кереп, аларның Хөсәен ханын куды, аннан ары «мин Хаҗитарханны Кырымга кушып куям», дигән булып, тәхетләренә беркемне дә якын җибәрмәде. Хәзер анда Хөсәеннең улы Дәрвишгали белән аның агасы Касыйм шаһзадәләр үзара бугазлашып һәм кан коешып ята, безнең кайгылар юк. Шуңа күрә сиңа гозерләнәм, абруең зур,

Көпшәксу, Сура буендагы чирмешләрне чакыр. Ханлыктагы бәп-бәләкәй генә көчләрне дә каз-үрдәкләр койган каурый төсле җыеп бәйләмәсәк, илне саклап калу, бәлеш-коймак майлау ләззәтләрен кичерү бик икеле.

Берәр атнадан соң ишетелгән җавап хан иненә канат бәйләгәндәй, сөенечле булды.

— Каенатаң Мамай хан синең карамакка утыз мең кадәре җайдакларын куган. Чирмешләр дә Сура яры буйлап ике төмән җайдак туплап бастырганнар. Казан астындагы олыслардан җыйган яугирләрне кушсаң, хан галиҗәнапләренең чирүе сиксән меңнән арта...

Арысланнар кебек котырып һәм ярсып орышсалар да, татар яугирләре туп утыннан меңәрләп кенә ауды. Йөзгә-йөз килеп, кылыч-сөңге белән орыш барышында да, чалгы астына эләккән кыяк үлән төсле, күмәк кырылдылар. Карачыбәк Аталык бәк үзе, аның янәшәсендә дистәләгән морза кулларына кылыч тоткан һәм аягүрә баскан көе шәһид булып китте. Ике көн орыштан соң алайларны кирмән эченә туплап санасалар, алтмыш мең чамасы яугирләрне таба алмадылар. Иң яманы — Сафагәрәй Арча каласына чыгып качкан, аның әйләнәсендәге тәнсакчылар бер мең кадәре дә юк ди. Моны белгәч, гаскәр янә хафага калган иде.

Ләкин Казан гына түгел, Мәскәү ягы да бик күп югалткандыр, өстәвенә, чирмеш җайдаклары, арткы яклап, аларның олаулары белән атларын да талап тора икән, өченче көн таңында кирмән эченә илче юллаганнар.

— Солых төзү өчен безнең хозурыбызга ил агаларыгызны туплап җибәрегез, ә без һөҗүмне әлегә туктатабыз.

Тагай, Тәүкил, Ибраһим шикелле илче итеп сайланган морзалар Мәскәү боярлары каршына барып баскач, барча Казан исеменнән гафу үтенгәннәр. Илчеләрнең язгы кар урынына мәлҗерәвен шәйләп, боярлар күпчелек морзаларны аманат урынына алып калганнар да, бер Тагай бәкне генә кирмән эченә кайтарып җибәргәннәр.

— Без Шаһгалине бирегә алып килдек. Аны тәхеткә утыртмисез икән, без һөҗүмне кабаттан башларга мәҗбүр булачакбыз.

Казандагы барча морзаларны хан сарае эченә чакырып тупладылар. Мәскәү ягы куйган катгый шартны Тагай морза кат-кат игълан итте. Морзаларның яңгыр астында шәбәргән чебеш төсле куырылып торуларын күргәч, кулына көпшә итеп уралган зур кәгазьне тотып, Гәүһәршад бикә белән Сәед атлы углан алга чыгып басты. Морзалар өчен Сәед углан зур аксөяк түгел, кайвакытта түбәнбаш, кайчагында Казан кирмәнендә сак башлыгы булып йөргән гади сәрдәр генә. Ләкин аның хакында «ул киявгә чыкмый калган Гәүһәршадның сөяркәсе икән», дигән сүзләр йөри, менә монысы теләсә кемне аның белән санлашырга мәҗбүр итә инде. Чөнки Гәүһәршад — унҗиде ел чамасы Казан тәхетендә утырган Мөхәммәдәмин ханның сеңлесе һәм, җитмәсә, шөһрәтле Ибраһим ханның төпчек кызы да бит әле. Гәүһәршадның исемен ишетүгә үк морзаларның күпчелеге ханлык вакытында бер тапкыр да Мәскәү алдында тез чүкмәгән Ибраһим ханны һәм түшәктә авыр сырхаулардан газапланып киткән Мөхәммәтәминне олылап искә ала, ә әлеге бикәнең үзен күрү теләсә кайсы иргә ләззәтләнү һәм соклану тойгылары гына китерә иде. Күз тимәсен, бишенче дистәсен куалап маташса да, аның йөзендә һичбер төрле җыерчык тоемланмый, муены — озын, шома. Биле бер куш учка сыеп бетәр кебек. Буе ирләрнеке төсле озын, зифа. Керфек-кашларына сөрмә тартырга, бит очларына иннек тидерергә һич онытмый. Ул — абыйсы Мөхәммәдәмин белән бергә Мәскәү сараенда, урыс кенәзләренең балалары белән уйнап үскән кеше. Абыйсы хан булып утырган вакытта бер генә диван утырышыннан, мәҗлесләрдән дә калмый торган иде, зиһенне күп җыйган, шунадыр, ахрысы, үзен эре, бик көрпәле тота.

Менә, хәзер дә ул морзаларга бер мәртәбә күз сирпеп алуга ук, үзен умарталагы ана корттай тоеп, бөереннән чыккан тавыш белән тезеп китте.

— Казан халкының Мәскәү кенәзенең рөхсәтеннән башка тәхет язмышын хәл итәргә хокуклары чикле. Василий кенәз бер мәртәбә китереп утырткан Шаһгалине куып, жамаягыннан зур сөякне тартып алган этне котырткандай, без Мәскәүне гел күз чалымына да китерми яшәдек бит. Янәмәсе, Сәхибгәрәй белән аның артыннан ук Сафагәрәйне мендереп утырттык та, моннан ары безне Кырым яклый, Кырым саклый, имеш. Ә чынлыкта, шушы ике ханны чакырганнан бирле Казан-йортның Мәскәү белән яусыз торганы юк. Менәрләгән корбан югалтабыз, Казан тоташ ут вә кан эчендә. Гәрчә Шаһгали ил тәхетендә утырган заманада Мәскәү тарафыннан ым да, шым да ишеткәнебез булмады бит безнең. Шаһгали олуг кенәзгә карата бик тә мохлис, бик тә ихлас иде. Ул Казан халкына да зарар китермәде. Казан урамнары буйлап тоташ кан елгасы агулардан туйдык. Олуг кенәз безнең өскә һаман-һаман гаскәр генә озаттырып торса, ханлыкта сыңар ир дә яшәп калмавы бар. Шуна күрә, әйдә, олуг кенәзгә дә, Арчада посып яткан Сафагәрәйгә дә хатлар юллыйк. Олуг кенәз безгә кабат Шаһгалине жибәрсен. Ә Сафагәрәйгә «халык үзе сине хан итеп танудан йөз чөерде», диик.

Болар карарны инде кәгазьгә үк теркәп чыкканнар, Сәед углан шуны төргәгенә карап тагын игълан итте. Әнкәләренең авызына текәлгән каз бәбкәләре шикелле сүзсез тору нык рәнжетте бугай, Булат Ширин, аталы-уллы Исмәгыйль белән Камай, Тагай морзалар капылт тавыш бирде.

— Юк, Шаһгали карачкыны Казан халкы теге чакта да кабул итә алмады. Кабат чакырып китерсәк, аның үзен куган морзалардан үч алуы мөмкин. Ул вакытта татар жанын татар кыя булып чыга. Мондый монафыйк адымга форсат куймыйк. Шаһгалинең унбиш яшьлек Жангали атлы энекәше дә бар бит. Ул Казан каршында бер гөнаһсыз инсан, әйдә, шуны чакырып китерик без...

Сафагәрәй каенатасы Мамай хан ышыгына, Нугай даласына чыгып качты. Казан тәхетенә сырхаулап яткан Мәскәү кенәзе алдында ант сулары эчкән Жангалине китереп утырттылар. «Ярхәмкә Аллаһ» яисә «Аллаһ әппәр», дип сакал сыпыручы гына күренмәде.

## 18

Баязит бакчасында Әнвәр атлы яна хадим пәйда булуга ук, жарияләрнен барчасы да әүвәле «аһ» итте. Егет күл камышы кебек зифа буйлы, чибәр, борын астында мыек төртеп кенә килә. Кыз балаларныкыдай гажәеп тә озын керфекләре арасыннан текәлгән күзләре төнге күк йөзе шикелле кап-кара һәм төпсез, елмайганда алар таң йолдызы булып кабыналар, ләкин егет кышкы кояш урынына бик-бик сирәк кенә елмая шул. Күбесенчә аның йөзе төнбоеклы күл өстедәй тыныч, ә күзләре сүнгән учактагы күмер төсле салкын. Ятим бала кебек һәрвакытта боек йөрүенең серен тиз ачтылар.

— Әнвәр элек шыгыйлар каһаны Исмәгыйль шаһтагы бер вәзирнең улы булган икән. Исмәгыйль шаһ үзбәк ханы Әбелхәергә каршы яуда йөргән чакта Әнвәрнең әтисе тәхеткә шаһның улы Такмасыпны утыртмакчы булган. Бу мәкер ачылгач, Исмәгыйль шаһ вәзиренең башын чаптырган, ә Әнвәрне безнең солтанга кол итеп озаттырган. Әнвәр мондагы харәм сараеннан беркая да чыгып кача алмый, һәрдаим күз уңында, шулай булгач, Исмәгыйль шаһның жаны гомерлеккә тыныч.

— Яманы шул: коллыкка озатканчы, Исмәгыйль шаһ Әнвәрне төбе-тамыры белән сөннәтләткән икән. Варшау каласыннан китерелгән ләһ кызы ябышып караган, ди. Әнвәр, бичара, әрнеп елаудан кала һичбер гамәл кыла алмаган шул.

Бакча эченә йөрергә чыккан чакта Хүррәм дә егеткә күз аткалап узды. Әнвәр асылда да дәрте ташып торган һәрбер хатын-кызны гашыйк иттерердәй төзек, чибәр, тик йөзе генә, менә, көл суы сипкәндәй, саргылт, боек, монсу. Ир булып та өлгермәс борын күргән михнәтләре эчен-жанын ут шикелле

талап торгангадыр, ул ялгыз калып, тын почмакта утыруны мәслихәтрәк күрә. Кулында йә Коръән Кәрим сүрәләре, йә каләм дә кәгазь.

— Син берәрсенә мәктүб, ягъни гыйшык хатлары язасынмы әллә? — дип бервакыт сүз кушкач, ул Хүррәмгә кызарынып кына җавап бирде.

— Мин робагыйлар тырмалыйм. Арада тәрлесе бар. Тик күпме язсам да, Гомәр Хәйәмнең хәтта өйрәнчек шигырьләренә дә якыная алмыйм.

Хүррәм учак шикелле гөлт итеп кабынуын сизмичә дә калды.

— Ул Хәйәм дигәнең синең элеккеге мөгаллимдер инде?

— Гомәр Хәйәм тәнендә җаны бар һәрбер инсан өчен иң олы мөгаллим, иң танылган шагыйрь. Миңа якын китапны баштан ахырына чаклы ятлап чыктым, Гомәр Хәйәмгә якыная алган чәчәнне таба алганым юк.

— Син аның китапларын миңа да бир әле? Мин дә аның робагыйларын укып багыйм, — дип ялынгач, Әнвәр икенче кичтә үк чыбылдык аша Хүррәмгә кулдан язылган олы төргәк сузды.

Хүррәм алар эченә кереп чумды да бөтенләй телсез калды. Йә Ходаем, җир йөзендә шушындый да камил, шушындый да моңлы юллар була икән!

Кем үстергән сине, кай багъда иккән?
Йөзеңне күрсә, ай тотыла нилектән?!
Бизәнә туйга дип җирдә гүзәлләр,
Ә син үзең бизәк туйларга, иркәм!

Кара, менә тагын берсе:

Йөзең көләч, сөйкемле, якты, нурлы,
Буең сәрви агачы төсле тугры.
Төшенмим, тик нигә биргән Ходаем
Кире алмак өчен синдәй матурны?..

Менә, күңелендәге мәхәббәт хисләрен нинди матур сүзләр белән аңлаткан бит! Ә Хүррәм ничәмә-ничә айлар һәм еллар буена Сөләйман солтанны бер үзенә генә гашыйк иттерә алмый газап чигә. Солтанга да менә шушыларга охшаш шигъри юллар багышларга, аның күңелендә дә гыйшык учагы кабызырга кирәк! Сөләйман — шәрык дөньясы хакиме, аның күңеленә шәрык ачкычы яратмыйча булмас.

Атна буе сузылган йокысыз төннәрдән соң ирен читләре белән елмаеп канәгатьләнердәй берничә юл туды.

Җир өстеннән әрфиядәй болыт булып,
Салмак кына атлап килгән чакларыңда,
Башын иеп, сокланып вә мөкиббән булып,
Каршылый бит сине бөтен җиһан.
Барча кошлар мин уйлаган җырны суза,
Җиһандагы бердәнбер мәхәббәт иясем,
Җир хуҗасы, бар байлыгым, юанычым,
Ул син генә, Сөләйманым, бөек солтан!

Аннары Хүррәм бакчага шыпырт кына Әнвәрне дәштерде. Көмеш чатыр күләгәсендә аптыраган егет пәйда булгач, аны гайреләрдән-гайре бүләк белән тәмам шаккатырды.

— Чамалыйм һәм алдан ук белеп торам, мин тудырган юллар син мөкиббән булган Гомәр Хәйәм робагыйларының олтанына да яраксыз әфтияктер инде. Әмма мин аларны чын күңелдән яздым, тыңлап кара әле.

Әнвәр шигырь тыңлаудан бигрәк Хүррәмнең үзен сокланып күзәтте. Солтанның

бу хатынын Кара диңгез аръягыннан, Карпат тауларыннан китерелгән, диләр. Чит кавем генә түгел, хәтта кәфер диненнәге кеше булган. Ләкин менә динен дә алыштырган, төрек, гарәп телләрен дә су урынына эчә, үз-үзен тотышына кадәр тулаем мөселманча. Сөләйманга гыйшык уты шулай үзгәрткәнме, әллә кабыгын салган елан шикелле үк бер соранмы? Тфү-тфү, гөнаһ уйлар өчен гафу кичер, Ходам, моның ише матур юлларны икейөзле кеше яза алмас.

— Камиллекнең чиге юктыр, хатын әфәнди, — дип Әнвәр бик тыенкы гына бәя бирде. — «Барча кошлар», дигән сүзләрне «яшь былбыллар», дип алыштырып була. «Салмак кына атлап килү»не «ил башлыгы булып атлауларың», дигән гыйбарә белән янарту да солтан галиҗәнапләре өчен шөһрәт һәм мәртәбә кебек яңгырар сыман. Ин мөһиме һәм иң кыйммәте — барча шигарьләрегез чын йөрәктән чишмә булып аккан, күз яшьләре кеби эчкерсездер. Солтан галиҗәнапләре өчен аларның кыйммәте дә шунда. Сер булса да, әйтим, солтан галиҗәнапләре үзе дә робагыйлар белән женләнә, җырулар чыгара бит. Без аларның байтагын бергә камилләттек. Сезнең шигырьләрдән дә ул, һичбер шиксез, үтә мәмнүн калыр...

Ә Сөләйман бу минутта бөтенләй дә чит-ят ләззәт белән мәшгуль, ул мунчада истирәхәт кичереп, ак болытлар өстендә йөзә иде. Баш хадиме Якуб аны иртән иртүк кереп сөендерде:

— Кырымдагы яна Сәгадәтгәрәй хан сез галиҗәнапләр хозурына шималь боланнары кеби ике кыз җибәргән. Ул аларны Мәскәү каласына ясаган яудан тотып кайткан. Икесе дә тай шикелле таза вә хөрмә җимешедәй пешкән чибәр марҗа.

Якуб таң атканда ук болай дәртләндереп куйгач, Сөләйман мунчаны да иртә әзерләтте. Зәнҗи җансакчылар бөркәвечле зур бишектә күтәреп илткән чакта мәрмәр залның һавасы гына түгел, ташлары да тәнне өтеп алырдай булып кызган иде инде. Тамбурчылар белән кубызчылар залның сул ягындагы шәрык капкасы артына кереп утырганнар, уң канаттагы ярымтүгәрәк сәхнә мәйданында билләренә бияләй чаклы гына ефәк япма аскан биюче кызлар еландай бөтерелә. Сөләйман кайнар мичкәләр уртасындагы кәнәфигә җайлап урнашуга, зал эченә ярымшәрә киенгән ун җария кыр казлары кебек тезелешеп керде. Билләренә нәкъ биюче кызларныкы шикелле үк ефәк япмалар асылган, нәни карбыз кебек имиләре адым саен як-якларга уйнап ымсындыра. Җарияләрнең кайсысы ап-ак тәнле, аккош кебек чиста. Икенчеләр мичкә кертеп ыслагандай куе-кызгылт, хәтта конгырт төстә. Боларының имиләре пешкән алма сыман кечкенәрәк бугай, тәннәре дә ябык, әмма хәрәкәтләре җәйрән кебек сизгер, уяу, дәртле. Җарияләр, кулларына зәйтүн мае, сабын, мунчала, тастымаллар тоткан. Аяк атлаганда ефәк япмалары читтән ачыла да гүзәллекне, рәхәтлекне мактый.

Тамбурчылар көйне янартуга, биюче кызлар сәхнәнең әле бер башына, әле икенче ягына килеп сикерә башлады. Сөләйман чамалап утырды: кайсы — җанвар, кайсы сунарчылар булып уйный инде болар. Әнә берсе кулларын җәядән ук аткан сыман уйнаклата, икенчеләр шуннан яраланган киек булып ауный. Идәндә тәгәрәгәндә ефәк япмалары бөтенләй юкка чыга, алар аякларын аерып уйнатканда ухылдамый гына утыру да читен. Шуны сизгән сыман, җария кызлар аның кызган тәненә килеп орынды. Аккош канатыдай йомшак куллар аның бөтен гәүдәсе буйлап йөзәргә тотынгач, рәхәтлеккә түзә алмыйча, Сөләйман күзләрен үк йомып онытылды.

— Солтаным, бөек солтаныбыз! — дигән пышылдау авазына керфекләрен ачкач, Сөләйман яу кырына чыккандай әсәренде.

Янда гына Якуб аның тарафына бөгелеп баскан, ияге белән ишек ягына ымлый. Ә анда... зәйтүн агачыдай озын буйлы яшь-яшь ике сылу. Гәүдәгә ир-егетләр кебек эре һәм гаярьләр. Беләкләре һәм ботлары елкы атныкы шикелле шома, юан, таза. Имчәкләре шултикле дә тулган, алар күкрәк өстенә генә сыймыйча, кавын сыман, ике якка тырпаешып тора. Кендек астындагы байлыкларын чамаларлык түгел, ефәк япмалары каплый төшкән.

— Сәгадәтгәрәй ханның бүләк маржалары шушы инде, — дип пышылдады янә янда торган Якуб.

— Әйе, әһем, — дип телгә килгән булды солтан, ә үзе төкерекләрен йотып җибәрә алмыйча һәм хыялларда йөзеп газапланды.

Аһ, әнә тегесе, имиләре бил өстенә җитә язганы бигрәк таза. Ә капчык шикелле тулган ул ботлары! Бәлки, алар мунча ташы шикелле кап-кайнардыр?..

Сөләйман янә күзләрен йомып, ләззәт дулкыннары кочагына чумарга өлгермәде, мунча ишеге дөмбердәп ачылды да залга чәчләре тузгыган Хүррәм чәчрәп керде. Тупсаны узуга ук яшен яшьнәгән тавышлар чыгарып чәрелдәргә дә тотынды.

— Солтаным хозурына мунчага кертмичә, нишләп юлыма аркылы төшә бу җыен алабай җансакчылар? Мин солтанның «нәзакәт хатын» исемен йөртүче яраткан хатыны түгелмен дә, мина үз баламның сөекле атасы янына керүләр дә олы киртәмени?

Югалып калудан, Сөләйман әле баш хадиме, әле ишек тарафына карарга мәҗбүр булды. Моны шәйләп алгач, Хүррәм йөзенә яна битлек киде.

— Ә мин сөекле солтаныма багышлап, төннәр буе керфек тә какмыйча, кайнар робагыйлар язган булам. Ә сөекле солтаным аларны ишетергә дә теләми, минем хәтта аның янына керерлек тә хокукым юк.

Ниһаять, Сөләйман да телгә килде.

— Нинди робагый ул тагын? Әллә мина багышлаган үз шигырьләренме?

— Әйе, үземнең, үземнең шигырьләрем! Сиңа багышлап, сине күккә чөеп, төннәр буе яздым. Син генә мине тыңларга теләмисең. Ә үзенне шигырь ярата, хәтта үзе дә шигырь яза, дигән булалар бит.

Хүррәмнең күзләреннән яшь саркып чыкты. Сөләйман үзе дә сизмиаңламыйча урыныннан сикереп купты да сөяркәсен кочагына алды.

— Мина багышланган булса, укы, укы, җаным.

Хүррәм бер минутка гына аның иңсәсенә башын салып үксегәндәй итте, аннары юлбарыс җитезлеге белән ыргылып, маржа кызларының берсенә барып ябышты. Үзе ярсый-ярсый аның беләкләрен югары күтәрә, ботларын як-якка каергалый, үзе зәңгәрле-яшелле тавыш белән чәрелдәвен белә.

— Сине Сәгадәтгәрәй хан ике маржа бүләк итеп сөендермәкче булдымы? Шушыларның савым сыерыныкыдай имчәкләренә, ботларына карап шаккаттыңмы? Менә кара, соклан инде хәзер. Әнә, күрәсенме, болар култык асларын, гаурәт җирләрен дә кыра белмиләр бит. Харәм сараена бет иләтәкәнче, мондый сыерларны читкә олактыру күпкә хәерлерәк. Үз кадеренне үзең бел инде син, бөек солтанкаем?!.

Яңа җарияләр мунча эченнән чыгып югалуга, Хүррәм җиң очыннан тыгыз итеп төргән кәгазь тартып алды һәм шул минутта ук назлы мәкамь белән укырга да тотынды.

Күк йөзендә бер кояш бар, тик ул ерак,
Ул сәламли генә булыр иртән, һәр таң.
Тик бер кояш кына мине назлый булыр,
ТәнНәремә, күкрәгемә тиеп алдан,
Җир өстендәге кояшым син, бөек солтан.

Икенче минутта Сөләйман инде онытылып-шашып Хүррәмнең яңакларын, кул очларын үбә иде һәм, әлбәттә, искиткеч шат иде.

## 19

Инде көн уртасы җиткәндә, иренеп-ялкауланып кына күз ачсалар, тупса арьягында Мөнәвир атлы вәзир көтеп тора.

— Безгә буйсынган Мисыр вилаятендә тагын фетнә купкан. Килек белән

Караман атлы бәйлекләрдәге шыгыйлар сөнни мәзһәбләрнең мәчетләрен, дәрвишләрнең төрбәләрен җимереп бетергәннәр, безгә салым җыеп озатудан бөтенләй баш тартканнар. Шыгыйлар үз солтаннарын сайлап куярга һәм синең кул астыннан чыгарга җыена. Алар синең атаң Сәлим солтан утыртып калдырган Хәйретдин пашага да буйсынудан туктаганнар инде.

— Минем яныма хәзер үк Ибраһимны чакыр! — дип үкерде Сөләйман, бәрхет юрганнарын тибеп ачуга ук. Вәзир күз алдыннан чыгып югалуга, янә котырынды.

— Мин ул туктаусыз фетнә куптарырга һәвәс Мисырга өч-дүрт ай элек кенә Гаязетдин атлы пашаны җибәреп карадым ла инде. Нишләп шул бер вилаятьне дә тезгә чүктереп кайта алмыды соң ул җебегән? Шыгыйлар иманга килүне белмәгәч, ул кавемне канга батырып бетерсен иде, миңа димәгәе!

— Тукта, кызмале син, бөек солтанкаем, — дип курка-курка гына аны бүлде Хүррәм. — Монда Ибраһимның да көче җитмәс сыман. Син теге юлы Каһирәгә Гаязетдинне мәмлүкләрнең яңа фетнәсен бастыру нияте белән юллаган идең бит. Аларның ата-бабалары элек Каһирәне уч төбендә биетеп һәм андагы солтаннарны оекбаш урынына алыштыра-алыштыра азып беткән кавем. Шулай да, Гаязетдин, мәмлүкләрне янә антка китереп, барысын да майлап-җайлап кайтты. Каһирә хәзер, әнә, тын чыгарырга да куркып, буаз сыер сыман, мышнап кына ята. Ә бу Килек белән Караман дигән бәйлекләрдәге шыгыйлар — алар бөтенләй башка. Алар син сөнни солтан булганга күрә үз мәмләкәтләрен төзү һәм үз солтаннарын сайлап кую өчен шашыналар. Салым дигәннәре хәйлә генә булуы да мөмкин. Дөрес, аларга бәйләрбәген синең атаң куеп калдырган бит. Аның вафатына дүрт ел вакыт узды, шуннан бирле син Хәйретдин пашаны үз эргәңә чакыртып та, күзәтче җибәреп тә берни белешмәдең. Гөнаһысына кермим, ә шулай да... бәлки, ул Хәйретдин байлык-нигъмәтләрне, ана каз шикелле, үз канаты астына җыеп узынадыр. Бәлки, атаң Сәлим солтан шыгыйларга ясак күләмен, чаманы онытып, күбрәк җиткергәндер. Менә шуннан ризасызлык, фетнә туа инде.

Гаҗәпләнүдән күзләрен акайткан Сөләйман Хүррәм тарафына борылып басты.

— Син минем уйларымны кычкырып кабатлыйсың. Мөселман дөньясындагы ясак-салымнарга тикле кай арада өйрәнеп бетердең син?

Хүррәм хәтта тамчы да каушамады.

— Ә ясак-салымнарның мөселман яки христиан дөньясы өчен һичбер аермасы юк. Мин кеп-кечкенә чактан бирле ишетеп-күреп үстем. Безнең шәһәрчекне йә ләһ алпавытлары, йә мадьярлар килеп таладылар. Килгән берсенә йә җыеп алган иген уңышының яртысы кирәк, йә алар синең көтүдәге малның яртысын талап китә. Абзардагы тана белән үгезеңнең берсен талап киткәч, калган малың ничек үрчесен соң? Менә шуңа күрә мантымады инде безнең халык. Шуңа һаман үз мәмләкәтен төзи, үз ханнарын сайлап куя алмыйча да чит-ятларны гына баетып ята...

Сарайга Ибраһим кияве килеп керүгә ук Сөләйман йодрыкларын усал селкеп тезде.

— Килек белән Караманга барып җитүгә ук, Хәйретдин пашаны Истанбулга озат. Сугым малы сыман дер калтыранып кайтмасын, мин аны дар агачына асып куярга җыенмыйм. Ишетүемчә, атай кулына килеп эләккәнче, ул диңгезләрдә һәр узгынчы карабны талаучы зур юлбасар булган. Үз-үзләрен алар йә пират, йә корсар дип олылаган була, ә асылда шул ук җан кыючы карак. Диңгез карагын коры җирдә башлык итеп куярга ярамаган, димәк. Шулай икән, мин аны янә үзенең элеккеге һөнәренә кире кайтарамын. Борын төбендәге Родос утравында, әнә, тәре явы белән килүчеләр йөз мең кешелек гаскәр тотып яши, узып баручы мөселман карабларын пыр туздыра. Хәйретдин, монда кайткач, кирәк кадәр флот туплар да шул Родос утравындагы алпарларны барып пыр туздырыр.

— Ә мин? — дип Ибраһим паша да тавыш бирде.

— Ә син тиз арада Килек белән Карамандагы шыгыйларны ипкә-сапка китер.

Алар мөселман бит, канга батыру саваплы эш булмас. Уйлап йөргән үлчәмем бар иде. Атай житкергән ясактан котылырга, халыкка салымнарны яна ысул белән житкерергә кирәк. Һәр гаиләдә ничәшәр жан яши, алар никадәрле имана жиренә хужа — салымнарны менә шуннан чыгып билгеләп карыйк әле. Әгәр бер гаиләдә ун, икенчесендә егерме кеше яшәп, икесе дә бер үк зурлыктагы басуга хужа икән, егерме кеше яшәгән гаиләдән салымны берьярым мәртәбә күбрәк каермыйча булмас.

— Ничек инде алай? Күбрәк кешесе булган гаиләне асрау өчен күбрәк ашлыкны алар кулында калдыру отышлырак ласа. Нәфес тыймый гел талыйсын икән, алар ачтан үлә, — дип Ибраһим белән Хүррәмнен икесе тин кайнап кабындылар.

Сөләйман кычкырып кына көлде.

— Менә, ялкау кешеләрнен фикер сөреше бу! Хатын белән түшәктә күбрәк ауна, балаларны унны, унбишне тап, ә алар өчен булачак ризыкны һаман, элеккечә, ун яисә унбиш кишәрлек жирдә генә үстер. Ю-у-ук, алай баеп булмый. Балаларынны да тук яшәтәм дисән, чәчүлек жиренне икеләтә йә өчләтә арттыр. Басуын никадәр зур вә ундырышлы — байлыгын шул чаклы. Ул чагында инде күршеннекеннән берьярым мәртәбә зуррак салымны түләү дә кыен булмаячак.

— Әй, белмим инде, белмим, алай булгач, — дип Хүррәм кул селтәде, ә Сөләйман Ибраһим алдында янә кабатлады.

— Салымнын шушы ысулын жайга салып кара. Әгәр халык балык урынына шушы жимне йотса, без отабыз. Барып чыкмый икән, янә-янә баш ватмыйча булмас...

Нәкъ бер айдан Истамбулга Хәйретдин атлы паша кайтып төште. Сөләйманнын аны күргәне юк иде, сыбай һәм пашалар аша шактый күп белеште.

Чокына башласан, Хәйретдиннен әтисе Барбаросса бөтенләй испаннар иленнән калкып чыккан икән. «Барбаросса» дигәне хужасы гәрәбәдәй сапсары чәчле булганы өчен тагылган бер кушамат кына, ә чынында Якуб атлы мавр булган. Яшь чагында Урта дингез ярындагы маврлар гаскәрендә янычар булып йөргән. Тәре йөртүче нәсара испаннар белән яуда яралангач, маврлар Барбароссаны гаскәрдән жибәргәннәр. Ә ул юнан побыннан калган бер тол хатынга күз аткан да, тегенә өйләнеп, Лесбос дигән утрауга күчеп киткән. Үзе балчыктан савыт-саба ясап кәсеп башлаган бу, ә юнан хатыны Орыч белән Хәйретдин атлы ике угыл тапкан. Ике туган әле үсмер вакытта ук юлбасарлык эшенә тотыналар, үз ишләре кебек ташбашларны байтак кына туплагач, болар Жирәбә утравында хәтта кирмән корып куя. Жирәбә утравы Африканын төньяк ярындагы Тунис каласында утырган мавр әмиренен биләмәсе булып исәпләнә, тик бертуган Орыч белән Хәйретдиннен юлбасарлары гына мона баш бирмиләр икән. Ничәмә-ничә еллар дәвамында Тунис белән Триполи калалары арасында йөзгән испан, португал, юнан корабларын талап торган болар. Таланган байлыктан өлеш чыгара белгәч, Тунис әмире бер тапкыр да болар өстенә жәза гаскәрләре юллап карамаган. Өерләре олы гына флотка әверелгәч, Орыч белән Хәйретдин хәтта Алжир каласын да испаннар кулыннан азат иткән. Әмма Тлемсен каласы янында булган нык аяусыз яуда Орыч һәлак булган, ә испаннар ялгыз калган Хәйретдин Барбароссанын флотын тар-мар итүгә ирешкән, ди. Хәйретдин, яклау эзләп, Сөләйманнын атасы Сәлим солтанга алтын белән тулы олы бер караб байлык юллаган, ә аннары анын ышыгына килеп елышырга мәжбүр булган. Сүрия белән Мисырны яулаганда күрсәткән батырлыгы өчен Сәлим солтан Хәйретдинне Африка ярынын бәйләрбәге дип игълан иткән. Фәрманы кипкән борчак сыман коры гына килеп чыкмасын дип, Хәйретдингә ап-ак төстәге аргамагын, асылташлар белән бизәлгән көмеш ятаган һәм ике койрыклы яу әләмен бүләк итеп юлларга да онытмаган хәтта.

Менә шушы бәйләрбәк Хәйретдин Сөләйманнын каршысында хәзер. Гажәп инде: Хәйретдиннен сакал-мыеклары, каш һәм керфекләре сәхрә комы шикелле алтын-сары икән. Озын буйлы, каклаган каз шикелле ябык кына гәүдәле ир үзе. Ә

шушы караб палубасына менеп алса, ятаганы-хәнҗәрләре белән унар әзмәвердәй яугирне урып сала, диләр. Гайрәт моның бәдәнендә, желегендә, димәк.

— Алтын Мөгез култыгының Жиде Чишмә дигән борынында өр-яңа илле караб төзи башладылар. Жилкән астына куярдай йөз иллеләп караб болай да әзер иде. Тиз арада яңаларын төзеп, карабларның санын ким дигәндә ике йөз иллегә йә өч йөзгә үк житкерергә кирәк.

Сап-сары керфекләр астында соргылт төстәге күзләр генә ялт-йолт килеп тора, Хәйретдиннең йөзеннән һичбер төрле тойгыларны укымалы түгел. Ризамы бу синең ниятләрең белән, арба мичәвенә җигелергә әзерме ул, юкмы — һични аңламассың.

— Мин булган карабларның барысын да синең кулга бирәм, — дип, инде тавышына корыч аһәң өстәп, дәвам итте солтан. — Һәр карабка ким дигәндә бишәр йөз чамасы яугир утыртырбыз. Тупларны бакыр белән кургашны катнаштырып койдык, бертуктаусыз йөз тапкыр атсаң да ярылырлык түгел. Мин синең тәре йөртүче кеферләрне сөймәвеңне беләм. Мин дә күрә алмыйм. Без — аркадаш. Родос утравы моннан йөз ел элек, әле Мәхмүт Фатыйх заманында ук алман каһаны Иоанн Габсбург өстереп җибәргән тәре йөртүче алпар этләре белән шыгрым тулы. Алман, испан, яһүд, норман, саксон — барчасы да шунда. Гел ир-аттан торган амбарларында ничек кенә итеп күнел ачалардыр да, нишләп бер-берсенә ябышып яталардыр — монысы бик шикле. Алар үзләрен «орден», дигән була, башлыклары «магистр» ди, имеш. Ник шайтан, димиләр, безгә төкерәсе. Борын төбендә меңәрләгән көфернең симереп вә зина кылып ятуына ирек кую гөнаһ. Максатыбыз берәү — Родосны көфер орденыннан, зина оясыннан чистартырга кирәк...

Күз кергәндә Жиде Чишмә борынынннан өч йөзләп карабны ярдагы туплардан ата-ата, шаулап озаттылар. Хәйретдин Барбаросса асылда да үтә елгыр корсар икән, берүк күз тимәсен, бер ай дигәндә утрауның аркылысын-буен ерып чыкты. Орден, орден, дип шапырынган йөз меңлек эт җыбыры төрекләрнең тупларына каршы тора алмаган, ярты гаскәре кырылганны күреп, «магистр» атлылары шәхсән үзе кирмән диварыннан ак әләм ташлаган, ди. Хәйретдин паша исән калган илле мең алпарга качып котылу өчен бер тәүлеклек кенә ара биргәч, тегеләр ватык-мотык карабларына төялеп, элекке ояларыннан чыгып югалганнар. Хәйретдин Родосны төрек вилаяте дип игълан иткәч тә туктап калмаган бит. Юлда барышлый ук испаннарның флотын тар-мар итеп, янә Алжир каласына барып урнашкан бу. Мондый тугры яраннарга сокланып, тик бер сүзне кабатларга кала:

— Афәрин вә машалла сиңа, солтанның яңа бер сәрдәре!

Күкрәгендә янартаудай кайнаган шатлыкка түзмичә, Сөләйман Хәйретдин тарафына аерым караб куды. Солтан фәрманын караб палубасыннан жиргә төшкәнче үк кычкырып укыдылар.

— Сөләйман солтан галиҗәнапләре Хәйретдин пашага «Алжир солтаны» дигән дәрәҗә бүләк итә. Моннан ары Хәйретдин солтан Истанбулга кайтып кергән чакта аңа Босфор бугазында утыз туптан атып сәлам бирәчәкләр!

## 20

Шул елның кышында ук Сөләйман янына һич тә көтелмәгән чапкын килеп төште. Баш вәзир Мөнәвир шактый карт булса да, һич тә шикләнеп тормыйча, моны солтан хозурына ияртkән дә кергән.

— Франциско атлы французлар короле юллаган яшерен арадашчы бу. Бургундия дигән вилаять өчен яуда яраланып, Франциско үзе алман-испаннар короле Карл кулына әсирлеккә төшкән. Элеккеге Рим каһанлыгын да тез астына салган Карл француз королен Мадрид каласына алып кайтып, зинданга ташлаттырган.

— Ничек инде, ничек? Бер падишаһ икенчесен ни рәвешле зиндан хәтле

зинданнарга ябып куя алсын? — дип, баш вәзире Мөнәвирдән бигрәк арадашчы чапкын тарафына текәлеп жикеренде солтан.

Чапкын әҗнәби[19] икән, кыяр-кыймас кына телгә килде.

— Безнен королебыз дошман кулында шул, котыла да алмый. Менә, инде өченче ай буена Мадрид зинданында газап чигеп ята. Каяндыр кәгазь-каләм юнәтеп, шуннан хат сырлаган. Мин ул хатны кәвеш табаны астына яшереп кенә испан сакчылары аркылы алып чыктым. Солтан галиҗәнапләренен кулына бирергә дә оят, әмма король Францисконын анда сезнен колагыгызга гына ирештерергә теләгән яшерен гозере бар.

Чапкын мәхбүс король хатын Сөләйманнын хозурына китереп күрсәтсә дә, әчтәлеген ашыга-кабалана үзе укып чыкты.

— «Мине зинданнан коткара күр, зинһар. Аннары Карл өстенә икебез ике яктан юлбарыслар шикелле ташланырбыз. Мин — Бургундияне, син Миланны үзенә кайтарырсын. Әгәр билен хәзер сындырмасак, явыз Карлнын Урта дингез хуҗасына әйләнүе мөмкин».

Сөләйман янә шашкан шикелле үкереп аваз салды.

— Юк, комсыз Карл дигәнчә килеп чыкмаячак! — Ул баш вәзире Мөнәвир тарафына ым ташлады. — Бүген үк хат яз да шушы чапкын аша ул адәм актыгына юлла. Францисконы тиз арада зинданнан чыгармаса, бар мөселман дөньясын күтәреп, мин ул бирән Габсбурглар токымын кандала өере урынына сытып атам!..

Бер ай чамасы дигәндә хәбәр кайтып житте, ни галәмәт, тәкәббер Карл француз королен Сөләйманнын хатын алуга ук азат иткән икән. Тик Сөләйманда гына ярсу басылмады, жиһанга яз борынлый башлауга ук, махсус фәрман барча вилаятьне дер селкетеп чыкты:

— Карл кубызына биегән Австрия вилаятен тез астына сузып салу өчен яна яу сәфәре башланачак. Солтан галиҗәнапләре йөз егерме менлек гаскәрне Босфор бугазынын очында каршыларга әзерләнеп тора...

Олуг фәрман турында ишеткәннән сон Сөләйман Баязит бакчасына тәүге килүдә үк анын янына Хүррәм чәчрәп кереп житте.

— Нишләп син һәрбер яу сәфәренә кимерергә сөяк таба алмаган эт шикелле үзен ташланасын? Син — ошбу жиһандагы ин зур каһаннарнын, солтаннарнын берсе. Төркиянен үзендәге колларын гына да унбиш миллион чамасы исәпләнә. Әле тагын унбиш вилаятькә чәчелгән әҗнәби[20] колларыннын саны егермедән гайре миллионга якын. Син үзен тәхеттә генә утыр да бөеклеген белән хозурланудан башка эшне белмә. Илен белән, иге-чиге булмаган ул колларын белән вәзирләрен, сәрдәрләрен, пашаларын идарә итсен. Ул Ибраһим киявенне Килек белән Караман калаларына бәйләрбәге итеп озатмаска иде, аны кабат Истанбулга кайтар.

«Тамчы тама-тама мәрмәр ташны да тишә» дигәннәре, валлаһи да, хак шул. Хүррәмнен көрешкән саен игәүләвенә түзмичә, Сөләйман Ибраһимны Мисырдан кайтарттырды. Тик Босфор бугазы очына беренче төмәннәр жыела башлауга ук һаман да шул кияве Ибраһимны ин беренче итеп озаттырды, үзе атна-ун көннән сон гына юлга чыкты. Пайтәхеттә баш вәзиргә янә берьялгызы теркелләргә калды.

Болай да Трансильваниядәге Янош белән тәкаләрчә сөзешеп яткан Лайош-Людвиг төрек солтаны тарафыннан яна зур яу килер дип күз алдына да китереп карамаган. Сөләйман Белград каласын сытып, Мохач инкүлегенә үтеп кергәч кенә йокыдан уянды ул. Габсбурглар нәселе Варшавадан китереп утырткан бу ләһ баен австриялеләр дә, валах белән мадьярлар да баштук сөймәделәр. Венадагы кенәз-аксөякләр анын һәр тәгәрмәченә таяк тыга башлагач, әле өйләнмәгән дә егерме яшьлек Лайош талап жыйган бар байлыгын Варшавага озата торган гадәтне

[19] Әҗнәби — чит телләр белүче.
[20] Әҗнәби — бу очракта чит ил, чит милләт вәкиле.

үз итте. Менә үч итеп, аксөякләр күршедәге молдаваннарны да, валахларны да үзенчә таладылар. Лайош килмешәкне алман, саксон, бавар халыкларын үз кубызына биеткән Карл гына король дип игълан иткән иде. Шул килмешәк Лайош Сөләйман солтан явына каршы чакыру ташлагач та, һичкем буйсынмады. Ярсуыннан, гарьләнүдән кысла шикелле кызарынган Лайош нибарысы дүрт мең җайдактан торган шәхси гаскәр белән Мохач кирмәне янында Сөләйман солтанга каршы чыгып басты. Лайош, ятып калганчы атып калыйм, дип ләһ алпавытлары янына чапкын куган иде. Әле ярый шулар егерме биш мең чамасы ләһ, бавар, Лифляндия, Богемия игенчеләрен җыеп җибәргәннәр.

Мохач инкүлеге — иркен, тигез ялан, ләкин әйләнә-тирәсе тоташ сазлык. Лайош күләгәсенә поскан килеш тә, ике яклы пычак сыман, Трансильваниядәге Янош тарафыннан күз алмыйча йөргән мадьяр кенәзләре аяусыз яу гына таләп итте:

— Безнең сазлыклар — солтан җайдаклары өчен үтеп чыккысыз упкын белән киртә. Сөләйман яуга төмән артыннан төмәннәрен ташлый алмаячак. Ике сазлык арасындагы коры инкүлеккә тезелеп басабыз да, бер адым да артка чигенмибез!

Мадьяр кенәзләре хәтта инкүлекнең икенче ягын Сөләйманның кара болыт кебек гаскәре каплап алгач та куркып калмадылар.

— Иң беренче булып, без үзебез һөҗүмгә ташланабыз. Яу һәм аяусыз яу гына безне коткарачак! — дип үз-үзләрен җилкендергән булып кыйландылар хәтта.

Шулар басымына буйсынып, Лайош гаскәрләргә һөҗүмгә күчәргә әмер бирде. Мөгезенә Лайош үзе баскан мадьяр җайдаклары, карчыгалар шикелле очып-кунып, төрек чылбырындагы беренче рәтләрне өзүгә ирештеләр. Тантана итә башлагач, төрек сәрдәрләренең нинди мәкерле ятьмә корып куюын да шәйләп-абайлап өлгермәде алар. Ә төрек җайдаклары бик тиз генә як-якка чәчелеп чылбырны урталай өзде дә, үзләренең калкан артына поскан янычарлар гаскәрен ачып салды. Сызгыра-сызгыра очкан сәрпи укларның берничәсе хәтта Сөләйман солтан тирәсендәге яу әләмнәрен тишеп-тетеп узды. Ләкин икенче минутта ук янычарлар йөзәрләгән җинел туплардан меңәрләгән ядрәләрне ташкын булып килгән мадьяр җайдаклары өстенә чәчеп очырдылар. Беренче рәтләр печән теземнәре шикелле киселешеп ауды, кирегә борылып берсен-берсе изә башлаган бавар-мадьярларны төрек җайдаклары ятаган һәм сөңге белән турарга тотындылар. Маңгаена ядрә кыерчыгы эләгеп яраланган Лайош та, сиптереп аккан кан чишмәсен куллары белән аралый-аралый, вак күлләвекләре белән коткаргыч салам булып күренгән сазлыклар ягына таба торып чапты. Әмма айгыры беренче күлләвек эченә сикереп керүгә үк алгы аяклары белән сазлыкка очрады да, кешнәп хушлашу авазы салырга да өлгермичә, мәтәлчек атынып, үзенең җайдагы — король Лайош өстенә сузылып ятты. Артта әүвәл Сөләйман солтанның, аннары Ибраһим пашаның кыргый аһәң алган фәрманы яңгырады:

— Тез чүгә белмәгән әсирләрнең безгә кирәге юк! Бер генә мадьяр йә ләһне дә исән калдырмыйча кырып бетерегез!..

Ике меңнән артык мәетнең баш сөякләреннән Сөләйман солтан чатыры каршында кибән чаклы зур тау төзеделәр. Король Лайошның гәүдәсен дә саз үз эченә суырып өлгермәгән, аны асылташлар белән бизәлгән очлымына карап аерганнар. Егерме яшьлек кичәге корольнең баш сөяген мәетләр кибәненең иң очына утыртып куйсалар да, Сөләйманда ярсу басылмады.

— Мохач кирмәне урынында көл дә калдырмыйча юкка чыгарыгыз! Тирә-якны талап чыгарга ике тәүлек кенә вакыт бирәм, ә аннары кабаттан Венага яуга кузгалабыз.

Чатырына кереп ялгыз калгач, Сөләйман ерактагы Хүррәме өчен махсус хат сырлады:

«Бүген көзнең беренче аена да аяк бастык инде. Иртән яуда шәһит киткән алты мең төрекне гүргә индерделәр... Ә тышта гел туктаусыз яңгыр. Мина бик күнелсез...»

Мадьяр иле тол хатын шикелле яклаучысыз торып калган иде, Сөләйман

иске пайтәхет саналган Будага да орыш-һөҗүмнәрсез генә үтеп керде. Үзенен Трансильвания атлы дәүләтеннән Лайошның көндәше Янош король дә килеп житкән иде. Сөләйман солтан корольләрнен иске сараенда шуның башына Стефани хакимнән калган иске таж кидерде. Солтан шунын ише «вак мәшәкать» белән шөгыльләнгән чакта сәрдәр-пашалар да тик ятмаган. Иске сарайдагы бар байлыкны, хәтта Корвини китапханәсен, Римнан китерелгән Аполлон, Диана, Геркулес сыннарын да зур-зур тартмаларга тутырып бетергәннәр. Корольләр сарае бакчасында заманында Белград белән Будапештларны яулап та солтан Мәхмүт Фатыйх алып китә алмаган гаҗәеп зур ике туп калган икән. Шул тупларны озынлыгы ун арбага житкән махсус олауларга күтәреп беркеттеләр. Буда каласы яфракларын койган көзге агач сыман шыр ялангач калган, анын кадере дә беткән иде инде. Сөләйман әмере буенча ана ут төрттеләр. Дунайны көймәләрдән корылган басма аша атлап чыгуга ук, солтан икенче як ярдагы Пешт каласын да исән калдырмады.

— Безгә кирәге юк, буйсынуны белмәс дошман кулына да берни тәтемәсен!..

Истамбулга кайтып егылырга да өлгерә алмадылар, арттан үтне сыткыч хәбәр куып житте:

— Үзен-үзе бөек король дип игълан иткән Карл Вена каласына бертуган энекәше Фердинандны китереп утырткан. Яклаучысыз калган Ян-Янош ләһ кенәзләре ышыгына качып котылган, ди. Буда хәрабәләре өстенә сейм җыеп, Фердинандны австриялеләр белән мадьярларның бердәнбер короле итеп тәхет өстенә күтәргәннәр икән...

Икенче кичтә инде «нахакка кыерсытылган» Ян-Яношның чапкыны хат суза.

«Зинһар, мине коткар, син атам бит. Король тажын кабат кайтарып бирсәң, мин сиңа ел саен егерме-утыз мең дукат алтын түләп торырга да риза. Аны гына азсынсаң, кул астымдагы халыкның уннан берен синең мәмләкәткә кол итеп бирәчәкмен».

Юктан көрәк булган яна король дә тажын саклап баш ияргә онытмаган икән. Сөләйман каршына анын махсус илчеләре килеп тез чүкте.

— Король Фердинанд Сөләйман солтан галиҗәнапләре белән теләсә нинди шарттагы солыхны төзергә дә әзер.

«Бүләк юк, ясак түләү турында сыңар гына сүз дә ишетелми. Коры кашык авыз ерта бит ул, аһ, башың беткере!» — дип кенә эченнән сүгенде дә Сөләйман солтан мадьяр илчеләрен зинданга озаттырды.

— Азау тешең чыксын, аннары сиңа да акыл керер әле!

## 21

Хүррәм, янә малай табып солтанны сөендерермен, дип зур өметләр белән көтсә дә, җиһанга кыз туды. Сөләйман моның ише вак-төякләр белән баш ватып вакланмады. Сабыйны күрде дә: «Тиен кебек бит бу, бөтенләй дә тик ятуны белми», — дип көлде ул, баланы тәүге тапкыр кулга алуга ук. Сабыйга Мәһруй дигән исем куштылар, ни галәмәт, Гайшә-солтанбикә дә оныгына гел мөкиббән булды.

Өченче бала булып, ниһаять, малай тугач, Хүррәм үзе кыл өзгәндәй кисте:

— Балаларны ата-бабаларның күләгәсе, әманәте саклый, әтиеннең рухын онытмаска кирәк. Шуның хөрмәтенә монысы Сәлим булсын.

Бу баласы бик елак булса да, Сөләйман ризалашты. Ул Баязит бакчасындагы иске солтан кирмәненә гаять сирәк килә, ә Сәлимнең елаклыгыннан күбесенчә Хүррәм берьялгызы михнәт чигә иде. Сабый шаккатырды: киндек карчыклары йә асрау хатыннарның кулы кагылдымы — буыла-буыла елый, Хүррәм үз кулына алса, тылсым кагылгандай, пуф-пуф килеп йоклый. Уяу ятса, карашын гел әнисеннән алмый, ыгы-ыгы дигән аваз чыгарып көлгән йә тибенгән була, кулга алмыйча, үчтекиләп сөймичә калулары читен. Сабый үзе дә моны сизенә диярсең, әнисе янәшә торганда майлаган коймак кебек, ә шәүләсе югала башлауга шәрран яра. Теләсә-теләмәсә дә, Хүррәм гел Сәлим бишеге янында бөтерелергә мәҗбүр.

Сәлим бәләкәчкә бер генә яшь тә тулып өлгермәде, бөтен Кара дингез буен котчыкмалы хәбәр көйдереп узды. Варяглар атавында янә чәчәк түләмәсе дигән афәт купкан, ә ул Балтыйк дәрьясын кичеп, алманнардан — мадьярларга, мадьярлардан валахларга күчә-күчә, мәмләкәт артыннан мәмләкәтне чалгы сыман урып килә икән. Хәбәр алынуга ук солтан галиҗәнапләренең фәрманын барча мәйданнарда кычкырып укыдылар:

— Базар тоту, сәүдә итү, һөнәрчелек, кунак кабул итү кискен туктатыла. Чәйханәләр, мәдрәсәләр эшләргә тиеш түгел. Куркыныч дәвам итсә, Аллаһ йортлары да һичшиксез ябылачак. Фәрман бозган гыйсъяннарны дар агачы белән учак көтә...

Мәркәздәге һәр ихата кирмән рәвешен алды, урамнар очына баштан-аяк коралланган каравылчыларны чыгарып бастырдылар. Һәр зур чатта зур учаклар янды, шулар ярдәмендә һавадагы зарарлы ис һәм хәтта бөҗәкләрдән дә котылу иде исәпләре. Элек солтан атна саен унар мең янычарны Баязит бакчасы астындагы зур мәйданга тезеп, алар алдында нотык тотарга ярата торган иде, хәзер ул үзенең Топкапе кирмәненә посып, сукыр тычкан сыман, тын чыгармый ята.

Солтаннарның иске кирмәне саналган Баязит бакчасын да корыч капкаларга бикләделәр, ишек ачып урамга чыгулар, бүлмәдән-бүлмәгә хәл белешкән булып гайбәт җыеп йөрүләр — барысы да бетте. Һәммәсе иң якын туганы белән очрашкан чагында да чүпрәк битлек кигән булды, әмма кара кайгылардан котыла алмадылар.

— Мәхмүт шаһзадә ут шикелле яна, — дип иң беренче булып асрау хатыннарның берсе кергән иде.

Икенче көнне табиб мөһер сукты.

— Мәхмүтегездә чәчәк түләмәсе. Сөт сүленең дә һичбер файдасы юк, коткарып кала алуыбыз бик икеле.

Коткара алмадылар...

Хүррәм инде түләмә афәте үтеп киткәннән соң да, ай буена туктамый өзгәләнде. Сөләйман бүләк артыннан бүләк өйгән булды, ярсу басылмады. Ә Гөлбаһар шушы бәладән дә юаныч тапкан бит, каһәр. Аш өстәле артына кереп барган чакта, иреннәре аша ысылдап, еландай чагып алудан да тартынмады.

— Мәхмүтеңне шаһзадә булмагае дип очындырган идең, канатларың көйде. Минем Мостафам атасына бердәнбер алмашчы булып калды инде, менә.

Хүррәм түзә алмады, шул кичтә үк үз янына баш хадимне дәште.

— Минем эргәмә Ибраһим пашаны мыштым гына чакырт. Чапкыннарыңа да, сакчыларыңа да хәер-сәдака кирәк булуы бар. Минем алтыннарым әнә теге тартмада, никадәрле хаҗәт, шулчаклы ал.

Ибраһим көне-сәгатендә очып килеп җитте. Күз карашы элеккечә үк ач-мөкиббән, шикләнерлек түгел, хыялында Хүррәм белән назланышу уе һаман яна әле.

— Күзгә күренеп үзгәрдең, ай саен яшәрәсең, син хәзер гүзәлләрнең гүзәле, янәшәңә куярдай бүтән чибәр җир йөзендә юктыр.

— Йә-йә, Ибраһим паша, мин ялтыравык пыяла ватыгы белән чын алмазны гына аера беләм инде. Күзгә төтен җибәреп, телеңне әрәм итмә.

Хүррәм солтанның нәзакәт хатыны булып исәпләнә, Ибраһим аны тешен кысып тыңларга гына мәҗбүр.

— Миңа ел-елъярым чамасы элегрәк кителмәгән бер хат китерделәр, — дип сүзне мөгезеннән эләктереп алды Хүррәм. — Юллаучысын беләм, минем белән бергә әсирлеккә эләккән Никола якташым ул. Хәзер кайдадыр Истанбулда яши, аның базарларда алачык йә кибет тотуы да мөмкин. Кичекмәстән менә шул Николаены эзләп табу мөһим.

— Ә нигә соң ул сиңа? Элек гыйшык тоткан ярың түгелдер лә? Солтан колагына барып ишетелсә, ул икебезнең дә башны кистерәчәк.

Хүррәм янартаудай котырып ысылдады.

— Анын колагына ирештерерлек бозау булсан, сөйләшмәс тә идем. Ә барысы да мин дигәнчә барып чыга икән, синең гади паша булып йөрүләрдән котылуың мөмкин. Сезнең юнан халкында: «Төнге сынар кәккүк бакчадагы йөз былбылдан да сөйкемлерәк сайрый», — дигән гыйбарә юкмыни? Әй, кызганыч. Иллә мәгәр моны синең ишеләргә биш былтыр ук төшенергә вакыт. Шуңа күрә суга сусаган карга сыман авыз ачып йөрмә. Ул Николаны нинди генә юл белән булса да шушы кирмән эченә үткәр. Үзем шәһәргә чыгып очрашсам, ул минем бер генә сүземә дә ышаначак түгел. Сакчыларга акчаны кызганма. Үзеңдә булмаса, миндә син ташыган алтыннар һаман исән әле...

Ибраһим яллаган шымчылар Истанбул базарларына эт өере сыман ябырылды, һәр почмакка кереп иснәнделәр. Хүррәм өчен һәрбер сәгать утлы күз өстендә йөргәндәй газап иде, адым саен җәя җебе булып тартылгандай иләсләнеп көтте. Ниһаять, бер атна дигәндә, төн кереп килгәндә Ибраһим ишек какты.

— Таптым мин синең элекке сөяркәңне. Гаҗәп түгел, ул бүген дә синең өчен ут эченә керергә әзер тора.

— Кайда ул? — дип Хүррәм, әсәренеп-янып, урыныннан ук купты.

— Бакча түрендәге, чишмә буендагы көмеш чатыр хозурына атла. Николанны шунда илтеп куйдым.

— Син Николадан тыш биш-алты шымчы яшермичә кала торган эчкерсез җан түгел. Аларны хәзер үк җыеп ал да олак.

Хүррәм ачыргаланып кычкыруга түзмичә, Ибраһим да шундук артка чикте.

— Ярар алай булса, мәйлең-мәйлең. Алай-болай ул сиңа котырып ябышса, мин сине коткара алачак түгел.

— Юк-бар өчен көеп, чәч агартма. Кем янына — комган, кем янына калкан белән барырга кирәклекне генә чамалыйм мин.

Ибраһим күз алдыннан китеп югалуга Хүррәм өстен-башын төзәткәләргә керешкән иде дә, аннары кул селтәде. Тышта дөм-караңгы булу өстенә ул өч, ә юк, ике бала анасы бит хәзер, шушы кадәр төенчекле хатын кайсы иргә кирәксен ди инде?

Көмеш чатыр таныш, таныш аңа. Тәүге тапкыр шунда Гайшә солтанбикә белән очрашты ул, шуннан бирле солтан анасының аны читкә какканы юк. Бер юл уңа торган урынның икенче мәртәбә дә хәерле булуы бар. Тик Никола ничек каршылар соң аны? Мәхәббәтле һәм кайгысыз яшьлекне инде күптән томан каплап китте. Гомумән, танырмы ул аны?

Хүррәм сарайдан көмеш чатырга кадәр сукмак буйлап яланаяк көе ватык пыялалар өменә баскандай куырылып атлады. Әнә, моңлы чишмә чылтыравы яңгырап ишетелә. Әнә, чатыр ниргәсенә сөялеп баскан озын, ябык шәүлә. Элек Хүррәм бу егетне хәтта исе буенча да йөз кеше арасыннан аера алыр иде, хәзер ул ниндирәк икән дә, нык үзгәрде микән?

Менә шәүлә чатырдан аерылды, өч-дүрт адымлык араны ике сикерде дә Хүррәм сынын кочагына состы. Колак очындагы карлыкканрак тавыш аяк табанына чаклы көйдереп узды.

— Мин бит сине җиде ел буена тилерә-тилерә эзлим, Роксолана. Башта татарлар, аннан моллаваннар кулыннан качып котылдым. Кара дингезне ярык тагарак шикелле баркасларда, каекларда кичтем. Эзләренне шушы Истанбулда гына эзләп таптым. Үлсәм-үләм, әмма сине урламыйча моннан китәсем юк. Миңа синнән башка бер кеше дә кирәкми. Мин гомер буе сине генә сөячәкмен, алтыным, Роксолана!

— Син, зинһар, тынычлан, тынычлан, Николакай, — дип Хүррәм дә яшьлегендәге шикелле кайнарланып, шаша-шаша кочты. — Син минем нинди зинданга килеп эләгүемне аңламадыңмыни? Мин солтанның харәм йортында бит, мин — аягын да юа белмәгән төрекләр җариясе. Кайсы якка гына атласам да, артымда йөзәрләгән шымчы, дисталәгән кизү. Шушы Баязит бакчасының

капкасын да атлап чыга алмыйм. Хәтта хадимнәр белән сөйләшкән чагында да йә йөземә пәрәнҗә кияргә мәҗбүрмен, йә чыбылдык аша. Мин — гап-гади кол. Инде түзәрлегем калмады, үземә кул салсам, гөнаһыннан куркам.

— Мондый уйларны башыңнан чыгарып ташла, газапларың бетте, бәгырькәем. — Никола шашып-шашып аның бармак очларын, уч төпләрен үпте. — Мин сине моннан урлап алып чыгам. Без үзебезнең Рогатин каласына кайтып китәбез дә кабат бәхетле булачакбыз, Роксолана, җаным!

Хүррәм Николаның кочагына сеңде, бармакларын егетнең чәчләре арасында уйната-уйната иреннәреннән, яңагыннан үпте.

— Минем кабат туган җиремә әйләнеп кайтасым, кабат бик тә бәхетле буласым килә, Николаша. Фәкать синең белән, синең белән генә, җаныкаем! Ләкин... ләкин минем кулларымда, аякларда богау. Коткар мине, коткар!

— Әйдә, хәзер үк качабыз, качабыз, бәгырькәем! Сине азат итү өчен кирәк булса, мин ун сакчыны да, егермесен дә бер ялгызым көе урып салам!

Хүррәм кайнар итеп үбә-үбә һаман шашындырды.

— Сине сөңге очына алулары, кулларыңа зынҗыр салулары мөмкин, Николакай. Сакчыларның, шымчыларның игътибарын читкә алу өчен берәр төрле хәйлә уйлап табу йә фаҗига кирәк. Син ут чыгар, җаным. Минем зинданым — харәм сарае ул. Шуңа ут төрт, аны күккә очыр. Сакчылар шуны сүндерергә ташланмыйча калмас. Ә без шул мәхшәрдә капкалар артына чыгып котылырбыз.

— Әйе, әйе, син акыллым минем, Роксоланам! Мин хәзер харәм сараена ут элдерәм, ә син бакча түренә яшерен дә тын гына көт...

Соңгы кабат суырып үбешүдән соң Никола караңгылык эченә чумып юкка чыкты. Җиһанның һәр мизгеле кайнар энә белән газаплаган шикелле көйдереп һәм көттереп уза бирде. Ходайның рәхмәте, менә берзаманны харәм сараеның бер як диварында ут көлтәсе пәйда булды, аннары сулышларны бугыч төтен күтәрелде. Ул да түгел, бакча буйлап ачыргаланып кычкыра-кычкыра йөгерә башладылар.

— Янгын, янгын! Харәм сараеның тышына ут төрткәннәр!

Берникадәр вакыттвн соң тантаналы яңа гауга купты.

— Ут төртүче бәдбәхетне кулга төшергәннәр! Ул явызны Ибраһим паша шәхсән үзе солтан кулына илтеп тапшырачак!

Үзе өчен шәхси фәрман янгыраган шикелле, Хүррәм көмеш чатыр артына поскан аулак урыныннан сикереп чыкты. Үзе иске кирмән капкаларына таба җәйрәндәй сикергәләп йөгерә башлады, үзе чабулап барышлый өстендәге күлмәгенең якаларын, җиң очларын умыргалап атты, чәч толымнарын тузгытып бетерде. Капка артында торган беренче җайдакны шәйләп алуга ук, иярдә утырган ирнең аягына килеп ябышты да, ис-акылын җуйган бичара шикелле өзгәләнеп һәм ялварып дәште.

— Мин солтанның иң яраткан хатыны Хүррәм булам. Көнчеләрем мине яндырып үтерергә җыенып, ут кузгатты. Иярең ал да, коткара күр мине, Топкапега апкит. Моның өчен сине солтан алтын көшеленә күмми калмаячак!

Бер-ике минуттан соң җайдак инде юлдагы вак күперләр һәм тар сукмаклар аша солтаннарның яңа кирмәненә таба канатланып очты.

Сөләйманга иске кирмәндәге янгын турында хәбәр итеп өлгергәннәр, ул күптән аягына торып баскан иде. Сарайга үтеп кергән Хүррәмнең кыяфәте үк аның өнен алды. Житмәсә, Хүррәм ачыргаланып үксүләре белән дә аның ихтыярын, мин-минлеген мәңгегә оныттырды.

— Мине үтерергә җыенып, яшәгән сараема ут төрттеләр. Син монда берүзеңә өч йөз бүлмәле сарайга кереп постын да, газиз балаларыңа да төкереп, сукыр вә чукрак шикелле тын ятасың. Ә тегендә синең баларынны яндырып йә агулап китәчәкләр. Чит илләрдә падишаһ, корольләр белән аларның хатыннары бер сарайда яши, бер түшәкне уртак итеп йоклый. Анда корольләр хәтта шәһәргә чыкканда да сөекле

хатынын үзеннән бер адым калдырмый, хатынынын гүзәллеге белән бар халыкны сокландырып йөри. Кунаклар кабул иткәндә дә, бию-тамашалар караган чагында да, учларын-учларына куеп, янәшә утыралар. Бер син генә даладагы кыргый хаким төсле, бер син генә хатыныңны базга ябып, мәмләкәттән аерым яшәтәсен. Юк, үлем көтеп, газап чигеп, ут эчендә яшәүләргә түзеп тора алмыйм. Мин халык алдына йә чит ил кунаклары каршына чыгарып күрсәтмәстәй шыксыз хатын, гарип хатын түгел! Беркая да китмим, мин янында калам. Теләмисең икән, дарга озат мине, муеныма элмәк сала торган җалладларны чакыр!..

Хүррәм хәтта котырган, ярсыган чагында да искиткеч гүзәл иде, Сөләйман аның таләпләрен кире кагардай гайрәт таба алмады. Ә иртәгәсен бөтен Истамбулны шаккатыргыч хәбәр урап узды:

— Кичә кәнизәк булып йөргән Хүррәм бүгеннән башлап солтан сараенда яшәп калган. Моңа кадәр солтаннар сараенда хәтта бер төнгә куна калучы хатыннар да булганы юк иде. Хүррәм, итәге белән каплап, Сөләйманнын ушын алган икән. Солтан хәзер, бирнәләр әзерләтеп, никахлар укытып, кәнизәк Хүррәмгә өйләнәчәк, диләр. Менә сиңа иң кадерле итәк! Ислам дөньясында күрелмәгән хәл бит бу, кыргый бер яналык, әстәгъфирулла... Йә машалла!

## 22

Топкапеда туй шикелле күңел ачулар шаулап үтүгә үк Хүррәм Сөләйманны төн буена гөжләп сихерләде.

— Мәхмүт-бәгырькәем шаһзадә дәрәҗәсенең тәмен-ямен татый алмыйча да китеп барды, мәрхүм. Сәлим үсеп килә. Минем бер генә улым да шаһзадә бәхетләрен кичерү өчен тумаган микәнни соң инде, йә Ходаем?!

Түзеп тора алмыйча, Сөләйман Хүррәмне: «Булыр, булыр, вакыты җиткәч Сәлимең дә берләнбер шаһзадә дәрәҗәсен алыр. Барысы да Ходай Тәгалә кулында бит, анын исә Гөлбаһар белән Мостафаны да үзенең янына алып куюы бар», — дигән саксыз сүзләр белән юатырга мәҗбүр булды. Хүррәм исә, моңа байтак мүк үстереп, Гөлбаһар тарафына агу-мәкер койды.

— Солтан Сәлимне шаһзадә дип игълан итәргә әзерләнә. Ә Гөлбаһар белән Мостафаны чиркәс тауларына озатып җибәрәчәк.

Бу хәбәрне алгач, исән-сау көенә тол яшәгән Гөлбаһар чыгырыннан-чыгып котырынган, диләр. Ләкин Баязит бакчасы Сераль борынынын икенче ягында, бик-бик еракта бит, Гөлбаһарның көйдергеч ут ялкыны Топкапега килеп ирешмәде.

«Солтан-ханым» дәрәҗәсенә ия булган Хүррәмгә бәхет капусы күк йөзеннән ишелеп төшкән микән, ике-өч айдан соң ул янә дә угыл алып кайтты. Монысы борча кебек хәрәкәтчән, елгыр, шуны шәйләп, Сөләйман аңа ерак бабасынын исемен кушуны мәслихәтрәк тапты.

— Минем бер бабам Баязит дигән күркәм исем йөрткән. Дошманнар өстенә ук шикелле кадалганга күрә үзенә «Елдырым» атлы ләкаб тә өстәгәннәр. Ул бабамны галәмәт эре сөякле, бик мәһабәт ир-ат булган, диләр. Минем бу улым да Баязит булсын әле.

— Ул бабаңның башын Аксак Тимер чаптырып үтергән бит. Бик начар фал. Безнең бу кече улыбызны да кайгы-афәт сагалавы мөмкин, — дип Хүррәмнең каршы сүз әйтүен Сөләйман солтан бөтенләй ошатмады.

— Җыен ырым-шырымнарга табынудан тукта. Мин Баязит, дидем. Әйттем, бетте!

Бәхәсләрне дәвам итүләрнең нигезе юк, кендек карчыклары Баязит сабыйны адаш бабасы тøзеткән иске кирмәнгә алып китеп өлгергәннәр иде. Моннан ары аны Хүррәмнең үзенә ин еш дигәндә дә атнага бер мәртәбә китереп күрсәттеләр, ә күз алдында тупырдап үсмәгәч, сабыйның газизлеге дә бик тиз онытылды.

Сөләйман үз янына әле Мөхәммәдияр атлы баш казыйны, әле шәйхелислам дәрәҗәсен йөртүче Хөсәен хәзрәтне дәшеп кенә тора. Хүррәмнең дә ишек катына килеп колак салганы бар, «Мултекә әл-үсәр» атлы кануннар җыелмасы төзеп ята болар. Ул тупланма «Дәрьялар кушылганда» дигән мәгънәне аңлатса да, төрек мәмләкәтенең нәкъ җиһан уртасында канат җәюенә бер киная инде. Дөнья кендеге дәрәҗәсенә дәгъва итүләре дә бик урынлы сыман, кайсы яктан гына күз ташлама, Анадола атавы барча мәмләкәтләр уртасына җәелеп урнашкан бит. Әйтерсең лә, читтәге, башка далалар шушы төбәктән әниләренең итәгеннән төшкәч тәпиләп киткән сабыйлар шикелле бар җиһанга таралган, чәчелгән кебегрәк килеп чыга. Өстәвенә, Анадола атавын дулкыннары белән юган-чәбәкләгән төп дәрьяның исеменә кадәр «Урта диңгез».

— Тупланмада калаларны төзү кануннары, мәгърифәт, сәүдә эше, салым тәртипләре — һәммәсе дә урын алачаклар. Балаларыбыз үзара җәдәләшеп баш ватмасын өчен аларга иң төп кануннарны үрнәк рәвешендә калдырырга кирәк, — дип Сөләйман шапырына.

Ә игътибар беләнрәк тынласаң, Мөхәммәдияр казый белән көн дә ызгышалар.

— Син Ибраһим паша аркылы Килем белән Караман вилаятьләренә керткән салымнар микъдары да бик чамасыз һәм дә кансыз түгел, — дип казый әүвәл солтан белән ризалашкан була. Ә аннары көрәш келәменә баскан пәһлеван урынына Сөләйманны аркасына әйләндерә дә сала.

— Иллә мәгәр, солтан, тәртәләрне бөгә-бөгә тәгәрмәч ясарга маташуда һичбер ләгать юктыр. Арба тәгәрмәчен дә, салым тәртибен дә безгә кадәр биш былтыр ук уйлап тапканнар бит. Атабыз Чыңгызхан язып калдырган «Яса» тупланмасын гына актаргалап кара. Чыңгыз бабабыз әле өч гасыр элек үк вилаятьләрдән вә һәрбер игенче-һөнәрчедән табышларының уннан бер өлешен генә салымга җыйнауны канун итеп керткән. Бирән нойоннары моны бик азсынгач, Чыңгыз бабай әнә ничек итеп тегеләрнең авызын томалаган. Менә, тыңлап кара. «Мин үземнең балаларымның да тук вә җиткелекле хәят илә яшәүләрен телим. Сез таләп иткәнчә, мин табышның биштән яки өчтән бер өлешен җыя башладыммы, һөнәрчеләр остаханәләрен ябып бетерәчәк, ә игенче чит кешегә барып бил бөгәчәк. Ул чагында иген басуларын әрем, алабута, шайтан таяклары каплап китәр. Шуның эзеннән үк гыйлемлек-осталык та, гаскәр тотулар да юкка чыгар. Мәмләкәт минем улларымның кулына да бай һәм гаярь көенә күченергә тиеш».

Ахыр чиктә Сөләйман ризалашты, салым тәртибе турындагы «Канун-Райя» дигән бер тупланма махсус фәрман белән вилаятьләр буйлап таратылды. Әлеге канун каһанлык чикләрен дә үтеп чыккан икән. Аның даны сарай хозурына тиз арада кайтып ишетелде.

— Мадьяр ирләре вә валахлар, авылы-авылы белән кубып, король Фердинанд кул астыннан кача башладылар. Алар төрек вилаятьләрендә үзләренә чәчүлек җир сорый. Уннан бер өлеш салымны түләп торырга һәрберсе риза.

«Канун-Райя»дан соң пайтәхеттә хөкем тәртибе турындагы фәрманнарның берничәсен мәйданнарда кычкырып укыдылар.

— Кала әмиренең рөхсәтеннән башка тауарларга бәя күтәрүче бирәннәрне базар уртасында иллешәр камчы белән суктырырга.

— Ялган акча яисә ялган рөхсәт кәгазе ясаган явызларның уң кулларындагы бармакларын кисеп җәзаларга.

— Ришвәт бирүче карак һәм аны алучы казый табыла икән, икесенә дә — дарда сүс элмәге...

Мәгърифәт өлкәсен үз кесәсе сыман актармаган, янартмаган хаким була алмый. Сөләйман да Белград, Будапешт, Каһирә, Баһдад калаларына тикле йөри-йөри байтак гыйбрәт җыйды.

— Сигез гади мәдрәсәдән кала Истанбулда ушлы балаларны аякка бастырырдай гыйлем учагы юк, — дип кунагының итәгенә утлы күмер ташлады Сөләйман, инде шәйхелислам Хөсәенгә чират килеп житкәч. — Париж, Берлин, Мадридларда, әнә, яшь буынны дарелфөнүннәрдә[21] укыталар, диләр. Ун-унбишәр еллар буена, ди. Шуңа күрә алардан ис-акылыңны жуйдырырдай сарайлар төзеп куючы мигъмарлар да, иң куәтле ядрәләр дә жимерә алмаган кирмән диварларын күккә очыручы дарычы да, яман зәхмәттән гомер буе михнәт чиккән зәгыйфьләрне сөлек белән аякка бастыра белүче табиблар да — һәммәсе дә чыга. Ә без һаман мәдрәсәләрдә сүрә-аять ятлатып кына сабыйларның башын катырабыз, әстәгъфирулла, көфер сүзем өчен үзең ярлыка күр.

Шәехисламның да як-ягына төкеренүен күргәч тә тукталмады, элеккечә тезде.

— Син килгәнче, бармак бөгә-бөгә, юри санап чыктым. Истанбулда Зәнгәр мәчет, Айя-Суфия, Аксарай, Каләм-манара шикелле күркәм-матур Аллаһ йортларының саны үндүрт икән. Менә шуларның һәммәсе каршында дарелфөнүннәр ачтырырга кирәк. Элеккеге сигез мәдрәсәне тагын алтыга арттырып, аларын жиде-сигезәр ел укышлы югары сыйныфлы мәктәпләргә әйләндерми булмас. Син үзең дә аксап-туксап йөреп, дөньядан артта калган шыр-томана түгел. Хәтта Баһдад белән Басра мәктәпләрендә дә балаларга мантыйк, жәгърәфия, фәлсәфә, инсаннарның тән саулыгы, йолдызлар, санау, үлчәм фәннәре укытылуын биш бармагың кебек беләсеңдер. Безнең мәктәпләргә дә кичекмәстән шундый гыйлем кертелергә тиеш.

— Кадим мулла-мунтагайлар жәнжал куптарачак, — дип шәйхелислам сүз кыстырган иде, Сөләйман мондый дәгъваны да ярты юлда өзде.

— Син — бер дин генә түгел, ә мәгърифәт өчен дә иң жаваплы кеше. Махсус фәрман язам. Моннан ары шәйхелислам кеше минем мәмләкәттә баш вәзир белән бер үк дәрәжәдә йөри башлаячак! Кирәк булса, дарелфөнүн мөдәррисләрен түмәнбашлар дәрәжәсенә күтәрү дә әлләни ерак йөрмәс...

Халык сарык көтүе шикелле мәнсез дә һәм сукыр да түгел. Солтанга тиз арада «Сөләйман-Кануни» атлы ләкабне тагып өлгерделәр. Анысы гына бер хәл, Варшава, Венеция, Парижлардан, хәтта күз күрмәгән Лондон каласыннан да һич көтмәгән илчеләр даирәсе килеп төште. Кулларында — корольләрнең солых кәгазьләре, телләрендә — соклану һәм мактау.

— Син әйләнешкә керткән салым тәртибе турында ишетеп, минем король моңа гел мөкиббән.

— Безнең байгуралар синең мәмләкәттәге байлык-иминлекнең яшерен серен һич төшенә алмый интегәләр.

— Аурупадагы алманнар да, испан белән норман сәрдәрләре дә синең гаскәрендәге тәртипкә сокланып шаклар ката. Яугирләрең пашалар әмиренә пәйгамбәрләр сүзенә ышанган шикелле үк бердәм буйсыналар. Яуда синекеләр шәһит китүдән дә куркып тормый. Синекеләр сәрдәрләрдән шәраб белән икмәк таламыйлар, яу кырында алар суда болгатылган арпа белән тукланырга да риза. Ничек пәйда булды мондый тәртип? Шуның серен, зинһар өчен, безнең корольләргә аңлата күр...

Сөләйман солтанның кычкырып көлүдән бүтән чарасы юк, ә күңелне әллә нинди шайтан кытыклап тик тора. Бүген кунак булган бу илчеләр еллар буена яшәргә калалар бит, тешләре үтсә һәм зиһеннәре житсә, тора-бара барысын да төшенерләр әле.

*Дәвамы киләсе санда*

[21] Дарелфөнүн — университет.



Гарифҗан
Мөхәммәтшин

# КОЯШ ЧЫГАҺӘРКӨН САЕН ИРТӘН...

РОБАГЫЙЛАР

* * *

Яэҗүҗ-мәэҗүҗ басып алды дөньяны –
Уй-хәсрәтсез икән бүген кем жаны!..
Бертуктаусыз низаг, сугыш, ызгыштан
Сүнә икән хәтта җанда ил гаме.

* * *

Ялган менсә, алдау менсә мөнбәргә,
Сулау өчен һава бетә мөңнәргә –
Бу ил бүген тынчулыктан тыны беткән,
Давыл көтеп, тынып калган бер мәлдә.

* * *

Үзе белән һәркемнең үз Мәүләсе –
Мавзолейда һаман Ленин гәүдәсе,
Коммунизмның кояшы сүрелсә дә,
Рәсәй буйлап йөри кара шәүләсе.

* * *

Нәрсә булды сина, нәрсә булды, авыл,
Урамында ишетелми бала-чага шавы,
Өсләреңнән кабат үтте мәллә таптап
Күзләрен кан баскан Явыз Иван явы?..

* * *

Тезләнгәндә уйлап тезлән – кирәкме?
Бер тезләнгәч тормаганнар сирәкме?!
Туры атлап үтү кирәк тормыш юлын,
Яшен сугып туктатканчы йөрәкне.

---

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН (1941) – *шагыйрь; «Килегез, дусларым», «Бәхет», «Робагыйлар бакчасы» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Балтачта яши.*

* * *

Сүнми кояш күкне болыт каплап кына,
Мантымассын дөньяга үч саклап кына,
Бар дөньяны гаеп итеп, үзен аклап,
Үз-үзенә ләззәт таба ахмак кына.

* * *

Һәркөн саен арта бара «акыллылар»,
Искә-анга килмәгәнне такылдыйлар,
Язгы таңда йокы бирми, туйлар ясап
Бакылдашкан бакалар күк бакылдыйлар.

* * *

Нигә кеше эзли икән гел хакны?
Хаклык белән тапкан икмәк ник татлы?
Тик бу илдә хаклык эзләп йөреп кенә
Икмәк-тозга туюларың бик шартлы...

* * *

Диңгезләрнен, күрдем, инен-буен беләм,
Тормыш — диңгез, аны кичү кыен, беләм,
Кичәласың киерелеп йөзсәң генә,
Мавыкмасаң юк-бар белән, уен белән...

* * *

Ялгышулар була алмый язмыштан,
Ялгышулар килеп чыга азмыштан —
Ялтыравык ямьнәренә бу хаятнең
Күзең төшеп, акылыңнан базмыштан...

* * *

Тәүгеләргә булмый юлның такыры,
Эзләүчегә юк юлларның ахыры —
Гомер буе юлда булыр егетләрнең
Зур бәхеткә лаеклы һәм батыры.

* * *

Бу яшәеш бер болганчык базар икән —
Читтә торсын мең бизәкле мозаикан,
Барын ташлап жир читенә качар идең,
Качып булмый, Аллаһ шулай язган икән...

* * *

Кеше бүген ялгыз меңнәр арасында,
Беркем белми үзенең кая барасын да,
Барысы да кыйбласыз бер хәрәкәттә,
Хәрәкәте түгел ләкин бәрәкәткә...

* * *

Гомер үтте — үпкәләргә елларгамы,
Әллә инде утырып бер еларгамы?
Гомер үтте — артта берни эзе юк,
Аллаһымнан яңа гомер сораргамы?!

* * *

Бер карыйсың, әллә ничек уйландыра,
Әйтерсең лә яшәү тоташ уйдан тора,
Өйдән чыксам, ыгы-зыгы, узыш-чабыш,
Юк ла, яшәү бөрөзлексез туйдан тора...

* * *

Бу дөньяда бары да кыска гомерле,
Күр син әнә учактагы күмерне —
Әле генә ялкынланып яна иде,
Күз алдында пыскый-пыскый сүрелде...

* * *

Ыслый-ыслый син мине гел котырттың,
Йөрәгемә шик-шөбһәле ут төрттең —
Синең кебек әверелмим шайтанга дип,
Бакчама чыгып бер чәчәк утырттым.

* * *

Бу башымнан үтте бик күп кыраулар —
Чәчләремнең агаруы шулардан...
И Гарифҗан, инде хәзер нинди файда
Чәчең нигә агаруын юраудан?!

* * *

Күп яшәдем ахры инде дөньяда,
Туйды ахры инде миннән дөнья да.
Алай дисәң, дөнья иске искесен дә,
Туып килгән кояшлы көн өр-яңа!

* * *

Картаюлар шул буладыр, күрәсең,
Төшләреңдә әллә ниләр күрәсең,
Начар төшләр кермәсен, дип кичләрен
Кат-кат укып ятам «Әлхәм» сүрәсен...

* * *

Үтте гомер, унга-сулга карамадым,
Золым белән ерак булды араларым,
Илдә инде башка җилләр исә бүген —
Коллары без шул имансыз замананың.

* * *

Күрәсең, бу бер уртакул түрәдер,
Бик биектәгеләрне тик күрәдер,
Түбәннәргә өстән карап, бәйдәге
Усал эт күк котырынып өрәдер.

* * *

Картайгач та яшәүләрнең мәгънәсе бар
(Өлкәннәрнең сынау узган кәгъбәсе бар!),
Аллаһының үз кәгъбәсе булганнарны
Җәннәтенә кертәм дигән вәгъдәсе бар!

* * *

Бар әле, бар шашып дөнья куасы —
Бар бит әле оныкчыклар туасы!
Уйланам да, барысына әзер мин, дим,
Житәр микән тик йөрәкнен куәсе?..

* * *

Кайчакларда карыйм көзгегә мин,
Уфтанма ла, әле көз генә, дим,
Көзнең була алтын чаклары да,
Алтын көзен житәр, түз генә, дим.

* * *

Сөбханаллаһ, күз тимәсен, күр син, ә,
Нинди кызлар үсеп килә күршедә —
Илле ел гомерне иннән алып ташлап,
Гашыйк булыйм мәллә, димен, берсенә!

* * *

Керфекләрен чәчләремне тарасын,
Кояш булып балкып торсын карашын,
Тик мәхәббәт назы гына якынайта
Өзелеп сөйгән гашыйкларның арасын.

* * *

Була үтә яраттырган чакларын,
Бик яратып карап торган чакларын,
Бу арада әллә нигә бик ешайды
Шикле итеп тамак кырган чакларын...

* * *

Кабызыйм, дип, жанында наз учагын,
Чәчәк ташыдым тутырып кочагым,
Салкын жанга булмый икән ут кабызып,
Барысы да әрәм китте, пычагым...

* * *

Әллә нинди хәйлә-тозак корсаң да,
Йөрәкләрне бер-берсенә орсаң да,
Бозлы жанны булмый икән эретеп,
Йөрәгенә утлар ягып торсаң да...

* * *

Минем кебек януларга кемнәр чыдар —
Күлгә чумсам, күлнен суы кайнап чыгар,
Ә югыйсә араларда киртә дә юк —
Гомер үткән, син дә сынар, мин дә сынар.

* * *

Кояш чыга һәркөн саен иртән,
Былбыл сибә дәртле жырын куктән,
Таң жилләре сыйпап үтә биттән —
Бәхет өчен нәрсә житми бүтән!

# «Казан утлары» архивыннан




*Шагыйрьләр Рәшит Гәрәй һәм Әхмәт Рәшитов (сулдан икенче, өченче) Марий Эл Республикасының Бәрәңге посёлогында район зыялылары белән. 1990 ел.*



*Фәнзаман Баттал. 1969 ел.*



*Ярты гасыр элек төшерелгән фоторәсем. Сулдан уңга: Хәсән Туфан, Габдрахман Минский, Нәкый Исәнбәт, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Әнвәр Давыдов. 1965 ел.*



*Беренчеләрдән булып Тукай премиясен алган әдип Әхмәт Фәйзине соңгы юлга озату. Халык агымы Г.Камал театрыннан кузгалып, Пушкин урамы буйлап бара. 13 август, 1958 ел.*



Рәшит
Бәшәр

# АЧЫК КҮҢЕЛ ИШЕГЕМ

## Яктылык эзләү

Куначада йоклый әтәчләр,
Килә генә офык алланып.
Илләр гизеп тузган биштәргә
Ипи тыгып куям, бал ягып.
Юлга чыгам... Баш очымда ук
Ак йолдызлар тора эленеп.
Күкләр тарта... Шул йолдызлыкта
Яшәдем лә бугай мин элек.
Гашыйк булгач таңгы гөлләргә
Сикерепләр җиргә төштем дә,
Ак йолдызлар ерып күкләрдә
Йөрим инде хәзер төшемдә.
Күкнекеме, җирнекеме мин,
Яшим әле менә исән-сау.
Ерагая ләкин йолдызлар,
Биегәя һаман менәр тау.
Гөлдән салкын чыклар сибелә
Бәхет эзләп арган аякка.
Яктылыкка тәмам сусадым,
Кояшлырак көннәр кай якта?
Илләр гизеп тузган биштәрем
Иңнәремне баса... Таң ата.
Белмим, нинди көннәр көтәдер
Мин барасы ерак тарафта?
Юлга чыктым... Барып җитәрмен,
Житәчәкмен, әйе, барыбер.
Кыргый җәнлек чапкан урманда
Бер яктылык, бәлки, табылыр?!

Якты алан, бәлки, табылыр...

---

Рәшит БӘШӘР (1949) – *шагыйрь һәм прозаик; «Иртәгә дә яшисе бар», «Сандугачлы бишек», «Ачык капка» һ.б. китаплар авторы. А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Чаллыда яши.*

## Шагыйрь

*Булмамын, юк, картайсам да, чын карт кеби.*
Г.Тукай

Ул күчереп яза гына –
Шигырь – Ходай әмере.
Гөлгә кунган Былбыл бит ул,
Шаһ дәүләтнең Әмире.
Жирдән күккә күпер салган
Илаһи бер Илче ул.
Картайса да, япь-яшь калган
Сәях жанлы Юлчы ул.

## Йолдыз күләгәсе

**1**

Жан сызлаган кара төннәрдә
Ай шәүләсе керә өемә.
Бер чарасыз ятам уйланып,
Колак салып жилләр көенә.

Яктылыкка сусап ятам мин
Жан сызлаган кара төннәрдә.
Түтәлемдә гөлләр сулмасын,
Сулар сибим иртән гөлләргә.

Шингән гөлләр балкыр тураеп,
Гөлгә башын ияр һәр юлчы...
Жан сызлаган кара төннәрдә
Якты булып төнгә тулыймчы.

Кояш булып күккә куныймчы,
Бал кортлары гөжләр гөлләрдә...
Мин янәдән ятам терелеп
Жан сызлаган кара төннәрдә.

**2**

Арды жаным, бик нык тундым мин,
Жылы эзләп озак йөрдем мин.
Карурманны ерып кердем мин,
Үләннәрдән чатыр кордым мин.

Төшәр-төшмәс кояш нурлары,
Жилләре дә исәр-исмәс гел.
Алан тып-тын. Телсез гөлләре.
Үзем дә мин иләс-миләс гел.

Яуды янгыр, шырпым чыланды,
Дертләп сүнде ялгыз учак та.
Төнге жиллә яфрак леперди,
Йолдыз салкыннары – кочакта.

Жылынырмы жаным? Кем белгән...
Иле тоташ салкын күләгә.
... Әллә янгыр, әллә күз яше
Тамып тора төнге гөлләргә.

## Гасырлар кайтавазы

**1**

Жәйрәп ята илдә яшел болын,
Урман тулы жәнлек, кош-корты.
Мәңгелеккә диеп салынгандыр
Иркен даладагы таш йорты.

Кошлар йоклый гөлләр арасында,
Ай нурына бишек эленгән.
Сөт тамчысы ап-ак мендәрчеккә
Тәгәрәде сабый теленнән.

Йорт каршында кешни ак аргамак,
Иртә таннан хужа жиккәндер.
Башын иеп килеп чыга урыс,
Салым түләр көне житкәндер.

Күкселләнеп тора ерак урман,
Урманнарга илтер юл озын.
Бала-чага чабар жиләк коеп,
Гөрләп торыр Ватан көнозын.

**2**

Бисмилласыз өйләр. Катнаш нихак.
Азды-тузды татар даласы.
Хәлсезләнгән милләт баласы без,
Гамьсезләнгән халык баласы.

Мәскәү елмайганда елмаябыз,
Йөзен чытса, йөзне чытабыз.
Дивардагы келәм түгел инде,
Сүсәрепләр беткән чыпта без.

Ничек инде манкорт үрчемәсен,
Утка ат та сабый бишеген.
Ил сорап та, тел сорап та халкым,
Шакып карый урыс ишеген.

Ташкыялар калкып чыга алда,
Азатлыкка илтер юл озын.
Илдә август. Сары басуларда
Соры төлке уйный көнозын.

## Ике саташу

### *Штрафбат*

Хөкем ителгәннәр үлемгә...
Карлы биеклекне алсалар,
Бәлки акланырлар иде лә.

Алга китте рота кар ерып.
Кар эчендә ялгыз... Яланбаш
Ятып булмый иде каңгырып.
«Үрмәлә... Кирәк үрмәләргә,
Кирәк бары үрне менәргә!»
Сул аяк юк... Төшеп калгандыр,
Төшеп калган табан җылысы.

*... Чыгып килә иде урманнан,*
*Гөмбә белән тулы тырысы.*
*Керфекләргә куна кичке нур,*
*Табаннарда үлән җылысы.*
*Битен юды салкын чишмәдә,*
*Су түгел лә, ап-ак кар икән.*
*Кар да түгел... Юк, кар түгел бу,*
*Әллә ниткән куе кан икән...*

Ул күзләрен ачты. Көн суык.
Рота киткән алга. Еракка.
Бер уч җылы гына бары тик
Оялаган хәлсез йөрәккә.

*... Кайтып килә инде урамнан,*
*Кул авырта, авыр тырысы.*
*Кинәт ярып керде борынны*
*Җирән алашаның тир исе.*
*Әтисе бит. Кая ашыга?*
*Манма тиргә баткан аты да.*
*Ат чаба. Дугасына кунып*
*Сыерчыклар таган атына.*
*Таныш капка. Әни. Ак көчек.*
*Кайтып җиттем, рәхмәт яугыры!..*

Күзен ачты янә. Көн суык.
Өскә ява пуля яңгыры.
Кара керфекләргә боз каткан,
Канлы ботка баткан тар каеш.
«Кай төш соң бу, ә? Кай төш?»
Төшләнде ул үлем аралаш:
«Өйгә кайтышым бу... Кайт... Кайтыш...»

Тәнен салкын җилләр өшетте.
Күзен йомды егет. Саташты.
«Кара урман» көен ишетте.

Беткән иде рота кырылып.

Сынык тәртәләрен өстерәп,
Тик ялгыз ат йөри кар ерып.

***Чишмә челтери***

*Зәңгәр, зәп-зәңгәр иде күлмәген,*
*Ак чәчәкләр иде зәңгәрдә.*
*Чиләгенне янтайтып су эчтем*
*Чишмә сукмагында... эңгердә.*
*Әйләндеме башым кинәт кенә,*
*Чайпалдырып минем күңелне,*
*Тар сукмакның яшел гөлләренә*
*Чиләгеңнән суың түгелде.*
*Чырык-чырык көлден... Кичке тынлык*
*Якты көлүенә күмелде.*
*Пышылдады кемдер колагыма:*
*«Кочаклап бер үпче сенелне!»*
*Кем эндәште, белмим. Фәрештәме*
*Иңнәремдә канат кагынды.*
*Чибәркәйнең алсу иренәнә*
*Кичке шәфәкъ нуры ягылды.*
*Күккә тигән биек агач очы*
*Ал нурларга әнә буялган.*
*Бала чыгаргандыр. Бер ана кош*
*Аска карый алсу оядан.*
*Житәкләшеп төштек чишмәгә без,*
*Көянтәсе кызның иңемдә.*
*Кытыклый колагымны сулышы,*
*Кулым салам җылы биленә.*
*Тирән тынлык. Кичке шәфәкъ сүнә,*
*Челтерәве тына чишмәнең...*

... — Күзеңне ач, егетем, нишләдең?
Санитар кыз канлы гимнастёрка
Төймәләрен чиште ашыгып.
Эре-эре күз яшьләре кызның
Чирәмнәргә тамды таш булып.
Ыңгырашты... Кулы хәлсезләнде,
Ә аннары жиргә тезләнеп,
Йомдырды ул япь-яшь егеткәйнең
Кичке шәфәкъ сүнгән күзләрен.

Егет башын салып яткан үлән
Кан табына әнә буялган.
Каурыйлары көйгән ялгыз бер кош
Үрелеп карый кара оядан.

Тынычланды дөнья... Атышлар юк.
Келт-келт-келт... Сәгать теле йөри.
... Бик еракта бала чыгара кош,
Бик еракта чишмә челтери.



Алмаз
Хәмзин

# ШАМКАЙ

БӘЯН

## Аны белмәгән кеше юк

*Әгәр Шамкаев Рәшит булмаса —*
*Шамкай да булмас иде.*
Минтимер Шәймиев

Кем сон ул? Каян чыккан исем? Исемме ул, кушаматмы?

Үзе турында чыгыш ясаганда, ул: «Шамакайдан ерак китә алмаган Шамкай!» — дип җиффәрә. Мишәрлеге белән исә тәбәнәк, юан, килбәтсез гәүдәсе белән мактана, калын кашы белән горурлана, һич көтмәгәндә җырлап-биеп тамашачыны мөкиббән китерә. Мәзәк сөйләве үзе бер тамаша.

Исемдә түгел хикмәт — җисемдә!

Бу җисемгә соңгы вакытта байтак тел-теш тигезәләр. Үзе әйтмешли, «авыз чайкыйлар». Көнләшәләр дә инде... Әйе шул: ул бик актив, аны концертларда, юбилейларда, мәҗлесләрдә катнашырга чакыралар, ничә карама телеэкраннарда балкый, сабантуйлар түрендә дә Шамкай. «Кайвакытта үтүк табасында да шәйлим мин аны», — ди Шәрәфи. Шамкайны белмәгән кеше юк. Әйбәтме, начармы — анысы башка мәсьәлә. Шунысы ачык: ул — милли мөлкәт. Милләт кочагында барлыкка килгән, аның хозурында канатланган, алкышларында үсенгән. Шамкай — татарның көзгедәге чагылышы. Ләкин милләтнең хәзергесе һәм киләчәге Шамкайда булсын диясем килми, дөресрәге, Шамкай тасвирлаганча, Шамкай сөйләгәнчә... Аның мәзәкләрендә безнең яшәешкә, тормышка каһкаһә ята. Вазгыятьне, гамәлләрне ул уч төбенә куеп, «менә без шушындый» дип кенә бирә. Инде шул билгеләмәдән соң үзебез нәтиҗә ясарга тиеш. Без бит үзебез дә Шамкай көлдергәндә, бот чабып, күз сөртеп, коелган тешләрне күрсәтмәс өчен авыз каплап кына утырабыз. Анда-монда «ай-яй оятсыз анекдот сөйләде» дип, өйгә кайткач, оялып, нәтиҗә ясыйбыз. Күп тә үтми, янадан өелешеп, хәтта балалар белән, концертына ыргылабыз. Кем кушкан безгә анда балаларны йә булмаса әниләрне, әбиләрне алып барырга? Кем тәрбияли ул балаларны? Без — үзебез бит. Шамкай мәзәкләреннән начарлык кына эзләп утырырга кирәкми. Әйтик, оятсызрак сөйләнә торган жирендә кешенең әдәпсезлеге, түбән культурасы

---

Алмаз ХӘМЗИН (1947) – *прозаик, шагыйрь; «Озак яшисегез килсә» китабы һәм күп җырлар, юморескалар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

чагыла, әхлакка төреп сөйләнә торган урыннарында безнең кайбер җитәкчеләрнең булдыксызлыгы, наданлыгы күрсәтелә, исерекләр булып кыланауы бу социаль төркемгә мыскыллы көлү аша көчле нәфрәт уята.

Менә шушы нечкәлекләрне галәмәт оста чагылдыра белүенә сатылабыз без Шамкайга! Юкка әйтелми: «Дөньяда да, урыста да мондый артист юк, татарда да ул берәү генә!» — дип. Ничек шулай ургылып популяр булды соң әле Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының ким-хур булмаган элеккеге артисты Рәшит Шамкаев? Аны хәзер белмәгән татар кешесе юк. Театрдан китсә дә, танылуы һаман үсә. Юкка китте бугай, дип уфтанып та куябыз кайчакта. Нинди рольләр уйнады, нинди образлар тудырды бит! Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ында Григри — керәшен татары образын гына исегезгә төшерегез. Әле ул — Шамкайның чын артист түгел, сәхнә эшчесе булып йөргән чагы. Ну уйнап та күрсәтте инде бу рольне. Хәтта Мәскәүдән килгән комиссиянең бер яһүде, спектакльне тикшергәнче үк, урыныннан торып: «Товарищи, прежде чем обсуждать спектакль, покажите, пожалуйста, того артиста, который играл Григри — крещённого татарина», — дип сораган. Безнекеләр: «Он у нас рабочий сцены», — дип әйткәннәр. «Как, у вас и рабочие так играют?!» — дип гаҗәпләнгән теге яһүд. Икенче көнне үк Шамкайны 62 сум 40 тиенлек окладка утыртып, «ярдәмче артист» дип, театрда приказ чәпәгәннәр.

Шамкайга нинди генә рольләр бирелсә дә, ул аларны күпертеп уйный. Менә, күз алдына китерегез: «Портфельле кияү» спектакле бара. Шунда ул чыга да, самогонның гайрәтен күрсәтү өчен, авызыннан керосин бөркеп, ут төртә. Билгеле, халык шакката инде бу могҗизага.

Артистлар арасында, гадәттә, «отсебятина» дигән тискәре нәрсә бар, ягъни үзеннән кушу. Бу нәрсәне куллануны режиссёрлар тыялар. Әгәр дә мәгәр, кайберсе бик отышлы була икән, режиссер кайчакта килешергә дә мөмкин. «Зәңгәр шәл»дә бер күренеш бар — урмандагы качкыннар. Соңгы өлеш тәмамланганда, Илдар Хәйруллин белән Хәлим Җәләл «сальто» ясыйлар. Менә шунда Шамкай өстәл өстенә утырган җиреннән, кызып китеп, ике кулына сикереп төшә дә музыкага тыпыр-тыпыр биергә тотына. Шамкай уйлап чыгарган бу алымны Марсель Сәлимҗанов үзе дә хуп күрә һәм әлеге күренешне шушының белән тәмамлап, пәрдәне ябып куя торган итә.

Шамкайның мутлыгына таянып, кайчагында Сәлимҗанов аңа шаян эпизодлар тәкъдим иткәли. Комсомолец Пүләнне уйнаганда, Марсель Хәкимович аңа: өстәлдә йөргән чебенне тот та ботын йолкып утыр, ди. Бер-ике репетициядә Шамкай ул әйткәнне эшләп утыра, ләкин соңыннан булмаган чебен тунауны оныта. Марсель дә бу мәсьәләне кузгатмый. Берзаман, байтак спектакльләр уйналгач, искә төшә бит бу нәрсә. Шамкай, өстәлдә йөргән чебенне күз алдына китереп, учына себереп ала да менә утыра ботын умырып. Янындагы Дунаев телсез кала, Хәлим Җәләл нишләргә белми, бөтенесе — өнсез. Менә-менә спектакль өзелә дигәндә, көчкә ерып чыгалар. Шунда сәхнә артына Марсель Сәлимҗанов йөгереп керә дә, бик каты ачуы килеп: «Нигә син анда чебен ботын йолкып утырасын?» — ди. «Соң, үзегез кушкан идегез бит», — дип җавап кайтара Шамкай. Сәлимҗанов кулын селтәп китеп бара. Исенә төшкән бугай.

Шамкай театрда характерлы рольләрне уйнау остасы булды. Үзе әйтмешли, ул беркайчан да зур-зур рольләргә дәгъва кылмый һәм бервакытта да рольсез утырмый. Бу яктан ул Марсель Сәлимҗановны зур хөрмәт белән искә ала һәм аңа рәхмәтле. Ләкин пенсия яшенә җитеп, башкалар шикелле театр кырыендарак урамнан фатирлы була алмавына күнеле кителә. Театрга тамашачы Шәүкәтне, Шәрәфине, Тажине, Нәҗибәне, аны һәм тагын берничә шундый яраткан артистын күрергә дип килә иде бит. «Директорыбыз Шамил Зиннурович

та минем гозер буенча йөрмәде түгел, йөрде», — ди ул. Ләкин бездә бит, бөек шәхеснең язмышын ниндидер билгесез бер «винтик» хәл итә дә куя. Парадокс — бөтен халыкка ошый Шамкай — тик «берәүгә» генә ошамый. Китте Шамкай театрдан, үпкәләп түгел, пенсиягә чыгып, ләкин югалып калмады.

...Без инде сугыш балалары, дип башлады ул бервакыт үзенең тормыш юлы турында сөйләүне, биш яшькә хәтле сугыш эчендә үстек. Тамак туя торган чак түгел, ачлык-ялангачлык, юклык... Шуңа чыныккан да инде без.

Бервакыт безнең Ярмәккә Минзәлә театры килде. Мин артистларның уйнаганнарын исем-акылым китеп карап тордым. Ул Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» дигән пьесасы иде. Артист буласы килү теләге йөрәгемне яндырып алды. Шуларга ияреп Минзәләгә үк киттем. Андагы бер артист, исемен әйтмим инде, мине «йөрмә монда күз алдымда буталып» дип этеп кенә җибәрде. Миңа ул йолкыш песи баласын куып җибәргән кебек булды. Ләкин анда Сабир абый Өметбаев бар иде. Аның киңәшләре минем алдагы тормышымда, иҗатымда маяк булып барды. «Улым, — диде ул, — сез бит мишәр, телегез мишәрчә, театр өлкәсендә чиста татарча сөйләшергә кирәк». Мин әйтәм: «Өйрәнермен, Рәшит Ваһапов егерме ел җырлап та һаман мишәр булып калган», — дим. Шулай итеп, мин елый-елый трактор «дустым» янына кайтып киттем.

Вакыт үтә торды. Минем «чи-пи» килә торган приёмнигым бар иде, шуннан Казанны тоттым. Казан каласында театр училищесы эшли, үзенә сәләтле яшьләрне чакыра, дигән белдерү ишеттем. Сөхәриләремне киптердем дә вагон тамбурына сикердем. Казанга сыпырдым. Килеп җиттем дә, училищега бардым. Алмаска булдылар: кыяфәт юк, авыл малае, буй кыска — Ходай бирмәгән. Ширияздан Сарымсаков, моннан нинди артист чыксын, дигән... Ләкин Празат абый ана каршы төшкән, без укытабыз аны, син укытмыйсың, дигән.

Бар чүтеки әйбәт кешеләр!

Театр училищесында уку миңа, ни дип әйтим, инешне йөзеп чыккан кебек кенә булды: мәтәлчек атарга кушсалар, ике кул белән йөгерә идем.

Минзәләдәге сөйләшүдән соң татар теленә нык игътибар итә башладым. Чиста итеп татарча сөйләшергә өйрәндем. Училищены тәмамлагач, Минзәләгә барырга максат куйдым, мин шул театрда эшләячәкмен, дидем. Минзәләдә яхшы эшләдем, әйбәт рольләр уйнадым, җибәрмәскә иттеләр. Ике елдан соң Казанга әйләнеп кайттым. Театрга алмыйлар, һаман шул: кыяфәтем юк, буй... Ләкин йөрәк зур, белеп торам, мин бит Гамлетлар уйнарга дәгъва кылмыйм, миңа бәләкәй рольләр дә бик житкән. Барыбер, мәйтәм, мин кирәк булачакмын! Барыбер, барыбер...

## Ярмәккә сәфәр

*Ярмәкләргә кайтыр идем*
*Алмачуар ат җигеп.*
*Әгәр кулда атым булса,*
*Йөрмәс идем дә чыгып.*

Рәшит Шамкай[1]

Хәмзәнең «Биш татар» юмор төркеме белән концертлар куеп, акча эшләп алган яңа «буханка»сы[2] иплэп кенә Самара өлкәсенә юл тотты.

Җәйге көннәрнең иң матур чагы. Машина әле урман кырыйларына, әле су буйларында тукталып, юлчыларын табигать белән хозурландырып бара. Кырда игеннәр баш чыгарган, юл кырыендагы чирәмлекләрдә тузганаклар пумалаланып, чәчләрен акка мандырган, һавада серкәләре кайный. Гомере буе

[1] Алга таба эпиграфларда Р.Шамкаев шигырьләре бирелә.
[2] «Буханка» — «УАЗ» автобусын үртәмеш.

бал корты чагудан куркып яшәгән Сабир машинаның чираттагы туктавында ян ишеген ачты да куаклыкка йөгерде.

— Мине ташлап китмәгез тагын! Теге вакытта да хур иттегез, — дип, агачларның куерак жиренә кереп югалды.

— Тагын мунча себеркесе жыя торгандыр инде. Өченче мәртәбә туктата бит. Әйдәгез, без дә бераз һава сулап алыйк!

Шәрәфинең табигатькә мөкиббәнлеген кем генә белми. Аңа ияреп Жәлал дә баскычтан төште.

— Шәп бит, егетләр, һавасы, ә!

Тирәнрәк сулау өчен, Шәрәфи кулларын күккә чөйде.

— Аяклар оеган, — дигән булып Жәләй чүгәләргә кереште, гимнастика ясый, янәсе.

— Кичә, Сабирның Балык Бистәсендә, глава мунчасының себеркеләренә сокланып, гомер күрмәгәндәй чабынуына игътибар иткәнсездер. Иренми егет, вакытны әрәм итми, жаен таба белә, — дип, Шәрәфи куаклыктагы Сабирны мактап алды.

— Күрәсең, каен себеркесенең авырткан буыннарына шифасы тигән.

— Безгә дә комачауламас иде Ярмәктәге абыйга бер-ике бәйләм, — дип, әлегә хәтле тавышы чыкмаган Рәшит алда утырып барган утыргычыннан төште.

— Ярый, Сабир жыйганнардан сайлап бирербез әле. Менә син, Рәшит, безне алып кайтып авыл халкына изге гамәл кылырга уйлагансың. Ягъни мәсәлән, авылдашларыңа олы хөрмәтеңне белдерәсең, рәхмәтеңне әйтәсең, истәлекләр, хатирәләр аша үткән гомерләрен искә төшерәсең. Бергә-бергә үткән гомердә кыенлыклар булгандыр... Жиңүләр, жиңелүләр... рәнжешләр... Тормыш булгач, бар да була. Ләкин менә шуларны лаеклы кичеп, берәүгә дә үпкә белдермичә, ирешкән уңышларыңа, дәрәжәләреңә таянып, аларга рәхмәтле була алу — шәхеснең бөеклеген аңлата. Син бүген шуларның берседер!

— Шулай шул, тизрәк кайтып житәргә иде, Искәндәр абый борчыла торгандыр.

Рәшит сүзенә ияреп, барысы да машинага кереп утырдылар.

— Менә хәзер Сабир кулына берәр чәчәк тотып киләчәк. Карап торыгыз, — дип сүзен дәвам итте Шәрәфи. — Отвлекающий манёвр...

Чыннан да, машинага таба каен себеркесе бәйләме белән кечкенә генә зәңгәр чәчәк тотып Сабирның килүе күренде. Жырлаган була.

...Зәңгәр чәчәк минем төс ул,
Ал да түшеңә када!

— дип, Шәрәфинең түш кесәсенә кадап куйды.

Көлештеләр.

— Әй, егетләр, кичәге мәжлесне әйтәм әле. Сәнгать жанлы, әдәбиятны, артистны хөрмәтли белгән район башлыклары да байтак бит, ә! — дип Хәлим Жәлал Балык Бистәсендәге әлеге сыйлауны яңадан искә төшерде. — Табын, мин сиңа әйтим!.. Урман!.. Һава!.. Мунча!.. Бер дә «Мин глава!» дип кәпрәеп йөрмәде Хатыйп туган! Безне мунчага алып кереп ләүкәсендә бишебезне бер итеп чапты. Ләүкәдә хуш исле печән ястыгы! Ну, малай, таза да кеше икән! Мин үзем эссегә әллә ни түзем түгел, ул кадәр мактана алмыйм, ә бит ул, бер тапкыр да парнойдан чыкмыйча, барыбызны жиренә житкереп, тәмләп, тәнгә бал ышкып дәвалады. Вәт аны врач дисәң дә ярый. Инде үләм, житте дип уйлыйсың, ул тагын таш өстенә су чыжлата. Карале, Рәшит, син ничек чыдадың шул галәмәткә? Син бит утыз градуслы жәйге эсседә дә үләм дип ятасың?

— Түзәсең инде, артист хуҗаның ишәге бит.

— Һай, егетләр, андый җәннәтне бүтән җирдә күреп булмастыр инде.

— Булыр, булыр, безгә бердәмлек кенә кирәк. Сездәй-бездәй егетләр татарда бишәү генә! Шулаймы, Сабир?

— Шулай, Хәмзә!

— Ә парнойдан соң, егетләр, мунча ишегалдындагы яңа чапкан җиләкле печән түшәге! Шәп-шәрә килеш, әле яңа туган бала сыман ауныйбызмы — ауныйбыз. Зәңгәр күктә йөзгән ак болытларга карап, бу дөньяның үзе җәннәт икәненә инанасың!

— Шулаймы, Шәрәфи, Сабир, Рәшит, Хәмзә!

— Шулай, әйдә, «бахбай», алга — Ярмәккә!

Хәмзә машинасын алга ыргыды. Шул мизгелдә җырлап та җибәрде.

Кама буе — туган як ла,
Гөлләр үсә торган як.
Гүзәллеге күңелләрдән
Җырга күчә торган як!

— Их, дусларым, ямьле дә соң безнең яклар! Бөтен Татарстанны әйтәм. Әнә, карагыз, Чулманның теге ярында Балык Бистәсе җәелеп ята. Глава — молодец! Инде күргәнегезчә, эш кешесен дә, артистны да хөрмәт итә белә. Шуның өчен үзен дә яраталар. Эшләре дә гөрләп бара. Район күрсәткечләре дә мактанырлык.

— Сезнең кебек бөек артистларны ничек хөрмәтләмисең инде, Равил абый. Сез бит Хәлим абый белән бөтен татар дөньясына мәгълүм кешеләр. Шулай булгач, районның да горурлыгы.

— Рәхмәт, Хәмзә, татлы сүзләрең өчен. Глава әле менә аерым рәхмәтен әйтте, сезне алып килгәнгә. Югыйсә мин алып килүче дә түгел идем — син идең, Хәмзә.

— Хәмзә — безнең шеф, күз генә тимәсен, — дип Хәлим Хәмзәнең салпы ягына бер көлтә салам кыстырып куйды.

Шулчак Рәшит тә:

— Безне бу сәфәргә дә Хәмзә котыртты, — дип өстәде.

Мактауларга көчкә түзеп баручы Хәмзә рульдән каерылып артына борылды да:

— Ну, ничек анда хәлләр, Сабир? — дип, теманы икенчегә күчереп алды. — Рәтләнәсеңме?

— Нәрсә рәтләнә?

— Тынычланамы, ди? — дип Хәлим Сабирның эченә төртте.

— Балык бик майлы иде.

— Котыртма әле, Равил абый, үзен дә бик яхшы состың чөгәләрне. Карагыз әле, ни... сезне әйтәм: бер Солтан авылыннан күпме бөек шәхес чыккан! Син — Равил абый, Хәлим абый, син дә Солтанныкы, тагын кемнәр соң әле?..

— Саный китсәң, күп инде ул безнең якта язучылар: Вакыйф Нуруллин, Роберт Әхмәтҗанов, Кадыйр Сибгатуллин, Мидхәт Миншин, Әхәт Сафиуллин, Гаффарлар... Бармагың җитмәс, — дип Хәлим Җәләл горурлыгына чумды. Соңыннан: — Ник, сезнең авылдан шәхесләр аз чыккан мәллә? Разил Вәлиев, Рафаэль Сәхәбиев, Зөлфәт Хәким, үзең — Хәмзә!

— Суыгыз шифалы, чишмәләрегез, инешләрегез күптер, урман-күлләр, елгалар бардыр. Тауларыгыз биектер, үзәннәрегез киндер...

— Әйе, Сабир дус, чыннан да, матур бездә табигать! Кешеләр искиткеч әйбәт. Килгәнең бар бит инде Түбән Камага, беләсең безнең якларны!..

Хәмзә кырыенда оеп барган Рәшит телгә килде:

— Беләбез, Хәмзә, күрдек, кунак та булдык. Менә рисковать итеп үзебезгә алып кайтам, эчем поша, сездәге кебек каршы алырлармы? Бездәге халык саранрак бит.

— Үзен тәсле, — дип шундук мөһер сукты Шәрәфи.

Рәхәтләнеп көлештеләр. Көлү жырга күчте:

...Чирмешән буйлары ямьле,
Ял итәргә килегез.
Эштә уңган яшь кызларны
Безгә килеп күрегез!

Машина тәрәзәсеннән «Чирмешән районы» дип язылган матур аншлаг күренде. Зур башак рәсеме ясалган бу район чигенең билгесе әлеге төбәкнең игенчелек белән генә шөгыльләнүенә ишарә ясый, күрәсен.

— Шәп тә инде, егетләр, районнарга багышлап язылган элеккеге җырлар: «Арча»ны әйтәсенме, «Минзәлә», «Сарман», «Кукмара», «Әтнә»ме? Тынлагыз әле тагын, — дип, Хәмзә «Чирмешән»не сузып җибәрде.

...Чирмешән буйлары ямьле...

— Әйбәт барабыз, егетләр, шоферыбыз — лётчик! — дип, Рәшит Хәмзәне мактап алды. — Сөйләшкән, килешкән вакытка Ярмәктә булырбыз, Аллаһу боерса.

Рәшитнең күнеле һаман тыныч түгел. Борчыла. Туганнары, авылдашлары ничек каршы алыр. Күнел дигәнең икеләнә шул, ләкин юкка. Хәмзә анын җанында ни кайнаганын сизеп кайта. Шуны белеп Рәшитнең колагына үрелде дә:

— Бер дә хафаланма, Рәшит, авылыңа күренекле дусларыңны алып кайтасын, урыс әйтмешли: «Всё будет окей!» Не хала-бала Рәсәйнең һәм Татарстанның халык артисты — Равил Шәрәфи! Хәлим Җәләл — шундый ук дәрәҗәдәге шәхес, Сабирны әйтәм — эстрада йолдызы, анын кебек нәфис сүз осталыгына житә алганнары юк әле, шулай ук халык артисты, үзе — планета исеме куярлык танылган даһи, дөньяда бердәнбер татар мәзәкчесе, актёр, халык артисты — дер селкетәбез Ярмәкне, менә күрерсен!

— Үзеңне калдырма, Хәмзә! Син — безнең житәкче, татарда белмәгән кеше юк үзеңне. Хәзерге көндә син арала ин популярыбыз!

— Соң, шулай булгач, ник боегып кайтасын. Күтәр борыныңны!

Рәшит җырлап җибәрде:

...Широка страна моя родная,
Много в ней лесов, полей и рек.

Шәрәфи жырны икенче төрлерәккә борып алып китте:

Широка страна моя родная,
Много в ней подушек, простыней.
Приходи ко мне, моя родная,
Будем делать маленьких детей.

Киң Самара өлкәсенең кырларына татар егетләренең гайрәтле тавышы таралды. Тынласыннар, ишетсеннәр — Ярмәккә бер «буханка» шатлык кайта. Эче тулы жимеш — сатира!

## Мондадыр безнең бабайлар...

*Гомер иту бик җиңел дип әйтмим,*
*Гомер иту түгел авыр да.*
*Гомер буе кылсаң гел изгелек,*
*Мәгърур исмең калыр халыкта!*

Ниһаять, машина, жыр гөрләтеп, Рәшитнең туган ягы Камышлыга килеп керде. Рәшит горурланып үз төбәгенең тарихын сөйли башлады.

— Монда, мин сезгә бәян итәсе вакыйгаларга кадәр дә, гадәти тормыш кайнаган, авыр хезмәт куеп гомер иткән тырыш халкы әледән-әле килеп чыккан ил газапларын үз жилкәсенә салып, Ходай шулай язгандыр, дип утка-суга кергән. Ни генә күрмәгән бу төбәк, ниләр генә кичермәгән газизкәйләр, сабыркайлар? Нәрсә кирәк соң, ни житми комсыз патшаларга? Жирме? Сумы? Канмы? Мең елның унында тыныч тормыш була алды микән бу илдә? Әйтегез? Йә төрек, йә поляк, йә француз, йә немец, япон, кытай, фин, әфган, чечен сугышлары — барысы да «изгелек» белән, Ходай Тәгалә «ният»е белән дип башлана. Аллабыз югыйсә бар халыкка да бирәү: нишләп соң Ул жинүчедән әүлия ясый, ә әфган, татар, чеченнән — дошман китереп чыгара? Гаделсезлеккә баш житмәслек дәлилләр. И, Ходаем, кичер, Синең исем белән искә алынган кансыз гамәлләр безнең мәмләкәттә дә санап бетергесез.

Егетләр, әнә теге урман артында, тау төшкәч, Самарадан бире, Бөгелмәдән ары, Камышлыдан унике чакрымнарда, Суыксу елгасының ярымутрау ясап аккан жирендә, Юкәтау ышыгында безнең Иске Ярмәк авылы жәелеп ята. Казан ханлыгында Мөхәммәдәмин һәм Сафагәрәйләр хан булып торганда, Ярмөхәммәт исемле кешенең бабаларын ил каршындагы зур хезмәтләре һәм батырлыклары өчен ханнар күп сандагы жир, өстәп тарханлык дәрәжәсе белән бүләклиләр. Казан ханлыгы жимерелгәч, илбасарлар бу жирдәге халыкны да буйсындыра. Заманалар узу белән, патша хөкүмәте әлеге төбәкне ышанычлы токым вәкиле Туйгилде оныгы Ярмөхәммәткә бүләк итә.

— Әллә ниләр беләсең син, — дип, Шәрәфи бик тәмләп сөйләп баручы Рәшитнең сүзен бүлде.

— Оят белмәскә!.. Үз туган ягының тарихын, кешеләренең язмышын, әби-бабаларының кемлеген һәркем өйрәнергә тиеш!

Менә алга таба тынлагыз. Рәсәй империясе бу елларда көчләп чукындыру сәясәте алып бара башлый. Бертуктаусыз барган бу вазгыять Иске Ярмәккә дә килеп житә. Чукынмаган өчен Ярмөхәммәтнең бөтен жирләрен тартып алалар һәм ул моннан китеп бара. Авыл халкы тирән төшенкелектә кала. Чөнки аларның мона кадәрле шактый нык тормыш хәлләре Ярмөхәммәтнең булдыклылыгы, халкын ярата белүе, эш-хезмәт нигезләрен яхшыртуыннан килгән була. Ярдәмчел, кинәшчел, тирән акыллы, зирәк бу кешенең китүе әйтеп бетермәслек фажига сыман кабул ителә. Киләчәктә ничек яшәргә икәнен аңлатып, үзенең бөтен йорт-жирләрен, утарларын халыкка калдыра ул.

— Элек байлар мәрхәмәтле булган, әйеме, Хәмзә? — дип куйды Сабир, Ярмөхәммәткә соклануын яшермичә. — Хәзер андыйларны аяз көнне шырпы кабызып эзләсәң дә очрата алмыйсың.

— Алар, Сабир, укымышлы да, зиһенле дә, тапкыр да булган. Хәзергеләре караклыктан, комсызлыктан туган әтрәк-әләмнәр генә. Мондый юл белән байлык туплаган кешегә зыя-тәрбиянең кирәге шуның кадәр генә. Укымышлы, белемле булсаң — урларга ярамаганны аңлыйсың бит ул.

— Димәк, безнең белән наданнар хакимлек итә.

— Шулай килеп чыга, Хәлим абый. Талантлы кеше хакимияткә үрмәләми.

— Жә, ярый, мин сөйләп бетерим әле, — дип, Рәшит тирән үзләштергән

туган як тарихын бәян итүен дәвам итте. — Халык Ярмөхәммәтне онытмый, яратып, ихтирам йөзеннән авылны «Ярмәк» дип йөртә башлый.

— Ә-ә, имәндә икән чикләвек. Мин кайдан шулай «Ярмәк» дигән атама килеп чыккан икән дип баш вата идем.

— Уйланырлык хәлләр бар безнең якларда, Хәлим туган. Менә тыңла. Авыл халкы Ярмөхәммәт васыятьләре белән яшәвен дәвам итә. Авыл ныгый, зурая.

— Мин үзем Ярмәкне теге Себерне яулап алучы юлбасар Ермактан дип йөрдем.

— Бер син генә түгел аны, Хәмзә, шулай уйлаучылар. Урыслар да шул теориягә бора. Алай түгел. Мин сезгә чын тарихны үзем сөйлим.

Иске Ярмәк турындагы мәгълүматларны Шәмкәй ыруыннан, Хөснетдин бабай язып калдырган истәлекләрдән дәвам итәм. Минем бабам — Ходайбирдин Сәйфелмөлек, икенче чукындыру дулкыны башлангач, бөтен мал-туарын, ишле гаиләсен төяп, Алатыр якларыннан Казанга килә. Көчләп чукындыруга түзәрлек булмагач, Башкортстан ягына юл ала. Ул якларга барганда, Ярмәк җирләре аша уза, Уфага китә. Анда да шундый ук хәлләр икән, бабай кире борыла. Күрәсез, бабай кеше бик сәламәт, таза, фикерле кеше булган. Мескен, юаш кеше булса, андый ерак, хәтәр юлга бөтен йорт-җирләрен, мал-туарларын төяп, бала-чагаларын калдырмый чыга алмас иде. 1740 елда Ходайбирдин Сәйфелмөлек хәзерге Иске Ярмәк урынына килеп төпләнә.

Миңа кагылышлы шәҗәрәнең мәгълүм тәртибе түбәндәгечә килеп чыга. Мин белгән иң беренче бабай Туканай исемле була.

— Тукай, дисеңме?

— Туканай, дим. Колак аппаратыңны көйлә, Шәрәфи. Аннан соң мин искә алган Сәйфелмөлек бабай, аның улы — Шәмсетдин, китә — Хөснетдин, аның нәселен дәвам итә — Борһанетдин, улы — Шиһабетдин, Шиһабетдиннең улы Мирзаҗан минем әти була, аннан мин туган, минекеләр — Айдар улым, Гөлнара кызым.

Шәмсетдин бабайдан сез яратып әйтә торган «Шамкай», үзебезчә әйткәндә, «Шәмкәй» ыруы башлана. Шәмсетдиннең уллары күп була, алар җиргә һәм кул көченә интекми, шуңа да һәрвакыт урта хәлләләр рәтендә яшиләр.

Менә хәзер әнием Шәймәрдән кызы Бәдрикамал ягыннан бабаларымны саныйм. Миңа мәгълүмнәре: Ядъкәр, Ваһап, Ширияздан, Шәймәрдән.

— Ай-яй, малай, никадәр эш, хезмәт башкаргансың. Афәрин! Мин үз-үземнән оялып утырам. Өч буын бабамны да белмим бит.

— Эзләнергә кирәк, Сабир, эзләнергә, архивларны актарырга. Үзеңнең нинди токымнан икәнеңне белмәү — оят та, гонаһ та... Шигырь, хикәя ятлап йә булмаса роль текстлары өйрәнеп кенә ятсагыз, нәселегезне онытырсыз әле.

Туймадыгызмы әле минем сөйләүдән, ялыктырмадыммы?

— Юк, әйдә сөйлә. Барыбер бүтән эшебез юк. Юл озын.

— Менә шул: Рәсәй дәүләтенең тотрыксыз сәясәте нәтиҗәсендә килеп чыккан фаҗигаләр Иске Ярмәкне дә читләтеп узмый. Беренче Бөтендөнья сугышыннан калган гарип-гораба, аяк-кулсыз бабайлар әле дә күз алдында. Ә инде 1917 елгы революция Ярмәкне дер селкетә. Шуннан ата — улны, ана кызны белми торган Гражданнар сугышы. Шамкаевлар нәселенә кагылган бер өлешенең русча чыганаклары бар: «Колчаковские банды заняли в 1919 году село Ярмекеево. Зверски замучили и расстреляли активных членов бедноты. Галиуллина Хайруллу — в селе, а Вагапова Батыргалия увели в Седяково, где находился их штаб, зверски расправлялись. После нескольких выстрелов раненый Батыргали продолжал стоять, тогда бандиты обезглавили его клином».

— Шуны яттан беләсеңме? — дип аптырап сорап куйды Хәмзә.

— Минем йөрәгемне сыкраткан, аңа кан саудырган вакыйгаларны ничек күңелдән белмисең ди инде. Батыргали — безнең якын туган. Ширияздан белән

Батыргали баласы Шәймәрдән бабай сөйләгәнне сезгә житкерәм: «Хәйрулла бабайны әфисирләр атып үтергәч, Батыргали абыйга әйттем: «Бар, печән чүмәләсенә кереп кач, синең арттан да киләчәкләр, дип, ә ул «күкәй тавыкны өйрәтә», диде». Бабайны башын чабып үтергәч, якыннары төнлә кача-поса килеп Сидяково авылы янындагы тау битенә күмгәннәр. Менә без бәйрәмнәрдә, мәктәп балалары белән барып, бабайның каберенә чәчәкләр куеп кайта идек.

Ишле гаиләнең әтиләрен эт аткандай атып, алай гына түгел, башын чабып үтерерлек нинди гөнаһлар эшләгән соң ул Батыргали бабай?..

Рәшит сөйләп бетергәч, барысы да дога кылып куйды. Тынлыкны:

— Әй-йе-е, — дип сузып Сабир гына бозды. Аңа ияреп:

— Булган хәлләр!.. — дип ухылдады Җәләл. — Рәхимсез заман. Шул чакларда яшәгән булсак безне нишләтерләр иде икән?

— Ике дә уйлап тормыйча атып үтерерләр иде, белдегезме? — диде Рәшит. — Шәрәфине — беренче, мине — икенче, Сабирны — өченче, Хәмзәне — дүртенче, Җәләлне — бишенче итеп. Хәзер менә мәктәп балалары каберебезгә чәчәкләр куярлар иде. Һәйкәлебезгә: «Монда атаклы «Биш татар» күмелгән», — дип язылган булыр иде.

Шәрәфи:

— Куйсалар әле ул һәйкәлне...

Җәләл:

— Куймаслар шул.

Сабир:

— Әле рәхмәт тә әйткәннәре юк.

Хәмзә:

— Менә кичәге Балык Бистәсендә куйган концерт өчен бишәр мең акча бирделәр. Мәгез!

Рәшит:

— О-һо! Яшибез икән! Жырлыйбыз, әйдә!

...Яшәгән саен яшисе килә,
Яшәреп яшиек, чын дуслар белән!

Җәләл жырның икенчесенә күчте:

...Хәмзә безнең командарм,
Дошманнарның җиңдек барын
Данлы елларда!

Жырны Рәшит бозды:

— Җәмәгать, тынычланыгыз! Авыл күренә! — Барысы да тәрәзәгә ябырылды. Без кергсе авыл башына кешеләр җыелган сыман. Рәшит пошаманга төште. Авылда берәр хәл булды микән әллә? Нишлиләр анда?

Куркып кына машинаны туктаттылар. Бәйрәм сыман кебек тә тоела. Әйе шул, кемнедер каршы алырга җыелганнар.

— Әйдә, без дә төшик әле, — дип, Рәшит машина ишеген ачты. Башкалар да урамга аяк басты. Шулчак ак каеннар төсле киенгән чибәр кызлар, тастымалларына бавырсаклы таба тотып, килеп тә җиткерделәр. Болар аптыраштa калды. Араларындагы иң чибәр кыз, тагын да алгарак чыгып:

— Хуш киләсез, кадерле кунаклар! — дип каршылаганнан соң, кыстый-кыстый тәм-томнары белән сыйлый да башладылар. Шундук кунакларны авыл халкы сырып алды. Кул биреп исәнләшүләр, итагатьле итеп кочаклашулар китте. Әйтерсең

лә һәммәсе дә шушы авылда туып үскән! Читләшү, кыенсынуларның әсәре дә юк. Шәрәфи, Шамкай, Җәләл, Сабир, Хәмзә халык арасында эреп югалдылар дисән дә дөрес булыр, чөнки аларның гадилеге туганлык хисләренә якын иде.

Беркавымнан каршылаучылар арасыннан житдирәк кыяфәтле, әмма бик канәгатьлелек тойгысы белән бер ир-зат уртага чыгып, ялкынлы сүзләрен тезә башлады:

— Кадерле авылдашыбыз Рәшит туган! Сине һәм синең якын дусларың, ижатташларыңны, туган ягына, туган туфрагына басуың белән котлыйбыз һәм дә сөенәбез. Син безнең данлы Ярмәгебезнең шөһрәтен тагын да ныграк арттыручы. Рәхмәт Сина! Сине һәм дусларыңны телевизордан гел караштырабыз. Тик бу якларда ул начаррак күрсәтә. Әллә биек тауларыбыз каплый, ләкин синең исемеңне, кылган хезмәтләреңне бернинди таулар да, киртәләр дә каплый алмый. Ижатың безнең йөрәкләргә сеңгән, үзебез дә син булып беттек: шаярабыз, көләбез, жырлыйбыз. Ягез әле, егетләр, кунаклар хөрмәтенә «Ярмәк вагын» типтерик!

Яшьләр биюенә тузан купты. Купсын, күтәрелсен! Яшәгәч яшәргә кирәк! Тузан гына түгел, Рәшит сөйләп сагыш салган батыр Ярмәк бабайлары рухы күтәрелсен!

Кунаклар кайтуга авыл ашханәсендә мәжлес оештырылган иде. Ашап-эчеп алганда артистларны атналык кунак булырлык программа белән таныштырдылар. Ләкин Рәшит дусларының кайтуын ике көнлек кенә дип аңлатты. Шуңа күрә көн тәртибе тамырдан үзгәреп, ике көнгә жайлашты. Димәк: бүгенгесенең өч сәгате — Рәшитнең Искәндәр абыйларына кайту; аннан кичен клубта зур концерт кую, иртәгесен — «Ак каен» ансамбле белән очрашу мәжлесе.

Рәшитнең абыйсы белән жиңгәсе искиткеч ягымлы кешеләр булып чыкты. Шулкадәр зур әзерлек белән табын корганнар. Аш-су, пилмән, бәлеш, табак-табак ит, каклаган каз, кош теле — ризыкның чуты юк. Искәндәр абыйсы тәкъдим иткән «шешәле нәрсәне» шундук читкә алып куйдырттылар. Ярамый, кичен эш көтә, халык каршына чыгасы бар. Сөйләштеләр, көлештеләр, жырлаштылар, елаштылар... Хәмзә шкаф өстеннән карап торган гармунны алып уйнап та жибәрде.

...Үскән чакта үскән идек
Тал тамырлары кебек...

Озак жырладылар. Жырлап арыгач, Шәрәфи авыл табигате белән танышырга чыгып китте. Жәләл шкафтагы китапларны актара. Сабир жиңгәчәй белән уртак тел тапкан. Рәшит белән абыйсы, иңнәренә кул куешып, һаман өстәл артында сөйләшәләр. Хәмзә стенага элнгән фоторәсемнәрне карый. Искергәннәр, саргайганнар инде. Бар булганы, саклангангы пыяла астына тезеп куелган. Монысы бабасы микән, әнә тегесе әтиседер, мөгаен, әнисенең рәсеме дә бар бугай... Балаларның кайсысы Равил, кайсысы Искәндәр, Рәшит икәнен аерып булмый. Әнә тегесе, бик тә моңсу күзлесе, сагыш баскан йөзлесе — Рәшит, ахрысы... Шулдыр. Рәшит, синме бу? Ник дәшмисең? Сөйлә сагышларыңны?..

## Кичке концерт

*Без але дә һаман алгы сафта —*
*Омтылабыз куйган максатка.*
*Яшьләр кебек сөеп сөеләбез,*
*Шактый гына яшьтә булсак та!*

Ярмәктәге кичке концертның могжизаларын сөйләп бетерерлек кенә түгел. Сәхнәнең түренә кунакларның искиткеч зур осталык белән ясалган шарж-портретлары элнгән. Кайсы рәссамның кыланмышы икән болар?

Сораштыргач, тыйнак кына: «Бездә күп алар — Шамкай кебек мачтырлар!» — дип кенә куйдылар.

Сәхнәнең артында, җыйнак кына бүлмәдә, чигешле тастымал белән каплап, өчпочмак, пәрәмәчләр өелгән өстәл тора. Киштәләрдә баян, гармуннар... Шкафларда клуб эшендә кулланыла торган китаплар, эш үрнәкләре... Бар да пөхтәлектә, тиешле урында.

Рәшит фойеда, авылдашлары кочагында йөри. Башкалар артистлар бүлмәсендә утыра. Авыл халкы кунакларны борчымасын дигәннәрдер инде. Кирәксә-кирәкмәсә дә артистларны яратканлыгын белдереп, чама белмичә, яннарына кереп, теленә салынып йөрүчеләр күп бит ул.

Менә белегез, Ярмәк халкы нинди культурный! Хәтта артистның психологик үзенчәлегенә хәтле аңлый. Үзләре дә артист икән бит алар. Рәшит юкка әйтмидер: Безнен Ярмәкләр каршында чыгыш ясау — ул сиңа театр училищесына яки Мәдәният институтына имтихан бирү генә түгел — залда өч йөзләп профессор утыра!»

Хәмзә түзәме соң?.. Рәшит ана, бар булган кассеталарыңны ал әле, бәлки, Ярмәктә сорарлар, сатарсың, дигән иде. Шуларны күтәреп чыгып китте. Әнә, сатасы урында өләшеп йөри. Халык шуңа өелгән, бүләккә — бушка булгач, ябырыла инде ул. Сабир моны күреп: «Минем дә бераз бар иде, алып киләсе калган икән, истәлеккә шәп бит алар, кассеталар», — дип, тавышын сәхнәгә яраклаштыргандай калайландырып әйтеп куйды.

Шулвакыт фойеда кемдер гармун тартып җибәрде. Сыздырыпмы сыздыра бию көен! Шәрәфи бизәнү бүлмәсеннән үк кулларын җәеп, бии-бии чыгып та китте. Теттерә, малай! Концертка җыелган халыкның бер өлеше залдан чыгып, шаккатып карап тора башлады. Уртада кем икәнен күргәч, дәррәү кул чабарга тотындылар. Вәт егет, ичмасам, дигән булалар да, картлач Шәрәфине дәртләндерәләр. Шәрәфи дә махы бирүчеләрдән түгел. Ярмәк абыйлары да сыната торган булып чыкмады — янчиләр генә идәнне! Әллә нинди тыпырдаулары белән йөрәкне өтәләр. Уртада — егетләр! Оп-па, оп-па!

Көтмәгәндә, Шәрәфи каршына, яулык чите белән йөзен каплаган булып, бер апа биеп чыкты. Юк, аны бии генә дип әйтеп булмый — ул матур чүәкләре белән хәрәкәтләр чигә, җанга бал тамыза. Шәрәфи андый вакытта нишләргә белә — артист чүтеки. Татар халкының иң асыл егете кыяфәтен алып, Сафагәрәй Сөембикәсен алиһә итеп зурлагандай, апа-җанкай янында бөтерелә башлады. Кагылмый ул аңа, ләкин назлый, иркәли. Бер сүз белән әйткәндә, татар хатын-кызларына бию алымнары белән дан җырлый.

Халык бу сихри, тылсымлы күренешкә тын да алмый сокланып торды. Их, тагын бераз биемәде шул апа кеше дигән идек, аның эзләренә басып, апакай кереп киткән җәннәт почмагыннан, канатын җилпегән аккош сыман, гүзәлләрнең гүзәледер — бер сылу кыз бөркелеп чыкты. Аның салмак адымнарына ияреп, инде хәле бетеп егылырга тиешле Шәрәфиебез кабат бөркетләнде. Уртадагы аккош мәхәббәтенең кульминациясе — гармунчы кинәт бию көен Мендельсонның туй музыкасына күчерде. Шәрәфи каушап калмады, кызның нәфис кулларыннан тотып, моңа кадәр берәү дә игътибар бирмәгән, ләкин Ярмәкнең өйләнешүче яшь парларын беркетә торган, фойеның түр башындагы ике балдак символикасына таба юнәлде. Моны сизеп, авызын ачып карап баккан халык котырып кул чабарга керешә һәм бу тамашаның ахыры көлешү, шатланышу белән тәмамланды. Халыкка концерт башланырга вакыт икәнен белдереп, залга чакырдылар. Артистлар да сәхнә артына атлады. Шунда Шәрәфи, тыны кысылып: «Чибәр дә инде, заразы!» — дип әлеге кызга югары бәясен бирде.

Концертның барышын сөйләп тору кирәк түгелдер. Рәшитне бик зурладылар, котладылар, бернинди юбилей-мазар булмаса да, күкләргә чөйделәр һәм ул ана

лаек та иде. Кичәгә ныклап әзерләнгәннәр. Районнан вәкилләр килгән, Ярмәк житәкчеләре дә сынатмады — кыйммәтле бүләкләр тапшырдылар. Башка артистлар да бүләксез калмады, һәммәсе чәчәкләргә, алкышларга күмелде. Концерттан соң тагын сый-хөрмәт. Кунакчыллыкның чиге юк, сөйләп бетерерлек түгел.

Ул төнне юньләп йоклый алмадылар. Урын-жир лапас түбәсендәге яңа чапкан печән өстендә булса да йокы кермәде. Очрашулар тәэсирендә күңелләр урыныннан купкан иде. Житмәсә, Шәрәфи, клубта теге чибәр кыз белән биегәннән соң, тыны кысылып чүт кенә үлми калуына ишарә ясап, анекдот сөйләргә тотынды:

— Ике дус хатын очраша. Берсе шәп киенгән, ясанган, бизәнгән — бәхетле, икенчесе — бәхетсез, кием-салымының да рәте юк, йөзендә өметсезлек. Бәхетлесе моны яшәргә өйрәтә, син, дустым, болай ит. Менә мин берәр ир белән танышам да аны өйгә алып кайтам. Тегенең «ташын» кыздырам һәм... урынга ятабыз. Шулчак яшерен кнопкага басам да, ишектә кыңгырау шалтырый. Шуннан, ай, харап булдык, ирем кайтты, бик көнче, кач, юкса икебезне дә бәреп үтерә, дип елый башлыйм. Теге тәрәзәдән сикерә, пиджагы белән бумажнигы миндә кала. Син дә шулай ит, баерсың! Бер ел чамасы вакыт үткәч, болар тагын очраша. Теге бәхетсезе бөтенләй ябыккан, киемнәре тагын да ныграк сәләмәләнгән.

— Ни булды сиңа? — ди бәхетлесе. — Мин әйткәнчә эшләдеңме?

— Әйе. Кыңгырау шалтырауга: «Ирем кайтты», — диюем булды, карт академигымны паралич сукты. Тугыз ай урын өстендә ятты, үзе гел нидер әйтергә теләде. Тугыз ай карадым, туганнары алмады. Инде, ниһаять, сөйләшә башлады.

— Беренче сүзе нәрсә булды? Рәхмәт әйткәндер инде?

— Нинди рәхмәт? Ирең кайда соң синең, хәшәрәт, — диде...

Лапас түбәсендәгеләр көлеп тончыга яздылар. Тынычланып, хәлгә килгәннән соң, Хәмзә Шәрәфигә:

— Әллә син дә бүген шундый хәлгә төштеңме? — диде.

— Күреп тордыгыз бит, көчкә рәткә кердем. Әле сәхнәгә чыккач та сулышыма ут кабып торды.

— Без инде хәзер яшь вакыттагы кебек түгел, чамасын белеп кыланырга кирәк, чамасын белеп...

— Йөрәккә боерык биреп булмый шул, — дип, Шәрәфи сүзен төгәлләде.

Инде тынычланып, йокыга китәбез дигәндә генә Рәшит телгә килде:

— Аның бит мондыйрак картлары да бар әле. Бер бабай унсигез яшьлек кызга өйләнә. Кордашы әйтә ана:

— Акылыңа кил! Ун елдан сиңа — сиксән, ана егерме сигез яшь булачак! Нишләрсең?! — ди.

— Бик исем китте, — ди бабай, — аерып жибәрәм дә яңадан унсигез яшьлеккә өйләнәм! Ха-ха-ха! Менә сиңа мә!

— Йә, житте сезгә, егет-хәсрәтләр, әнә Сабир жырлый да башлады, — дип, аның борыны сызгыруга ишарәләп, Жәлал барысына да тыныч йокы теләде. — Иртәгә жаваплы очрашулар көтә!

Иртән ишегалдындагы гармун һәм жыр тавышына уянып киттеләр. Баксаң, унбер тулып килә икән. «Ак каен» артистлары уятырга килгән. Төшке аш шуларда билгеләнгән иде. Юынып-нитеп алдылар да, өйдә чәй эчәргә кыстауга карамастан, гармунчы артыннан чакырылган жиргә ашыктылар. Жиңгәчәй белән Искәндәр абыйлары да аларга иярде. Килеп житү белән, күптәнге дусларын очраткан күк, гөрләшеп алынды. Сезне көтә-көтә ашларыбыз суынып бетә язды, дигән сүзләргә өндәлеп, табынга сырыштылар.

Ансамбль житәкчесе сүз башлады.

— Инде кичә сезне карадык, бөек артистлар чыгышы безнең өчен үтә тансык, сезнең кебек булдырып булмаса да, инде бүген безне багыгыз. Безнең дә сезгә

үз һөнәрләребезне күрсәтәсебез килә. Казанга кайткач, менә шундый «Ак каен» дигән ансамбль бар икән дип сөйләрсез, ямегез, — дип нотыгын тәмамлады.

Артистлар рәхәтләнеп концерт карадылар. Гаҗәеп матур тавышларга, таныш булмаган җырларга мөкиббән китеп байтак утырдылар. Соңрак Җәләл, барысын да шаккатырып», «Кыңгыраулы яшел гармун»ын сөйләде. Хәтере яхшы каһәрнең, бер әзерләнмичә, хуҗалар соравы буенча, бәрде дә салды. Нәфис сүз ярышында Сабир белән икесе инде алар беренчелектә. Гармун сүзе телгә кергән икән, ул янгырамый калмый дигәндәй, дәртле бию көе шигырьне алыштырды. Ансамбль «Ярмәк вагы»н төяргә керешә. Ну биеп тә карыйлар инде, малай! Хәрәкәтләренең, ваклый-ваклый тыпырдауларының аңлатып булмастай гайрәте бар. Иләннән нәрсәләр чүпләгән кебек кенә башланган бию ахырга таба түзә алмаслык хәлдә дәртләндерә. Билләһи, атылып уртага чыгардай булып утырасың... һәм чыгалар да.

Биючеләр, кичәге уңышын кабатлау өчен, Шәрәфине тагын уртага чакырганнар иде дә, чыга алмады. Бүген аягын көчкә сөйрәп йөри. Чаманны белми биегәнсең, карт тәре, дип үзен-үзе битәрләп алды. Шәрәфине коткарырга теләгәндәй уртага, масаебрак, Рәшит чыкты. Чамалап, чутлап кына бераз йөренгәч, «вакка» сиптерә башлады. Барысы да, гомер күрмәгән шикелле, карашларын аңа юнәлтте. Юантык, тәбәнәк гәүдәнең ниләр кыланганын күрсәгез иде!

— Кара, бу дәүләт ансамблендә эшләгән мәллә? — дип шаккатып тора Сабир. — Чын биюче бит безнең каршыда! Беренче күрәм...

Рәшит кырыйга чыкты. Сабир кулын кысарга атылды.

— Карагыз әле, мышнамый да!

— Без бит шушы авыл егетләре! — диде Рәшит, үзенең бию осталыгына әллә ни әһәмият бирмичә. Һәм: Китәргә кирәктер, — дигән сүзләрен теләмичә генә өстәп куйды. Шулай дисә дә, йөзендә канәгатьлек, күзендә шатлык чыклары җемелди иде аның.

Озатырга бөтен авыл халкы чыккан диярсең.

— Сугышка китмибез лә, тагын бер әйләнеп кайтырбыз әле, туганнар!

Шәрәфи, машинадан ярты гәүдәсен чыгарып, купкан тузан өермәсе эчендә кулын болгап барды. Ярый, «Ак каен»ның мәҗлес шәраблары дезинфекция булыр. Авыл күздән югалганчы җыр суздылар.

> Авыл капкасын чыккач та
> Күтәрелде тузаннар...

— Их, егетләр, яшибез бит әле!

Җәләлнең бу сүзләре тормышның гүзәллегенә басым ясап, хәзерге мизгелдә рухның күтәренкелеген билгеләде.

Рәшитнең дә кәефе, бер сүз белән әйткәндә, шәп иде. Ул:

— Менә бездә шулай инде, егетләр! — дип, бу хәлләргә нокта куйды.

Күчтәнәчләр белән шыплап тутырылган машина, Хәмзә җаена карап, әкрен генә кайтыр юлдан сыптыра.

## Озату

> *Өзелеп, өзелеп сайрый бер сандугач,*
> *Туган ягы аның — Ярмәге.*
> *Бөдрә таллы мондый җирләр барда,*
> *Ул башка як сайлап йөрмәде.*

— Безнең якларда, күрәсез, бик күп каеннар үсә. Май аенда зифа буйларына яшел яулык ябынган кызлар, апалар сыман тау итәкләрендә, юл кырыйларында талгын гына чайкалып, һәр үтеп барган юлчыны сәламләп калалар. Күзгә

кергәч, сары сагышка уралып, монаялар, ә кышларын, гөнаһсыз чибәркәйләр кебек, язмышларын юрыйлар. Аларнын да өмете жылы жәйләргә төбәлгән сыман. Ә кышларын аларда башка гүзәллек. Көмеш кунган ботаклары кояш нурларында энже тезгән сәйлән кебек жемелди. Әкияти гүзәллек! Сөйләү түгел, моны күрергә кирәк, күрергә!

— Син нәрсә, Рәшит, безне кыш житкәч тагын бер мәртәбә алып кайтмакчы буласыңмы?

— Нигә алып кайтмаска, Хәмзә, син каршы килмәсәң, машинаң йөреп торса, ниятләргә була.

— Һаман саен кунакка йөрү бик килешеп бетмәс шул, Рәшит. Сагындырып кына кайтуга ни житә инде...

— Шулай да бит, менә кышкы Ярмәкне дә бер күрсәтәсе иде сезгә. Йә, ярый, насыйп булса тагын бер әйләнербез әле бу яклардан. Әнә кара, Хәмзә, каеннарны әйтәм, бер-берсенә шундый охшашлар! Әмма юк икән шул, бу тышкы яклары гына, ныграк карасаң, алар да аерылалар икән. Һәркайсының үз язмышы, сере, тарихы.

Шундый серле каеннарның берсе Ярмәк авылы янында үскән. Һәм монда, нәкъ йөз егерме биш ел элек, бу каенның чордашы шагыйрь Зыя Ярмәки дөньяга килә. Авыл мәдрәсәсендә укып йөргән көннәрнең берсендә ул әлеге каенга гашыйк була. Менә шундый хисле малайның шагыйрь булып китүенә әлеге каен йогынты ясамагандыр дип кем әйтә ала? Еракларда йөреп, байтак гомер кичерсә дә, каенын онытмый ул. Гади генә булмаган каен, аның сихри көче егетне Уфалардан, Оренбурглардан әйдәп, туган ягына кайтара һәм 1913 елда үзенең яраткан шул каены турында «Ак каен» дигән шигырен яза. Әйдәгез, жырлыйбыз!

Яфраклары яшел ак каенның
Хәтфә жәйгән кебек һәр ягы.
Әйлән-бәйлән уйный яшь балалар,
Гөрләп тора һәркөн тау ягы.

Ак каен ул инде бик картайган,
Яшьләр күңеле аның куенында.
Ялгыз гына үсә, ялгыз яши
Әүлияләр тавы буенда.

— Көен кем язды икән?

— Нииндидер Вәлиев дигән кеше. Менә шуны ачыклыйсым бар.

— Көе дә шәп, шигыре дә! Безне кунак иткән ансамбльнең исеме дә шуннан чыккандыр әле — «Ак каен».

— Әлбәттә, бернәрсә дә монда очраклы була алмый. Ярмәкинең «Жәй башы», «Иртә», «Кич», «Язгы тамчы» кебек шигырьләрен без мәктәп дәреслекләрендә укый идек.

— Аларын да беләсеңме? — Сабир һаман гажәпләнә бара.

— Ничек белмәскә инде, авылдаш бит. Күренекле татар шагыйре Әнвәр Давыдов та безнең күрше авыл Камышлыдан. Заманында Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир урынбасары булып эшләгән. Беләсеңме шуны, Хәмзә? Син язучы кеше — белергә тиеш.

— Язучы икәнен беләм.

— Әнвәр Давыдов — татар шигъриятендә публицистик яңгырашлы, ватандарлык хисләре белән сугарылган фәлсәфи лирик поэмалар авторы буларак танылган шагыйрь. Жәл, ул кырык тугыз яшендә Казанда вафат була. Танылган татар язучысы Халикъ Садри да Иске Ярмәктән. 1890 елда туган.

— Анысы кем тагын?

— Хо-о! Монысын, һичшиксез, белергә кирәк сезгә, егетләр! Ул — 1920 елда, татар халкы вәкилләреннән берсе буларак, Мәскәүдә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын игълан итү турындагы тарихи Закон

проектына кул кую тантанасында катнашкан кеше. Ватан сугышы елларында Халикъ Садри хәрби полк комиссары буларак сугыша. СССР Әдәби фондының Татарстан Язучылар берлегендәге вәкиле булып эшли. Аның хикәяләре, пьесалары, повестьлары әдипнең башыннан үткән хәлләргә, үзе кичергән вакыйгаларга нигезләнгән. 1955 елда Казанда вафат була. Менә аның каберен табарга кирәк әле туганнарыннан сорашып.

Шагыйрь һәм драматург Рөстәм Мингалим турында сөйләп тә торасы юк, аны үзегез беләсез, ул да безнең авыл күршесе — Йолдыздан.

Рәшитнең озак сөйләвеннәнме, әллә арыганлыгы үзен сиздерәме, машинадагылар утырган килеш йоклауга күчкәннәр иде. Рәшит, үзенә эндәшмәгәнне сизеп, артына борылып карады да:

— Әһә, болар болай икән, — дип, үзе дә урынын җайлап күзен йомды. Йоклау өчен түгел, очрашулардан туган татлы хисләре белән ул яңадан авылына кайтып китте. Уйлансын, уйланырлыгы бар...

Хәмзәнең Рәшитне туганнары, авылдашлары белән очраштыра алуына сөенече күңелен кузгатты. Зур шатлык һәм савап бит дустының куанычын уртаклаша алу. Ул үзе котыртмаса, дөресрәге, кыстамаса, Рәшит әле бу эшкә алынырга батырчылык итмәс иде. Аны да аңларга була: мәшәкате күп бит туган якларга кайтып килү дигән нәрсәнең. Әле дусларың ризалашамы, юкмы? Машинасын табасы бар, шофёры, дигәндәй... Ә асылда ничек килеп чыкты: Хәмзә барлык борчуларны үз өстенә алды да, үз машинасына үзе утырып, җырлатып кына, инде кире кайтып та килә. Рәхмәт димичә, ни дисең... Чын дуслар менә шундый була! Җәләл дә каршы килеп маташмады, Сабир да, Шәрәфинең дә егетлеге бар инде. Рәхмәт барысына да, барысы өчен дә. Рәшитнең үзенә дә сынатмаска кирәк булыр алар чакырганда, онытмаска кирәк игелекләрен.

Бераздан аның сулышы тигезләнде һәм ул матур гына гырлау рәвешенә кереп, ниндидер көй сыйфатына күчте. «Ай, әле бик еракта идек без», — дигән җырга охшаган дип әйтимме? Ярар, йокласыннар, арыганнардыр...

Хәмзә кабат Рәшитнең стенадагы фоторәсемен күз алдына китерде. Бәләкәй Шамкай... Ямаулы бишмәт, эчтән күлмәк сыман нәрсә кигән, башында бүреккә охшаш әйбер... Күзме, кышмы икән?.. Күзләр... Монсу йөз...

Хәмзәнең дә күзе йомыла түгелме? Аллам сакласын. Рульдәге кешедә никадәр адәм язмышы?!. Йоклама, Хәмзә!

Юк, ул шулай кавым-кавым Рәшитнең кечкенә чагын хәтер арасыннан эзли. Үзенең дә аныкы кебек рәсеме бар. Әбисе солдат шинелен сүтеп, аңа тегеп биргән пәлтәсе... пәлтәсе... Чү, аны чыннан да йокы баса бугай, мәлҗерәтә. Туктарга кирәк.

Хәмзә машинасын читкәрәк алып, юл кырыендагы чирәмлектә чыелдатып тормозына басты. Бөтенесе: «Нәрсә булды, нәрсә булды, — диеп, куркышып, капылт уяндылар. Хәмзәнең дә йокысы шул мизгелдә үк качты. Ишекне ачып, җиргә төштеләр. Шәрәфи, бүтәннәргә арты белән борылган килеш, басуга карап, мекерди-мекерди, Сабирга сүз катты:

— Карале, Сабир, син кайсыдыр концертта безнең бөтен министрларның тетмәсен теткәнсең икән. Шулай дип сөйлиләр, дөресме?

— Ике уйламый әйтәм, Равил абый, дөрес. Хәзер уйланып йөрим, ул министрларны сүгүдән ни файда? Бөтен илендә дә тәртип юк бит әле, шулаймы, Җәләл абый?

— Шулай, мин горурланам синең батырлыгыңа!

— Горурлан, Хәлим абый, горурлан, мине утыртып куйсалар сөенерсең дә әле.

— Юкны сөйләмә инде, Сабир. Мин синең кыюлыгыңа, дөреслекне вакытында маңгайга бәреп әйтә белүеңә шаккатам.

— Шаккат, Хәлим абый, шаккат! Шаккатырлык хәлләр бар безнең сферада. Хәзер безнен татар жырчылары, кызларын әйтәм, популяр булыр өчен тәннәрен сата. Дөресме, Равил абый?

— Дөрес! Мин дә бу нәрсәгә каршы киләм.

— Килеп нишли аласын син, Равил абый? Сина бит инде тиздән житмеш тула. Нормальный эш һәм яшәү шартлары кирәк ул кызларнын сафлыгын сакларга. Яна житәкчелек кирәк, милли жанлы, артист яклы акыллы башлар кирәк татарнын генофондын киләчәккә калдырырга.

— Бигрәк каты чыгыш ясагансын ди шул.

— Әйе, сүктем. «Каракнын бүреге яна» дигәндәй, мин сүккәнгә чыдый алмый залдан чыгып китте. Кызган идем, исемен әйтмәдем, ләкин халык күреп калды кем икәнен.

Жәләл:

— Афәрин, шул кирәк ул оятсызларга! Симерделәр, — дип, Сабирны тагын женләндереп жибәрде.

— Милләт, милләт, дибез! Кем ясый ул милләтне? Без ясыйбыз, без тәрбиялибез аны! Сәнгать киләчәкне коткара! Әдәбият, гомумән — матурлык! Болар мин әйткән сүзләр түгел, мин кабатлыйм гына, әмма бу дөрес сүзләр! Туп тибү, шар тәгәрәтү, шайба шудыру тормышны алга жибәрми, күнелне тәрбияләми. Кешене шул ук сәнгать, театр тәрбияли. Менә акчаны кая түгәргә кирәк. Тупны аны маймыллар да тибә.

Бәхәскә Рәшит кушылды:

— Акча! Акча! Акча — король! Акча — патша, император! Акча бирмәсәләр, мин сәхнәгә дә чыгып йөрмәс идем. Акча — фатирлар! Акча — яшь кызлар! Әнә бер мәгънәсез татар миллионеры ничә чибәр жырчы кызның башына житте. Һәрберсеннән берәр бала, һәрберсенә берәр иномарка машина, фатир, фәсмәтәннәр... Шулаймы, Сабир?

— Шулай. Әнә арт ягына да типтеләр. Хәзер үзен бөтен ил белән эзлиләр.

— Акча тирәсендә мәж киләләр. Хакимиятнең югары эшалунында да шул бандитлар... Кырмыска оясына таяк тыкканнармыни... Болгаталар... Болганалар...

— Түзегез, бер жайга салыныр әле... Карга карганың күзен чукыганы юк. Моны мин әйтәм — Равил Шәрәфиев!

— Сабирның хак гамәлләренә кушылып һәм яклап, һәм мактап үземнең 50 яшьлек юбилей кичәсендә аның сәхнәдә ясаган чыгышын искә төшердем бит әле, егетләр! Сез дә шунда идегез, — дип сүзен башлады рульгә таянып, бик игътибар белән әлеге әңгәмәне тынлап барган Хәмзә.

— Әйе, хәтерлим.

— Ну яхшы чәпәден син анда да житәкчеләргә. Син сүзенне болай башладын. Чыктын да: «Безнең сүз сәнгатендә бөек шәхесләребез күп булды: Әзәл Яһүдин, Фәйзи Йосыпов, Айрат Арсланов, Илдус Сафин, — дип тезеп киттең. — Әзәл Яһүдин картлык көнендә бөтенләй онытылып бетте, анын дөньяда барлыгы, исәнлеге турында белүче дә булмады; Фәйзи Йосыповка да шундый ук язмыш насыйп ителде, сонгы көннәрендә караучысыз калды; Айрат Арсланов та, олыгайгач, филармония һәм министерствога үпкәләп, рәнжеп йөрде, чөнки ул бөекне дә оныттылар; Илдус Сафин йөрәгендәге батарейкасы эшләүдән туктап әрәм булды. Ник ул шундый чиргә юлыккан? Чөнки шундый хәлгә китереп житкергәннәр», — диден. Әйе, алар бакыйлыкка китте. Урыннары ожмахта булсын, дип теләден. Алар булмагач, ни телевидениедә, ни театрда, ни радиода татар теленең тәмен, сүзнең ямен белеп сөйләүчеләр бетте. Шулаймы, Хәмзә, дип миңа борылып әйттең. Дөрес сөйлисен, Сабир, дип сүзенне жөпләдем.

— Карале, син минем чыгышны дикъкать белән тыңлап утыргансың икән.

— Әйе, син әле һаман дәвам иттең. «Шәһәрне» — «шәхар», «сөям» дигәнне «ө» урынына «и» куеп сөйләүләрен тәнкыйтьләдең. Тагын әллә нинди сүзләрне якладың, мин болай сөйләргә, мәсәлән, оялам, дидең. Аннан, тагын... җитәкчеләр ягына карап, язучыларның һәм кайбер танылган шәхесләрнең юбилейлары алдыннан берәр ай гомерләре калганын белгәч кенә мактаулы исемнәр бирәсез, дип шелтә белдергәнең дә истә. Мин сиңа шул чакта, син нәрсәгә намекаешь, Сабир туган, минем юбилей кичәсендә, дип сиңа сүз каткан идем. Юк, Хәмзә, син яшисең һәм мәңге яшәячәксең, дип сәхнәдән чыгып киттең.

Рәхмәт сиңа шуның өчен, яме! Мин инде ул рәхмәт сүзләрен шул чакта ук әйткән идем, ләкин тагын кабатлыйм. Үзең булып кал!

— Аларны, өстәгеләрне, гел шулай шөшкенләп торырга кирәк!

— Шулай, шулай, — диештеләр барысы да күмәкләп.

Әңгәмәгә Рәшит кушылды.

— Сабир! Син Усман Әлмиев белән ул үлгәч тә очрашып йөрисең, дигәннәре дөресме?

— Анысын үзем уйлап чыгардым. Ярым-йорты дөрес. Менә тагын сөйлим инде. Бу Сабирга ни җитми дип уйлыйлардыр. Һаман шул «өстәгеләргә» ачу килгәннән килеп чыккан уйдырма инде ул.

Усман абый үлде бит инде. Бөек кеше. Заманында Татар операсын оештыру эшендә башлап йөргән даһи зат, галәмәт популярлык казанган артист. Сугышларга барып җырлап йөргән батыр йөрәкле, курку белмәс, фидакарь җырчы. Менә аны соңгы юлга озатуны бер тыгын театр бинасында оештырганнар. Әлбәттә, халык килгән. Ничек килмәсен инде сөекле җырчысы белән хушлашырга. Күпләре үлүен белми дә калгандыр. Югыйсә аның җәсәде, үзе белән опера сәнгатен тудыру турында хыялланып йөргән якын дусты Муса Җәлил бөеклегенә таянып булса да, бөтен иҗади гомерен операга багышлаганын исәпкә алган очракта да, Опера һәм балет театрына куелырга тиеш иде.

Үз илеңдә әүлияләр булмый. Исәннәрнең кадерен белмибез, үлгәч, әштер-өштер илтеп күмәбез.

Җәсәде кырыенда басып, менә шушы сүзләрне әйтеп, Усман абый белән хушлашам. Ә үзем, әкрен генә, кеше күрмәгәндә табуты эченә кесә телефонымны тыгып куям. Озаттык Усман абыйны соңгы юлга. Атна-ун көннән соң шалтыратам мин монда. Алды, малай, телефонны, сөйләшә. Нихәлләр, мәйтәм, Усман абый? Хәлләр ничек? Ал да гөл, сездәгеләргә караганда монда әйбәтрәк, ди. Дөньялыкта ни кылган булсак, монда да шуның белән шөгыльләнәбез, ди. Карале, Сабир, нишләп телефоннан сөйләшеп акча туздырып, вакыт әрәм итеп торабыз соң әле, давай, килгәч сөйләшеп бетерербез, тагын ике атнадан үзең монда киләсең икән бит, афишаларыңны күрдем, ди.

— Ну, уйлап та чыгарасың инде, малай, — дип, сузып куйды Җәлал. — Шулай да хикмәте бар. Чыннан да, кешенең кадере юк бездә.

— Юк, кәнишне, — дип алдырып китте Рәшит әлеге фикерне. — Менә сез пенсиягә чыккач та һаман тырышып-тырмашып театрда эшләп йөрисез. «Нобель» премиясе бирерләр дип өмет итәсезме? Шиш, тоттырдылар ди! Коры куаныч булып йөрмәгез дә, Шәрәфи, Хәлим. Сезгә дип бирсәләр дә аны, җитәкчеләрне әйтәм, үзләренә алачаклар. Рәхмәт, Сабир, бу сүзләремне боларга күптән әйтмәкче булып йөри идем, җай чыгардың.

— Алар театрдан китсә, Камал театры бетә бит.

Хәмзәнең бу фикерен Сабир куәтләп җибәрде:

— Бетә шул! Тажи китсә, Әзһәр, Илдус Әхмәтҗан, Нәҗибә, Дания, Алсу... һәм башка өлкән артистлар...

— Яшьләр хәзер театр дип бик өтәләнеп йөрми. Кайсысы кайда өстәмә бизнес ачып көн күрә, — дип Шәрәфи көрсенеп куйды. — Безнең заман түгел...

Хәмзәнең: «Сездәге хезмәт хакына мин бер көн дә яши алмыйм», — дигән сүзләре боларны бөтенләй боектырды.

Хәлим Җәләл бирешә торганнардан түгел:

— Шулай да безгә театрдан китәргә ярамый. Бу гамәл безнең тарафтан җинаять булып каралыр иде. Бернигә карамыйча, кыенлыклар, кимчелекләр белән көрәшә-көрәшә, театр яшәргә тиеш. Егетләр, үзегез өчен генә яшәмәгез әле, милләт бар бит, телебез бар, сәнгатебез, халкыбыз, тамашачыбыз. Бары тик үзебезгә йөкләтелгән эшне намус белән башкарырга гына кирәк.

— Ил башлыкларына да гадел булырга һәм һәммәбезгә гаделлекне сакларга, үтәргә, башкалардан шуны таләп итәргә дә өйрәнергә кирәк. Шунсыз булмый.

— Анысы шулай, Сабир, тик ил башлыкларына кагылганы, Мөхәммәт Мәһдиев әйтмешли, «едва ли» үтәлер.

Сөйләшә, бәхәсләшә торгач, юл кыскарган икән. Алда Казан күренде. Күңелләргә бердәм җыр керде:

Яктырак яна Казан утлары,
Чакыра безне үзенә һаман.
Кайтабыз сиңа, кайтабыз, Казан,
Учак янына җыелган сыман.

— Егетләр! ГАИ посты, тынычланыгыз! Җыр сүзләре тынып, пышылдауга күчте. Ля-ля-ля-ля, ля-ля-ля-ляу

Барысы да тәрәзәгә капланды.

Сабир машинаның ян ишеген ачты да, Хәмзәне иснәргә килгән инспектор янына чыгып:

— Энекәш, арт ягы шәрә маймыл күргәнең бармы? Кып-кызыл булып бетә ул агач башында ышкылып йөреп. Менә шул, ничек әле исеме, орангутанг кебек. Бик ерактан, халкыбызга зур мәдәни хезмәт күрсәтеп кайтып киләбез. Салонны ачып-нитеп торма, анда милләтебезнең бөек шәхесләре утыра — «УАЗ» булуына карама син безнең машинаның! Эшләгән кешенең иномарка алырга куәте җитми аның. Урлап кына баеп була. Аңладыңмы? Ә бездән сиңа бер тиен дә тәтеми. Без бүген хәйрия концерты бирдек. Иснәмә син Хәмзәне, аракы эчми ул, эчкәне дә юк. Бир документларын кире! — дип, машинага утырды да Хәмзәгә: «Трогай!» — диде.

Инспектор, ни әйтергә белмичә, юл уртасында басып калды.

Салондагылар Сабирның ГАИ хезмәткәре белән әңгәмәсенә бәя биреп тормады. Арыганнар, күрәсең. Шулай, Казан да кичкә таба моңсулана. Кабан күле өстендә ялтыраган ут шәүләләре дә күңелдә ямансу хисләр уята.

Казансу да агуыннан туктаган сыман. Хуҗалары кайткан йортларда берән-сәрән утлар кабына. Тәрәзәләр — өйнең күзе...

Моңсу күзләр... Соңгы көннәрдә бу сүзләр Хәмзәнең иреннәрендә еш кабатланып торды. «Бәләкәй Рәшитнең моңсу күзләре»... Нигә алар шундый?.. Елаттылар микән әллә? Стенадагы фоторәсемнәр арасыннан ул аңа карап тора... Елап туктаган чагында төшергәннәрдер... Юк, күзләренең моңсулыгы аннан түгел, сәбәбе бүтәндер, әйе, бүтәндер...

## Давыллы көн

*Дөрес туганмын мин бу дөньяга,*
*Кирәклегем барын белгәнмен.*
*Рәхәт күрми үтсә дә балачак,*
*Кешеләргә шатлык бирә-бирә,*
*Тормыш юлы буйлап киләмен.*

Тар гына ишегалдында, дөньясын онытып, бер малай уйнап утыра. Аның өчен бу кечкенә тарлык та зур бер ил. Монда бөтен нәрсә дә бар: чикләре-коймалары, капкасы; сарае, лапасы, келәте; тавык-чебеш, казлары; сыер, бозау, атлары, колыннары; этләре, мәчеләре... Көнозын ул шунда мәш килә. Абыйлары кебек әллә кайларга баралмый — бәләкәй, диләр. Үскәч өлгерерсен, яме, Рәшит, безнең дә бит шушы Ярмәктән ары китә алганыбыз юк, дип юаталар. Әллә ялганлыйлар шунда. Бик чыгасы килә дә Рәшитнең, абыйларына ияреп, Фәррах урамнарына. Тагын әллә нинди урамнар да бар икән, «Фатыйх» урамымы шунда, «Пират» дигәнен дә телгә алалар. Түбән оч, югары оч, аргы яклар... Үзләре безнең авыл зур, диләр, тик нигәдер аңа күрсәтмиләр. Менә бер качып чыгып әйләнеп кайтырмын да, шаккатырырмын әле үзегезне, дип уйлап куя ул кайчакта. Ачуланырлар шул. Бабасы да усал, әбисе дә, әнисе дә. Абыйлары да ияртмиләр, аннан качалар, артларыннан гел елатып калдыралар. Менә үсеп житәр дә үзегезгә дә кызыклар күрсәтмәс әле Рәшитегез. Сугышканда да якламас, әй, болай гына әйтә инде, яклый, билгеле. Әнә беркөн Искәндәр абыйсы сугышып кайткан, ул шунда булса кыйната идеме аны? Баш белән иягенә китереп бәргән булыр иде, мәтәлеп китәр иде шул Кәләпүш Кәримулла малае Хәким. Үзен күргәне юк әле, үсеп кенә житсен, күрсәтер ул ана күрмәгәнен!

Олы абыйсы Равил да сугыша. Күз төпләре күгәрмәгән көне бик сирәк. Әнисе, нигә сугыштың, дип сорагач, дөреслек өчен, ди. Нинди була икән ул дөреслек, беләсе иде шуны? Безгә Сәлимгәрәйләр тел тигезәләр, дип әйтә дә өйдән чыгып йөгерә. Аннан соң ишегалдында елый. Әнисе аны юатырга тотына: балам, түз, сабыр бул, өтермәгә апкитәрләр үзенне, дия-дия үзе дә елый. Нәрсә икән ул өтермә?

Инде менә бераз үсеп тә китте. Күп нәрсәләрне аңлый да башлады. Урамга да чыкканы бар. Кайбер нәрсәләрне үз теле белән аңлата белә.

Гел сугыш та сугыш. Урамда да, авылда да, илдә дә. Әтисе сугышта, бабасы да гел сугыш турында сөйли. Ишегалдында әтәч тә сугышмый тормый. Әнә-әнә, тагын тавык өстенә менеп башын чукый. Көн саен әле берсенең, әле икенчесенең өстенә менеп таптый, каһәр суккыры, һич кенә тавыклардан аерып, күз-колак булып житешә алмый шул жүнсезгә Рәшит. Күрше әтәче белән генә сугышуы житмәгән, инде үз тавыкларын талый, мәлгунь. Соңгы вакытта Рәшиткә дә гел кырын карап йөри, ачуы килә, күрәсең, тавыкларны рәнжеттермәгәнгә.

— Әни, әни! Кара-кара, әнә тагын берсенә үрмәли! Көш-көш! Хәзер таяк белән мин сине...

— Әй, балам, нишлисең син анда, ник ул әтәчне куасың?

Инде әнисе өйалдына ук чыгып житкән.

— Тавыкны кыйный ул, әни. Канатлары белән кыса.

— Тимә син аңа, ул бит тавыкны ярата, ә син комачаулыйсың гына.

— Ул көн саен шулай итә, әни.

— Ә син көн дә шул әтәчне сагалап йөрисеңме?

— Әйе, чукый бит ул аларны, талый!

— Әйтәм жирле бу араларда тавыклар йомырка салуны киметте... Син икәнсең сәбәпчесе. Әй, бала... Әйдә, өйгә кер, ашарга вакыт.

Тора-бара Рәшит әтәчкә әһәмият бирми башлады. Тавыкларның йомырка салу-салмаулары әтәч мәхәббәтенә бәйләнгәнен төшенмәсә дә, ишегалдында кызыграк шөгыльләр белән мавыгып, онытылыбрак китте. Этләре Сарбайга бәләкәй арба тагып утырып йөреп булмас микән дигән фикергә батты. Болай муенына бау тагып, артыннан йөгереп йөри анысы, ләкин арба таккач, тик тора, тартмый. Бабасы ясап биргән бәләкәй генә арбага утырып: «На-на!» — дип тә карый, селкенми дә Сарбай, койрыгын болгап торудан узмый. Аркасына чыбык белән суккач, борылып ырлый гына. Аңгыра булып чыкты ул. Капка астыннан кеше балагына ябышырга яки урам буйлап үткән эт заты белән ырлашырга оста ул. Җә, ярый, песине жинә инде. Шулай да беркөнне Ярулла абзыйларның мәчесе алар ишегалдында каракланып йөргәндә, койма аша сикерә алмый егылып төшкәч, Сарбай моны ботарлыйм дип уйлаган гына иде, чинап кире атылды. Мәче аның күзен тырнаган икән, айлар буе берсе агып, күрмәс булды дускаеның.

Шулай, Рәшитнең бөтен дөньясы шул ишегалды инде. Иртәдән кичкә кадәр эт, мәче, тычкан, бөҗәкләр белән уйный. Кайчагында түбәгә менеп еракларга да карыйсы килә аның. Рөхсәт итмиләр, егылып төшәрсең дә имгәнерсең, диләр. Өйдәгеләр каядыр югалып йөргәндә, бер мәртәбә менгән иде инде ул баскычтан. Авыл кырыендагы биек тауларны күргәч, шаклар катты. Урманнар, ерганаклар бар икән. Аннан соң, ул бит кояшны күршеләр өй түбәсеннән чыга да икенче күршеләрнең лапасы артына бата дип уйлый иде. Хәзер каян чыгып, кайда югалганын да белде. Кояш бер таудан икенче тауга күчеп, шунда ял итә икән бит. Бу ачышын ул бабасына да, әбисенә дә, әти-әнисенә дә — берәүгә дә әйтмәде, югыйсә түбәгә менгәнне беләчәкләр.

Беркөнне шундый көчле җил купты. Әллә кайлардан кара болыт чыкты да, кояшны ботарлап ыргытып, авыл өстенә килә башлады. Рәшит куркуыннан өйгә кереп, юрган астына качты. Әнисе эштә, бабасы лапаста, абыйлары кайда икән? Ярый әле әбисе өйдә. Яшен яшьнәп, күк көлтерәп, аждаһа килә сыман. Байтак вакыт өй дер селкенеп торды. Кайда соң болар? Абыйлары ник кайтмый?

— Әби, әби! Мина түшәмнән су тама...

— Читкәрәк күчеп ят, улым!

— Монда да ага...

— Менә монда коры, монда кил.

Рәшит, юрганын башыннан каплап, почмакка шуышты.

Шулчак бабасы өйгә керде.

— Ят, улым, ятып кына тор! — диде дә кабат җәһәннәм эченә чыгып китте. Ул анда җеннәр белән сугыша бугай. Бик озакка сузылды бу үлем белән көрәшү.

Әкренләп күк күкрәү тынықланды, әнә яшене дә еракта сызыклар ясый. Рәшитнең юрган тишегеннән куркудан акайган күзләре ялтырый. Инде тәрәзәнең бер читендә яктылык хасил булды. Аждаһа-болыт мәхшәр ясап китеп бара икән. Яңгыр туктаган. Ишегалдында бабасы, манма су булып, салам, киртә, такталар белән кайнаша иде. Әнисе, абыйлары да кайтып керде. Давыл бөтен каралты-кураны пыр-туздырып аткан. Әнисе Рәшиткә: «Монда йөрмә, балам, бар кер, өйдә генә утыр!» — дип тә әйтеп карады. Юк, кермәде, үзенең уен кирәк- яракларын барлый башлады. Таба гына алмый бит. Түбә саламын бастырган киртәләр дә кайсы кайда ята, бабасы шуларны аралый. Бу мәхшәрдән куркып калган тавыклар да һаман тынычлана алмый, Сарбай улавын белә. Рәшит, кит дип әйткән саен китмичә, үҗәтләнеп шунда кайнаша: пычранып, юешләнеп беткән.

Шулвакыт моңа хәтле түбәгә чак кына эләгеп торган алагаем киртә Рәшитнең башына килеп төште. «Кит!» — дип кычкырырга да өлгерми калдылар. Янына, атылып, бабасы килеп житте, кулларына оныгын күтәреп, кан сиптергән башын учлары белән каплады. Бетте, бетте балам, дип ни еларга белми; хәлсезләнеп тезләренә сыгылды, жиргә таянды. Рәшитнең селкенеп куйган иреннәреннән: «Әни, әнием...» — дигән соңгы сүзләре генә чыкты. Ул күзен йомды.

Аңына килеп, күзен ачканда, Рәшит әллә нинди бүлмәдә ята иде. Башында зур шеш. Үтереп сызлый. Чыдар хәл юк. Янына ниндидер апалар килеп китә. Аңа сәерсенеп карыйлар. Нәрсә булды икән? Һич искә төшерә алмый. Янәшәсендә ят кешеләр. Ярмәктә юк бит аның мондый апалары. «Камышлы, Камышлы», — дигән сүзләр ишетелә. Алар авылы тирәсендәге авыл түгелме соң ул? Абыйлары аны Ярмәктән дә зур дип әйтәләр иде. Рәшит Камышлыда микәнни? Ул бер уянып, бер йоклап китә, йокысы — гел саташу, сугыш та сугыш. Әтисе шунда бит. Аның әтисе янына сугышка барасы килә. Барып, бөтен явызлыкларны кырып бетермәкче була. Немес, диләрме әле, менә шуларны. Кинәт янында бомбалар шартлый, күктә кара төтен чыгарып, немес самолётлары улап жиргә мәтәлә, колак кырыеннан сызгырып ядрәләр оча. Ике абыйсы да шунда канга батып сугышалар, ул жан ачысы белән кычкыра: «Әнә, абый, әнә тагын берсе», — дип самолётларга күрсәтеп елый.

Аның кычкыруына медсестралар килеп житә. «Хәзер, хәзер авыртуың бетәр, тынычлан, тынычлан, жаный!» — дип куллары белән сыйпап юаталар. Ул, янында сугыш юк икәнен белгәч, жайлана төшә, күкрәгеннән атылып чыгардай булып типкән йөрәге сабырлана. Рәшит бары тик әнисен генә чакыра: «Әни, әни!»

Әнисе кая? Уянган саен башын тотып карый. Башы бәйләнгән. Тирә-юньдә һаман шул ак халатлы апалар бүлмәдә әрле-бирле йөриләр. Шәймәрдән бабасы искә төшә... Рәшит әле генә аның янында уйнап йөри иде бит. Бабасы нәрсәдер эшли, кабалана, ачулы сүзләр әйтә, күрәсең, эше килеп чыкмый, ә Рәшит ул ясап биргән самолётларын эзли. Берсенә, немеснеке дип, кара билге ясалган, ә икенчесенә, безнеке дип, кызыл йолдыз беркетелгән. Әле ике самолётның ничек сугышканын да күрсәткән иде бабасы. Их, шул давыл килеп чыкмаган булса... Хәтере кара вакыйгаларда буталып, ул давыл өермәсенә кереп югалды.

Рәшит больницада байтак ятты. Табиблар: «Без балагызның сәламәтләнүенә ышандыра алмыйбыз», — дигәч, әнисе аны елый-елый авылга алып кайтып китте. Сугыш хәсрәтләре генә житмәгән, Шәмкәйләр өенә кара кайгы булып авыру бала өстәлде.

Нәселнең барлык олы ир-заты сугышта, киттеләр дә югалдылар. Исәннәрме икән алар?..

Еш кына Рәшитнең әтисе сугыш хәлләрен сөйли торган иде...

«...Сугышның иң котырган чагы, станкавай пулемёт белән ятам. Баш күтәреп, кая атарга чама юк. Тирә-якта акырыш-бакырыш, шартлау, чинаулар, жан өзгеч тавышлар, кыскасы, ата улны белми сүгенеш, гомумән, мәхшәр. Янәшәдә генә минем кебек солдатлар ята. Кайберләре тәгәрәп-тәгәрәп китә. Хәзер инде ул вакытларда кичергән тойгыларны искә алуы да авыр. Хәер, аларны искә алып тору кирәк микән әле? Яшәргә өмет өзелгән иде. Немеснең сугыш машинасын безнекеләр ничек туктата алдылар, әле дә башка сыймый.

Шулай итеп шул: станкавай пулемёт белән ятам. Алда ниндидер шәүлә күренсә, шуңа тырылдатып алабыз. Бервакыт бөтен гәүдәмә күсәк белән суккан кебек булды, шуннан оныттылдым. Бермәл күземне ачсам, кемдер баш артымнан үрелеп күземне каплый. Әле аңламыйм, кем бу, ни бу? Күзне каплаган теге кулны этеп жибәрәм, кул янадан кире кайтып, күзне яба. Ята

торгач аңладым — бу минем үз кулым икән, кулбаш сөяге чәрдәкләнгән дә кул озынайган һәм җилкә аша каерылып, маңгайга салынып төшкән. Бу хәлне аңлап, тетрәнеп, тагын аңымны җуйдым. Тагын бик каты шартлаулар булды кебек. Үлдем, ахрысы... Юк икән. Берзаман сулышым кысылып, газапланып аңыма килдем. Колакларым, күзләрем, авыз-борыннарым балчык белән тулган. Исән кулым белән битемне чистартам. Интегә торгач, күзләрем дә ачылды, ис сизү, тавыш ишетүләр юк. Контузия?.. Шулай да үз аңыма килеп беттем бугай. Мин каты яраланганмын, янымда гына бомба шартлаган булып чыкты. Чөнки әле кайчан гына андый зур тирән чокыр бу тирәдә юк иде бит. Яраланган кулым сызлый, чыдарлык түгел, аны үз файдама юрадым. Авырта, димәк, кул бөтенләй эштән чыкмаган. Күргәнегез бар микән, кечкенә генә, нокта кадәр булса да, берәр бөҗәкне борчысаң, ул туктап, куырылып кала. Янәсе ул чүп яки үлгән. Ходай шушы җан иясенә дә яшәү чарасы биргән, ягъни җан саклау инстинкты калдырган. Ничек кенә булса да шул чакта исән калу дәрте миндә дә ныгыды. Яшәргә, яшәргә, ярты гәүдәм калса да яшәргә кирәк, дим үземә! Күз алдымнан туганнарым, балаларым, чибәр хатыным чагылып узды. Яшәргә! Ничек кенә булса да!..

Исән кулым белән җансыз кулымны гәүдәмә кыстым да, бар булган көчемне җыеп, куш аяклап ясалма балчык кабердән чыгып, варункы төбенә тәгәрәдем. Әйтерсең лә йөз яшен берьюлы яшьнәде, күз алдымда тоташ ут уйнады. Бу авыртудан мин тагын аңымны җуйдым. Күпме вакыт узгандыр, хәтерләмим, хәер, монда вакыт кайгысымыни, аны уйларлык хәлем бармыни минем?..

Күземне ачтым. Варункы төбендә чалкан ятам икән. Күк йөзе зәп-зәңгәр. Аңламыйм. Бик ерактан «ах-ух» иткән тавышлар ишетелә. Карале, мин ишетә башлаганмын бугай, дип уйладым. Сугыш ераклашкан, ахрысы. «Ах-ух»лар снаряд шартлаулары булгандыр. Миңа нигәдер рәхәт. Үзем дә аптырап ятам. Ни өчен? Чамаладым. Варункы әле яңа. Салкын түгел, шуңа тәнем җылынып эреп ята. Яраларымнан җылы кан саркып, тәнемә тарала икән. Ә ул яралар бер генә түгел. Әллә бүре, әллә эт яныма килеп, мыш-мыш иснәп китте. Бераз кымшанырга тырышып карадым, селкенеп тә булмый, бөтен тәнемне җиргә кадаклап куйганнармыни. Башны борып карыйм. Тирә-якны күзәтерлек рәт бар. Чокырда бер мин генә түгел, дүрт-бишләп кеше булып чыктык. Шундагы казакъ егетенең сүзләреннән аңлашылганча, без, Власов армиясендәге солдатлар, чолганышта калганбыз. Ул тагын: «Шевелитесь, держитесь, скоро откроют коридор», — диде дә китеп югалды. Күпме булыныгандыр, белмим. Ни хикмәт, миннән ике метрлар чамасы арада утырган бер солдатка күзем төште. Шуңа караган саен карыйсым килә. Аның да бер кулы шинель җиңенә кереп баткан. Исән кулы белән солдат котелогы төбеннән нидер казына. Шуннан алган валчык кебек кенә нәрсәләрне авызына каба. Аңа карап минем дә ашыйсым килеп китте. Их, дим, берәр телем ипи ашап җибәрсәң! Ә солдат һаман котелок төбендә чокына, мин аңа карап каткан. Тукта, бу мин үзем түгелме соң дигән мәгънәсез уйлар башымнан йөгереп узды шул чакта. Саташам, ахрысы, әллә инде акылымны җуяммы?.. Тукта, бу сакал-мыек баскан, һәммәбез кебек таушалып беткән солдат... Кем соң бу?.. Бу минем бертуган абыем Шәһемирза бит, әйе, билләһи, шул. Абый, синме соң бу, дип, бөтен авыртуларымны җиңеп, аңа таба шуышам. Ул да миңа тартылды. Канлы яшь аралаш үкси-үкси елаштык. Исән кулларыбыз белән кочаклаштык.

Коридор ачылды, безне чолганыштан чыгарып, төрлебезне төрле госпитальләргә озаттылар. Мин үзебезнең Куйбышта дәваландым, анысын үзегез беләсез. Улым Рәшит белән икебез ике больницада үлем белән көрәшеп ятканбыз. Аның авыруы зәһәррәк булып чыккан икән шул».

## Яшәү өчен көрәш

*Дөнья малы — дуңгыз каны,*
*Ага да бетә.*
*Кадрен белсәң, сәламәтлек*
*Гомергә җитә.*

Баласы терелүгә өмете өзелгән Бәдрикамал үз хәлен үзе генә белгәндер. Рәшитнең авыруы көчәйгәннән-көчәя. Ул һаман сызлана, үзен-үзе белештерми. Туганнары аның соңгы көннәрен көтә. Нишлисең, Ходай Тәгалә шулай язгандыр. Ләкин кул кушырып утырырга ярамый, ахыргача көрәшергә кирәк. Көрәшергә!

Авыл кешеләре, бигрәк тә күрше-күлән, Рәшитнең язмышына битараф була алмады, билгеле. Үзләренең хәле хәл булса да, Бәдрикамал янына килеп аны юаталар, тынычландыралар, төрле киңәшләр бирәләр иде. Берочтан иренең дә хәлен сораштыралар, үз туганнарының да хәбәре юк микән дип кереп чыккалыйлар. Инде Мирзаҗанның Куйбышев госпиталендә ятканы бөтен авыл халкына мәгълүм булгач, аның аркылы да берәр хәбәр ишетелмәс микән дип, соңгы өметләрен барлыйлар. Каһәр суккан сугышның һаман бетәсе юк. Шулай да аның ил чикләреннән ераклаша баруы күңелләрне җылыта иде инде. Бәдрикамалның сөенеченә караганда көенече ныграк. Иренең сугыштан исән-имин чыгып, Куйбышевта савыгып ятуы куандырса, кече улының өметсез килеш түшәктә авырып интегүе җанын көйдерә иде. Соңгы көннәрдә Бәдрикамал төннәрен мендәренә капланып үкси-үкси елый башлады. Ходай Тәгаләдән ялварып улының савыгуын сорады. Ярый әле ялгыз түгел, карт-карчык янәшәсендә, тупырдап торган тагын ике улы янында. Күз яшьләрен аларга күрсәтүне кирәк дип тапмады. Көчсезлеккә, ихтыярсызлыкка, өметсезлеккә бирелеп, аларны борчуга саласы килмәде. Күреп тора бит: картларның да үз хәлләре хәл.

Беркөн янына һич көтмәгәндә көндәше Хәлимә килеп керде. Чүлмәккә мул итеп кайнар тавык шулпасы тутырган, бүтәксе, муен өлешләрен дә табакка салып, сүзен башлады:

— Бәдрикамал, менә шушы шулпаны эчертеп ал әле Рәшиткә, бәлки, хәле җиңеләеп китәр.

— Хәлимә, ничек килергә булдың, өйдәгеләрең яратмас бит.

— Бер дә борчылма, Бәдрикамал, үз өлешемне яшереп калып, шушы баланың авырып ятуына үзәгем өзгәләнеп, тоттым да килдем.

— Сәлимгәрәйгә ни дип аңлатырсың?

— Ул әле сугышта. Ни әйтсә дә әйтер, кыйнаса кыйнар, ярабби, исән генә кайтсын. Бәлки, гадәтләре дә үзгәрер, каткан бәгыре дә йомшарыр. Сугыш бит ул. Менә үзең күреп торасың, юкка да еларга торабыз. Яшьләребез генә кипте. Бәдрикамал, сиңа бер үпкәм дә юк. Үзеңә рәхмәтләр генә укыйм. Сәлимгәрәйгә бер тамчы да өмет биргәнең булмады. Мин генә утта янып яшим, күрәсең бит, көеп беттем, сүндем, суырылдым, саргайдым. Моңа кадәр гел синең белән саташып яшәде ул. Сиңа этлекләр эшләмәсә дә, Мирзаҗанга гел таяк тыгып торды. Барыбер мин аңа Бәдрикамал белән рәхәт яшәргә ирек бирмәячәкмен, дип янап яшәде. Аңа да көн күрсәтмәде, үзе дә янды, мине дә көйдерде.

Шулчак ишектә кемдер чалынды.

— Йә, Бәдрикамал, ни... Рәшиткә җылы чагында эчерт әле теге шулпаны, файдасы тими калмас, — дип, чүлмәген тастымалына төреп, Хәлимә китәр юлына атлады. Шәймәрдән бабай, артыннан аптырап:

— Ни йомыш белән килгән соң әле бу бала монда? — дип калды.

— Тавык шулпасы китергән ул, эти. Яхшы ният белән, күңелендә бер дә начарлык юк аның.

— Шулайдыр, бәхетсезрәк тормышка дучар булды шул ул, Сәлимгәрәй кулына капты. Бозды ул эт шушы изге җан иясенең тормышын. Ләкин сер бирми. Зарланмый. Түзә. Тешен кысып яши. Алла ярдәм бирсен үзенә! Бәдрикамал, — дип, Шиһабетдин бабай сүзен кисәк икенчегә борды. — Болай баланы тилмертеп яткырып булмас. Әнә башы һаман шешә тора, әйдә, бер чарасын табыйк. Фатыйх урамындагы теге Галиулла Садриенең малае Фәйзелхакның бер заманны кулбашындагы ярасы төзәлми интектереп йөрде. Хәтерлисеңдер. Бүлнистә кулын кисә яздылар, мин шуна дәва табып булмас микәнни дип, агулы үлән дисәләр дә, аксыргак яфрагы киптереп, шуның онын бәйләгән идем.

— Теге, мал ашамый торган кыяклы үләнне әйтәсеңме, эти?

— Әйе, шуны.

— Менә шуның файдасын күрде бит ул Фәйзелхак. Солдатка да алдылар әле үзен.

— Әйе шул. Нигә элегрәк башына килмәде икән бу даруың?

— Монысы кул гына түгел, баш бит. Баш! Куркыта. Мин духтыр түгел, үзең беләсең, үземчә шухыр-мухыр гына китерәм, дарулар булмаганга күрә.

— Бөтен бар-булган дарулар сугышка озатыла шул.

— Әйдәле, кызым, шуны, Аллага тапшырып, сынап карыйк әле. Карчыгыма әйттем, киптергән аксыргагы бар иде аның, шуны сөенеп уып калды. Хәзер алып киләм. Аллаһу боерса, төзәлер балабыз. Нигә алданрак уйламадык икән, әй картлык диген, ә, бер дә җүнле нәрсә түгел инде бу картаю, хәтер дигәнең беткән... Хәзер, хәзер, — дип, Шиһабетдин бабай карчыгы янына йөгерде.

— Абынып егыла күрмә!

— Хәзер, хәзер...

Шамкайларның яше-карты Рәшитне терелтү өмете белән ыгы-зыгы килә башлады. Кемгә апа, кемгә сеңел, кемгә кызлары булган Сәмәриянең зур тырышлык белән табып җибәргән даруларын бер төенчеккә төйнәп куйдылар да, Рәшитнең бераз калка башлаган чәчен кабат такырга кырып, аксыргак оны сиптеләр. Бу гамәлне Сәрбиҗамал әбиләре теләсә нинди табибтан да остарак һәм пөхтәрәк башкарды. «Әфсен-төфсен, Рәшит улыбызның чире бетсен», — диеп тә өстәде. Башкалар тын да алмый карап тордылар.

Нәтиҗә озак көттермәде. Беркадәр вакыттан соң, әлбәттә, көннәр, атналар үткәч, өйдәгеләр шаккаткыч хәлгә тап булдылар. Рәшит иртүк уянган да урын өстендә башын бәйләгән чүпрәкләре белән уйнап утыра. Шеше сытылган, түшәкне буяп бетергән. Мал-туар яныннан кергән әнисе шатлыгыннан барысын да уятырлык итеп ботын чәбәкли иде.

— Ай улым, ай улым! Карагыз әле, утыра бит. Торыгыз әле, уяныгыз! Рәшитебез терелгән!

Көтмәгәндә өй эче яктырып киткәндәй булды. Барысы да шатлыктан күз яшьләрен сөртә-сөртә куана. Шулай итеп, гаиләгә беренче шатлык нурлары сирпелде. Көн арты көн үтә торып, Рәшит күз алдында тернәкләнде, аягына басты, сөйләшә, уйный-көлә башлады. Шатлык өстенә шатлык өстәлеп, көннәрдән бер көнне госпитальдән әтиләре кайтып төште. Иң әүвәл уларын кочты ул, Рәшитне бер кулы белән югары күтәреп, битеннән үпте. Шул кочакка әниләре килеп кушылды. Әби-бабайлар каршында болай тору башка вакытта мәсләккә туры килмәсә дә, бу юлы өлкәннәр үзләре дә куанычларын яшерә алмадылар, яннарына килеп, бер кочакка елыштылар. Күптән һәм бик озаклап зур сынаулар, хәсрәтләр кичергән кешеләр язмышы яңадан укмашып, бер дулкын булып, тормыш елгасына кушылды.

Рәшитнең күзе гел әтисенең кулбашын чәрдәкләгән ядрә эзенә төшә иде. Әтисе ул төшен эчтән, тыгыз итеп, ак чүпрәк белән бәйләп куя. Өстеннән сугыштан киеп кайткан гимнастёркасын кия дә муен аша каеш белән яралы

кулын асып йөри. Әтисенең җәрәхәте төзәлеп тә бетмәгән икән, һаман шул ярасыннан вак сөякләр чыга тора. Кайвакытта Рәшит аннан:

— Авыртамы? — дип сораштыргалый.

Әтисе:

— Юк, — дигән була. Ә төннәрен сызланып чыга. Аның ыңгырашуларын Рәшитнең еш ишеткәне бар. Кайчагында әтисе үзе дә, аның башындагы җөйләнгән ярасына күрсәтеп:

— Үзеңнеке авыртамы? — ди.

— Юк, — дигән була Рәшит тә.

— Ничек кенә авыртса да, авырта димә, улым. Түз! Берәүгә дә сер бирмә, яме! Кызгандырма үзеңне!

— Менә әйтмәдем бит инде, әти, авыртса да...

— Нык авыртамы соң?

— Нык авырта, әти. Түзәрмен, яме!

Алар бер-берсенә дәрт һәм көч биреп яшәүләрен дәвам иттеләр.

Әтисенең тәнендә тугыз җәрәхәте бар. Шуңа карамастан шаярта, көлә, шул мәхшәрдән исән кайттым бит, дип куанып сөйли, күпләрнең яу кырында ятып калуларына көенеп, күзендә яшь бөртекләре күренә иде. Рәшитнең күпме дусты әти ышыгы күрми ятим үсте. Өйдә, түр башында әтиең басып тору — беләсезме, нинди зур бәхет! Бу халәтне сугыш елларында әтисез калган балалар мәңге күрә алмаслар шул...

Беркөнне авылга, эшләре тыгыз булса да, Мирзаҗанның сеңлесе Сәмәрия кайтып төште. Ишегалдында уйнап йөргән Рәшитне күреп:

— Рәшит, акыллым, синме бу? — дип, бераз аптырап торды. Аннан соң йөгереп килеп кочагына алды. — Мин бит сине...

— Чү, балага телеңә килгәнне әйтә күрмә тагы, — дип, Бәдрикамал аны бүлдерде. — Ул хәзер бөтен нәрсәне аңлый. Бик каты үпкәләтерсең җә, елатырсың.

Чыннан да, Сәмәрия, уйлаганын әйтә торган туры сүзле партия работнигы буларак, бала күңелен рәнҗетүне белмәскә бик мөмкин. Теге вакытта, Рәшит каты авырганда да, ул өйдәгеләргә өметсезлек ясап киткән иде. Янәмәсе, табиблар терелтә алмаганны үзегездән булмас, юкка газапланмагыз, дигәннәре барысының да күңеленә яра булып сеңеп калды. Каты бәгырьле булуы тормышында бер рәхәт күрмәвендә чагыла аның. Сугышта зенитчица булып катнашуын әйтсәң дә, юньле ир назы күрергә туры килмәвен исәпкә алсаң да, хатын-кызга хас ягымлылык сыйфаты кимегәндер инде. Ике югары белем алуына да хатын-кыз кодрәте генә җитмәс шикелле. Күрәсең, дорфалыгын искә төшереп бүлдергәндер Бәдрикамал, кайтып кергәч тә, бу бала дурак булып калыр, ахрысы, дигәнен чамалап.

Рәшитнең исән калуына Сәмәриянең шаккатуы һәм сөенүе чиктән тыш булып чыкты. Рәшит инде кочакка алып сөярлек яшьтән чыгып килсә дә, ул аны алдыннан төшермәде. Димәк, могҗизаларны партия карарлары гына башкармый, ә гади авыл кешесенең җылы кулы да, назлы сүзе дә тудыра ала. Ул, төпченеп, ничек итеп дәвалауларын сорады. Ана тәфсилләп сөйләп бирделәр. Сәмәриянең гаҗәпләнүе арта төште. Ахырдан:

— Мин Аллаһы Тәгаләнең барлыгына ышанам бугай, — дип, төпченүен киметте.

Ике көн авылда булуы белән өйдәгеләрне үзе дә гаҗәпләндерми калмады, әлбәттә, Сәмәрия. Кеше күрмәгәндә генә, гимнастёркасын, юбкасын салып, Бәдрикамалның Мирзаҗанга кияүгә чыккандагы күлмәген кигән. Әй, көлделәр инде, менә хәзер сине бер генералга кияүгә бирсәң дә була, диештеләр.

Ул һаман горурлыгын җуймый:

— Сугышта күп бөтерелделәр минем янда. Апагыз честь тә биреп маташмый иде шуларга. Хәзер дә обком, райком секретарьлары селәгәй агызып кала.

— Сон, нәрсәгә һаман ялгыз йөрисен, кызыгучылар барда?

— Лаеклысын, үзенә тинен тапмый апагыз!

— Безнең дә бит кияү күрәсебез килә. Кара, өй тутырук егетләр генә.

— Шулай булгач, нәрсәгә сезгә кияү?

— Әй, шапырынасың гына ахрысы син?..

— Шапырынмыйм. Берәү бар-барын...

— Башта ук шулай диләр аны!

Сәмәрия кайту хөрмәтенә суйган тавыктан бәлеш пешерергә тотындылар. Хужабикә булу бик тә килешә икән үзенә. Кулы кулга йокмый. Матур итеп җырлый да.

Тыпыр-тыпыр биергә,
Имән идәннәр кирәк.
Имән идәннәр өстенә,
Хәтфә паласлар кирәк.

— Егетләр, барыгыз әле идәндәге паласларны, сәкедәге мендәрләрне, юрганнарны кагып керегез!

Команданы шәп тә бирә инде Сәмәрия апалары, үтәмичә кара! Чын командирларча!

Кичкә Шәмкәйләрдә зур бәйрәм оешты. Чәй, бәлеш һәм Сәмәрия алып кайткан күчтәнәчләр белән җырлы-мәзәкле табын гөрләп торды. Тормышлары алга таба да шулай дәвам итәр төсле иде...

## Авыр еллар дәвамы

*Килде яшьлек газап, шатлык төяп,*
*Артта калды назлы балачак.*
*Бик мавыгып йөрсәк, сизелмичә*
*Гомере дә артта калачак.*

1947 елгы яз иртә килде. Беренче апрельдә үк ташулар китте... Шул елны Рәшитнең әтисе Мирзаҗан абыйны колхоз рәисе итеп куйдылар. Инде Рәшит тә беренче сыйныфка укырга керде. Май бәйрәме житкәч, бөтен мәктәп укучылары рәтләргә тезелеп, быргылар кычкыртып, барабаннар кагып, авыл советы янындагы агач трибуна каршына юнәлде. Балаларның күбесе ялан-аяк, бер генә сәдәфле ыштаннардан, ялан-ялан сикергәләп алалар — юешкә басасылары килми. Вакыт-вакыт кайберләренең ширинкалары ачылып, суыктан зәңгәрләнгән пелдиләре күренеп-күренеп ала. Ә кызлар чыркылдап көлә. Ленин-Сталин тәгълиматлары белән сугарылган яшь каһарманнарның алар көлүенә исләре дә китми, күпме тавышлары бар — кычкырып җырлыйлар.

Мы готовы к бою,
Товарищ Ворошилов!
Мы готовы к бою,
Сталин — наш отец!
В бой за Родину,
В бой за Сталина!

Җыр өзелә, балалар рәте тынып кала. Трибунага фуражкасын кырын салып, колхоз рәисе Мирзаҗан кәпрәеп менә. Ул исән кулын болгый-болгый озак

итеп сөйли. Докладының ахырын: «Яшәсен иптәш Сталин, яшәсен коммунизм — якты киләчәк!» — дип тәмамлый. Шулчак бөтен авылга «Ур-ра!» яңгырый. Балалар чәрелдәвенә халыкның башын катырып «опиум таратып яткан» мәчет манаралары чынлап тора.

Мирзажан абыйны колхоз рәисе итеп бер елдан артык тотмадылар. Гаебе булгандырмы-юкмы, анысын әйтеп булмый, булса — амбар мөдире итеп куймаслар иде. Бәлки, колхоз эшен җитәкләргә тәҗрибәлерәк, укыганрак, белдеклерәк кешене тапканнардыр... Партия эше...

Хезмәтен тырышып башкарып, күңел салып йөргәндә, колхозның бер амбарыннан симәнәгә дигән унике пот бодайны урлыйлар. Караклар бик оста кыланган — аскы ниргәне бораулап белән тишеп, бодайны капчыкларына агызганнар.

Шәмкәйләр өенә тагын кара кайгы, ачы хәсрәт килеп керде. Бәдрикамал белән Мирзажан, ни уйларга белмичә, ут йотып яши башладылар.

— Утыртырлар микән инде үзенне, Мирзажан, ә?

— Туктале, Бәдрикамал, бәлки, шаяртканнардыр, берәр җиргә илтеп аударганнардыр гына...

— Ул кадәрле берәүгә дә этлек эшләрлек гаебең, гөнаһың юктыр бит инде, Мирзажан! Әйттем мин сиңа прсидәтел дә, мөдир булырга да ризалашма, дип. Тыңламадың. Кәттә кыланып, масаеп йөри беләсең...

— Минем натурам шундый...

— ...Ә менә шушындый хәлгә юлыксаң, калтырап төшәсең. Әйдә, үземә рөхсәт бир, дусларны җыям да, кемдә шигебез бар, берәм-берәм кысабыз. Иманнарын әйбәтләп укытсаң, телләре ачыла аларның.

— Кысылма, Бәдрикамал, эшләр зурга китеп, әллә нинди фаҗига китереп чыгарырга мөмкинсең. Аллам сакласын!

— Һе, Алланы искә ала башладың.

— Әй, сүз җае гына ла...

— Азрак типкәләп, бәргәләп, күсәкләп алсаң, саталар алар бер-берсен. Әллә син бу эшне кемдер берүзе генә эшләгәндер дип беләсеңме?

— Әйтә алмыйм, берәүме, икәүме...

— Кемдер сиңа үч итә. Әйдә, мин әйткәнчә эшлик, Мирзажан!

— Көтик. Колхоз җыелышы буласы бар. Шунда хәл ителер нәрсәдер, бәлки, ачыкланыр да...

— Ачыкланыр, әмма соң булыр.

— Мин партийный, андый юлга бармыйм, партия кагыйдәләренә синең уй-фикер туры килми.

— Ә төрмәгә җибәрүләре — партия карарларын үтәүгә рас киләме? Ай-һай сезнең партиягез кеше язмышын җайлы хәл итә!..

— Бәдрикамал, мин сине аңлыйм да, нишлим соң? Иртәгә халык нәтиҗә ясар, хәзер бу мәсьәләне без чишә алмыйбыз. Йокла!

— Йоклады ди...

Шуннан соң байтак кына сөйләшми яттылар. Төнге тынлыкны бозып, Бәдрикамал тагын телгә килде:

— Теге вакытта мине Сәлимгәрәйгә бирмәскә ничек батырлыгың җитте соң синең?

— Мин ул чакта коммунист түгел идем. Йокла, дим!..

Барыбер таңга кадәр күзләренә йокы кермәде. Балалар да, гаиләгә ниндидер афәт киләсен сизенгәндәй, төне буе борсаланып яттылар. Бары тик таң яктысы офыктан үрләгәндә генә өйгә тынлык иnде.

## Җыелыш

*Кара төтен кубарылып күренәдер*
*Пожар каланчасыннан.*
*Бөркет булып очар идем, тик узалмыйм*
*Тавык кунакчасыннан.*

Кемнәр жинаять кылганын, әлбәттә, ачыклый алмадылар һәм бу җәһәттән җыелган колхоз җыелышы «түләтергә» дигән карар чыгарды. Кайберәүләр хәтта «утыртырга» дигән куркыныч сүзләр дә ычкындырды. Мирзаҗанның өч улы да шунда иде. «Утыртырга!» — дип кычкыруларын алар бик яхшы истә калдырдылар.

Эш, үзәктән комиссия килеп, каралты-кураларны, базларны тикшереп, актарып йөрүгә хәтле барып җитте. Янәсе, бодай эзлиләр. Мирзаҗан дәрәҗә яратса да, үзен яклый белми һәм... аларга тәки шул бодайны түләттеләр. Ярый әле шулай итеп төрмәсез генә котыла алды ул бәладән. Еллары нинди бит, бодае да, бигрәк тә орлыкка дигәне алтын бәясе торган чаклар.

Нишлисең, берәр ел рәхәтләнеп, тамак туйганчы ашап яши алмадылар, ләкин кош-корт, мал-туар асрау исәбеннән бу хәсрәтнең очына чыктылар. «Котылдык, Ходай рәхмәтеннән ташламады», — дип куанып утырганда, күршеләре Ярулла агарып килеп керде. Йөзендә курку.

— Мирза абзый, ялгыш бер сарыгыңны аттым. Абзарга бик күп күгәрченнәр җыелган иде, шуларны атам дип сезнең сарыкны тәгәрәткәнмен.

Мирзаҗанның мыегы да селкенмәде. Бәдрикамал гына ах-вах килергә маташкан иде дә, ул да тиз суынды.

— Ничек соң ул безнең сарык сезнең абзарга килеп эләккән, ә?

— Чурт белгән аны, безнекеләр исән, карыйм, ят сарык җан биреп ята.

— Суйдыңмы соң аны, Ярулла?

— Нәрсәне?

— Сарыкны әйтәм.

— Суйдым инде, бөтенләй әрәм булганчы. Карыйм, тамгасы сезнеке. Ах, мәйтәм, бетте баш... Сразы сезгә йөгердем.

— Язмыштан узмыш юк. Әҗәлен эзләп сезгә кергәндер ул, күрше, кайгырма. Баш бәласе түгел. Чирләп үлмәгән, димәк, туныйбыз да ашыйбыз. Күптән теш арасына ит кысылган юк иде. Әйдә, Ярулла, ите уртакка булсын. Килештекме? Сиңа да ит кирәктер.

— Кая ул кирәкмәгән, Мирзаҗан абый, — диде дә Ярулла, җырлап ук җибәрде. Ул кичне күршеләре йортында гармун тавышы тынмады.

Башка килгән — бәла түгел,
Илгә бәла килмәсен!

Мирзаҗан йортындагылар да рәхәтләнеп ит ашады. Бигрәк кыен вакытлары иде шул: әҗәтләре дә күп җыелган, күршеләре дә ахылдарлык зыян салган. Бер-береннән хәленә кереп, дус яшәүгә ни җитә инде.

Бу вакыйганы алар читкә чыгармыйча гына җырлап үткәрделәр, ләкин ашлык югалу шаукымы һаман саен кабатланып торды.

Инде Рәшитнең абыйлары да буйга шактый калыкты. Ат җигәләр, чалгы белән каерып-каерып печән чабалар, кибән өяләр, урман кисәләр. Күкрәкләре киң, беләкләре таза. Борын астыннан сызылып киткән мыеклары егетләрнең асыллыгын билгеләп тора. Күзләре — ут, фасоннары — кәттә. Нәрсә уйласалар, шуны эшли торган чаклары. Хәтерләре дә сынатырлык түгел. Әтиләренең язмышы хәл ителгән җыелышны да онытмыйлар.

«Төрмәгә!» дип кычкырып утырган абзыйларның кайберләрен бик яхшы хәтерләп калганнар.

Беркөнне Равил абыйлары шул бәндәләрнең берсен кибет артына алып чыккан да: «Әйдәле, Галимулла абый, берне салыйк, — дигән. Бер чәкүшкәне тегенә сыйлаган рәвештә салып бетергәннән соң Галимулла:

— Рәхмәт, энекәш, мин сине бик хөрмәт итәм, — диюгә Равил моны дөмбәсли дә башлаган.

— Рәхмәтен рәхмәт... Менә синең ничек оятың юк, Галимулла абзый, үзең олы кеше, син кайчандыр төрмәгә утыртырга маташкан Мирзаҗанның малае кулыннан сыйланып торасың. Кем урлады ул симәнәне теге вакытта? Әйтмәсәң, хәзер җаныңны алам. Син үзең урладыңмы? Әллә теге Мөктәсип артында кычкырып утырган шайкамы? Әйт, хәшәрәт!

— Тимә, Равил, миңа. Олы кешегә кулыңны күтәреп гөнаһлы булма!

— Карале син моны, гөнаһ турында авыз ача бит, муллалыкка ният итәсең дип ишеттем.

— Андый уем юк, гайбәт сү-үз...

— Тотлыга башладыңмы? Менмә манарага, егылырсың, җә төртеп төшерерләр! Әйт, кемнәр эше иде ул!

— Әйтмим, ул үтерә мине.

— Ә мин үтермимме?

— Син үтермисең. Үтерсәң, төрмәдән башың чыкмасын үзең дә бик яхшы беләсең.

— Ә мин сине гарип калдырам.

— Андый этлек эшләсәң, бөтенләй әйтмим.

— Кайчан әйтәсең?

— Ул кеше үлгәч кенә.

— Алдан үзең үлеп китсәң?

— Балаларыма әйтеп калдырырмын. Мин ул серне каберемә алып китә алмыйм.

— Кабахәт! Бәдбәхет!

Равил Галимулланы ярсуы басылганчы кыйнады. Ахыр чиктә: «Үтерәм бугай, ахрысы...» — дип, типкәләвеннән туктады. Галимулла аягына басып, өс-башын каккалады да аунаклый-аунаклый өенә таба атлады.

Икенче көнне аны ат арбасына салып Шәмкәйләр капка төбенә алып килделәр. Карарлык җире юк иде бичараның. Кылган гөнаһларың өчен кайчан да булса җавап бирергә кирәк шул.

Галимулланың туганнары да байтак җыелып килгән. Ике арада көчле бәрелеш булырга тиеш төсле иде, ләкин килүчеләр үзләрен тыныч тоттылар, эндәшмәделәр. Күрәсең, Равилнең Галимулланы кыйнау сәбәбен алар барысы да белә иде; күрәсең, алар бары тик әтиләренең ни хәлдә икәнлеген күрсәтергә генә теләгәннәрдер, яисә кыйнаулардан соң, алай-болай үлә калса, шаһитлык факты ясау өчен генә эшләнгәндер бу очрашу.

Ике як та әлеге дошманлыктан тыныч кына сабак алды. Ләкин Мирзаҗан моннан үзенчә нәтиҗә ясады: эшләр начарга китеп, малаен утыртып куя күрмәсеннәр дигән хафада, Галимуллага күпмедер түләүне кирәк дип тапты. Һәм шулай эшләде дә...

Балада әти-әни кайгысы тирән булмый, ә менә әти-әни бала хәсрәте белән соңгы көннәренә хәтле яши. Шулайдыр...

Искәндәрләре шундый ук, гаделлекне яклап үләргә әзер егет булып җитлекте. Сугышканда, гаебең булса, аңа якын килмә — бетәсең. Армиядә дә хезмәт итте. Шуннан кайткач, Келәүлегә военкоматка учётка басарга барганда, монысы тагын әтиләре өстеннән нахак сөйләгән бер кеше белән машина әрҗәсендә

туры килгәннәр. Машина зур тизлектә барганда, Искәндәр пычагын чыгарган да тегенә:

— Сикер машинадан! Сикермәсәң, эченне актарам, — дигән. — Теге вакытта бик батыр идегез бит, ник дереллдисең, Мөктәсип абый, әтине төрмәгә тыгарга да курыкмадыгыз. Сикер!

— Алла хакы өчен әрәм итмә, Искәндәр, жаный! Минем бер гаебем дә юк.

— Ә кем гаепле сон? Теге вакытта ин көчле кычкыручысы син иден бит.

— Ул чакта да синең кебек берәү арттан пычак терәп кычкыртты.

— Кем иде ул?

— Әйтмим. Үтерсәң үтер!

Искәндәр Мөктәсипнен ялварулы күзләрендә мескенлек чаткылары күрде. Көчсез карт кешедән үч алуны ул батырлык дип чутламады.

— Намусың бимазалый башласа, әйтерсең әле берзаман. Сине кыйнап кул пычратып тормыйм, — дип, картка кул селтәде дә, кабина түбәсен шакып, барасы жиренә барып житмичә үк төшеп калды. «Безнен юллар — бер түгел», — диде ул эченнән генә.

Икенче көнне монысын да арбага салып алып килделәр. Куркуыннан телсез калган Мөктәсип бер сүзен дә әйтә алмый. Туганнары чәчрәп Искәндәргә ябышмакчылар иде, капкадан Равил белән Рәшитнең күкрәк киереп чыгуларын күргәч, тынычланыбрак аңлашырга керештеләр.

— Менә, Мирза абый, безнең Мөктәсипне Искәндәр нишләткән, — диюдән ары сүз куертмадылар.

— Нишләткән? Мин бернинди дә зарарланган жирен күрмим.

— Сөйләшә алмый, телсез калган.

— Жыелышта «Төрмәгә, төрмәгә!» дип бик яхшы кычкырып утырган иде бит әле.

— Тик кенә тор, улым, алай сөйләшә торган чак түгел, — дип, Мирза Рәшитне тыйды. Мөктәсипнен туганнары белән читкәрәк китеп пышылдашкач, жайлаштылар, килештеләр, ахрысы, төрмә белән куркытмадылар.

Бу вакыйгалар — ишетелгәннәре генә, ә мәгълүм булмаганнары күпмедер. Хәер, мондый хәвефле мажараларны ишетмәвен әйбәтрәк.

## Хәмзә командасы

*Без күп йөрдек, бик күп хезмәт куйдык,*
*Инде ихтирамга лаек без.*
*Без бик аздык, хәтта юлдан яздык,*
*Бар да узды, инде аек без!*

Камал театры директоры Шамил Зиннурович кабинеттан чыкты да, савытыннан кайнар аш чөмереп утырган вахтёрдан:

— Шамкай бүген күренмәдеме? — дип сорады.

— Юк шул, Шамил Зиннурович, бер дә күзгә чалынмады, ник, ул бүген килергә тиеш идемени?

— Иртәгә спектакле, шуны онытмады микән, диюем. Бу арада театрда бер дә күренми. Тагын Хәмзә белән гастрольгә чыгып киткәндер әле.

Ике сәгатьләп вакыт үтте микән, директор, хәзер ашын чәйгә алыштырып, шикәр салган стаканын аш кашыгы белән болгатып утыручы вахтёрга шул ук сораулы карашын төбәде. Вахтёр да аны аңлаган кыяфәттә «юк» дигәнне белдереп, башын якка-якка чайкады. Шамил Зиннурович «һе» дигән сыман аптыраулы халәттә кабинетына кереп китте. Табарга кирәк бит инде моны. Телефон аша гына, театр складында баштанаяк эшкә чумган Рәшитнен хатыны — Суфия ханымны чакыртып алды.

— Суфия, Рәшит кайда икән ул безнең, иртәгә спектакле бит.

— Ә-ә, ул белә, белә аны. Ул үзенең дублёры Әсхәт белән сөйләшеп киттем диган иде.

— Сөйләшүен сөйләшкәндер дә, ә менә халык бу юлы тамашада аны күрергә тели. Тамашачылар «Килә ява»ның икенче составында уйнаучылар белән дә кызыксына. «Шамкай да Шамкай!» — диләр. Һаман Хәмзәгә ияреп йөриләрме?

Коридордан, Суфия ханымны эзләп, берәүнең тавышы ишетелде.

— Суфия, син кайда?

— Гафу итегез, Шамил Зиннурович, склад ишеге ачык калган иде, әнә, эзлиләр дә бугай, — дип, әлеге сорауга җавап бирүдән качып, ялт кына чыгып шылды.

— Шул Хәмзә белән йөриләр инде, алай булгач. Шәрәфие дә, Җәләле дә шундадыр, — дип, Шамил Зиннурович үзалдына мыгырдап куйды. — Туктале, тикшерим. Хәмзә кайда икән?

Ул Хәмзәнең өй телефонын яттан белеп бетергән, номерын хәтереннән генә җыйды.

— Тәнзилә ханым! Шамил абыең әле бу — театр директоры. Нихәлләрегез бар? Әйбәт кенә яшәп ятасызмы? Алия ничек? Җырлыймы? Малай ничек, малай? Кызның кечкенәсе үсәме?

— Рәхмәт, хәл белеп торуыгыз өчен, әлегә барысы да таза-саулар, Шамил Зиннурович.

— Карале, Тәнзилә ханым, Хәмзә өйдәме? Бик кирәк иде.

— Өйдә юк шул әле ул, «Биш татар»ын җыеп Мансарга киттеләр. Хакимият башлыгы бик үтенеп сораган үзләрен.

— Шулайдыр, шулайдыр, бик популяр бит алар, һәркайда чакырып торалар, — диде дә, «сау булыгыз!» дияргә дә онытып, трубкасын куйды.

Нишләргә инде болар белән? Теләсә-нинди җай табып, чыгалар да китәләр. Җә чирләгәнгә сабышып, справка алып киләләр, җә үзләренә алмаш-дублёр табалар, ә син монда шартла-ярыл... Кара инде син, миндә штатта утырып, артистларыма тимә инде, яме, бу юлы дип, Хәмзәгә ялынып-ялварып ятам бит. Тегеләр дә, «Безнең Хәмзә», дип кенә сөйләшәләр хәзер. — Хәмзә дә Хәмзә! Бер баруда чыгышлары өчен бер окладлык акча биреп кайтара диме аларга?! Инде бу юлы Мансарга ычкынганнар.

Шамил Зиннурович артистларын барлау мәшәкате белән хафаланганда, «Биш татар» инде «Укытучылар көне» уңаеннан оештырылган зур бәйрәм тантанасының үзәгендә, меңләгән халык кочагында аларга рухи байлык өләшәләр иде.

Әнә, Шәрәфигә чират җиткән. Ул сабантуй мәйданын хәтерләткән табигый театрда — табигатьтә!

Шәр-шәр-шәр-шәр,
Шәрәфи, хи-хи, шәрә!
Шәрәфидән көлә-көлә,
Каласыз бит шәп-шәрә!

Аның сүзендә дә, мәзәкләрендә дә, җырында да — яшәешебез, чынбарлыгыбыз!

Шәрәфи янында, әйтеп тә тормыйча, Шамкай калка. Калка дигәнем дөрес түгел — тәгәри. Һәм җырлый.

Син кем булып тудың, агай?
Мин мишәр булып туган.
Тел очымда йомры сүзләр
Сезгә сүләми торган.

Кай, кай, мин — Шамкай!
Ләкин тегел, ләкин тегел
Габдулла Тукай!

Аннан, үзе әйтмешли, «Сүләргә» керешә: булган, күргән хәлләре, мәзәкләре...

— Спектакль уйнаганда, импровизация алымнары кулланам, — ди ул. —Үзеннән-үзе килеп чыга. Мәсәлән, Зөлфәт Хәкимнең «Килә ява» спектаклендә Шәйхи ролен башкарам. Шунда аны күтәреп караватка салганда: «Гомерем буе исерек ташыдым», — дип җибәрәм. Тамашачы, әллә үземне урамнарда еш кына Шәйхи хәлендә күргәнгәме, тәгәри-тәгәри көлә. Ник, булды андый хәлләр. Шәйхи кебек кенәме әле!.. Әнә, Хәмзә алларга ирек бирмәс...

...Бер җәй көнне Хәмзә белән аның «Буханка»сына утырып гастрольләрдән «хәйран» булып кайттык. Хәмзә мине гел өйгә хәтле озатып куя. Мин артык назлы түгел, таләпчәнлек тә әллә ни юк, машинаны йортымнан еракkарак туктатам да шул төштән тәпиләп кереп китәм. Нигә андый зур машинаны ишегаллары буйлап, кысаннан йөртергә. Саубулашыр алдыннан тагын берәр стаканны чүмәлткән генә идек, башыма бер фикер килде.

— Нигә, мәйтәм, Хәмзә, син мине беркайчан да кунакка чакырмыйсың?

Хәмзә никтер икеләнебрәкме, аптырап калды.

— Әйдә, — ди бу.

Ахрысы, миндәй зур артистның, ник чакырмыйсың, дигәне аңа гаять зур дәрәҗә кебек тоелды. Мин йөзендә шундый чаткылар күрдем. Киттек.

Хәмзә фатирының ишеген ачты да:

— Хатын! Күрәсеңме, бездә кунак бар! — диде.

Хатыны бик чибәр икән, егетнең. Чын татар кызларына хас елмаюын, шомырт кара күзләрен, озын толымга үргән чәчләрен абайлап алдым. Өстенә ни кигәнен хәтерләмим. Мин аның матурлыгыннан тагын исердем. Хатыны: «Әй, нигә аны кунак килә дип алданрак кисәтеп куймадың. Тамак ялгарга берәр нәрсә әзерләгән булыр идем», — диде бугай. Сизәм, хатыны минем килүгә чын күңеленнән сөенде. Хәмзәнең әйтүе буенча, аларга әле Разил Вәлиевтән гайре бөек кешеләрнең килгәне булмаган. Менә хәзер мин монда.

Тиз генә бар булганы белән табын әзерләнде. Капкалап утырырга тагын ни кирәк: колбаса бар, тавык боты, карабодай боткасы, кыяр...

— Җитәр! — мин әйтәм, әйдә, Хәмзә, җиппәрик әле берне!

— Әй, хатын, кая соң теге нәмәрсә?

— Нигә кунакны тилмертеп утырасың? — дип, эчке бүлмәдән әллә нинди шәп күлмәкме шунда, халатмы киеп, кулына коньяк тотып чибәркәе чыкты. Кара син, пеләш тәрене, үзенә күрә түгел, татарның иң гүзәл кызын хатыны иткән бит бу.

— Әйдә, Хәмзә, хатыннарыбыз өчен берне күтәреп куйыйк әле!

— Рәшит абый, Суфия апа югалтмагандыр бит үзеңне? — дип сорап куйды Хәмзәнең хатыны. Урынлы сорау. Ошады бу сүзләр миңа. Ошады. Ягымлы итеп әйтә. Каян минем хатынның исемен белә диген? Әй, хатын-кызның белмәгән нәрсәсе юк бит аның. Хәзер кайтам, акыллым, Суфиям янына кайтам, димен.

Хәмзә чокырларга тагын коньягын бүлде. Тагын җиппәрдек, тагын бүлде — тагын чәкештек. Өстәлгә өр-яңа коньяк шешәсе менеп утыргач, башымны кыяр савыты янына куйганмын. Рәхәт иде миңа: никадәр хөрмәт, ничаклы җылы, назлы сүзләр әйтелде бит минем шәхесемә, никадәр иҗатыма ихтирам, яшәвемә мәдхия сөйләделәр миңа бу гаиләдә. Җылап та алганмын икән. Рәхмәт, Хәмзә! Бу бәләкәй генә кухня өстәле артында әйтелгән сүзләр бөтен җиһанга таралды сыман. Мин әнә хәзер тәхеткә утырган килеш йолдызлар арасында очам. Галәмдә бары тик: «Шамкай, Шамка-а-ай!» — дигән шау гына яңгырый. Кая очам мин? Кая?..

Ара-тирә Хәмзәнең: «Клиент готов, хатын, урын җәй!» — дигән әмере бөеклеккә очкан юл кырыйларында сузылып ишетелеп кала.

Бер заманны уянып киттем. Караңгылык. Мин бит әле генә галәмдә оча идем

түгелме? Үзем чишенгәнмен, ятканмын.. Ап-ак җәймә... Өемдәге диван бит бу. Чалбарым?.. Әйе, күлмәгем, кәчтүмем урынында. Аллага шөкер, мин өйдә икән...

Минем кыштырдаганны, шыбырдаганны ишетеп, ут кабыздылар. Хәмзә икән.

— Нишләп тордың, ятарга иде әле! — ди бу.

— Бәй, монда нишләп йөрисең? Бар, кайт өеңә! — димен аңа.

— Рәшит, мин сездә түгел, син бездә бит, — ди Хәмзә миңа. Ах, шайтан, әйткәннәр иде бит врачлар теге вакытта ук, сиңа беркайчан да эчәргә ярамый, дип. Тагын эчелгән. Җә, ярый, Ходай Тәгаләм, бу юлы да коткарсаң, тәүбәгә киләм, дип ант иттем.

Кая инде ул килү!..

Мансарда укытучылар бәйрәме гөрләп узды. Артистларның һәммәсенә, чыгыш ясаган өчен, чех вазалары бүләк иттеләр. Рәхмәт укытучыларга, район башлыгыннан артистларга үтенеп, ялынып бүләк сорап алганнары өчен. Соңыннан күнелне тагын да җебетерлек итеп: «Район житәкчебез әле сезгә «конвертларын» да бирер», — дигән татлы сүзләрен дә ишеттерделәр. Артистларның бу юмартлыкка исләре-акыллары китте. Килгәч-килгәч, районның тагын өч авылында концерт куюларын зинһарлап үтенгәнен дә җиткерделәр главаның.

Шулхәтле сәнгатьле Мансар халкы алдында чыгыш ясый алуларына куанып, дүрт көннән соң «конвертларын» алырга һәм район җитәкчелегенә олылап, рәхмәт сүзләрен әйтеп, кешечә кайтып китәргә дип хуҗаның кабул итү бүлмәсендә байтак утырдылар. Уңайсызлык һәм төшенкелек, мәгънәсезлек, ихтирамсызлык баса башлагач, кыюлыкларын җыеп, бишесе дә, вазаларын күтәреп, район башлыгы дип аталган түрәнең мыскыллы чыраен күргәч, үзләренә карата мөнәсәбәтен аңлап, әллә ни төпченеп тормыйча, вазаларны борын төбенә шапылдатып куеп чыгып киттеләр.

Бу гамәлләренә Җәләл юл буе горурланып кайтты.

— Карагыз әле, глава булдым дигәч тә, әллә кем булып, күркә шикелле утыра. Үзе чакырып алды бит, үзебез сорап килмәдек. Мескен. Ну, егетләр, булдырдык! Артык вакланып тормыйча, вазаларын, бердәм рәвештә шакылдатып, маңгаена ябыштырдык. Әле болай моны акылга утыртканнары булмагандыр? Дүрт концертның акчасына үзе тыгылсын! Хәерчедер? Баер! Әйдәгез, җырлыйбыз!

Мансар буйларыннан киткән чакта,
Тыңларсыңмы, җырлар җырлармын.
Күзләреңне тутырып карарсыңмы?
Зәңгәр таудан яулык болгармын.

Шәрәфи җырның мәгънәсен үзгәртеп җырлап куйды:

Кесәләрең тутырып калырсың да
Зәңгәрләргә яулык алырсың.

— Үпкәләмә, Мансар, безгә! — дип Шәрәфи җитди төс алды. — Сезнең якныкы түгел ул, читтән килгән оятсыз зат.

Шамкай бу мәсьәләгә мәзәге белән җавап бирде:

— Бик салкын кыш. Очып барган чагында бер чыпчык бик каты туңган, гәүдәсе боз булып каткан да бу зеңгелдәп җиргә мәтәлгән. Шулчак бу юнәлештә сыер үтеп бара икән һәм әлеге чыпчыкның өстенә җылы «коймагын» ләпелдәткән. Ни гаҗәп, чыпчык җылынып китеп, акылга килгән дә, башын чыгарып, чыркылдый башлаган. Янәшәдән үтеп баручы мәче моны күреп алган да тотып ашаган.

Монын өч морале бар:

Беренчесе — сине ашаган теләсә кем дошман түгел, икенчесе — сине нәҗестән чыгарган теләсә кем дус түгел, өченчесе — баткансың икән нәҗескә — чыркылдамавың хәерлерәк.

Әйе, егетләр, батырдык без бу главаны нәҗескә, ятсын шунда.

— Менә шундый түбән дәрәҗәгә төшәргә язмасын! — дип, Сабир үзалдына мыгырдап куйды.

— Илдә хәлләр болай барса, мондый адәмнәр адым саен очрап торачак, Хәлим абыегыз әйтте, диярсез!

— Хәлим абый, һәм барчагыз да, гафу итегез, мондый уңышсызлык минем оештыру тәҗрибәсендә беренче мәртәбә, кайткач, үзегезне бәхилләрмен, ямегез! — дигәч, Хәмзәнең сүзләренә һәммәсе ризасызлык белдереп ябырылды.

— Син, Хәмзә, борчылма! Мондый түрәләрнең борынына чиертү ул бездә горурлык хисе генә уятты, шулай бит, егетләр!

Барысы да: «Шулай, шулай!» — диештеләр.

Сабир дәвам итте:

— Белсеннәр, «Биш татар» төркеме ул — шәхси мәнфәгатьләрен кайгыртып йөрүче тар фикерле артистлар гына түгел, ул — югары зәвыклы, вазифаларын җуя баручы җәмгыятькә юмор-сатирасы белән сабак өйрәтүче мәктәп һәм укытучы да!

Рәшит юл буе үзенең язмышы турында уйланып кайтты. Нигә бу тормыш дигәнең җайлы гына бармый икән? Елга кебек борыла-борыла ага, ташларга, ярларга бәреләә; җил кебек талгын гына исми, давыллап ала; зәңгәр күктә дә гел кояш кына балкымый: ае да, йолдызлары да була, болытлар да каплый. Йөрәк тә кайчак ярсый, үзәк тә өзгәләнә, җан да бәргәләнә, күңел дә кайный. Кеше гомере менә шуларны кичереп, үзенең ахырына бара. Әле кайчан гына шалапай малай булып йөгереп йөри иде бит, юкса.

## Батыр аналар

*Артык шикәр тешләмичә,*
*тамагыннан кыса,*
*Бик сак кия берәү киемен.*
*Инде, шөкер, рәтләндем дигәндә,*
*карак дәүләт*
*Талап ала соңгы тиенен.*

Мәктәптә уку Рәшиткә бик авыр бирелде. Гел башы авыртып йөдәтте аны. Шуңа күрә җәйге ял көннәрен ул түземсезлек белән көтеп йөрде. Сихәтләнгән кебек була җәйләрен. Җәй — җәй инде! Ярмәкнең табигате искиткеч матур аның. Борглана-боргалана аккан Суыксу буйлары куе агачлар белән капланган, кай җирләрендә тигез болынлыклар елганың ярларына хәтле сузылган, аргы-бирге ярларында зирек, шомырт, балан куаклары, карлыгандыр, бөрлегәндер... Халең җиткәнче җый. Суыксуда балыкның күплеге: кушбаш, күккүз, җәен, чуртан, һәй... тагын әллә ниндиләре!

Балалар гел шул елгада чупырдаша. Ятьмә белән балыгын тота, учак ягып таяк очында кыздырып та ашыйлар. Болында искиткеч күп юа үсә, тау кырыйларында җиләк, алма бакчасында өелеп алма уңа. Җәй сугыш елы балалары өчен ачлыктан котылып тору чоры булды. Суыксу куены җәннәтнең уртасыдыр.

Ләкин мондагы җирләр, печәнлекләр Камышлы идарәлегенә кергән, шуңа күрә бу биләмәләрне шул авыл кешеләре саклаган.

Ходайның бер бирмеш көнендә Рәшитнең әнисе Бәдрикамал белән Бибинур апай икешәр чиләк асып, әрәмәлеккә балан җыярга китә. Чиләкләрен тутырып кайтырга гына чыгабыз дигәндә, болар каршына атка атланган ике Камышлы егете килеп чыккан. Ике арада сүз куерып киткән:

— Сез кемнәр, апалар?
— Без Ярмәклеләр.
— Ни эш кылып йөрисез?
— Менә бераз балан җыйган идек.
— Сезгә кем рөхсәт бирде?
— Нигә, аның өчен кемнәндер рөхсәт алу кирәк идемени?
— Әлбәттә.
— Ә кемнән?
— Менә, мәсәлән, миннән.
— Ә син кем соң шул хәтле?
— Күп белсәгез, тиз картаерсыз, апалар, — дигәннәр дә бу ике алыптай егет, атларыннан төшеп, орчык кадәрле өчәр балалы бу ике хатынның чиләкләрен тартып алып, печән таптап йөрисез дип, баланнарын куе үләнгә сипкәннәр. Һәм бу «каһарман батыр егетләр» Камышлыга юнәлгән. «Җинаятьче» Бәдрикамал белән Бибинур борчыла-пошына Ярмәккә кайтып киткәннәр. Инде төрмәгә ябарлар микәнни дигән шикләнүләре юкка булган, алай-болай бу турыда сүз куермаган. Тыныч кына котылдык дигәндә, «кунак ашы — кара-каршы» килеп чыккан. Күпмедер вакыттан соң Бәдрикамал күршеләре Зәйнәп апаларга керә. Ни күзе белән күрсен, йорт ишегалдында бик яхшы арбага печән салынган һәм шунда шәп ат утлый. Гаҗәпләнерлек берни юк, әлбәттә, ләкин Бәдрикамал апага ничектер бу ат таныш кебек тоела һәм ул сагаеп кала. Кача-поса гына күзәтеп, кунакларның теге «батыр» Камышлы егетләре икәнен танып ала. Болар Ярмәккә төн йөрергә килгәннәр икән. Бәдрикамал Бибинур апаларга төшеп китә. Рәнҗеш-нәфрәт белән ярсыган бу ике хатын утырып киңәшләшәләр дә мал суя торган зур пычакларын үткенләп һөҗүмгә күчәләр. Караңгы төшә, егетләр клубка китә. Өйдә ут сүнә һәм Бәдрикамал белән Бибинур апа дошманның җигелә торган арба-дирбияләренә ябышалар. Бөтен каешларын тураклыйлар, тәгәрмәчләрне төрле якка тәгәрәтәләр, кендекне алып бәрәләр, инде атка чират җитә. (Болар бит сугыш елларында үгез җиккән хатыннар!) «Ярамас! — ди Бәдрикамал. — Гөнаһсыз хайванга тимик». Атны Камышлы юлына чыгарып, камчы белән берне сыдыралар да — юртак Камышлыга оча!

Әйе, кешене беркайчан да рәнҗетергә ярамый. Иртәме-соңмы җавабын көт тә тор...

...Рәшит, әлбәттә, Мансар районы башлыгына күңеле белән бик рәнҗеде. Ләкин эчке сиземләве аны бу түбәнчелектән йөз мәртәбә өстен икәнлегенә инандырды. Ә бит язмышында мондый мескенлеккә калу очраклары байтак булды. Ул аларга беркайчан да баш бирмәде. Изсәләр дә, киссәләр дә...

## Мәхәббәт һәм хакыйкать

*Синең күзләр һаман якты сибә,*
*Кояш кызы микән әллә син?!*
*Синең янда нурга коенамын,*
*Синсез салкын, синсез күңелсез...*

Сәлимгәрәйләр белән Шәмкәйләр тагын сугышканнар, дигән хәбәр, төн уртасы булуга карамастан, яшен тизлеге белән бөтен авылга таралды. Бу хәл Ярмәкнең данлыклы гайбәтчесе Гөлмәрьям әбинең өенә кайту вакытына минуты-секунды белән туры килгән. Элегрәк тә килеп чыккалый иде инде ул алар арасындагы низаглар. Ә бу юлы... Кара син, ә, Гөлмәрьямнең очравын! Бу кадәр зурга китми иде лә инде мондый чәкәләшүләр. Егетләр арасында ни булмас? Нәрсәдер бүлешә алмаганнардыр йә бер-берсенә ялгыш сүз әйтешкәннәрдер... Кем белсен? Үтә дә китә, онытыла бит ул тора-бара яшьләрнең андый җүләрлеге. Ләкин бу юлы

эшләр хөртиләнгән. Гөлмәрьямнең сөйләвенә караганда, хәтәррәк юнәлеш алган булып чыкты. Аның әйтүенчә, Шәмкәй Рәшите Сәлимгәрәй Гамиленә читән казыгы белән сугып башын ярган, ә тегесе, ярсып китеп, Рәшитнең бугазына ябышкан. Эш канашып сугышуга күчкән. Буылып үлә язган Рәшит Гамилнең кулларыннан котылып, эченә типкән.

— Мин күргәндә, Гамил: «Уф, үләм, үләм, эчем, эчем, — дип бөгәрләнеп җирдә ята иде», — ди әллә каян шунда пәйда булган Гөлмәрьямнең сердәше Сания. Монысына тагын ни җитмәгән? Каян килеп чыга шулар? Өй җылынгач уянган кышкы чебеннәр кебек. Өендә генә ятса ни була? Күптән йокларга вакыт бит инде карчыкларга. Ә-ә, имәндә икән чикләвек, монысының да биләмнән кайтып килүе икән.

— Уф, бер-берсенә әллә нинди әшәке сүзләр әйтешәләр, әстәгъфирулла, тәүбә, минем андыйларны гомеремдә дә ишеткәнем булмады, — дип сөйләнә гарьләнгән булып Саниясе.

Гамил Рәшиткә:

— Айсылуга якын киләсе булма, әгәр сине аның белән тагын бер күрсәм, үзеңне генә түгел, нәселегезне корытам, — ди икән.

Рәшит ана каршы:

— Тимә нәселгә, нәсел турында сүз кузгатырга әле синең борын астың кипмәгән, җепшек танау, — дигән сүзләр аттыра ди.

Тегесе һаман үзенекен тукый:

— Беренчедән, башта акылыңа кил, аннан соң сөйләшербез; икенчедән — бераз үс, кәтәнә; өченчедән — хәрәмләшеп сугышма!

— Кем хәрәмләшә, кем кәтәнә, кем акылга җитешмәгән? Бирермен мин сиңа, карак токымы!..

— Кем карак токымы? Авызыңны чамалап ач, Шәмкәй көчеге! — дип ябырылды Рәшиткә әллә каян төн актарып килеп чыккан Хәернисә әби.

Монысы да Гөлмәрьям белән Сания сыңары, атаклы өч гайбәтченең тагын берсе шул Сәлимгәрәйләрнең данлыклы вәкиле.

— Күрсәтермен мин сиңа каракларның кемлеген!

Күрәсең, бу сүзләре, Рәшитнең әтисе амбар мөдире булып эшләгәндә, нахакка бурлыкта гаепләнгән җыелышта Хәернисаның әйтелмичә калган ачуыдыр. Ләкин кызган баштан чыккан сүзләрнең мәгънәсе бүген тагын ачылмый калды, чөнки Рәшитнең ике ягына, аякларын киң җәеп, кулларын баһадирлар кебек дугалап, учларын йомарлап ике абыйсы килеп баскан иде. Сугышның бу этабы шуның белән тәмамланды. Теге яктан әбиле команда чәүчәләкләнеп өйләренә таралды, ә бу яклар:

— Һаман шул Айсылуың өчен чәкәләштегезме? — дигән сүзләр белән тыкрыкка юнәлде.

Тыкрык аулак. Бүген анда берәү дә юк. Баш очында галәттәгечә Ай көлә. Юк, ул көлми, сагышлы ул бүген. Рәшитнең дә елыйсы килә. Шушы көннән башлап алар күрешә алмаслар микәнни? Югыйсә Айсылу ярата бит аны. Ярата! Рәшит аны аңлый. Башкалар кебек түгел ул — ягымлы. Менә шушындый айлы кичләрдә алар бер-берсенә сыенып, бер сүз эндәшмичә, озак итеп карашып торалар. Аның күз-кашы, борыны, иреннәре шундый матур... Куллары җылы... Рәшит аны үзенә тарта. Айсылу карышмый. Ике йөрәк бер-берсенең тибешен тыңлый. Алар менә шулай гомергә бергә булырлар, бу арага берәү дә керә алмас. Рәшит күңеленнән ант итә: Айсылу бары тик аныкы гына булачак, ул аны бәхетле итәчәк!

Айга карап, йолдызлы күккә хыял атканда, татлы хисләрен Искәндәр абыйсы бүлде:

— Шулкадәр нык яратасыңмыни шул Айсылуны, ә?

# *100 нче бит: чор, милләт, вазгыять*

## ЯҢА БАЙЛАРЫБЫЗ ТАТАРМЫ?

**Бертуган Рәмиевләр Оренбургта «Вакыт» газетасы, «Шура» журналы чыгарып яткан, зур мәдрәсә тоткан. Уфадан Диния нәзарәтенең баш казые Риза Фәхреддинне чакырып (хәтта, аена 130 тәңкә түләү хакына яллап, диярга дә була, ә ул чакта бер сыерның бәясе 6-7 тәңкә), аны мәдрәсә хуҗасы һәм «Шура» журналының баш мөхәррире иткән. Шул ук Оренбургта миллионер Хөсәеновлар олы мәдрәсә төзеткән. Муса Җәлил, Нури Арсланнар укыган бу «Хөсәения» бик күпләргә мәгълүм. Бертуган Мотыйгыйлар нәшрият төзегән, «Чикерткә», «Чүкеч», «Яз» ише дистәләгән гәзит-журналлар, йөзәрләгән китап чыгарган. Гомумән, революциягә чаклы Рәсәй мәйданында татарча чыгып килгән 90нан артык гәзит белән 35кә якын журналның һәркайсысы фәкать милли байлар хисабына гына нәшер ителгән. Казандагы «Мөхәммәдия», Уфадагы «Госмания» мәдрәсәләрен дә үзебезнең байлар салдырган. Бөтен Европада иң зур булып саналачак Петербург мәчетен 1906 елда Нижгар бае Гатаулла Баязитов төзетә башлаган, аңа Темников, Сергач, Алатырь тирәсеннән чыккан татарлар хәләл акчаларын биреп кушылган. Мәскәүдәге җәмигъ мәчетне салу өчен дә иң беренче чиратта татар байлары үзләренең байлыгыннан өлеш бүлеп биргән. Миллионер Әсәдуллаев үз акчасына нәкышле өч катлы таш йортны салган да, аны соңыннан татар җәмгыятенә бүләк иткән. Уфада Сәлимгәрәй Җантурин «Галия» мәдрәсәсен салу өчен 30 мең алтын тәңкә акча бүлеп биргән. Ул суммага бай агаебыз үзенең утарына көмешләнгән ияр-йөгәнле ике мең чаптар ат сатып алалган булыр иде. «Галия» мәдрәсәсеннән Галимҗан Ибраһимов, Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Шәехзадә Бабич кебек атаклы шәхесләр үсеп чыгуында аның өлеше дә бар... Нижгар, Әстерхан, Сембер, Җаек, Иркутск, Новосибирск, Сарытау, Пенза, Симферополь, Феодосия, Судактагы һәм тагын әллә ничә каладагы йөзәрләгән мәчетне төзү өчен дә, аларның һәркайсы каршында мәдрәсә салу һәм ачу өчен дә акчаны Рәсәй патшалары бүлеп бирмәгән, һәммәсен дә, нигездә, татар байларының сәрмаясы белән калкытканнар. Шул ук байлар татарны матбугатлы, китаплы, театрлы иткән. Ә хәзер?**

**Бүген Җантуриннар, Хөсәеновлар, Рәмиевләр, Мотыйгыйлар, Мәрҗаниләр... гомумән, офыкта юк. Кайда, кемнән нинди тәрбия, үрнәк алып җитлеккән соң бүгенге милли байларыбыз? Югыйсә нинди генә байлар, «тузлар» юк бит бездә. Бөтен дөньяга таралучы «Форбс» журналы язуга караганда, татарлар арасында да долларлы миллионерлар әллә ничә дистә икән! Һәм ни аяныч, кайсыныңдыр Гатаулла Баязитов калкыткан һәйкәлгә тиң искитмәле мәчет салуы; фәкать татар балалары өчен генә институтларга биргесез мәдрәсәләр, көллиятләр, сәнгать яисә спорт мәктәпләре ачу; Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхреддин, Гаяз Исхакый кебек акыл ияләренең том-том китапларын бастырып халыкка тарату; татар яшәгән һәр төбәккә барып җитәрдәй күләмдә гәзит яки журнал чыгара башлау; бөтен дөнья буйлап сибелгән татарлар файда күрсен өчен милли банк төзү... хакындагы хәбәркәйләр бер дә ишетелми.**

**Вахит ИМАМОВ**

— Әйе, яратам.

— Ана караганда да матуррак кызлар бар бит авылда.

— Алары үзегезгә калсын. Ә Айсылу минем өчен иң матуры, иң кадерлесе.

— Әле син бик яшь бит. Тормыш күрмәгән. Дөньяның төрле чаклары булыр: кыенлыгы, авырлыгы... Ул бер алдын, бер артын күрсәтә, диләр. Артын күрсәтсә, Айсылуың белән нишләрсең?

— Бергә җиңеп чыгарбыз! Әй, абый, син миңа нигә акыл сатып торасың. Олырак икәнсең, тормыш тәҗрибәң бар дигән сүз түгел бит әле бу.

— Болай гына әйтәм, энем, сине кызганып кына, хәлеңә кереп кенә. Башта армиягә барып кайтыйк әле, аннан сөйләшербез.

— Мине анда алмыйлар.

— Ник?

— Буем метр ярым гына.

— Алалар, энем, алалар! Синең кебек батыр егетләр бик кирәк анда!

— Туктагыз әле, энекәшләр, — дип, моңа кадәр уйланып, бер дә сүзгә катнашмый, караңгы тыкрыкта нәрсәнедер типкәләп барган олы абыйлары Равил сүзгә килде.

— Рәшит, сиңа бер киңәш. Әйбәтләп тыңла мине, әтинең сөйләве буенча, бу безнең Сәлимгәрәйләр белән тынышмау тирәндәрәк ята. Миңа ышанмасаң, әнә әтидән, әнидән сора. Бәлки теге вакытларда әтинең колхоз рәисе булып эшләве дә моңа сәбәпчедер. Ул вакытта Сәлимгәрәй белән әти арасында нидер килеп чыккан. Бәлки, сәбәп тирәндәрәк ятадыр, яшьлек елларына кадәр барып тоташадыр... Үзегез беләсез, әти чи коммунист, намуслы. «Яшәсен Сталин! Яшәсен Советлар Союзы!» — дигән тәгълиматтан бүтәнне белмәде. Аның шундый булуы безгә дә рәхәтлек китермәде, ләкин без гомер буе аның белән горурланып яшәячәкбез. Кемгәдер ул ошап та, ярап та бетмәгәндер. Шул исәптән, Сәлимгәрәйгә дә. Әнә бит, Хәерниса әби, карак дигән сүз чыккач, ничек чәчрәп куйды. Димәк, нәселдә булган. Бурлык, караклык йогышы тамырда бар икән, ул — төзәтеп бетермәслек чир. Аны каннан чыгарып булмый. Ярый, бу очракта да әти бит аларны сатмады, чөнки ул аларның кулыннан тотмаган, шикләнү генә бар. Караклыкка сугыштан соң да ай-яй хәтәр хөкемнәр чыгарганнар. Әтине дә утырта алмадылар, ләкин шуңа ачулары калган кешеләр әле дә бетмәгән. Безнең гаиләнең матур гына яшәвеннән көнләшүчеләр күп. Тагын шул: әнинең безнең әтине сайлап алып кияүгә чыгуы да Сәлимгәрәйнең ачуын кабартып тора. Мин аны сезгә сер итеп кенә әйтәм. Тешегезне кысып, телегезне тыеп йөрегез. Яшь чакта Сәлимгәрәйнең ничек итеп әни артыннан өзгәләнеп йөрүләре, миңа кияүгә чыкмасаң, көн күрсәтмим дип куркыту-янауларын да онытырга ярамый. Үчле кеше ул. Әнә, күрәсез, балаларын гел котыртып тора. Юктан сәбәп таба, үчекли. Янәмәсе, без вак-төяк, тәбәнәкләр, алар озын, мәһабәт гәүдәлеләр. Әйтсен, сөйләсен, ләкин безнең ана әлегә кадәр махы биргән юк. Төптән таза безнең нәсел, бабаларыбыз токымы! Энем, хәтереңдәме, синең мәктәптә Гамил белән шундыйрак бер хәл булып алган иде.

— Күптәнге нәрсә бит ул.

— Күптәнгесен күптәнге, әмма ләкин шул Сәлимгәрәй токымы белән килеп чыккан тәпәләшүегез әле һаман истә.

Сүзгә Искәндәр кушылды:

— Теге вакыт, әйе, сине әти белән әни, кимчелеге булган балалар өчен махсус мәктәпкә бирмичә, үзебез янында укысын, читтә ятим булып йөрмәсен дип, авылда калдырдылар. Минем хәтердә әле аларның сөйләшүләре. Күз-колак булырбыз, авыруы бер дә төзәлмәслек түгелләр, диделәр. Әнә, авыру дип саналмасалар да, никадәр балага уку авыр бирелә, шулар белән бергә, туган авылында үтәр әле гомере, дип мәктәпкә йөрттеләр.

— Әйе, көчкә укыдым, ләкин рәсем, жыр, физкультура дәресләрендә мине узучылар юк иде.

— Беләбез, энекәш, беләбез... Үпкәләмә генә, яме?!

— Юк ла... Сез булмасагыз, мин бөтенләй чыгырдан чыккан булыр идем. Әле күп вакытта, хаксыз булсам да, сугыша башлыйм.

— Гамил белән нигә бәрелешеп алдыгыз соң теге вакытта?

— Үзе бит, тиктомалдан «псих», диде. Синең укуың безнең мәктәптә түгел, психбольницада, безнең Айсылуга карама, тагын бер карасаң, психыңны чыгарам, — диде. — Мин аңа барыбер карап торачакмын! — дидем. — Шуңа күрә син псих, — дип тагын кабатлады. — «Мә-ә-ә», — дип телен чыгарып күрсәтте.

Мин кукиш ясап үртәдем. Төрткәләшеп алдык. Ләкин төне буе, йоклый алмыйча, шул әйткәләшүгә хурланып яттым. Мин бит аны мәсхәрәләмәдем. Акылга утыртырга кирәк үзен. Эндәшми калу — җиңелү. Күрсәтим әле мин аңа «псих»ның ничек булганын!

Икенче көнне синнән, Искәндәр абый, учка киеп сугыша торган теге — кургаштан коелган әйберенне урладым да аулак җирдә Гамилне көтеп тордым. Анда да Гамил сугышны үзе башлады. Мине күрү белән:

— Нихәл, псих? — дип төртүе булды, бераз чыдап тордым да иштем үзен. Теттем тетмәсен. Битенә синең әйбер белән өч тапкыр чәпәдем. Шул кирәк сина, мәйтәм. Үзең башладың сугышны, димәк, үзең гаепле.

Мәктәп шаулый. Рәшит Гамилне кыйнаган, гомер булмаганны... Гамил класска керә, күлмәге белән битен каплаган да: «Ул кайда, мин аны хәзер үтерәм!» — дип акыра-акыра елый икән.

Әлбәттә, рәхәт түгел ул бер сугышкач кабат дуслашуы. Әнә, күрәсез, дошманлык һаман дәвам итә. Айсылуга да көн күрсәтмиләрдер. Әнисе Хәлимә апа да кызганыч, ул миңа гел: «Сугышмагыз, балалар, тату гына йөрегез!» — дип күпме әйтте инде. Гамилләре бит, әнә, әллә нинди...

— Ярый, энем, җирдәге халык төрлесе төрле, охшашлары бик юктыр, шуңа күрә яманнарга түгел, яхшыларга тиңләш, — дип, Рәшитнең ачынып сөйләүләренә йомгак ясагандай, Равил абыйсы сүзгә кушылды. — Ә хәзергә безгә көрәшергә туры килә, үзебезнең хаклыкны, дөреслекне сугышып булса да, дәрәҗәне төшермичә, исбатларга тырышыйк. Айсылуыңны яратасың икән — бирешмә! Без янәшә булырбыз.

— Рәхмәт, абыйларым!

## Рәнҗешләр һәм куанычлар...

*Калмый икән яшьлек артта,*
*Шулай кебек кенә күренә.*
*Яшьлек бары кучә генә*
*Гомерлеккә йөрәк түренә.*

Хәмзә белән Шамкайның телефонын бөтен Рәсәй белә. Беркөнне Ижау каласыннан шалтыраталар:

— Рәшит абый, үтенеп сорыйбыз, үзегезнең «Биш татар»ыгыз белән Ижауга килмәссез микән? Халык бик сорый. Иртәгә үк кирәк. Чөнки берсекөнгә бездә Сабантуй, кунаклар күп кайта. Кичен Мәдәният сараенда куяр идегез. Чыдар хәл юк, сезне сорыйлар, берүк каршы килә күрмәгез инде, яме?

— Туктагыз әле, исемегез ничек?

— Язилә.

— Ә-ә, исәнме, Язилә? Иртәгә үк?! Нәрсә, бүтән группалар риза булмадымыни? Хәзер без кирәкмени?

— Юк ла инде, Рәшит абый, акчасын бүген генә таптык. Сезне сорыйлар, сезне көтәбез. Күпме түләргә сон, әйт? 25 житәме, өч нулен өстәп?

— Ә үзенә күпмесен кысасын?

— Нәрсәгә инде, Рәшит абый, анысы сина? Акча табу жинел эш түгел ул.

— Хәмзәгә шалтырат, ул безнен шеф. Ул нәрсә әйтә, без — как штык, әзер! 56-13-80 номеры.

— Беләм. Синен аша аны күндерим дигән идем. Хәмзәне үгетли, йомшарта, юмалый тор әле.

— Карале, кызый, мин йомшартып, мин гаепле булып кала торган булмасын! 50не — яме? Килештекме? Хәмзә, белмим, тагы күпме өстәр.

— Үземә калмый ич.

— Кала, кала, беләбез сине.

Иртәгесен иртүк алар Ижау юлына чыктылар. Күнелләре күтәренке. Театр ялда — болар юлда. Жәйнен икенче ае башланып килә. Шәрәфи үзенең бәләкәй чакларын тәмләп-тәмләп сөйли. Анын авыз ижаты барысын да жәлеп иткән. Рәшит «буханка» салонынын алдагы почмагына оялаган да, галәттәгечә, тыныч кына тыңлап бара.

— Без бит авыл малайлары. Тормыш авыр дип тә тормадык, һаман шук булдык. Анын жинелрәк тә, әйбәтрәк тә булырга мөмкинлеген кем белгән? Барыбыз да сәләмә киемнән, ачлы-туклы дигәндәй, аннан сон сугыш еллары булса да, ил хәсрәтенең миндәй малай-шалайга, әби-бабайларга, апаларга төшкәнен үзебез дә сизми йөргәнбез.

Беркөн Сталинны күрдем. Ап-ак кительле, мин синайтим. Шул кителен киеп безнең Тегермән тавына менеп бара... Иртән шулхәтле рәхәтләнеп уяндым. Миннән дә бәхетле кеше юк иде кебек ул көнне. Сталин хәтле Сталинны күр әле син! Дусларыма шул төшемне сөйләп ушларын алдым. Берсе, мылтыгы бар идеме, дип сорый. Икенчесе, сине күрдеме, ди. Күрде, мин әйтәм, баштан сыйпап китте. Әле сина да сәлам әйтте, дигән булам. Мина нәрсә диде, дип башкалары да ябырылды.

— Карале, Шәрәфи, без дә шул Сталин мылтыгы белән женләнә идек, үскән чагында, — дип, Хәмзә анын сүзләренә кысылды. — Айзат исемле дустыбыз бар иде, ул менә гел шул Сталин мылтыгы турында күп сөйли иде. Без күктәге Айга нәрсә белән атып житкереп була дип бәхәсләшкәндә, Айзат, бәхәсләшмәгез дә, Айга бары тик Сталин мылтыгы белән генә тигезеп була, ди торган иде. Шәрәфи, әйдә дәвам ит, гафу, бүлдердем инде сине.

— Шуннан сон, кыш житкәч, безнен алагаем зур ап-ак кәжәбезне бер бүре шул Сталин күренгән жирдән — Тегермән тавыннан алып китте. Ул елларны бүреләр бик азган иде. Күрәсен, без ач, бүреләр тагын да ачрак булгандыр. Авылдан ерак түгел жирдә кәжәбезнен гәүдәсен таптык. Ашап бетерә алмаган. Әйткәнемчә, зур иде шул. Төштәге ап-ак кительле Сталин белән ап-ак кәжәбезне нәрсә бәйләгәндер — аңлатыа алмыйм. Ил бәлагә батты, без сөтсез калдык.

Хәзер тагын бер булган хәл турында сөйлим. Сугыш вакыты. Әти сугышта, бер абыем да шунда. Әни ялгызымны өйдә бикләп калдырып эшкә китә. Мин сугыш беткәнче өйдә утырдым. Өстемә кияргә киемем дә, аягыма кәлүш тә юк. Пес итәргә чиләк калдыралар. Өйалдына чыгам. Тәрәзәсе юк. Берзаман күрәм — пыяла ишек. Каян килгән бу? Күзләремне уып карыйм, өнемме-төшемме? Алдымда ап-ак сарык бәрәне арт аякларына басып пыялага шакый. Ишекне ачып кертмәкче булам, келәне күтәрә алмыйм. Маташтым, тырыштым — ул ара бәрәнем югалган да.

Хәзер гомерләр узгач уйлыйм: мина изге бәрән килгән булгандыр. Агнец божий диләрме әле икенче телдә? Аны мина Ходай жибәргәндер. Кертергә кирәк

булган да бит, килеп чыкмады шул. Кертә алган булсам, бәлки, тормышым икенче юлдан киткән булыр иде.

— Моннан да яхшырагы кирәкмәстер, Равил абый, сиңа. Син, сөбханалла, сау-сәламәт, әле сиксәнне дә, туксанны да тутырачаксың, аласы мактаулы исемнәрне алып бетердең, менә пенсияңне дә кочак тутырып бирә башласалар, синнән дә бәхетле кеше булмаячак, — дип, Сабир Шәрәфи хикәясенә нокта куйды сыман.

— Учлап кына, чеметеп кенә бирәләр шул, Сабир туган, — дип, Шәрәфи юри мескен тавыш ясады. — Умырып бирсәләр, мин сезнең белән Ижауга хәтле сәфәр чыгарга ризалык бирер идемме? Ыштан туздырып, бил бетереп, вакыт уздырып... Әле бит аның акчасын бирәләрме, юкмы? Билгесез. Ул Язилә дигән туташны беләм мин. Аның уйлары көненә биш үзгәрә.

Бервакыт ул безне бик кызык итте. Зинһарлап, бер ай чамасы алдан артистлар җыеп, Ижауда концерт билгеләде. Ниләр генә вәгъдә итмәде инде! Мин исә чүт ли миллионер булып кайтып китәчәкмен! Ай, матур да сайрый кызый! Сипкелле чибәр! Әллә шул сыйфаты башымны әйләндерде: гипнозлады бит бу мине — карт җүләрне. Шул концерт көненә туры килгән спектакльне үзем катнашмаган икенчегә алыштырттым театрда. Барыр көн килеп җитәрәк, хәбәр ишетәм: концерт булмый, бүтән көнгә күчерелә. Соңыннан әйттеләр — концерт куелган, безнең урынга башкалар чакыртылган. Андый «тамашалар» гел оештырыла. Халыкка «фәлән-фәлән зур артистлар киләчәк» дип хәбәр таратыла да тамаша вакытында «безне, ягъни оештыручыларны алдалыйлар» дип әйтелә. Шуннан аңлашыла инде — зур артистларга вәгъдә ителгән акча кесәләренә чума, ә безне алыштырган вак-төякләргә аз түләсәң дә ярый.

Яшьтән үк шулай беркатлы, кешегә ышанучан булып үстем мин. Ярый әле хатын-кыз булып тумаганмын, отказ бирә торган гадәтем юк.

— Равил абый, юкка төшенкелеккә бирелеп барма әле. Гел-гел кешене алдап булмый ул.

— Шундый вакытта халык мәкале исемә төшә: «Чир китәр, гадәт калыр». Безне әти-әни «Кеше әйберенә тимә, намуслы, ярдәмчел бул!» — дип үстерделәр. Әле сөйләп бардым ич. Сугыш вакыты, ач-ялангач йөргән чаклар. Кая ул кеше өлешенә кагылу. Колхоз кырында үскән бер башак урлап кайтсаң да, башың төрмәдә бетәчәк заманнар иде бит.

— Ә хәзерге чор башка, — дип сүзгә Җәлал кушылды. — Менә Язилә турында сөйләп килдең. Минем дә шундыйрак бер хәл исемә төште. Себер якларында концертлар куеп, «себерелеп» кайтып киләбез. Йөри-йөри арт яклар чиләнеп бетте. Акча эшләргә бардык бит инде. Алдан ук Себердә халык концертларга күп йөргәнен ишетеп киттек, тик баргач күрәбез, бер дә алай түгел: заллар яртылаш та тулмаган — күнелләр китек.

Безгә концерт өчен матур гына түләргә вәгъдә биргән оештыручыбыз — Бакир бу хәлгә аптырамый да кебек. Гастрольләребез тәмамланып, инде кайтып киләбез. Концертлар санын һәр көнне биреләчәк акчага тапкырласаң, байтак кына сумма чыгарга тиеш тә бит... Саныйбыз, һич тә алай түгел. Түзмәдем: «Энекәш, әллә син мине бу хәтле ерак җәһәннәм тишегенә Себер халкын яратканга бардым дип белдеңме?» — дидем.

Сөйләшүгә Сабир кушылды.

— Себердә шулай. Андагы администраторлар концерт дип төркем җыялар да гастрольләр оештыралар. Үзләренчә тырышып та эшлиләр кебек. Тик аларның изге гамәлләре, ягъни татар халкы өчен «янып-көеп йөрүләре»нең нәтиҗәсе бик кечкенә булып чыга. Чөнки үзара дуслык юк. Алар акча белән дус. Акча дигәндә бер-берсенең бугазына ябышалар, концертларын яманлап сөйлиләр,

ябыштырылган афишаларны ертып, чакырылган артистлар турында гайбәт тараталар. Шулай, хәзер Себергә барырга уйласаң, кайтыр өчен кесәнә акча тыгып кит.

— Шулай бервакыт, элегрәк, — дип сүзгә Рәшит иярреп китте. — Теге, сукыр баянчы бар бит әле — Баншах, шул, акчаны шәп түләрмен диде дә Себергә алып китте. Ул андагы себерелеп йөрүләрне, интегүләрне сөйләп аңлатырлык кына түгел. Ярый, анысы башка мәсьәлә... Халык концертка йөри йөрүен — зарланырлык түгел, ә менә чебен-черкигә түзәр әмәл юк. Канны прәме йөрәктән суыралар. Ун көн буе шуна чыдап, Баншахның тәмле теленә ышанып, кулга керәчәк утыз алты меңне уйлап, куанып, халыкны күңеле булганчы көлдерергә тырыштым.

— Йә, сузмый сөйлә, ничек булып бетте. Бирдеме соң утыз алты меңне?

— Кукиш!.. Инде ун елдан артык вакыт үтте, очраганда: «Бирермен, бирермен», ди дә югала.

— Судка бир!

— Бернинди килешү кәгазьләре тутырылмаган, мөһер сугылмаган, аннан соң сукыр кеше белән судлашып йөрү дә әллә ничегрәк...

— Анысы шулай инде. Ну капкансың син, малай, капкыңга!

— Ходай Тәгалә бар бит, мин булмасам, Ул тигезли. Эләкте Баншах аның кармагына. Тыңлагыз, сөйлим.

Шул гастрольләргә китәр алдыннан Баншах кибеттән өр-яңа кесә телефоны сатып алды. Моңа беренче ун көндә, рәхәтләнеп, акча түләмичә, бушка сөйләшә аласың, дип әйткәннәр. Автобуска кереп утыру белән шалтыратырга тотынды бу. Башта хатынына шалтыратты: «Сөеклем, телефон алдым, колагымдагы ин беренче тавыш синеке. Мине юксынмыйсыңмы? Түз, бәгърем! Күп итеп акча алып кайткач, Урта Дингез буйларын әйләнербез, яме? Пока».

Телефонның теге башыннан да хатынының «пока» дигәне ишетелә. «Ымма» дип чупылдатып үбешү тавышлары яңгырап куя боларның. Юл буе шулай: «Менә хәзер Биектауга җиттек. Әйбәт ишетеләме? Кайткач, сиңа да шундый телефон алып бирермен. Мин сине яратам, көт, сөеклем! Ымма, ымма!» Телефонга һич тынгы юк. «Менә Кукмарага кердек, Можганы үтеп барабыз, Чайковский артта калды, алда Барда күренә». Сөйләшүнең ахыры гел һавалы үбешү белән тәмамлана. Башка кызларга шалтыратулар да «ымма»лы булып бетә. Бу телефонга янәшәсендә утырып баручы бүтәннәр дә җайлашты. Мәскәүдәге сөяркәләренә дә шалтыраталар, Казандагыларга да. Шулай йөри-йөри гастрольләр дә тәмамланды. Ниһаять, өйләребезгә кайтып аудык.

Берничә көннән соң Баншахның тавышын үземнең телефоннан ишетәм. Акча бирәме, дип торам. Юк икән, һаман үз кайгысы... Карале, Рәшит абый, минем кесә телефоным белән теге вакытта — гастрольдә йөргәндә кемнәр файдаланды, хәтерлә әле, ди. Нигә ул сиңа, дим. Ун көн буе бушка теләсә кем белән сөйләшергә була дигәч, әллә кемнәргә биргән идең бит. Мин кулланмадым, дим. Әйе, син сорамадың, беләм, ә менә кемнәр шалтыратты — очына чыга алмыйм, беләсе иде, ди.

Нәрсәгә хафалана бу, чамалый башладым: «Ымма, ымма», — дип сөйләшүләргә егерме алты мең түләргә счёт килгән икән моңа.

Бер карасаң, кызганыч та инде үзе, сукыр бит. Ходай Тәгалә гариплеккә карамый, хәрәм малга нәфесен тыймаганнарны барыбер җәза кыла икән.

— Ходай Тәгалә җәзасын бирә дигәннән... — дип әңгәмәгә Хәмзә кушылды. — Яшьрәк вакытта бер профессионал рәссам белән колхозларда оформление ясап йөрдем мин. Исеме — Фариз.

Күп очракта колхоз рәисләре бик саранланалар яки эш өчен бөтенләй

түләмиләр. Мондыйларга ачуы чыккан Фариз хәйләгә кереште: договор төзегәндә, председатель алдында сөйләнә башлый: «Менә үткән ел «Дуслык» колхозында оформление ясадык. Килешкән вакытта җитәкче кеше болай әйбәт зат кебек күренә иде, ә эш үтәлеп, түләү турында сүз чыккач, бик ямьсез кыланды. Кыскасы, төрле сәбәпләр табып, расчёт бирми интектерде. Шулхәтле рәнҗедем шуңа, шулхәтле рәнҗедем!.. Рәнҗеш төшә бит ул — күп тә үтмәде, хатыны үлде. Ул хәтле нык каргамаган да идем югыйсә», — дип хушын алды тегенең.

Аннан тагын бер очрак — Кама Тамагы районындагы бер колхоз рәисе белән булган хәл. Үзе чакырып кайтарды. Әле, җитмәсә, без оформление ясаган колхозларны күреп, шаккатып кайтканлыгын сөйләде. Килештек. Аның фантазиясе буенча, эш җиренә җиткереп башкарылды. Түләргә, дигәч тотлыга башлады. Күпсенде. Югыйсә күп тә сорамадык инде. Күренми дә, качып йөри. Бер тоттык без моны. Фариз теге методны кулланмый булдыра алмады. Әле моңа хәтле мин дә ишетмәгән рәнҗешен сөйләргә тотынды... «Түләмәгән иде берәү. Рәнҗедем. Күпмедер вакыт үткәч ишетәм, хатыны үзен сөяркәсе өстендә тоткан. Өеннән куып чыгарган. Ул заманнарда партия законнары — эшеннән дә арт ягына тибеп чыгарганнар».

Фаризның монысы турында сөйләп бетерүе булды, әлеге рәис төзелеп бетеп бара торган договор кәгазен идәнгә атып бәрде дә безне идарәдән куып ук чыгарды. Соңыннан белдек, Анталиягә ял итәргә баргач, бер марҗа белән типтереп йөргән икән. Хатыны сизгән, артыннан барып, ни кыланганын күреп кайткан. Хәзер өйгә кертми, бу идарәдә кунып ята ди.

Шулай итеп, соңгысында бер тиен дә эшли алмый калдык. Чыннан да, рәнҗеш төшә икән ул, төшә икән...

Сүз артына сүз ияреп, байтак юл үтелгән, вакыт узган. Әйе, юлга чыкканда «Биш татар»ның әңгәмә өчен тема беткәне юк әле. Ижауга килеп кергәннәрен сизми дә калдылар.

Мәдәният сарае каршында зинһарлап чакырылган артистларны Данир исемле егет көтеп тора иде. Ул Хәмзәгә ят кеше түгел, Ижауда татар җәмгыятенең күренекле шәхесләреннән берсе, шактый гына бай кеше, сәнгать яратучы һәм, алай гына да түгел, бик әйбәт җырчы да әле. Машинадан төшүче һәр кунакны кочаклап, ихтирам, хөрмәт күрсәтеп, итагатьлелек белән каршы алды.

— Язилә кайда соң, Язилә? — диеште артистлар.

— Язилә? — диде Данир, уйланыбрак торгач, — ул бүген бу Мәдәният сараенда башка артистлар белән мәшгуль. Гафу итегез, абзыйлар, каршы килмәсәгез, мин сезне үземә алып кайтам, минем бүген туган көн.

«Биш татар» аптырашта калды.

— Ничек инде?.. Без бит концерт куябыз дип килдек. Ну, кабахәт тә инде бу кызыгыз, ничек әле исеме? — дип, Җәләл чыгырыннан чыга башлады. — Аллаһы Тәгаләнең ачы каһәре төшсен! Әле юлда гына шундыйлар турында сөйләшеп килгән идек...

Җәләл әйтеп бетергәнне көтмичә, сүзгә Данир кушылды:

— Абзыйлар, борчылмагыз! Барысы да әйбәт булыр. Минем өйдә хәзер сезне туган көнем уңаеннан җыелган кунаклар көтеп тора. Мин Язиләнең мондый начар гамәл кылганын әле генә ишеттем. Йөрәгем шуңа әрнеп, сезне каршыларга килдем. Туктале, мин әйтәм, сезне туган көнгә чакырыйм — шундый бөек шәхесләребезне. Кайчан күрергә насыйп булыр әле барыгызны бергә? Яхшылап бәхилләтермен, минем ана гына мөмкинлегем бар. Равил абый, һәммәгезгә егермешәр мең җитәрме?

Сумманың нихәтле икәнен шундук чамалап алган Җәләл:

— Молодец, энекәш, егет икәнсең! — дип, Данирның кулын кысты.

— Әйбәт килеп чыкты әле бу — Язиләнең этлеге! Шулай бит, егетләр! Хәмзә, ник дәшмисең?

— Яхшылыкны комментировать итмиләр.

— Ну, эчәбез икән!

— Кит инде, әчкән кеше кебек сөйләшкән була! — дип, Сабир Рәшитнең эченә төртеп куйды.

«Биш татар», алтауланып, Данир коттеджына юл алдылар.

## Тормыш тыкрыклары

*Ары тарттым, бире тарттым,*
*Шактый малым калды түгелеп.*
*Шул малларымның астында*
*Мәхәббәтем калды күмелеп.*

Мәктәпнең тугызынчы классын тәмамлап, Алексеевка бистәсендә урнашкан тракторчылар курсына барып кергәндә, Рәшитнең буе бер метр да утыз җиде сантиметр иде. Ә инде училищега кергәндә, егерме биш сантиметрга үсеп, бер дә алтмыш икегә җитте. Тәбәнәк булуына бик гарьләнә иде, әлбәттә, әмма юлбашчыларыбыз Ленин белән Сталинның да шул чамада булганлыкларын белгәч, көенеп йөрүдән туктады. Кечкенәсен кечкенә дә, ә кызларга багышлап шигырьләр язарга, һинд киноактёры Радж Капур кебек җырлап, аларны гашыйк итәргә бик остарды. Шуларның берсенә, башын югалтырдай булып үзе дә гашыйк, тик менә Айсылуы бар. Исеме дә матур юкса — Ләйлә. Шул Ләйләне очратса, Рәшит кызара, тирли, нишләргә белмичә, әйтәсе килгән сүзләрен оныта, әйтә башласа, тотлыга. Ул аның атлаулары, елмаюы, кыйгач кашларының, керфекләренең сирпелүе... Их, кулыннан гына тотса да... Их, сулышын тойса да... Их, төшендә генә булса да үпсә, кочса иде Ләйлә... Ләйлә...

Аның «Ләйлә, Ләйлә» дип пышылдап саташып йөрүен күргәч, дусты Әсхәт татлы хисләрен боза торган иде.

— Чирлисеңме әллә? Врачка бар! — ди ул һаман саен.

Тәмам үлә инде бу дип уйларсың аңа карап. Бүтән кызлардан оялып та тормый, җүләргә сабышып, күкрәкләренә килеп ябыша. Сугып та җибәрәләр. Ә Ләйлә янына барып: «Исәнмесез!» — дип әйтергә теле әйләнми. Ләйләнең исә аңа бер караш ташлаганы да юк.

Шулай да Рәшит беркөнне, бөтен кыюлыгын җыеп, Ләйләне аулаграк урында көтеп алды. Шунда әллә ничек ирексездән: «Яратам мин сине, Ләйлә!» — дигән җөмләсе бүселеп чыкты. Бигрәк тупас әйтелде кебек. Кыз бармагы белән үзенең чигәсенә төртеп күрсәтеп, «акылыңдамы син, егет» дигәндәй китеп барды. Рәшитнең бар булган мәхәббәте коелды да төште.

Рәшит катып калган багана кебек шунда байтак басып торды. Карале, нишләп соң әле бу кызга дөньясын онытып гашыйк булып йөри ул? Әллә ни матур да түгел икән бит. Кәкре аяклы бугай, сипкелле дә... Үзе тагын салкын таш кебек. Вәт, җүләр, кемгә гашыйк булган бит! Әйткән иде аны Әсхәт: «Кай җиренә кызыктың соң син аның?» — дип.

Рәшит кырт борылып, борынын өскә чөеп китеп барды. Коридорда очраган яшь кенә укытучы апасына күз дә кысып алды әле. Тегесе дә күз кысып җавап бирде. Менә бит, тормыш дәвам итә!

Рәшит ял көннәренең берсендә, авылына ялга кайткач, Ләйләгә ачу итеп, маркасыз хат язып салды, сыңар куплет такмактан гайре бүтән бер сүз дә юк иде.

Ал минем түбәтәем,
Гөл минем түбәтәем.
Хөкүмәткә файда булсын —
Ун тиен түләтәем.

Шуннан соң Ләйлә сырпаланып караса да, Рәшит инде аны Ярмәгендәге Айсылуына алыштырырга теләмәде. Бүтән Ләйләгә сәлам дә бирмәде. Курсларда уку бик тыгыз булса да, бер кичне җай табып, Айсылуга багышлап шигырь язды.

Һай сылу да бит син, Айсылу,
Күрми торсам, була ямансу.
Китмәм бүтән ерак-еракларга —
Авыр бигрәк сине юксыну.

Конвертны ике эчле итте. Тышына: «Ярмәккә, Шамкаев Равилгә», — дип куйды, ә эченә: «Абый, монысын Айсылуга тапшырырсың әле», — дип, бәрәнге изеп ябыштырды да хатны почта әрҗәсенә илтеп салды. Тагын бер күчермәсен кесәсенә салып куйды, кайткач, бәлки, үзенә тапшырырга мөмкинлек булыр. Чыгармыйлар бит Айсылуны.

Бер группада егерме сигез курсант, араларында ике татар малае да укый. Рәшитнең «Урал» исемле, ни кулныкы, ни кесәнеке түгел — зур сәгате бар. Шул сәгать нигәдер холыксызлана башлады: йә бик нык алга китә, яисә бөтенләй туктый, кайчагында хәйран гына йөргән дә була. Тулай торакта ул аны сатарга тырышып карады. Алмыйлар. Тыңлап-тыңлап карыйлар да, «носи сам» дип, үзләренчә мыскыл итәләр. Нишләргә моның белән?

Бервакыт укучыларны физкультура дәресендә салкын сулы тирән күлгә коенырга алып баралар. Рәшит физрук Василий Ивановичка: «Хәзер фокус күрсәтәм, бернича курсантның трусигын сезнең каршыгызга китереп ташлыйм», — ди. «Как это?» — дип гаҗәпләнә укытучы. «А вот так», — ди дә Рәшит:

— Уважаемые курсанты, менә алтын сәгать, кем дә кем шушы сәгатьне күлдән таба ала — сәгать шуныкы, — дип сәгатьне суга тондыра.

Нәкъ Рәшит әйткәнчә килеп чыга. Егерме сигез малай «чумбылт» суга сәгать артыннан. Эзлиләр. Тончыгып өскә калкалар да кабат чумалар. Күл өсте кайнап тора. Алар — Ярмәк малайлары, бик тә җитез сулы елга буенда үстеләр. Берберләрен узу өчен әллә ниләр кыланып бетәләр иде. Су астында иң озак торучы ул — Рәшит. Астан килеп, су өстендә йөзүчеләрнең трусигына ябышсаң, ул берни дә эшли алмый, аякларын болгый-болгый, үзе үк салдырырга булыша. Шундый алым белән Рәшит алты малайның трусигын салдырып, Василий Иванович каршына илтеп ташлый. Ә сәгать?.. Бичара сәгать әле дә булса һаман күл төбендә ятадыр.

— Да, — ди Василий Иванович, татарларны хитрый халык диләр иде, дөрес икән!

— Әйе, Василий Иванович, без әле мудрый да. Безне өйрәтергә түгел, безне өйрәнергә кирәк! — дип, Рәшит мактанып куя шулчак.

Ниһаять, укуны бетереп, эш башлана. Рәшитне Куйбышев өлкәсенең Алексеевск районы Барак совхозы кырларына җир тырмалауга куялар. Булышчысы — бергә укыган Әсхәт, үзе төсле шәп егет. Җир тигез. Әсхәт кырның бер башында, Рәшит — икенчесендә. Тракторны боралар да җибәрәләр, боралар да җибәрәләр. Утырып йөрү юк, ышту син, тузан сулап йөрергә, аларны кем дип белдегез? Берзаман карасалар — тракторлары юк, кая киткән? Эзли торгач табалар — тирән ерганакка төшеп сүнгән икән. Бу татарларның юньле эше булмас, дип егетләрне сүгәләр дә өйләренә кайтарып җибәрәләр.

Ул елларның авырлыгын, хәсрәтләрен сөйләп кенә бетерерлек түгел. Авылның Суыксуын буып эшләнгән электр станциясе бар. Аның көче барлык хуҗалык эшләрен башкарырга, ягъни фермаларга, авыл йортларына ут бирергә җитә. Менә шунда әллә ничек биш хатынны ток суга. Дүртесе исән кала, ә Рәшитнең олы абыйсының хатыны, ягъни җиңгәсе үлә. Шулхәтле яраткан җиңгәсенең якты дөньядан китүен ул бик авыр кичерә. Шәмкәйләрнең барлык туганнары көн-төн елашалар. Җиңгәсенең чөгендер алу мәшәкатьләре дә әнисе белән Рәшиткә төшә.

Колхоз шулай ук дуңгызлар үстерү белән дә шөгыльләнә. Татар авылында ике мең баш дуңгыз карау үзе бер газап инде. Мирзаҗанның ферма мөдире булып эшләгән чагы. Сыер, сарыклар да аның карамагында. Ул елларда сарыкларга бүреләрдән дә тынгылык булмый. Ирләр, төннәр буе каравыл торып, кышын Юкә Тау башыннан төшми.

Бер елны җитмеш биш атны яшен сугып әрәм итә. Болай да яртылаш кына исән Мирзаҗанга язмыш авыр сынаулар өстәп тора.

Җитмәсә Шәмкәйләр белән Сәлимгәрәйләр ыруы арасындагы гомерлек дошманлыкка Рәшит килеп кысылды. Онытa алмый егет Айсылуын. Шул ике арадагы киеренкелеккә ут өстәп тора. Югыйсә юньләп күрешә дә, очраша да алмыйлар бит инде.

Гомер агышының алдагы көннәренә карап, Рәшит 1956 елны Бөгелмәгә шофёрлар курсына килде. Инде байтак укылып, эшләр таныклык алуга бара дигәндә генә, язмыш аңа тагын рәхимсез гамәл кыла... Имтихан тотканда, ул кинәт егыла.

## Җәләл хәлләре

*Әллә ничек булыр төсле минем язмыш.*
*Гел өстәлеп кенә тора сагыш-ялгыш.*
*Бер гөнаһым юктыр төсле гамәлемдә,*
*Булса әгәр, кичерегез шул хәлемдә.*

Тормыш син уйлаганча гына бармый шул.

«Биш татар» төркеменең гөрләп эшләгән чагы. Җәләл бик авыр хәлдә дигән хәбәр күпләрнең йөрәген какшатты. Спектакльдә уйнаганда билен авырттырган икән дә, больницага алып киткәннәр. Хәле көннән-көн начарая бара дигән җан өшеткеч сүзләр Хәмзә белән Рәшиткә дә килеп ирешә. Ике уйлап тормыйча, авыру янына киттеләр. Моңа хәтле аны төрле больницаларга күчереп йөрткәннәр, чөнки төгәен генә диагноз куя алмаганнар. Консилиумнар җыйганнар. Шәһәрнең иң көчле табиблары ни әйтергә белми торганда, бер больницаның Камил Зыятдинов дигән баш табибы, анализларын тикшергәннән соң, бу — минем пациент, мин аны дәвалый алачакмын, дип үз больницасына алып киткән.

Рәшит белән Хәмзә шунда килделәр.

Җәләл үзенең дусларын шат йөз белән каршы алды:

— Менә шушында килгәч, хәлем бераз җиңеләйде, исән калырга өметем барлыкка килде. Җә, шеф, безнең эшләр ничек бара анда? — дигән булып, Хәмзәнең кулбашын кагып куйды.

— Хәлим Бәдриевич, без Рәшит белән бик пошынып килгән идек, күз тимәсен үзенә, таяк белән булса да йөрисең икән ич, — дип, Хәмзә сөенүен яшермәде. — Югыйсә эштәгеләр хәлеңне нык яман тасвирлаганнар иде.

—Җәләл бит ул! Үтерерсең Җәләлне! — диде Рәшит. — «Әҗәл» күренмәдеме? Ник аптырап карап торасыз миңа?.. Шәрәфине әйтәм, бакчасында ятадыр, чәчәк үстереп.

— Ул килеп китте инде әхвәлемне белеп. Кеше җанлы бит ул Шәрәфи. Больницадан курыкса да, янымда булды, рәхмәт төшкере. Сабир да килде, бер капчык алма, апельсин китергән күчтәнәчкә. Алып китегез әле күп итеп.

— Менә без дә шундыйрак әйберләр алдык. Хәмзә, кәнишне, тырышты, — дип, Рәшит пакеттагы алмаларны, җимешләрне караватка аударды.

— Егетләр, мин моны ничек ашап бетерим?

— Борчылма, шәфкатьле туташларга өләшерсен.

Шулчак палата ишегеннән, башларын тыгып, әле бер, әле икенче медсестра Рәшит белән Хәмзәне күзләп алды.

— Керегез, кер, кызлар, менә минем дусларым килгән, — дип, Җәләл аларны чакыра ук башлады.

Озак та үтмәде, бөтен больницага «Биш татар» төркеме Хәлим Җәләл янына килгән дигән хәбәр таралды. Инде китәрбез дип коридорга чыккан Хәмзә белән Рәшиттән туташлар белән бергә авырулар да автограф алырга керештеләр. Бу хәлгә борчылып, табибәләр Рәшит белән Хәмзәне үзләренең бүлмәсенә төртеп керттеләр. Анда матур гына чәй табыны әзерләнгән икән. Рәшит керү белән медицина темасына бер-ике мәзәк сөйләп көлдерде дә, рольне Хәмзәгә тапшырып, коридорга чыкты.

Больница шыксыз, идән такталары черегән, түшәмнәрдән штукатурка коела, стена буяулары купкан, күңелдә шом уяна. Рәшиткә бу больница ерак еллар авазын хәтерләтә. Әйе, ул яткан психбольницадан артык түгел бу. Егерме беренче гасырның менә дигән врачлары эшли торган бинага йөз еллап ремонт кермәгәндер.

Иллә бардак: Африкадан миллионлаган долларга туп тибүчеләр сатып алабыз; Европа белән Америкадан — алка шудыручылар. Ә үзебездә халык ыңгырашып ята. Ярый әле ярага дару тамызучыларыбыз бар.

Рәшит үзенең Куйбышев өлкәсенең Томашев дигән җирендәге акылга зәгыйфь кешеләр больницасына килүен искә төшерде. Андагы мәхшәр! Беренче көнне үк аның янына өч яшүсмер килде дә: «Кругосветное путешествие оештырабыз, безгә моряклар кирәк, бармассыңмы безнең белән, как раз син подходишь», — диделәр.

Һәркөнне иртән тегеләр белән күрешәләр. Сәяхәт турында сөйләшәләр. Алар утрауларны, дингезләрне, океаннарны күп беләләр икән. Сәяхәтләре шул психбольницаның ишегалдында иде. Аннан кая да булса чыгып качу мөмкин түгел. Стеналар биек. Көннәр буе гел ишегалдында йөриләр. Кайчагында врачлар да боларга кушылып киткәли.

Психбольницаның рәшәткәле тәрәзәсеннән самолётлар очканы да күренә. Алар бик күп, гүләүләре бер аска төшеп, бер өскә күтәрелеп күңелдә шом уята. Тагын сугыш башлангандыр төсле тоела. Янәшәдә аэродром булган икән.

Бу йортта байтак дәваланып яткач, беркөнне аңа: «Шамкаев, отец-мать приехали, хотят тебя забрать!» — дип кычкырдылар.

Дүртенче май көне иде ул. Чыннан да терелдем микәнни, дип уйлаган иде ул шул вакытта. Кайтканда әнисен яңадан тетрәндереп алганы хәтерендә.

— Әни, — диде ул, — авыл өстендә самолётлар ду кубып очамы?

Әнисе елап җибәргән иде шулчакны.

— Әй, улым, терелмәгәнсең икән бит, терелмәгәнсең...

Үкседе дә үкседе әнисе.

Врачлар Рәшиткә нишләргә ярый, нишләргә ярамый икәнен болай аңлатканнар: «Тәмәке тартырга ярый, ләкин аракы эчәргә ярамый, ә менә жениться надо!»

Шушы авыруы аның тагын берничә мәртәбә кабатланды. Ул чорларда грипп бик көчле таралган иде, өйдәгеләр, кеше алдында авыруын шуна сылтаган булдылар.

...Медперсонал бүлмәсеннән Җәләл белән Хәмзәнең чыгып килүен күргәч кенә ул әлеге уйларыннан арынды. Аларны янадан сырып алдылар. Рәхмәт сүзләренең чиге юк иде. Кулын кысып озатып калган табиблар арасында Җәләлне үлемнән йолып алган баш врач Камил Мөхәммәтович та күренде.

Хәлимнең күзендә шатлык яшьләре ялтырый иде.

## Яшәсен дуслар

*Без бүген сау, без — сәламәт —*
*Уйныйк, көлик, җырлыйк, биик.*
*Берәү дә мәңгегә килмәгән,*
*Исәннәрнең кадерен белик.*

Күрәсең, дуслык көче кешегә тизрәк терелергә, аяусыз үлем белән көрәшергә ярдәм итәдер. Җылы сүз, ихлас дуслык хисләре күздән шатлык тамыза ала икән. Шәрәфигә карасаң да, Сабирны мисалга алсаң да, алар белән бергә эшләвенә сөенәсең. Чөнки алар авыр минутларда һәрчак ярдәмгә килергә мөмкиннәр. Җәләл үзе дә шундый, Хәмзәне әйткән дә юк. Шәрәфи белән Сабир да мәрхәмәт ияләре: берсе әбисен гомеренең соңгы көннәренә хәтле кадер-хөрмәттә тота, икенчесе әнисен урын өстендә килеш авылдан Казанга алып килеп, сөеп кенә, назлап кына яшәтә. Дуслар яхшы, күз генә тимәсен үзләренә.

Тормышы юлында Рәшитнең дуслары күп булды. Ул Ярмәктәге кечкенәдән бергә уйнап үскән Равилне искә төшерде. Әйе, Ярмәктә Равилләр күп, әмма абыйсы Равил белән бу Равилдән якыны булмады. Барлык малайлар арасында иң акыллысы, иң зирәге, иң хәйләкәре дә ул иде. Менә шул Равил тавык йомыркасын бик оста урлый. Тавыкларның йомырка салганчы һәм салганнан соң ничек кытаклавын да аера белде ул. Тора-бара шулкадәр остарды ки, тавыкның йомырка салып бетерүен көтеп торырлык түземлеге калмагач, тотып алып, йомыркасын кысып чыгара башлады. Кибеткә алып бара да, йомырканы «Дукат» папиросына алыштыра, Рәшит тәмәке тартырга шул Равилдән өйрәнде инде.

Аннан соң Равил, өйләрендә тавык ашаган саен, урамга чыгып, ядәч аера иде. Әлбәттә, «ә» дигәнче ота да иде.

Бервакыт бәйләнде бит бу Рәшиткә: «Әйдә, аерабыз, бетте-китте». Ядәчне аердың исә, аның шарты буенча, отар өчен көндәшең кулына берәр нәрсә тоттырырга кирәк.

Рәшит белә үзенең отыласын, шулай да ике йомыркага килешеп, ядәчне аердылар. Ул елларда йомырка акча кебек кадерле, аның белән кинога да кертәләр иде. Әй, тырыша Равил Рәшитне отарга, әй тырыша. Ләкин җай чыкмый. Әллә зиһене әйбәтләнгән, әллә саранлыгы көчәйгән тегесенең.

Бәхәс беренче апрельдә тәгәлләнә. Равил бераз ялгышып куя: әбисе белән бабасын Сәләхетдин бабайларга мунчага җибәрә. Әби һәм бабай, ныклап әзерләнеп, җепшек карга бата-чума барсалар, мунча бөтенләй ягылмаган икән. Болар кайтып Равилнең әтисенә әйтәләр. Әтисе каеш-чыбыркы белән «пешерергә» улын эзләргә керешә. Шулчак Равил әтисеннән качып Рәшитләргә килеп керә. Әтинең ачуы сүрелгәнче генә сездә торыйм әле, ди. Рәшит этлеген җигеп, дустының хәленә кермичә, сәкедән Равилнең бүреген алып, кулына тоттыра да, кабаланып: «Әтиең керә», — ди. Равил шул минутта, суга чумган үрдәк баласы кебек, сәке астына кереп юкка чыга. Ә Рәшит, үз-үзен белештермичә, «Ядәч!» дип кычкыра. Борылып тәрәзәгә караса, ишегалдында чыннан да Равилнең әтисе басып тора икән. Кулында камчы. Ул заманнарда кәҗә бәтиләрен, сарык бәрәннәрен көннәр җылынганчы өйдә тоталар иде.

Рәшит йөгереп барып ишек келәсен элә дә кәҗә бәтиенең койрыгын бора. Ул, Рәшитне дә уздырып: «Ә-ә-дәч!» — дип кычкырып җибәрә. Равилнең әтисе Мисбах абзый, башын кашын тора да капкадан чыгып китә.

Менә шулай итеп ул дустын бәладән дә коткара һәм киного барырга акчалы да була.

## Дус бар, дошман бар

*Өзешәбез, сүзешәбез,*
*Этешәбез, төртешәбез,*
*Зур дөньяга сыймыйбыз,*
*Бер-беребезне сөймибез.*
*Юри генә «сыйлыйбыз»,*
*Бакчага «таш атабыз»,*
*Бер-беребезне сатабыз,*
*Патамушты — татар без!*

Галиәсгар Камал театрында өч артистның спектакльләрне ташлап «Биш татар» төркемендә акча эшләп йөрүе берәүгә дә ошамагандыр, билгеле. Ташлап, дип әйтү, әлбәттә, бик дөрес түгел, чөнки алар җитәкчелек белән дә, рольдәш дуслары-дублёрлары белән дә килешеп китәләр. Үзара аңлашу бар. Гаризалар язып калдыру, больничныйлар алу дисеңме. Алар өчен әллә ни кыен эш түгел, һәркайсының үз табибы бар, танылган, күренекле артистлар, чүтеки. Ләкин бу юлы нигәдер Шамкайга ныграк каныктылар: җыелыш җыеп, элегрәк булган «гөнаһларын» да исәпкә алып, катгый шелтә бирергә булдылар. Дошман күп, дуслар да бар, дигәндәй, Шамкай турында ни уйлаганнарын шушы җыелышта рәхәтләнеп чәчтеләр, күңелләрен бушаттылар. Һәрвакыттагыча Таҗи, Әзһәр, Шәүкәт абый аның яхшы якларына тукталып, алыштыргысыз артист икәнлегенә басым ясап: «Кемдә юк инде андый кимчелекләр, барыбызда да бар инде ул, актарып карасаң, Шамкайдагы кебек гөнаһлар: эчкәли-салгалыйбыз инде, чамасын оныткан чаклар да була кайчак», — дип, аңа карата басымны йомшарттылар. Тик шелтә белдерүгә каршы түгел иделәр.

Дусил, Рәсим күтәрелеп нәрсәдер әйтмәкчеләр иде дә: «Беләбез, яклаячаксыз, тик кенә утырыгыз, одна компания!» — дип, җитәкчеләр кул гына селтәделәр.

Аннан соң хатын-кызлар ду купты. Уйларында Шамкай, Шәрәфи, Җәләлнең концерт куеп йөрүләре түгел, театрдагы хезмәт хакына тормыш алып барып булмастай мөшкеллек иде. Чакырсыннар иде әле концертларга, без дә рәхәтләнеп катнашыр идек, чакыручылар гына юк, дип «өчлек»не яклап та куйдылар.

Хатын-кыз чыр-чуы астында Рәшит үзенең шушы мәшһүр театрга эләгү өчен күпме көч һәм ихтыяр куюы турында уйланып утырды. Җанын урталай кисеп, ут пычкысы яндырып алды. Аһ, гомер буе хыялланган максатына, өметенә — Камал театрына эләгүенә хыянәт итә түгелме соң ул?

Аның зиһене томаланды. Җыелыштагыларның әле берсе, әле икенчесе, утыра-калка нидер сөйләп, күкрәк кага-кага, кемгәдер төртә-күрсәтә, йодрык болгый-болгый дөреслек яулый. Баш режиссёрның аларга карап бармагын төртеп күрсәтүе, «бетте баш», дигәнне аңлата сыман иде.

Нинди карар чыгарырлар икән инде миңа, дип уйлады Рәшит. Никадәр көч куелган иде бит шушы театрга эләгү өчен, никадәр сәламәтлек беткән, гомер яндырылган, аһ, бу ялгышулар...

...Театр училищесына Рәшитне җиңел генә алмадылар. Әлеге дә баягы шул «актёрские данные» җитеп бетми, диләр. Юк анда буй, юк тавыш, юк тел — йөрәк зур да бит, ул — күренми. Хәер, күрә белгән кеше күрә икән. Атаклы режиссёр, педагог Празат Исәнбәт Рәшитнең башкаларга күренми торган актёрлык осталыгын

һәм сәхнәдәге киләчәген аермачык сизә. Ул аны үз канаты астына ала. Имтиханнар алып, нәтиҗә ясап, Шириаздан Сарымсаков, аннан актёр чыкмый, дигәч, Празат Исәнбәт: «Сез укытмыйсыз аны, мин укытам», — дип, Рәшитне студентлар исемлегендә калдыра. Ул аларны бер генә ел укытса да, Рәшит аны актёр һөнәренең әлифбасын беренче өйрәтүчесе, зур, акыллы режиссёры дип хөрмәтли.

...Менә шундый авырлыклар белән бөек театр дөньясына килгән елларын искә төшереп утырды ул. Ә бүген инде рөхсәтсез концертлар биреп йөрү көн тәртибенә куелган. Кемнәр дошман? Юк, юк, аның театрда дошманнары юк. Ул үз-үзенә дошман. Бу халәттән җайлы гына котылса, акылга килергә вакыт.

Ана каты кисәтү ясап, театр коллективы таралышты.

## Уку — кое казу

*Казан, Казан, синең хозурыңа килеп*
*югалттыммы, әллә таптыммы?..*
*Әллә адашып, үземне табалмый,*
*сазлыгыңа кереп баттыммы?*

Театр училищесында укулар башланды. Курста берничә шәһәр кызы һәм малае бар. Калганнары авылдан. Утызга якын кеше укый башлаган курс бер ел үтүгә, унбиш кешелегә кала. Кайберләрен әти-әниләре алып китә, кайсыларын өметсез дип, укытучылары чыгара, күбесе үзләре китә.

Училищедагы бер ел гел уку белән үтә. Укуның да бик тырышып, бик теләп йөрелгәне. Авырның да авыры икән ул беренче курс. Тулай торак юк. Фатирдан фатирга күчеп йөрүләр. Йә аларны ошатмыйлар, йә анда торырлык түгел, йә салкын, йә түләү хакы күтәрә алмаслык кыйбат. Интегүле тормыш. Шулай да бу сынау да үтелә. Ниһаять, икенче елны аларга тулай тораклан бүлмә бирделәр. Ул шатлануларының чиге юк иде. Хәлил Мәхмүтов, Роберт Әбелмәмбетов, Юныс Сафиуллин, Нуриәхмәт Сафин, Шәһисолтан Әхмәтшәрипов белән бергә тору, бергә укулар! Курсташлары арасында Дания Нуруллина белән Эльмира Хамматова да бар. Беренче курста Самара мишәре Рәшитнең төп максаты телне чарлау булды.

Икенче курста алар инде түш киереп йөрде. Кесәләрендә акча да бар: чөнки тимер юл кергән заводларга вагон бушатырга җай табылып тора. Дәресләрнең бетүе була, чаж шунда барысы да. Кызларны туңдырма белән сыйларга да, киногa чакырырга да акчалары җитә. Өченче курста аларны Камал театрының массовкаларына чакыра башладылар. Бу инде студентларга практика өчен бик кирәкле сәгатьләр.

Уку дәверендә кызыклы вакыйгалар да, күңелгә шөбһә салган минутлар да булмый калмагандыр, әлбәттә. Шуларның берсен Рәшит үзе сөйләгән иде.

— Без яшь чакларда, теләсәң дә, теләмәсәң дә, комсомолга алу бар иде. Мин дә, шул 16-17 яшьләр тирәсендәме икән, комсомол булдым. Кем алган, ничек алганнары төгәл истә калмаган. Истә калганы шул: минем комсомол билетына ябыштырырга күлмәк киеп төшкән фотом юк. Майкачан төшкән фотоны ябыштырдылар да куйдылар. Шул документ белән шактый йөрдем әле мин: Куйбышев өлкәсендә училище тәмамладым, Бөгелмәдә шофёрлар курсында укыдым. Инде Казанда театр училищесында укый башладым. Училищенең комсомол вожагы Наил Әюпов иде. Бервакыт комсомол билетларын җыеп алды бу. Тукта, Казан комсомолына мондый фото ярамас дип, майкадан гына төшкән фотога кара тушь белән пиджак һәм галстук ясап куйдым. Күпмедер вакыт үткәч, Әюпов мине эзләп тапты. Әйдәле, сине райком комсомолга дәшәләр, ди. Мин инде үземчә йә берәр партийный эш тапшыралардыр, йә нинди дә булса комсомол порученисседер дип уйлап барам. Наилдән сорыйм, нигә дәштеләр икән, дим. Төгәл генә әйтә алмыйм, ниндидер «за подделку документа» диебрәк сөйләшсәләр кирәк, ди бу. Беттем, коелдым да

төштем. Акча ясаган өчен йә аталар, йә гомерлеккә төрмәгә утырталар, дигәнне ишеткәнем бар иде, ә бу ялган акча ясаудан кай ягы белән ким?!.

— Борчылма ул кадәр, бәлки, гафу итәрләр. Анда мин үз сүземне әйтермен, — дип, Әюпов тынычландырмак була. Ә йөзендә... Әллә елый, әллә көлә инде, анламассың. Бу да, мәйтәм, Шамкайны кызганып еламсырап бара... Хушыгыз, кызлар... сөюләр, мәхәббәтләр!.. Әллә нәрсә булмаса да, училищеда калдырмаслар, куарлар инде дигән кара кайгы белән Бауман районының комсомол комитетына килеп кердем. Кергәч тә Әюпов озын өстәл артында утырган унлап кешегә: «Менә шушы ул», — дип, мина төртеп күрсәтте. Тотындылар миннән көләргә! Бик озак көлделәр, күзләре яшьләнеп бетте, сүзләрен әйтә алмыйлар!

Ә хәл болай була: учёт карточкасындагы фото әлеге дә баягы майка белән бит, ә билеттагысы — костюм-галстуктан. Яхшылап карасаң, ясалганы беленә бит инде аның. Әюповка, алып кил әле үзен, нинди кеше икән ул, дип рәхәтләнеп бер көләргә дәшкәннәр икән мине.

Көтелгән бәланең шушылай җайлы тәмамлануы яшәүгә ямь өстәгән кебек булды. Матур икән бит дөнья!

* * *

Ә кызлар, ә кызлар шундый чибәрләр! Бигрәк тә спектакльдә катнашучы, рольләр башкаручылары күңелне кытыклый. Милли киемнәр киеп җибәрсәләр дә, хет чабаталы, бәбитәкле күлмәктән, озын ыштанлы булсалар да, барыбер шулкадәр матурлар, сөйкемлеләр! Ә Айсылу төслесе күренми. Әллә андый кызлар бөтенләй юкмы? Рәшит аны эзли, көтә, һаман аның белән саташа.

Болай йөреп кенә торырга бар инде ул кызлар, юк түгел. Менә, Роза дигәне искиткеч! Йөзенә карасаң, күз чагыла. Үзе яшь, үзе чибәр, үзе чая! Тагын кем кирәк? Айсылу белән эшләре барып чыкмаса, шуңа өйләнер әле.

Тулай торакта шундый уйларга уралып, киенеп, хушбуйлар сибенеп, Роза белән очрашуга әзерләнә ул. Күңелендә әле генә язган шигыре:

Күңел түрендә бер изге урын,
Анда беркем үтеп кермәгән.
Анда чиста, аяк эзе дә юк —
Беркем тәртип бозып йөрмәгән.

Йөрәк түрендә бер бушлык ята,
Язылмаган анда хәреф тә.
Кайда адашып очып йөри икән
Шунда оялыйсы фәрештә?

Сизмәгәндә Роберт кайтып керә.

— Шигырең матур, кемгә багышланганын да беләм, тик Розаң, сине көтмичә, бер егет белән Горький паркына китеп барды, кисәтеп куюым, — диде. Бу көтелмәгән сүзләрдән соң Рәшит каушап калды. Йөзендә гарьләнү, ачу барлыкка килде. Дусты Роберт аны тынычландырырга керешә.

— Юкка хафаланма, артыннан да йөрмә, сәлам дә бирмә! Сиңа дигәне көтеп тора торгандыр әле, шуны бел, ахир! — диде.

Атналар буе котырынып йөрде дә Рәшит, ниһаять, тынычланды.

Тулай торакта дуслар күп була бит. Шулар арасында Асия исемле бик акыллысы да бар иде. Шул беркөнне көтмәгәндә:

— Рәшит, бәргәләнеп йөрмә, бер кыз белән таныштырам. Бик тәртипле, — димәсенме?

— Таныштыр! — диде Рәшит. — Болай ялгыз янып-көеп йөргәнче, бәлки, күңелгә җан тынычлыгы бирер ул сердәшең.

Очрашалар. Каршына нәкъ Айсылуга охшаган, аерып булмаслык кыяфәттәге — йөрешләренә хәтле тәңгәл килгән кыз атлый. Рәшит, күзен йомып-ачып: «Айсылу!» — дип эндәшердәй була. Әллә шулмы соң бу, дип икеләнә.

Төш тә түгел бит. Аптырап битен чәбәкли. Тора бит каршында, әйе, тора. Таныштырырга килгән Асия:

— Нигә үзеңне кыйныйсың, — ди.

— Юк, — ди Рәшит, — кыйнамыйм, черкиләрне генә куам. — Менә шулай, гомере буе хыялланган, сөйгән, яраткан, аның өчен үләргә әзер булган кызның нәкъ үзе төсле икенчесе каршында тора лабаса!.. Бер күрешүдә алар бер-берсен ошаттылар. Исеме Суфия икән.

## Минзәлә борылышлары

*Алны, артны, уңны, сулны күрми,*
*Эт кугандай чаптым да чаптым.*
*Инде күптән тиеш нәрсәләрне*
*Кырык яшемдә генә таптым.*

Училищедан аларны төрле театрларга тараттылар. Рәшит Минзәлә театрына эләкте. Монысының да хикмәте бар бит әле аның... Кайчандыр ул моннан елый-елый кайтып киткән театрга хәзер дипломлы актёр булып килеп төште.

Әйе, ул вакытларда кая барасың килә дип сорап тору юк, тоталар да үзләре теләгәнчә җибәрәләр. Нуриәхмәт Сафин бик житди кыяфәттә билгеләү комиссиясенә кистереп әйтә: «Теләсә кая җибәрегез, Минзәләгә генә булмасын». Күрәсең, аныңча әлеге театр юньлеләр рәтендә йөрмәгәндер. Рәшит бөтенләй киресенчә уйлый иде. Чөнки ул — шушы театрга элегергә хыялланып йөргән кеше. Ул андагы фидакарь артистларны белә, гәрчә шул фидакарьләрнең кайберләре аны, типкәләп дигәндәй, көчек сыман, куалап чыгарсалар да.

Менә хәзер ул, байтак еллардан соң, Минзәлә театрында матур гына эшли башлады. Тору — матур гына әбидә. Берүзенә аерым бүлмә. Янәшәсендәге бүлмәдә Венера Туктарова исемле артистка яши.

Минзәлә шыксыз, юллары юк, урамнардан йөрерлек түгел, авыш-тәвеш, үзәк урамнарында гына асфальт дигән нәрсә бар сыман. Шуңа җәйләрен сумала сылап интегәләр иде. Мич ягу, утын әзерләү — зур мәшәкать. Театр бинасы кирпечтән салынган элеккеге бай йорты булгандыр инде. 250ләп тамашачы сыярлык залы бар. Анда күбесенчә репетицияләр генә үткәрелә. Калган гомер — тәгәрмәч өстендә, авылларга чыгып йөрү инде.

Рәшит Суфиясен чакыртып ала. Нечкә билләре юанайган, кечкенәләрен көтәләр.

Артист тормышы гел бәйрәмнәрдән генә торырга тиеш ләбаса, ә аның язмышы фаҗигаләр белән үрелеп бара. 1968 елның сентябрь аенда авылыннан телеграмма килеп төшә. Әтисе, әнисе, Искәндәр абыйсының кызы авариягә эләккәннәр. Ул ашыгыч рәвештә Камышлы больницасына юл тота. Әнисенең бер аягы дүрт җирдән сынган, әтисенең умыртка сөяге чатнаган, сеңлесенең аягы сынган. Авария көчле булган, шулай да барысы да исән. Әнисе самолёт белән Куйбышевка озатыла, әтисе һәм сеңлесе Камышлыда калалар. Рәшит театрдан китәргә гариза яза. Сәбәбе бер — әти-әнисен карарга кайту. Җибәрмәскә бик тырышалар үзе. Ләкин өй тутырып авырулар булганда, театрда кеше көлдереп йөрү килешмәс шул. Минзәлә белән аралар өзелә.

Рәшитнең Ярмәккә кайтмаганына алты ел узган икән. Дүрт елын училищеда укыды, ике ел чамасы Минзәлә театрында эшләде. Ул күргән-белгән авыл кешеләре картаебрак киткәннәр, урамнар да бераз ятсынылган, су буендагы өянкеләр дә тупасланып калган. Ботакларында каргалар каркылдап, шом таратып утыра.

Шулай да якын аңа туган авылы. Каеннары ул үскәндәге кебек һаман сөйкемле, миләшләре күзне камаштыра, зирек алкалары әле кияүгә чыгасы

кызлар өчен бизәк булырдай нәфис. Берзаман чишмәгә суга төшкән Айсылуга ул зирек алкаларын кигезеп тә караган иде әле. Күңеленнән генә булса да, аны үзенеке иткәч, кибеттән алтынны алып бирергә вәгъдәләшкән иде. Насыйп булмады шул.

Рәшит, әнисенең ахирәте Бибинур ападан сыер саудырып, кичке салкынча һавада чирәм ашатырга малкайны тыкрыкка алып чыкты... Әнә Айсылу белән сирәк булса да күрешкәләп торган читән борылышы. Тегендәрәк — Гамилнең сыртына тондырган казык урыны. Урталай сынган иде, яңасы бүтәннәренә караганда ныграк. Әтисе алыштыргандыр инде, ни дисәң дә, Рәшит каерып алган казык ич ул.

Авылда кичке тынлык. Ара-тирә этләр өреп куя. Тыкрыкта черкиләрдән башка җан иясе юк. Малкай койрыгын болгый-суккалый чирәм умыра. Кара инде, көне буе көтүдә йөреп, ач кайткан диярсең. Сыер сыер шул инде ул, башта бүксәсенә тутыра, аннан абзарында ятып, рәхәтләнеп кикерә-кикерә күши.

Шулчак тыкрык башында салмак кына атлап килүче хатын-кыз шәйләнде. Рәшит аның кыенсынып атлавына игътибар итте. Апа кеше килеп җитәр-җитмәс туктады. Кем икәнлеген таныр-танымас килеш Рәшит аваз салды: «Хәлимә апа, синме?»

— Әйе, Рәшит, бу Хәлимә апаң иде әле. Ни хәлләрегез бар? Әниеңнең хәле ничек? Төзәләме инде?

Хәлимә элеккеге матурлыгын җуйган. Бу гүзәл апаның газаплы еллар агымына бирешүен күрү кыен иде аңа.

— Рәхмәт, Хәлимә апа, әни әкеренләп терелә инде. Аягы әле гипста.

— Терелер, Алла боерса, Бәдрикамал андый гына авыртуларны кичергән хатын. Җан газапларына ничек чыдарга менә? Ходай Тәгалә шунысын язмасын!

— Гамил кайларда гомер кичерә соң, Хәлимә апа?

— Сорама, Рәшит! Син менә укып зур кеше булып киләсең. Артист! Ә ул?..

— Нәрсә булды, Хәлимә апа, нигә елыйсың?

— Армиягә киткән җиреннән кайтып та күренгәне юк, әллә исән, әллә?..

— Кайда икәнлеге дә билгесезме?

— Кайдадыр Себердә...

— Эзләтергә кирәк.

— Әйтергә дә куркам. Җүнле җирдә түгел бугай ул.

— Сәлимгәрәй абый нәрсә карый? Мондый вакытта эндәшми яталармы?

— Паралич сукты аны — телсез калды.

— Кайгыгыз зур икән шул, Хәлимә апа.

— Әй, Рәшит җаным, ул гынамы кайгым. Гомер буе эчемдә саклый торган газаплы серләрем бар шул минем. Әйтә генә алмыйм, телем бармый. Хәер, хәзер инде аны әйтүнең әһәмияте дә юктыр.

— Айсылуның хәлләре ничек соң?

— Торалар әле.

— Нигә, кияүдәмени ул?

— Сиңа бирмәячәкне белгәч, үч итеп, урыска кияүгә чыкты. Ире әйбәт кеше болай, ләкин яратып чыкмады. Баласы да туды.

— Кем исемле?

— Роман. Айсылу аны Рәшит дип йөри. Кызымның бәхетен кистеләр — икесе. Син дә китеп югалдың.

— Нишлим соң, Хәлимә апа? Күрәләтә торып аны бәхетсез итәсем килмәде. Беләсең бит, мине юләргә чутлап йөрделәр. Гамил дә, Сәлимгәрәй абый да. Минем күңелемдә Айсылу һаман бар. Тик миндә хәзер — Суфия исемлесе — минем кадерле хатыным.

— Рәшит җаным, бәхетле булыгыз. Берүк Суфияңне ташлама! Бергә озын-

озак гомер кичерегез! Мин синнән бернәрсә дә өмет итәргә килмәдем. Минем сөйләшер, серләшер кешем юк бу турыда. Шуны аңла! Хәлимә апаң гаиләгезгә бары тик изге теләкләр генә тели. Аңла жанымның сагышлы ялгызлыгын! Син мина чит кеше түгел.

— Бирешмәгез, Хәлимә апа! Үзегезне саклагыз!

Хәлимә кара сагыш йомгагыдай төнге урамга кереп югалды. Рәшитнең дә күнеленә авыр хисләр эленеп калды. Житмәсә, ул нәрсәләрнедер әйтеп бетермәде, хәер, анысы мондый ишеткәннәрдән соң мөһим дә түгелдер инде. Вакыт бөтенесенә жавап та бирер, хөкем дә итәр. Көтик.

## Бөтенләйгә Казанга кайту

*Казан, Казан — син бит әүлияләр иле!*
*Хакыбыз бар синдә йөрергә.*
*Без жыелдык бүген салкын кирпечеңә*
*Жан жылысы килеп өрергә.*

Хыялларын канат итеп, төп максатына ирешү өчен, ул янадан Казанга юл ала. Әнисе аякка баскан, әтисе инде ишегалдында эшләштереп йөри, абыйларның үз тормышы. Рәшиткә нәрсә? Аны театр тормышына бәйләнеп киткән гомер юлы данлыклы Камал театрына алып килә.

Ул инде бу театрда студент вакытта ук монтировщик булып эшләп алган иде. Театр директоры Рәшидә Жиһаншина аңа: «Рәшит, бездә актёр штаты юк, аннары театрга урнашуны мин генә хәл итә алмыйм», — дигәч, ул: «Мин сезгә сәхнә эшчесе булып керәм, бераз бәләкәй-бәләкәй рольләр бирерсез», — ди. Мондый ниятен ул Празат Исәнбәткә дә әйтә. Празат ага житәкчелеккә кереп, аны шундый шарт белән эшкә алуларын сорый. Шулай итеп, Рәшит театрда сәхнә эшчесе булып эшли башлый. Аңа эпизодик рольләр дә бирәләр.

* * *

«И-и, татлы хыял! Кайчан гына гамәлгә ашырсың икән син?!» — дигән вакытлары Рәшитнең инде артта калды. Тик менә яшәү шартлары гына һаман жиңеләйми. Театр ипи-тозлык кына акча бирә бирүен. Ипи өстенә май да ягасы килә бит әле.

Ул «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсенең Горький исемендәге Мәдәният йорты директорына керә дә:

— Сезгә не пьющий, не курящий, не гулящий рәссам кирәкме? — ди.

— Бик кирәк тә, ләкин андый рәссам булмый бит ул.

— Менә алдыгызда басып торам ич, — дигәч, директор, бу бик күнелле кеше икән дип, шундук эшкә ала үзен.

Мәдәният йортының фойедагы тәрәзәсе урам ягында. Үткән-киткән кешеләрне көне буе күзәтеп утырсаң да, үзенә кирәкле образлар сурәтен табарга мөмкин. Аның киемен, килеш-килбәтен өйрәнәсең, инде чыгып сөйләшеп тә алсаң, холкын, тавышын, мимикасын ятлыйсың. Гомумән, тормыш, урам, жәмгыять тулаем театр ул...

Шуннан соң Рәшит роль алдымы, костюм цехыннан алама жыя башлый. Аңа бит этнең дә бульдогын, шүрәленең дә картын, кешенең дә алкашын уйнарга туры киләчәк. Мондый рольләрне ул үзе сорап алмый. Бирәләр. Өлешенә тигән көмешләрне алар...

Көчәнеп, ертылып уйнаган артист өчен актёр эше бик авыр. Ә инде эшен яратса, бирелеп уйнаса, ролен сагынып килсә... Актёр гүя гел күңел ача, ял итә, кыскасы, сәхнәдә дә, тормышта да рәхәтләнеп яши.

...Фатир юклыктан озак җәфа чигелә. Ирле-хатынлы икәүләшеп эшләсәләр дә, яшәрдәй бер почмак юнәтә алмыйлар. Суфия, склад мөдире булып эшләгәнгә, подвалда буяулар арасында утырырга мәҗбүр. Аны икенче балага узгач та декрет ялына чыгармыйлар. Начар исләр белән агуланып җәфаланулар тәэсир иткәндерме — Рөстәм исемле уллары тугач та озак яши алмый, үлеп китә.

Язмышының өметсез тапталып торуы, киләчәкнең мәгънәсез караңгы офыгы, җитмәсә, улларының үлү кайгысы аны тәмам эштән чыгара. Шулай бервакыт, кая сугылырга белмичә, Болак суына яшь коеп тора икән. Янына бер апа килеп: «Нәрсә булды, җаныкай?» — дип эндәшкәч, мөлдерәп тулган яшьле күзләрен ул аңа төби. Бер дә таныш булмаган әлеге ханым, аны кочагына кысып: «Ела, җаныкай, оялма син, ела!» — ди. Рәшит сабый бала кебек үкси. Башка кемнәр юатсын аны?.. Йа, Ходай Тәгалә! Нигә Син шулай интектерәсең бәндәңне?!.

Апа кеше шунда болай дип әйтеп куя:

— Күптән түгел генә минем дә ирем үлде. Яшәргә дәртем, көчем, өметем калмаган иде. Министр иде ул. Канатым сынды. Нишләмәк кирәк, беребез дә бу дөньяга мәңгегә килмәгән. Күрәм, син дә кадерле кешеңне югалткансың, ахрысы?

Рәшит аңа кайгысын сөйләп бирерлек көч тапты. Ике бәхетсез җан, берберсен байтак юатышып торганнан соң, икесе ике якка китеп барды. Кем булды икән ул апа? Кемлеген дә сорамады ичмасам... «Яшәргә кирәк, ничек булса да яшәргә!» — дигән юаныч белән аерылыштылар алар.

Тормыш дигәнең шундый бит ул: әллә нинди борылышлар, авырлыклар, газапларны җыйнап тора да, һич көтмәгәндә, кеше өстенә шуларны китерә дә өя... Теләсәң ничек түз! Әле дә ярый яраткан эше бар. Аның кыенлыклары кайчакта сизелми дә. Төне буе рольләр ятлавы, кешеләргә шатлык илтү өчен гастрольләрдә, авылдан-авылга йөрүләре дә әкренләп онытыла. Бары тик авырлыкларны оныттыра алырдай алкышлар гына, тамашачы мәхәббәте генә күңелдә кала.

## Театр бусагалары

*Күрәсеңме, якын дустым, ә,*
*Юл буенда ап-ак чәчәкләр!*
*Бу театр юлы дип уйлама,*
*Уйласаң әгәр, көләчәкләр!..*

Бермәлне Рәшитне театрда китапханә мөдире итеп куйдылар, кәҗәне кәбестә бакчасына сакчы итеп куйган кебек... Сыдыра гына бу китап укып, көнозын эштә баш калкытмый. Дөнья классикасын да, урысныкын да, татарныкы да актара, һәр мәгънәле җөмләгә, сүзләргә игътибар итә, кирәк дип тапканнарын күчереп ала: заманында «җүләр» дип йөрткәннәр иде, менә күрсәтә ул сезгә хәзер Шамкайның кем икәнлеген, тора-бара Ломоносов, диярсез!

Рәшит эшли башлагач, китапханәнең укучылары бермә-бер артты. Чөнки ул нинди дә булса китапны бик җентекләп укып чыга да, артистлар арасында буталып йөргәндә, берәр классикның әсәрен телгә алып, андагы искиткеч кызык күренешләрне сөйли башлый һәм соңыннан, моны укыганыгыз бармы, дип сорап куя. Әлбәттә, алар укымаган, кемнең нәрсә белән кызыксынганын белеп тора бит ул. Күбесенең балык тотудан ерак китә алганы юк. Их, наданнар! Учение — мучение гына түгел, ул — дәрәҗә!

Каракның бүреге яна дигәндәй, белем шүрлекләре түбән булган дуслары кереп, хәл-әхвәл сорашкан булып кыланалар. Берочтан, кергәч-кергәч, китап та сайлыйлар, шүрлекләрдә актарынгалыйлар.

«Достоевский», «Тургенев» дигән булалар. Француз, испан язучыларының

исемнәрен атап (каяндыр белешеп, билгеле), өйләренә алып китәләр. Бер уйласаң, театр тутырык әдәбият сөючеләр яши диярсең. Рәшитнең эше шаулыйгөрли. Гөрләвен гөрли, шулай да сизә: китаплар югала. Иң әйбәтләре, иң әһәмиятлеләре юкка чыга. Бу турыда байтак анлату эшләре алып барырга туры килә аңа. Житмәгән китаплар саны буенча ул бит хисап тотарга тиеш кайчан да булса. Күп кенә артистлар жай белән генә, гафу үтенгәләп, китапларны кайтаралар. Тик бер генә китап һаман табылмый — «Нюрнбергский процесс» дигәне. Китапханәне башка мөдиргә тапшырганда да ул күренми. Бәясен өчләтә түләп, китапханәчелектән азат ителгәч, Рәшит ныклап артистлык эшенә керешә.

Еллар үтә тора. Артистлар берсеннән-берсе матуррак иркен фатирларга күченә тора. Менә бүген берәүне яна фатирга күчерәләр, әйберләрен ташыйлар. Дусларның шатлыгын күчерешеп уртаклашу — театрда изге гадәт. Зур-зур жиһазлар, кием шкафлары, стенкалары, өстәлләре, савыт-сабалары, диван-караватлары, тартма-тартма, кап-кап китаплары!.. Каян шулхәтле байлык жыйган бу өлгер егет, кай арада?.. Артист акчасына гына бу кадәр мөлкәтне туплау мөмкин хәл түгел бит инде. Китапларын күр син! Галим диярсең. Күтәрер хәл юк. Картон капның дүрт почмагыннан дүртәүләп күтәргәннәр иде, тараллыкитте китаплар. Рәшитнең аяк очына берсе шап итеп килеп төшмәсенме? Карасалар, «Нюрнбергский процесс». Рәшит кулына алып, пичәтенә игътибар итә, театр китапханәсенеке түгел микән? Аһ, карак, аһ кабахәт! Шул, әйе, шул югалган китап!

Тавыш куптарма инде, диләр дуслары. Вакытында, шул урында кулыннан тотмагач шауләма, китап урлау — изге эш, диләр. Әйдә, аның бүген бәйрәме, синнән булсын яхшылык!

***

Рәшит әкренләп язмышына буйсынып, зарланмаска күнде. Нәрсәгә уфтанырга, әнә хәзер ике баласы — Гөлнарасы белән Айдары тупырдап үсеп килә. Сөекле хатыны — Суфиясе жан тынычлыгы өстәп тора. Борчылма, сабыр ит, Ходай Тәгалә безгә дигәнне язгандыр әле, дип юатып яши. Ул да тормышта рәхәт күргән кеше түгел. Әмма ләкин түзем, сабыр. Шундый хатының булу — тормышыңның ярты уңышыдыр, бөтенләй үк булмаса әле... Әнә, Рәшит беренче кавышкан көннәрен хәтерләп утыра.

...Казанның Некрасов урамы. Тинчурин театры артисты Хәлил Мәхмүтовның туган көн бәйрәме. Суфия белән ныклап танышулары шуннан башланды. Рәшитнең Суфия янына ике көннең берендә килүе гадәткә әйләнде. Ул һәрвакыт табада бәрәңге кыздыра. Аның тәмлелеге! 1965 елның 1 гыйнварында өйләнештеләр дә.

Суфия Арча районының Түбән Оры авылыннан. Һөнәре буенча кибетче. Бауман урамындагы яшелчә кибетендә эшли иде. Аннан соң аны Рәшит үз янына, театрның складына урнаштырды. Озакламый театр эшчеләренә һәм артистларына Идел ярыннан бакчага жир бүлеп бирделәр. Алган вакытта жире чирәм генә иде, эшкәртеп бакча ясадылар. Биш сутый. Үзенә күрә ике катлы өен дә житкерделәр. Тора торгач, мунчасын да эшләделәр. Тимер мичле, ягасың да керәсең, эче такта белән матур итеп тышланган. Күршедә генә Равил Шәрәфи бакчасы. Бүтән күршеләр дә бик әйбәтләр. Шулхәтле рәхәт — жәннәт инде менә, жәй буе кайтмый ятарлык.

Апрель аенда беренче теплоход кузгалу белән, Суфия шунда юнәлә. Иң элек өйне жыештырып чыга. Савыт-сабаларны юа, кояшлы көндә урын-жирне тышка чыгарып жилләтә. Аннан соң жирдә казына башлый. Ул чыннан да бакча эшен

бик ярата. Шуннан күңеленә сихәт, көч, тынычлык, рәхәтлек ала. Физик эш, чамалап кылансаң, бик файдалы ул. Кан басымнары әйбәтләнә, буыннар языла, баш авыртулары онытыла. Тизрәк яз житсен дип кенә тора Суфия.

«Аллага шөкер, хатыннан уңдым, кайтканын ашарына пешереп көтеп торам, — ди Рәшит, елмаеп. — Суфия минем турыда интервьюлар бирә. Әле соңгы вакытта килгәне, күренгәне дә юк, дигән. Хәзер артык тазарды, инде тауны да менә алмас, ди икән. Аны борчыйсым килми, концертлар куярга китеп, ничәмә мең чакрымнар үтеп кайта бит. Ул акчалата ярдәм итә, — ди икән. Менә нинди әйбәт минем хатын!» — дип, гел шулай сөйли Рәшит.

Бакчага соңгы баруында Рәшит бераз чүп үләннәре утап алган, сулар сипкән. Балалары: «Хәерлегә булсын әтинең бакчага килүе», — дигәннәр. Шул көнне давыл чыккан. Бөтен бакчачыларны куркытып китеп барган. Рәшит: «Ярый әле өй төбәсен кубарып ташламады, алайса, күршем Шәрәфи белән шаяру кайгысы бетә иде, — ди. — Шулай да давылның икенче көнендә: «Шыр жибәрмәдеңме?» — дип үчекләп йөрергә җай калды әле».

## «Биш татар» — Мәскәүдә

*Без әле дә һаман алгы сафта,*
*Омтылабыз куйган максатка.*
*Яшьләр кебек сөеп-сөеләбез,*
*Шактый гына яшьтә булсак та.*

Соңгы айларда «Биш татар» төркемен гастрольләргә чакырулар аеруча күп булды. Бармыйча да ярамый, ник дисәң, мәсәлән, Шәрәфине театраль дуслары, киләсен белеп, һәркайда алдан ук көтеп торалар, Шамкайның, Жәләлнең дә дуслары аз түгел. Ләкин шунысы кызык: моңа хәтле дә популяр булган бу артистлар, тел яшермичә, әйтәсен әйтә, ачыла башладылар. Баксаң, татар халкы Шәрәфи хәтле Шәрәфине дә бик белеп бетермәгән икән әле. Шәрәфи кайчак үзе үк әйтеп куя: «Мине Рәсәй күләмендә «Биш татар» белән концерт куеп йөрүләр популярлаштырды». Һәм ул шулай да. «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклендә Әжәл булып уйнау гына житми, эстрада киңрәк мәйдан били, ул ныграк таныта. Әнә Шамкай хәзер үзен Шәймиевтән кала бөтен дөньяда иң танылган татар дип исәпли. Әле ул хәзергә генә шулай, тора-бара, Минтимер агай президентлыктан китсә, Шамкай, һичшиксез, беренче кеше булып калачак. Моның өчен аның бөтен мөмкинлеге бар: дөньяда андый кыяфәтле бүтән адәм баласы юк, өстәвенә үткен сүзле, тапкыр, укымышлы һәм тормыш тәжрибәсен нык татыган, ягъни лаеш шулпасын күп чөмергән зат. Ул гел халык арасында, байтак кеше белән элемтәдә тора. Шул бер Клинтон белән генә очрашасы калган, вакыты юк, чөнки гастрольләре күп. Аның аша «Биш татар»га чакырулар килә. Менә әле тагын, болай да кайсысына барырга белмәгән, буталган чакта хәбәр алып килгән. Мәскәүдән яһүдләр хат язып салганнар.

*«Многоуважаемая группа мастеров юмора и сатиры «Биш татар!» К Вам обращается от имени миллионов татар города Москвы — художественный руководитель концертного зала гостиницы «Космос». Мы наслышаны о ваших успехах по всей России. Возможно ли будет поделиться достижениями в области юмора и радовать своих московских татар примерно через месяц, точнее в первых числах июля, на три концерта.*

*С уважением, Рублёв Николай Васильевич».*

Хат Шамкайга адресланган һәм элемтә өчен Мәскәүдәге телефон номеры күрсәтелгән.

Мәскәү хәтле Мәскәүдән чакыру хаты килгәч, барысы да уйга калды.

— Минемчә, — диде Хәмзә, — бармыйча калу һич ярамый. Бу безнең юморның Мәскәүне яулап алуы булачак.

— Анысы шулай да анын, тик без бит Раушаниям белән җәй буе бакчадан кайтмыйча ятарга сүз куешкан идек.

— Синең шул булыр инде, Шәрәфи, яһүдләр чакырып торганда, минемчә, кире уйларга кирәкми. Бу бит аларның татарга өметле карашын күрсәтә.

— Күрсәтә, күрсәтә... — дип үчекләп әйтеп куйды кирле-мырлы сүзен Шәрәфи. — Безнең концерттан файда күрерлек булмасалар, хат та язып маташмаслар иде әле.

— Беркем дә бушка эшләми инде анысы, — дип сүзгә кушылды Сабир. — Яһүд түгел, үзебезнекеләр дә шулай. Әле этлеген дә күрсәтми калганнары юк. Казанга китәсе поезд платформадан кузгалгач кына, бирәсе акчаларын тәрәзә аша төртәләр. «Уф, өлгермәбез дип курыккан идек», — дигән булалар. Әле бит: «Тагын килегез!» — дип тә өстиләр. Оятлары юк. Биргән акчаларын санап карасаң, поезд билетына житәрлек кенә була, ә бит заллары тутырык иде. Менә алар нинди_ләр, Хәлим Бәдриевич.

— Татар сәнгатен күтәрүчеләр без, — дип дөнья шаулаталар үзләре.

— Менә, егетләр, шуны белә торып барыйк әле без. Бу юлысы оештыручылары бүтән, — дип, сөйләшүгә мәгънәлерәк төс кертте Хәмзә. — Башта Николай Васильевич белән сөйләшик, телефоны бар ич.

— Әйе, — дип, аны Шамкай җөпләде. — Минемчә, барысы да яхшы булачак. Ник дигәндә, минем әле яһүдләрнең кеше алдаганын ишеткәнем юк.

— Нигә сез аның яһүд икәненә басым ясыйсыз соң? Кем белгән, кем күргән аның теге нәмәстәсен. Яһүд тә яһүд...

— Соң, Равил абый, фамилиясе «Рублёв» бит.

— «Таньков» булса, татар буладыр инде ул алай булгач. «Тәнкә» дигән мәгънә бар бу сүздә.

— Равил абый, тынычрак бул әле, җәй озын, өлгерерсең Раушанияң белән ял итәргә. Нинди бетмәгән мәхәббәт булды инде ул сезнең һаман?..

— Афәрин, Равил абый! Безгә дә хатыннарны яратырга вакыт! Шулаймы, Хәлим Бәдриевич? Синең дә Флёра ханымны калдырып өч көнгә чыгып китәсең килмидер.

— Милләт дигәндә, Хәмзә туган, Флёра апаң мине утка кертергә дә әзер ул.

— Акча, бакча дигәндә, минем Суфия дә Флёрадан ким түгел.

— Ә минем Раушания сәламәтлегем өчен борчыла. Юл ерак, ди, авырырсың, йончыгырсың, ди, менә шундыйрак...

— Йә, ярар, килештек, барабыз. Димәк, Хәмзә, син сөйләшәсең Николай Васильевич белән.

— Ярар, мина ышанып тапшырасыз икән бу җаваплылыкны, иртәгә үк элемтәгә керермен мин аның белән. Таралышыйкмы?

— Әйе.

Кул бирешеп таралдылар. Хәмзә икенче көнне Рублёвны көне буе телефоннан тоталмый интекте. Житмәсә, «Биш татар»ы хәл белешкән булып көне буе тынгы бирмәде. Ниһаять, кичке алтыларда гына телефонның аргы башында тавыш барлыкка килде.

— Здравствуйте!

— Добрый вечер!

— Николай Васильевич?

— Да, а кто это?

— Это Вас из Казани Хамзин беспокоит — один из тех «Биш татар».

Рублёвның тавышы сизелерлек ягымлыланды.

— Ой, извините, я очень рад вашему звонку.

— Мы хотим обговорить некоторые условия наших концертов. Значит, три концерта.

— Да, я думаю все три дня зал будет заполнен. Мы вас устроим в хорошие номера гостиницы «Космос», где расположен и концертный зал на тысячу зрителей. Заранее с вами рассчитаемся в долларах, на обратный поезд купим билеты и проводим. Хорошо?

— Хорошо!

— По приезду составим договора.

— О-о! Даже так?

— А как же еще, мы люди ответственные.

Телефонны кую белән Хәмзә дусларына шалтыратырга кереште. Мәскәүгә юл тотуга тагын нәкъ егерме ике көн калган иде.

Җәйнен мәшәкатьләре күп бит анын. Тегендә-монда чаба-йөри торгач, ул көннәр үтеп тә китте. Менә хәзер инде алар күптән очрашмаган дуслар кебек гөрләшеп-шаулашып бер купеда баралар. Әй, Мәскәү, түзеп тор, синең әле мондый кызык концертны күргәнең дә, ишеткәнең дә булмагандыр. «Биш татар» сине яуларга бара! Бертөрлелеккә күнеккән, гел эштән өйгә, өйдән эшкә йөгереп гадәтләнгән татарына, матур сүз, җылы юмор, әче сатира ишетмәгән милләттәшләренә бүләк төяп «Татарстан» поезды Мәскәүгә чаба...

Концертны башлар вакыт та җитте. Моңа хәтле сер бирмәгән Николай Васильевичның йөзендә борчылу чалымнары сизелә. Ул егетләрне җыеп алды:

— Дорогие мои, татары! Я огорчён тем, что сегодня в зале сидят не больше ста зрителей. Но вы не вешайте нос, не огорчайтесь, выступайте так, как вы это умеете. Наши условия договора остаются в силе.

Николай Васильевич озак акланып тормады, үзе дә залга чыгып утырды. «Биш татар» егетләре бер-берсе белән кул «чәкешеп» алдылар да эшкә тотындылар.

«Биш татар»ның беркайчан да бу хәтле куәтле дәрт белән чыгыш ясаганы юк иде әле. Концерт ахырында бар булган тамашачы күтәрелеп озак кына алкышлап торды. Тамаша залында халыкның аз булуына кыенсыныптыр инде, хөрмәт күрсәтүләре артыгы белән кул чабу рәвешендә барды.

Икенче көннең концертына да артистлар Мәскәү тамашачысының ни өчен килмәвен якынча ачыклап куйган иде. Шәрәфи әйтмешли, Мәскәү татарлары театрны күбрәк ярата икән, Сабир уйлаганча, мондагы тамашачыга халык җырлары һәм биетә торганрак такмаклар ошый, нәфис сүзгә бик исләре китми, Җәләлгә — оештыру җиренә җитмичә башкарылган, Шамкайга — ул киләсен юньләп пропагандаламаганнар сыман, Хәмзә моның гаебен Мәскәүдәге концертларны оештыручыларның «этлегеннән» күрә, ягъни бу концертны аларга түгел, ә яһүдләргә тапшырганнар. Менә шуна күрә алар тамашачыларга яман хәбәр таратканнардыр, имеш, бу юмор концертының рәте юк — начар. Менә шул.

Икенче концертның оештырылуы «Биш татар» егетләренең фаразлаулары дөрес икәнлеген күрсәтте. Әлегесендә ике йөзләп тамашачы утырса да, мең кешелек залда аларның барлыгы беленми дә иде. Шулвакыт, бу хәлгә әче пошкангадырмы, Шамкай, залдагы бер тамашачыга мөрәҗәгать итеп:

— Менә сез, күренегез әле, качып утырмагыз, сезнең исем Хамис бугай, ялгышмасам, әйеме, — диде.

— Әйе, минем исемем Хамис.

— Менә сез, Хамис, Мәскәүдәге концертларны оештыручы данлыклы администратор. Сез үзегезне милләт яратучыларның берсе, дип күкрәк кагасыз, ә менә шундый вакытта, нишләптер, бөтен Мәскәү татарларына: «Аларның

концерты начар, бармагыз», — дип ялган хәбәр таратkансыз. Әйе, сез бер үзегез генә түгел, әле сезнең кебекләр берничә, әйтик, Нәгыймә шундый ук — синең кебек администратор, Дилә һәм шундыйрак тагын берничә дустың үз халкына — дошман. Мин ни өчен күзенә карап әйтәм, Мәскәү татарлары арасында борын-борын заманнан килә бу яман гадәт — үзара ызгышу. Безне чакырып, менә шундый күңелле кичә оештыру үзегезнең кулдан, көчегездән килмәгәч, башкаларга аяк чаласыз. Бүгенге концертны сез оештырмадыгыз, аны яһүд егете — Николай Васильевич Рублёв үз кесәсеннән эшләде. Рәхмәт ана, зур рәхмәт. Менә бүген килгән тамашачылар исеменнән рәхмәт.

Залдагы тамашачылар гөрләтеп кул чабарга тотынды. «Рублёвны сәхнәгә, Рублёвны сәхнәгә!» — дигән ялкынлы тавышлар астында Николай Васильевич сәхнәгә күтәрелде. Ул, башын ия-ия, һаман бер сүзен кабатлады: «Рахмат, рахмат!..» Каян өйрәнгәндер?..

Өченче концертны куймау турында Николай Васильевичка шул ук кичне әйтергә булдылар. Николай Васильевич, шундый шундый хәл, Сезнең бу уңышсызлыкта бернинди дә гаебегез юк, безгә субъектив каршылыклар тудырган кешеләр залда утыра иде, диделәр. Өченче концертны куеп, Рублёв өстенә күрәләтә зыян салу рәхимсезек булыр иде. Бу тәкъдим Николай Васильевичның үзенә дә ошады. Ул, шуңа җавап итеп, ике көнлек концерт акчасын, алдан килешү буенча, долларлар белән бәхилләтте. Күренеп тора: үз акчасын да өстәп бирә. Шуны сизеп, егетләр, ошбу залны арендалау чыгымнарын исәпкә алып, бер өлешен кире кайтарып, кесәсенә тыктылар. Ул шунда, күңеле тулып: «От всего еврейского народа замечательным джигитам Татарстана огромное спасибо!» — диде. Күзеннән яшь тамчылары типте.

Икенче көнне дуслары белән зур автобуска «Биш татар»ны һәм утызлап яһүдне төяп, Урта дингез хәтле табын оештырып, җырлап-биеп, поездга утыртып Казанга озаттылар.

— Менә бит ул ничек?! Үз татарын өч тәнкәсен төртеп, поезд кузгалгач кына мыскыллап озата, ә болар — бәйрәм ясый.

— Син, Шамкай, теге юантык яһүд хатынын кочаклап биеп алдың әллә инде...

— Үзе бит, мин түгел.

— Һәрвакыт, һәркайда Кеше булып калырга кирәк! — дигән Хәлим Бәдриевичның сүзләре поезд сызгыруына кушылып, мәгънәлерәк яңгырады.

— Николай Васильевич, в Казань приезжайте! — дип, Шәрәфи кул изи, Сабир телефон номерларын яза иде.

## «Притон» планетасында

*Максатларга барып ирешербез,*
*Тиеш җиргә барып җитәрбез.*
*Хыялларны канат итеп, тагын*
*Бөркет булып очып китәрбез.*

Рәшит өчен шушы «Кишер басуы» бу кадәр тынгысызлыклар, борчылулар китерер дип һич уйланылмаган иде. Бер карасаң, ни-нәрсә бар инде кеше аягы басмаган планетадан ниндидер ике гуманоидның җиргә килеп төшүендә? Әле бит андагы кешеләрнең нинди төстә икәнлеге дә, килеш-рәвешләре дә күзалланырлык түгел. Ничек сөйләшәләр, фикер йөртү куәсе ни формада, гомумән, алар өйрәнелмәгән һәм монарчы күрешелмәгән. Җирдә уйлап чыгарган җен-пәриләр кебек. Йә, кайсыгызның күргәне бар шайтанны? Юк бит.

Рәшит бу спектакльдәге чит планета кешесен гәүдәләндерү өчен күпме

көч түкте. Фантастик кинолар карады, китаплардан сурәтләүләр эзләде. Ә менә ничек уйнарга?.. Әйтүче, өйрәтүче кайда? Менә шундый кеше күрмәгән уйдырма шәхес тудыру җинелләрдән түгел. Ул уйнаган чит планета кешесе көчле тәнкыйть утына тотылды. Ләкин тәнкыйтьчеләр тарафыннан бернинди дә исәпкә алырлык файдалы киңәшләр әйтелмәде.

«Кишер басуы» һәр уйналган саен халык тарафыннан көчле алкышларга күмелә иде. Нигә аны тәнкыйтьлиләр соң? Башы чатнар дәрәҗәгә җитеп эшли. Өйгә дә ашыгып кайтасы килми. Тәнкыйть түгелдер бу — хөсетлек, көнчелектер...

Ул театр алдындагы фонтаннар янында эскәмиягә утырды. Казан үз шавы белән яши бирә. Кабан өстендә күктәге айның шәүләсе бии. Нигәдер якынтирәдә кешеләр дә күренми. Бүген монда аулак.

Кинәт аның баш очында алагаем якты шар пәйда булды. Нәрсә бу? Әлеге шаккаткыч шар тавышсыз-нисез театр бинасы каршындагы баскычлар өстенә җайлап кына килеп утырды. Спектакльдә алар уйнаган тәлинкә сыман икән бит. Әллә шулмы? Әнә, Дусил кебек берәү чыгып килә. Юк, ул түгел икән, охшаган гына. Үзе белән бергә инопланетянин булып уйнаган Дусил инде өенә күптән кайтып китте ич.

Бу бит, бу бит — чын тәлинкә! Әнә, аны чакыралар, баскыч чыгарып салдылар. Рәшит үзе теләмәсә дә, ирексездән тәлинкәдән төшкән баскычка атлады. Әллә нинди сихри сигналлар аны шунда тарта иде. Ул ниндидер түгәрәк дөнья эченә кереп китте. Монда бөтен нәрсә бөтерелә, әйләнә, зур тизлек белән еракка ыргыла башлады. Рәшит үзенең югалганлыгын сизде. Бернинди авырту юк, бары тик рәхәт кенә, ул оча, тирбәлә.

Беркавымнан соң Рәшит күзен ачты. Ниндидер кеше сыман адәми затлар кин мәйдан тутырып аңа карап торалар иде. Спектакльдән соңгы башы чатнап авыртуының эзе дә юк, ул үзен яңа туган бала сыман тоеп, алдына җыелган халыкка күз ташлады. Гаҗәп, төш микән инде бу? Алай дисәң, үзеңне үзең чеметеп булмас иде.

Инде берсе сүз дә башлады. Татар икән:

— Без сине ни өчен монда алып килдек? Сез анда, «Кишер басуы» дигән спектакльдә, безне мыскыл итеп театр уйныйсыз. Беренчедән, безнең «Притон» халкы, сез уйлаганча, бик үк надан түгел. Әйе, «Җирдәге» кайбер хәлләр безгә аңлашылып бетми, сездәге вазгыятьнең торышы һәм агышы тормыш кануннарына сыймый. Сез ниндидер тилерткеч эчемлекләр эчеп, юләрләнеп йөрисез. Безне, чит планетадан килгәннәрне, үзегезчә уйнап кыланасыз. Менә, карагыз, без бит бөтенләй ямьсез түгел, милләтебез буенча сезнең кебек үк татарлар. Телебез — бер үк, ашсуларыбыз да милли: чәкчәк, бәлеш, пәрәмәч — безнең яраткан ризыкларыбыз. Киемнәребез — шул ук. Җырларыбыз уртак. Аерма шунда: без баш мингерәтә торган эчемлекләр кулланмыйбыз. Шамкай әфәнде, алай ярамый бит инде.

— Карагыз әле, сезләргә кем дип эндәшим? Иптәшләр, дипме, дуслартуганнар, димме? Нигә бу турыда сорыйм, чөнки сезне үпкәләтәсем килми, йә тагын рәнҗетермен.

— Сез дөрес кенә сөйләгез, кыланмыйча, ничек бар — шулай.

— Туганнар, кардәшләр, дип башлыйммы?

— Әйе, әйе, кардәшләр, дип башла.

— Кардәшләр! Юк, ватандашлар, дип башлыйм әле. Безнең президентыбыз халыкка шулай дип мөрәҗәгать итә.

— Юк, алай дөрес түгел. Син бит безнең «Притон» планетасында — еракта. Бу планета сиңа Ватан була алмый. Синең зур Ватаның — Җир, ә кечкенәсе — Татарстан иле.

— Әйе, әйе, сезнең каршыда бу юлы мин үземне наданрак итеп тоям.

— Кыенсынмагыз, үзегезне иркен тотыгыз.

— Ярар. Кызыксынган сорауларыгызга җавап бирергә тырышырмын. Ә менә беренче соравыгызга ачыклык кертергә өлгердем, ахрысы. Сез әйткән идегез, нишләп бездән көлеп, мыскыллап уйныйсыз, дип. Ул пьесаны драматург Зөлфәт Хәким шулай язган. Ничек язган — шулай уйнадык инде. Аннан соң, ул монда килеп күрмәгән бит сезне. Күргән булса, бу рольгә мине куймаслар иде. Үзегез сизеп торасыз: килеш-килбәтем бер дә сезгә охшамаган: кашларым калын, үзем юан, тәбәнәк, йонлач, ә сез монда барыгыз да бертөсле кыяфәттә — башларыгыз зур, шәрә, күзләрегез — алагаем, кулларыгыз — нечкә, аякларыгыз — силә кебек — сыгылмалы, нәфис, бер сүз белән әйткәндә, барыгыз да чибәрләр, сылулар. Үпкәләмәдегезме?

— Юк, юк, сөйлә, матур сөйлисең!

— Сөйләргә дигәндә сөйлибез инде анысы... Дөресен генә әйткәндә, үзегез шулай сөйләргә куштыгыз, үзем дә турысын әйткән кешеләрне хөрмәт итәм. Ялагай, сатлык, икейөзле кешеләрне күрәлмыйм. Мисал өчен бер генә вакыйганы искә төшерәм. Гафу итегез, килгәннән бирле әле берегезнең дә исемен сорамадым. Каушаудан, ахрысы, шулай килеп чыкты. Менә сезнең, минем белән әңгәмә алып баручы, исемегез ничек?

— Галәм.

— Оho! Менә, ичмасам, исем — Галәм! Ә бездә — җирдә Галим дип кенә кушалар.

Җыелыштагылар шаулашып алдылар, меңнән йөзләбе кулын күтәрде.

— Безнең исемнәр дә Галәм! — диештеләр.

— Сүземне дәвам итәм. Менә шул «Кишер басуы»н сәхнәгә чыгардык. Кулдан килгән кадәр тырыштык. Спектакль халыкка бик ошады, заллар шыгрым тулы булды. Бусы — нәтиҗәсе. Спектакльне халыкка тәкъдим итәр алдыннан күңелне нык кына рәнҗеткән нәрсәләр дә булып алды. Сәнгать советында мин уйнаган образны, ягъни «сезне» уйнауны бик каты тәнкыйтьләгәннәр.

— Сездә дә акыллы кешеләр бар икән.

— Бар. Моны театр тәнкыйтьчесе әйтсә, уйланыр да идең, шунда утыручы артистлар бераз онытылып киткәннәр. Тәнкыйтьнең мин кинәш йөзеннән әйтелгәнен кабул итәм, ә монысын хөсетлек, көнчелек дип аңладым. Бергә эшләгән кеше өстеннән сөйләүне мин бер дә егетлек дип санамас идем. Ә бит күп тә үтмәде, шушы роль өчен миңа Татарстан Республикасының Мактау грамотасын бирделәр. Карагыз әле, монда шундый грамота кәгазьләре бирәләрме? Мактаулы һәм башка лауреат исемнәре? Әйт әле, Галәм?

— Бездә андый гадәт юк, Шамкай туган. Без андый исемнәрне, грамоталарны ат, сыер, сарыкларга гына тагабыз.

— Ә бездә, Җирдә, шундый исемнәр алыр өчен талашып-сугышып бетәләр.

— Кирәкми ул безгә — без монда барыбыз да бертигез, һәркем үз эшендә — җаваплылык һәм төгәллек белән хезмәт итә.

Шулвакыт «Притон» халкы арасыннан берсе кулын күтәреп, сүз бирүләрен сорады.

— Исемегезне әйтегезче, — диде Шамкай.

— Җиһан.

— Сез ир кешеме, әллә хатын-кыз затыннанмы? Болай килеш-килбәтегездән берегезне дә аерып булмый.

— Хатын-кыз. Әле кияүгә чыкмаган. Сез андагы катнаш никахларга ни мөнәсәбәт белдерәсез?

— Сезнең соравыгызга сорау белән җавап бирергә буламы?

— Рәхим итегез!

— Ә сезнең үзегездә бу мәсьәлә ничек тора?

— Безнең планетада татарлардан башка бүтән милләт юк.

— Шулаймыни?

— Әйе.

— Алайса, сездә бу мәсьәлә хәл ителгән дип исәплик. Ә бездә ул иң катлаулы һәм четерекле хәлләр тудыра. Мин мондый сорауга киңрәк мәгънә салып, тулырак җавап бирермен. Әле күптән түгел генә Җирдә халык исәбен алу булды. Татарларның саны кайсы якка үзгәргән дип уйлыйсыз? Бу сорауга милләт язмышына битараф булмаган һәр кеше җавап эзлидер. 30 еллар элек Әбрар Кәримуллин, сез аны белергә тиеш!..

— Беләбез, беләбез! — дигән тавышлар бу очрашу митингында катнашкан притонлыларның бер чакрымга якын сузылган рәтләре буйлап еракка китеп сүрелде.

— Менә шул Әбрар Кәримуллин дигән олуг татарыбыз: «Мин Советлар Союзының җинаятьчел статистикасына ышанмыйм. Татар милләте ким дигәндә егерме миллионлап», — дип әйткән иде. (Ул заманнарда без биш миллионлап исәпләнә идек.) Хәзер дә мөмкин кадәр азайтып күрсәтеләр. Оятсыз рәвештә татар халкын төрле этник төркемнәргә бүлеп, күзгә карап артка тибү бара.

— Әйе, без хәбәрдар, күреп, карап, күзәтеп торабыз.

— Ә нигә күреп, карап, күзәтеп кенә торасыз соң? Әзрәк булышсагыз да, ярдәм итсәгез дә ярар иде. Карагыз әле, сездә никадәр көч! Сез дә татар бит.

— Без, чит планета эшләренә тыкшынырга ярамый, дигән закон нигезендә яшибез.

— Алайса, безне берәмтекләп үзегезгә ташып бетерегез.

— Анда яшәргә рәт калмаса, әлбәттә, ташырбыз. Безнең чит планетадагы милләттәшләргә ярдәм итәргә дигән интернациональ бурычыбыз шулай ук закон рәвешендә язып куелган. Әле сезнең андагы яшәү шартларын бик үк хөрти дип тә әйтеп булмый.

— Юк та... Югарыда бирелгән сорау үзенең җавабын табалмый бүленеп калды. Мисал белән дәвам итәм. Минем әтинең сеңлесенең улы, ягъни минем пләмәш Казанга укырга килде.

— Ни дигән сүз ул «пләмәш»?

— Без, мишәрләр, туганнан туганны шулай дип атыйбыз.

— Алай икән, дәвам ит.

— Саф татар кызлары тулып ятса да...

— Ничек инде саф кызлар дисең, үзләре «ятсалар» дип әйтәсең?

— Юк, алар чыннан да саф, без җирдә шулай сөйләшәбез.

— Саф татар кызлары күп булса да, пләмәш марҗага өйләнде.

— Анысы кем тагын? — дип алдагы рәтләр шаулашып куйды.

— Анысы урыс кызы, без татарлар аны «марҗа» дип йөртәбез. Бүлдермәгез әле. Менә шул пләмәш «хатынымның фамилиясен алыйм микән әллә?» дип сөйләнеп йөрде. Әйтерсең, марҗа түгел, ул кияүгә чыккан.

— Ай-яй катлаулы яшисез икән сез. Нәрсәгә инде ул фамилияләр алмаштыру. Ну надан законнар сезнең!..

— Син әйтәсеңме аны, минме?.. Пләмәшнең фамилиясе Мәхмүтов. Килен исә: «Бигрәк чи татар исеме», — дип колак итен ашый икән. Ә менә шул пләмәшнең апасы хохолга, сорамагыз, хәзер әйтәм — украин егетенә кияүгә чыкты. Шушы ике гаиләдә дүрт баланың ник берсе татарча белсен! Килен белән кияүне дә санасаң, шулай итеп, алты туганымны югалттым. Ә милләт дүрт татарын югалтты. Мин үзем ана телендә сөйләшмәгән кешене туганым дип кабул итә алмыйм. Сез килешәсезме?

— Килешәбез, хуплыйбыз! — дигән сүзләр жиһанга таралды.

— Димәк, татарларның Жирдә үрчеме булмаячак! — дип уфтанып куйды төркем түрендә берәү.

— Казанда безнең Ярмәктән күчеп килгән бер гаилә яши. Шулай бермәлне телефоннан сөйләшәбез тегенең белән. Исәнмесез, Мәсгудә апа, минәйтәм. Балаларыгыз үсеп, башлы-күзле булып беткәндер инде?

— Ник, сездә башсыз, күзсезләр дә бармыни?

— Безнең татар шулай сөйләшә, «өйләнештеләр» дигән мәгънәдә.

— Әйе, — ди Мәсгудә апа, — өч улым да тормыш корып жибәрде.

— Ничек соң, үзебезнекеләрме?

— Юк, икесе маржага өйләнде, беләсең килсә, маржа килennәр жайлырак та әле ул, — ди бу.

— Син, Мәсгудә апа, кодагыйларың белән чиркәүгә дә кереп чык инде — тормышыгыз тагын да жайланып китәр, — диясем килде. Мондый мәсгудәләр бездә буа буарлык.

— Сезне тынлап торгач, киләчәгегез бик караңгы булыр кебек, — дип көрсенеп куйды притонлыларның берсе.

— Безнең планетада яһүд дигән халык бар. Берзаман аларның теле бөтенләй беткән, онытылган булган. Израиль дәүләте оешкач, бөтен кулъязмалардан, бөтен дөньядан иврит телен, сүзләрен берәмтекләп жыеп, тәки телләрен тормышка кайтардылар. Ә безнең тел, шөкер, исән-сау. Ул диалектларга шулкадәр бай, без аның белән горурланып яшәргә тиеш. Рәсәйнең кайбер әрәмтамаклары шушы байлыгыбызны безне таркату өчен корал сыйфатында файдаланмакчы.

— Ни өчен аларга халыклар арасында таркату, дошманлык хисләре уяту кирәк? Без аңламыйбыз...

— Ни өчен, ни өчен?.. Түрәләргә байлык житми, ә байлык өчен көрәшү ул — аның эчке дөньясы, халәте, ягъни культурасы бик түбән дәрәжәдә дигән сүз. Минемчә, дөньяда иң зур бәһале нәрсә — халыклар дуслыгы! Ә Жирдә ул әле лозунгларда гына. Чынлыкта исә, хакимнәр үзара дустанә яшәүне кайгыртмыйлар, бары тик кесәләрен калынайту турында гына уйлыйлар. Алар өчен Жирдә нефть, газ һәм власть — иң зур байлык. Алар инде хәзер Жир иярчене булган Айны да бүлешеп яталар, чит планеталарга нәфесләре бар. Кисәтеп куям, үзегез сизмәгәндә сезне дә бүлешеп куюлары мөмкин. Ләкин курыкмагыз, аларга әле бу максатларына ирешү өчен байтак көч түгәргә кирәк булыр. Әнә сезнең техникаларыгыз нинди — мине утыртып килгән космик корабльне генә алыйк. Бездә аны тәлинкә дип атыйлар.

Притон халкы Шамкайның бу сүзләреннән эчләре катып көләргә тотынды. «Тәлинкә, тәлинкә, уф, «табак» димиләрме тагын».

Шамкайның мәзәк сөйләп Жирдәге концертта да тамашачыны бу кадәр көлдерүгә ирешкәне юк иде. Ул каршысында утырган берәүне, көлеп үлә бугай инде дип, түбәтәен жилпеп һушына китерә башлады. Мескен: «Бүтән андый кызык сүзләр әйтмә», — дип көчкә хәлгә килде.

Ниһаять, Притон халкы үз халәтенә кайтып, тынычланды. «Сөйлә, сөйлә, теге туктап калган жиреннән дәвам ит!» — диделәр.

— Дәвам итәм. Мина калса, урысларның безнең телне кисәргә дигән уйлары барып чыкмас... Хәер, кем белә... Мөстәкыйльлек алган елларны «татар уянды» дип куанган идек. Ялгышканбыз, татар йоклый. Бары тик борылып кына яткан булып чыкты. Минемчә, сездән ярдәм кирәк.

Халык арасында шау дулкыны кубып алды. Күпләрнең: «Булышырбыз!» — дигән фикерләре гүләп куйды. Шамкайның янында басып торган Галәм кулларын югары күтәреп, тынычлануларын сорады.

— Галактика кануннары буенча, без планеталарда яшәүче җан ияләренең яшәешенә тыгылырга тиеш түгелбез. Ягъни табигый эволюция шартларын бозу хакыйкатькә китерми, без һәм башка югары үсеш формаларына ирешкән аңлы адәм затлары бары тик күзәтү функцияләрен генә алып барырга бурычлыбыз. Аннан соң икенче зур вазифабыз — планеталарны гарасатка житкермәү, халыкларның үзара кырылышын соңгы чиккә куймау. Минемчә, бу эш безнең «Притон» планетасына йөкләнгән, шуңа күрә ахыргача гадел булыйк.

Шамкай Галәмнең бу сүзләреннән соң бераз кызып китте.

— Ничек инде сез күзәтеп кенә торырга тиеш? Татар башыгыз белән Җирдә безнең бөтенләй бетүебезне телисезмени? Менә сиңа туганнар! 1552 елны Явыз Иван Казанны алганда да күзәтеп тордыгызмы?

— Әйе, күзәтеп тордык. Сезнең ничек бер-берегезне сатып, илегездән мәхрүм калганыгызны карап шаккаттык. Ханбикәгез Сөембикәне шул Явыз Иванга биреп җибәрдегез бит. Аны озатасыз да, үзегез тәхеткә утырасыз, байлыгыгызга да берәү дә тими, имеш. Ә чынлыкта бөтенесеннән дә мәхрүм калдыгыз. Халкыгыз да кырылды, илегез дә бетте.

— Сез шуны күреп тордыгызмы? Ничек намусыгыз чыдады мондый мәнсезлеккә?

— Сез чамалап сөйләшегез һәм чит планетада икәнлегегезне дә онытмагыз! Без җирдәге татарларыбызга шул коточкыч мәхшәргә кадәр бик күп игелекләр эшләп килдек. Ләкин алар үкенечле хәлләрдән беркайчан да сабак алмадылар. Бер-берсеннән көнләштеләр, байлык, тәхет бүлештеләр, үтерештеләр, туганны туган дип белмәделәр, дөнья шулай без биргәнчә җайлы гына барыр дип уйладылар, илен ятларга сатсалар да, җаннары тыныч, телләре шул килеш калыр дип өметләнделәр. Еллар, гасырлар үтте, сезләрнең әле һаман да аңга килгәнегез юк. Һаман бер-берегезне сатасыз, ялагайланасыз, «өлкән туган»га тәлинкә тотасыз, үзенә тимәсеннәр генә, калганын хет су бассын. Менә шундый бит сез. Шулаймы?

— Анысы шулай. Әле шуның өстенә эчүчелек, әхлаксызлык, караклык, динсезлек, наркомания, ялкаулык — «чәчәк атабыз» дип әйтеп булмый инде. Бу форсаттан чыгып, синең сүзләрне куәтләп язган шигырем дә бар әле минем, Галәм. Сөйлимме?

Мона хәтле дә шыгрым тулы мәйдан тагын да тыгызланган иде. «Сөйлә, сөйлә, син матур сөйлисең!» — дигән сүзләр янадан яңгырады.

— Тыңлагыз!

Без сөябез башкортны,
Без сөябез чувашны,
Удмуртны, марины,
Мукшыны — юашны.
Урыс белән уртак без...
Патамушты куркак без!

Мәйдан тирән тынлыкта Шамкайны тыңлады һәм шигырь тәмамлангач та йөзләрен монсулык баскан притонлылардан хуплау алкышлары ишетелмәде. Шамкай күпләрнең күзләрендә яшь бөртеге күрде. Ул әле генә ялкынланып сөйләгән шигъри юлларының мондагы татарларга хәсрәт индергәнен аңлады. Юкка сөйләде ул бу шигырен, юкка. Нинди үкенеч! Халык елый. Безне кызганып елый.

Галәм, тамагына утырган ачы сагыш төенен йотып, сүз алды.

— Җәмәгать, Шамкай туганыбызга сорауларыгыз бармы әле?

Шамкайга күптәннән мөлдерәп карап торган бер зат сүз кушты:

— Шамкай абый, сез өйләнгәнме?

Мәйдан бу көтелмәгән сораудан шартлап көләргә тотынды. Әй, кул чабалар! Күрәсең, кызның кызыксынуы барысының да күңеленә хуш килгән икән, женси хисләр мондагыларга да ят түгел.

— Нәрсә дип әйтим, сеңлем. Өйләнмәгән, дисәм, сез Жирдәге һәр хәлдән хәбәрдар. Ялганлау килешмәс. Өйләндем. Улым, кызым бар, инде оныклар үсеп килә. Ә шулай да йөрәгем — женское общежитие, ягъни үзебезчә әйтсәк, хатын-кызларның тулай торагы. Анда сиңа да урын бар.

Мәйдан гү килеп куйды. Бу ризасызлык билгесе, ахрысы.

Мондый картка кыз бирәләрме соң. Ярый әле бу сүзләре өчен кыйнап атмадылар.

Сүзне, сәхнәгә менеп, Галәм дәвам итте.

— Кадерле ватандашлар, сезнең үтенеч буенча бик соратып алынган милләттәшебез Шамкай белән саубуллашу минутлары житте. Һәммәгез дә бу очрашудан канәгать булгансыздыр дип беләм. Сөекле жәмәгате Суфия ханым сөекле ирен югалткандыр инде. Аны хафага салмыйк, милләтебез горурлыгы Шамкайны өенә озатып куйыйк. Юл ерак, ләкин ул, безнеңчә әйткәндә, чүп кенә — илле мең яктылык елы арасы гына.

Жыелган халыкның Шамкайны кочаклап озатасы килде, ә чынлыкта моның һич тә мөмкин түгеллегенә үзләре дә ышана иделәр. Шамкайның үзендә дә шундый ук хисләр кайнады. Ул, әлеге дә баягы, күзе төшкән кызның яшьле күзенә карап, аның янына килде. Жылы кулларын учына алып, битенә китерде һәм үпте. Шамкай кызның исемен сорарга жөрьәт итте. Кызның сусыл иреннәреннән «Айсылу» дигән сүз сыгылып чыкты. Шамкайның йөрәге кысылып куйды. Аһ, бу исем! Монда да ишетелмәсә ни булган...

Шулчак мәйдандагы бөтен халык «аһ» итте. Кызның шаккатудан зурайган күзе Шамкайга текәлде. Әйе, ул бу кеше күңелендә нәрсәләр кайнаганын аңлады, ахрысы.

Жиһан белән Галәм халыкка нидер аңлатырга керештеләр. Әллә нинди чуалчык хәл барлыкка килде. Һәм... ниһаять, барысы да элеккеге күнелле, ләкин сагышлы озату вакыйгасына әйләнеп калды.

Шамкай кыз кулын үбүдән соң килеп чыккан чуалчыкны соңыннан гына аңлады. Кызның кулын үбү ул, аларча, мин сине хатынлыкка сорыйм дигән төшенчә булган икән. Әй, көлде инде үзеннән Шамкай, әй көлде... Соңгы вакытларда рәхәтләнеп көләргә дә туры килгәне юк иде бит әле...

## Ахыры булмас юллар

*Тыныч кына барган көннәреңдә*
*Зур хәсрәт төшсә башыңа,*
*Чын дусларың менә шундый чакта*
*Килеп басар синең каршыңа.*

Ах, бу гомер дигәнең!.. Жырдагыча «бер күз ачып йомган ара гына» икән. Инде менә Рәшит пенсиягә чыкканнан соң да ундүрт елга якын вакыт узган. Үткәннәрне уйласаң да уйлап бетерерлек түгел, кайбер ачыкланмаган вакыйганы искә төшергәч тә әле һаман буталасың гына. Нигә ул шулай булган, нигә алар болай эшләгәннәр, ә син — тегеләй?.. Тормышның аянычлы көннәре нишләп сине читләп узмаган, югыйсә язмыш икенче төрлерәк юнәлешкә борылыр иде кана. Нигә соң әле ул бу турыда соңгы вакытларда күбрәк уйлана башлады? Бар да яхшы, әйбәт бит юкса. Хатыны, балалары, оныклары — янында. Барысы да

сау-сәламәт. Үзе лаеклы ялда. Әле һаман да эшләп йөри. Ике көннең берендә: «Рәшит абый, бер генә атнага гастрольгә чыгып керәсе иде бит, каршы килмә инде, зинһар», — диеп чакырып торалар.

Нигә әле җанында, канында дәрт барында халык күнелен күреп кайтмаска ди. Репертуары зур, кирәк дип тапсалар, сәгатьләр буе мәзәк сөйләп көлдерерлек дарысы бар әле анын.

Әнә, Мәскәүгә кабат чакыралар, Себер яклары да бик сагынган ди үзен, Башкортстан, Татарстан район-авыллары — татар дөнья тутырук бит ул. Әле менә «Притон» планетасында да булып кайтты — әллә төш, әллә чын булды анысы... Үзе дә моның дөреслегенә шикләнеп йөри бу арада. Күз алдына килә дә баса андагы хәлләр. Чып-чын иде бит инде ул көрешүләр... Айсылу дигән кыз да чын иде. Булмаса, каян килеп чыксын ди ул? Рәшитнең ишеткәне бар бер төн эчендә кайберәүләрнең чит планеталарда булып кайтканын. Бик сәерсенеп карый иде ул аларга. Менә хәзер үзе шаһит. Барды бит инде, барды. Кабат китереп куйдылар, әле: «Син — Җирдәге үзебезнең милләткә бик кирәк кеше», — диделәр. Уф Аллам, кеше ышанмаслык чынбарлык бу, билләһи. Ләкин берәүгә дә сөйләмәскә кирәк, сөйләмәскә...

Соңгы көннәрдә улы Айдар еш искә төшереп тора: «Әти, әйдәле бер җыелышып Ярмәккә кайтып килик, күптән кайтканыбыз юк, туганнарның хәлләрен белербез, зиярәт та кылырбыз. Син бит гомер буе, Батыргали бабай кебек батыр булачакмын, дип йөргән кеше, анын каберенә дә чәчәкләр куярбыз. Син хөрмәт итеп сөйли торган Хәлимә апа да гүр иясе булган икән, анын кабере янында да догалар укырсың. Дөнья белән саубуллашуынын соңгы мизгелендә ире Сәлимгәрәйнең, дәү әтием Мирзаҗанны төрмәгә утырту нияте белән, амбардагы орлыкка дигән ашлыкны урлавын әйтеп калдырган. Ире өчен безнең дәү әтидән һәм барчыгыздан гафу үтенгән», — ди.

— Шулай булган, улым... Әйдә, машинаңны көйлә, иртәгә юлга чыгарбыз. Үземнең дә Ярмәккә күптән кайтканым юк. Әниен дә кайтыр, балаларың Әмир белән Гаделне дә ал.

Иртүк юлга чыктылар. Җәйге көннең матур иртәсе. Айдар радиодан ягымлы гына көйләр уйната. Ул тавышны көчле итеп куймый, чөнки балалар йоклый әле, бер уянып машинага кереп утыргач, кабат тәмле йокыга талдылар. Сабый чакта бигрәкләр дә татлы була шул йокы дигәнең. Машинанын тигез тавышы да эретә торгандыр инде аларны. Кечкенәсе — Гаделе башын дәү әнисенең алдына салган, олысы — Әмир, утырган килеш башын артка ташлаган. Аңа бераз унайсыз икәнен күреп, Суфия ханым утыргычка мендәр салды, Әмирнең башын шунда индерде.

Айдар ара-тирә радиода яңгыраган җырларга кушылып ала, күрәсең, күнеле көр, ник дисәң дә, әти-әнисен үз машинасында беренче тапкыр изге җиргә, туган якка алып кайта бит. Багажникта видеокамера. Ай, күп истәлекле урыннар төшерәчәк ул бу кайтуында! Әтисе сөйләгән никадәр гыйбрәтле хатирәләр кино булып калыр.

Рәшит Айдарга бик ашыкмаска куша. Аллам сакласын, артык куып, көтелмәгән һәлакәт килеп чыга күрмәсен. Әнә, Хәмзә никадәр сак йөреп тә зур бәлагә очрады бит. Әле дә күргән зыянны очлап, ямап чыга алмый. Машинасы көл булган, үзенә, шөкер, Ходай саклаган, берни булмаган. Рәшит тә андый авариядән чак исән калган кеше. 1999 ел. Ул, бу елның тугызлылары күп булуга бик шикләнеп: «И Ходаем, үзен сакла!» — дигән иде. Әле дә хәтерендә ул сүзләре. Һәм вакыйгалар озак көттермәде. 3 февраль көнне Башкортстанның Янавыл районында авариягә юлыкты. Машинанын алгы тәрәзәсеннән очып

чыгып, көрткә чумды. Шуннан сикереп торып, үзенең бөтен жирен капшаганнан соң, әҗәлнең бик якыннан гына узып киткәнен аңлады.

Инде менә Әлмәт юлыннан Чирмешәнгә таба борылдылар. Әмир белән Гадел дә уянды. Шулвакыт Рәшитнең кесә телефоны шалтырады.

— Алё, кем әле бу?

— Хәмзә бу. Рәшит, нихәлләр?

— Әйбәт кенә, үзеңдә саулык-сәламәтлекме? Теге борчуларың кимемиме?

— Түзәбез, Рәшит!

— Ярый, шулай булсын.

— Карале, Рәшит, теге минем исәпкә хәйрия концерты оештыруны Түбән Камалылар, ягъни якташларым, киләсе атна шимбәсеннән бүгенге шимбәгә күчергәннәр. Син килә алмассыңмы? Мина сезне жыюы бик уңайсыз. «Биш татар»ның калганнары төштән соң Казаннан юлга чыга.

— Борчылма, Хәмзә, эшлибез аны!

— Рәхмәт, дустым, көтәм.

Айдар машинасын туктатты.

— Хәмзә абыйга нәрсә булган?

— Ярый, болай итәбез, бор әйдә, улым, машинаңны Түбән Камага, Хәмзәгә ярдәм кирәк.

Суфия ханым куркынып калды.

— Ай Аллам, нәрсә булган тагын Хәмзәгә?

— Бернәрсә дә булмаган. Булганы бик житкән. Хәзер барыбыз да Хәмзә янына, авылларына кайтабыз. Алар бик кунакчыллар, берочтан ничек яшәгәннәрен дә күрерсез, танышырсыз да, безнекеләрнеке күк балалары да өй тутырык. Бүген кич Хәмзә өчен хәйрия концерты куябыз һәм аларда кунып, икенче көнне Ярмәккә кайтабыз. Башка фикерләр юкмы? Юк!

— Әти, бернинди каршылык булырга мөмкин түгел. Сез бит инде теге «Дүрт мушкетёр» кебек. «Один — за всех, все — за одного!» «Биш татар» дип кенә йөртелсәгез дә, бер-берегез өчен үләргә әзер сез. Мин сезнең белән горурланам. Атос, Партос, Арамис, Дартаньян!

Машинадагы оныклар жанланып китте. «О-hо! Без әле бүтән жирләргә дә барабызмыни? — диештеләр. «Урра», кычкырыштылар.

Аларның сөенечләре Рәшиткә дә күчте. Ул, Гаделгә карап:

— Улым, әйт әле, үскәч син кем буласың? — дип сорап куйды.

Гадел арткы утыргычка басты да, күкрәгенә сугып:

— Шамкай булам! — диде.

Барысы да бу җавапка чиксез куанып, Гаделдән кем буласын кабат-кабат сорадылар.

Айдар әтисе күрсәткән юлдан Хәмзәләргә борылды. Бөтен җиһанга «Шамкай, Шамкай!» дигән горур исем яңгырап калды...



Сания
Әхмәтҗанова

# АРЧА СУЛАРЫ

## Ана су

ЛИРО-ЭПИК ЦИКЛ

*И газизем — и атам —*
*Каерылып атны тартаек,*
*Ана Иделгә кайтаек,*
*Идел багына ятаек.*

«Идегәй» дастаныннан.

«Иделе бер — чишмәсе мең» — баксана...
Идел суым, агар юлың тапсана,
Гасыр кичеп, гасырларга аксана,
Олы дингез ярларына каксана.

Шанлы кала Итилгә син тиң идең,
Уең тирән, күңелең белән киң идең.
Болгарың һәм Кыпчагыңны үз күреп,
Багларына сыендырган син идең.

Күз-күз булып бәреп чыккан кизләүләр
Күзәнәген булып синдә тибәдер.
Инешләрдән куәт алган елгалар
Дәртләренә дәрман алып киләдер.

Аналарча сабыр-салмак агышың,
Үзегенә йоттың микән сагышың...
Кочагыңда бала сулар тирбәтеп,
Дингезләргә алып китеп барышың.

Чайкал, Идел, ялларыңны кабартып,
Дулкыннарың үчтекиләп уйнатып.
Кизләүләрең барлыйм әле бер кайтып...
Татыйм әле садә чишмә тәмнәрен,
Жанга кучсен туган якның гамьнәре.

Жилдер мине, жилдәй житез уй-атым,
Арча жире — болын, сулар буйлатып.
Йөзек салыйм чишмәләрнең учына,
Уйга талган догаларны уятып.

Сания ӘХМӘТҖАНОВА — *шагыйрә; «Оч ireккә, җырым», «Пар алма», «Гәрәбә» исемле китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Ашыт су

*Куе урманның төбендә*
*Куерып аккан Ашыт су...*

«Идегәй» дастаныннан.

Кайларга чабасың томырылып,
Кай ярга кагасың каерылып?
Ашкынма, Ашыт су, китәргә,
Жан ингән ягыннан аерылып.

Кайчандыр бу жирдә имәннәр
Шаулаган, хакыйкать даулаган,
Һәм төрки бабалар — ашиннар —
Кашлыкта[1] киекләр аулаган.

Суларын-сыйларын халкымны
Ачлыктан аралап калгандыр.
Коткарып зәмһәрир суыктан,
Михнәтле-афәтле елларда
Имәннәр башларын салгандыр...

Ә бүген, саеккан хәтернең
Уятып әрнүле ярасын,
Син, көмеш тәнкәле еландай,
Тын гына шуышып барасың.

Агасың язмышың ярыннан,
Мул сулы Иделгә уй тотып.
Туган як озата сәфәргә,
Баласын озаткан анадай,
Борчылып, сагаеп, ут йотып.

Ашыт су — ашин су, ашлы су,
Ялганып ярсулы Илләткә,
Тоташып тын сулы Иделгә,
Жай гына сәяхәт итәсең,
Дингезгә терек су илтәсең.

Онытма ашин су икәнең,
Үпкәндә кыялар итәген!

## Шушма су

*Шушма буе әрәмәлек,*
*Анда сайрый сандугач.*
*Әйләнәм дә шунда кайтам,*
*Өзелеп-өзелеп сагынгач.*

Жырдан.

Шушмабашның чишмәсеннән
Юл аламы Шушма елга?
Йөгереп китеп, Нократ суны
Куып тота «шошым»[2] елга.

Туган жирнең кан тибешен
Хәтерләтеп ага-ага,
Гасырларны кичкән елга
Малайланып кая чаба?

[1] Кашлык — яр чите, тау бите.
[2] Галим С.К.Кузнецов фикеренчә, «Шушма» атамасы «шошым» (чирмешчә — «яз») сүзеннән алынган.

Ниләр кайный бәгырендә? —
Кайчак тын ул, кайчак алкын...
Шушма елга һәр фасылда
Төрләндереп тора холкын.

Язлар җиткәч, җаны түзми:
Бер тулышып, ярсып ала.
Күнеленнән ташкан хисләр,
Балдак-балдак алкаланып,
Җәйләүләрне басып ала.

Агымсулар-ярсулар да
Күмәкләшеп гомер итә:
Нократ — Шушма, җитәкләшеп,
Чулмангача барып җитә.
Бер нарасый чишмә суын
Чал Иделгә алып китә...

Баласытып карамагыз:
Челтер-челтер нәни чишмә
Инешләргә кушылып чаба,
Елгаларга барып кага,
Дәрьяларга юлны таба,
Кире кайта болытларда:
«Шошым» җиткәч, Шушмаларга
Ләйсән яшьләр булып ява,
Моңы таныш, көе яңа...

## Казан су

*Кара урманның төбендә*
*Каралып аккан Казан су.*
«Идегәй» дастаныннан.

И Казан су, Казан су,
Күпне күргән-белгән су;
Арча җанында тибенеп,
Дөньяларга килгән су.

Газиз елгам Кесмәсемне
Кочагына алган су,
Сабый чишмә-инешләргә
Өлкән апа булган су,
Башларымнан сыйпый-сыйпый,
Чәчләремне юган су.

И Казан су, Казан су,
Таң дөрләгән шәфәкъларда
Ут тергезеп янган су,
Шул шәфәкъка бәгыремнән
Яшьлек хисем тамган су.

И олпат су, өлкән су,
Канлы яшьләр эчкән су...
Халкым белән ил шатлыгын,
Ил хәсрәтен кичкән су...

Каралыплар агасың,
Гел боега барасың,
Ялый-ялый ярларыңның
Иске-яна ярасың.
И Казан су, Казан су,
«Жир кендеге» — бер чишмәдән
Жан тибешен тапкан су.
Сенелләрен барлый-барлый,
Казаныма чапкан су,
Богылтауга[3] каккан су,
Йөз кизләүнең күзе белән
Ак кирмәнгә баккан су.

Заман аһын тоясың,
Хисеңне ник тыясың?
Ярларыңнан ташмак булып,
Чаптарланып куясың...
Ана Идел күкрәгенә
Исемеңне уясың...

Сәфәр башың — Казанбашың, —
Шулдыр синең гомер башың,
Онытырга кыймассың,
Исәрләнеп кочкан чакта
Мәгърур дингез кыясын...

***

Арча ягым, изге жирем-суым,
Мин бит синең газиз бер балаң.
Нәни инешеңдәй, зур елгалар
Куенына кереп агалам.

Агымсулар кебек, була минем
Тын чагым да, алкын чагым да...
Әмма һәрчак саф ниятләр белән
Иңем куям көчле агымга.

Үз фасылым белеп, ташып алам —
Ярсу жанга ярлар тардыр ла...
Шаулы дингезләрнең куәтендә
Тамчы гына дәхелем бардыр ла.

Газиз Арчам, мин бит күкрәгеңдә
Иркәләнеп аккан инешең.
Мин бәхетле, дәртле агышына
Куәт бирсә йөрәк тибешем.

Арча ягым, данлы-шанлы ягым, —
Ашкын елгаларның юл башы,
Чишмәләрең дәрьяларга житсен,
Юлын табып Идел йорт аша.
Синең гадел язмышың да шулай
Ил-жир язмышына тоташа.

[3] Богылтау — Казан кирмәне урнашкан түбә жир.

# БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕМЕ?

«ТҮГƏРƏК ӨСТƏЛ»

*«Милли əдəбият», «милли драматургия», «милли шигърият» төшенчəлəренə төрлечə караш, төрлечə бəялəмə бирүчелəр бар... «Милли» сүзе инде артык, глоболь дөньяда ул, ягъни милли төшенчə актуаль түгел дигəн сүзлəр дə еш ишетелə. Милли əдəбият булгач, милли медицина, милли тарих, милли география дə булырга тиеш диючелəр хаклыдыр бəлки... Əмма культура дигəн олы өлкəгə кергəн əдəбият, сəнгать традициялəре өчен милли атамасы бар һəм булачак та диючелəр күбрəк. Бүгенге сөйлəшүебезне милли драматургиядə, театрларыбызда милли каһарманнарыбыз, тарихи шəхеслəребезнең əдəби образларын тудыруга багышларга булдык. Фикерлəшүдə сəнгать фəннəре докторы* ***Гали Арсланов****, тарих фəннəре докторлары* ***Илдус Заһидуллин****,* ***Фаяз Хуҗин****, драматург* ***Зөлфəт Хəким****, филология фəннəре кандидатлары* ***Илсөяр Рəмиева*** *һəм* ***Рамил Ханнанов*** *катнаша. Əңгəмəне журналның баш мөхəррире* ***Илфак Ибраһимов*** *алып бара.*

**И.Ибраһимов:**



*– Хөрмəтле галимнəр, язучылар! Бүгенге фикер алышуыбызны шундый сораудан башлыйк əле. Тарихи чынбарлык һəм сəнгати фараз... Бу төшенчəлəр бер-берсенə һəрчак тəңгəл яраклашудамы, əллə аларның тəңгəллеге мəҗбүри түгелме? Ягъни вариантлар ихтималлылыгы да булырга мөмкинме? Мөмкин булса, ни дəрəҗəдə? Тарих фəнен, тарихи нəтиҗəлəрне инкарь итү дəрəҗəсендə түгелдер бит!..*

**Г.Арсланов:**



– Соңгы вакытларда дөньяда, бигрəк тə без яши торган Рус илендə, күп кенə табигать байлыкларына бəйле гомумкешелек төшенчəлəренə аерым милләтнеке генə итеп карарга омтылу сизелə, аерым миллəт атамалары тагыла (мисал: рус кышы, рус шикəре, рус кыры, рус каены һ.б.). Бу — бернинди дə глобальлек тəэсире түгел, бəлки аерым миллəт вəкиллəренең шовинизмы чагылышы. Ə фəн өлкəсенə килсəк, аның күп кенə төрлəрен миллəт төшенчəсе белəн берничек тə бəйлəп булмый торгандыр. Аларның милләте юк. Һəрхəлдə милли физика, милли химия, милли математика дигəн сүзлəр, төшенчəлəр, килешегез, абсурд буларак яңгырый. Əмма шул ук вакытта фəннең бары аерым миллəткə генə кагыла торган өлкəлəре, юнəлешлəре бар. Əйтик, тел, əдəбият, фольклор, этнография, сəнгать төрлəре (театр, музыка, кино) һ.б. Алар халыкның үзен билгели, милли үзенчəлеклəрен ача. Аларны өйрəнү халыкның милли үзаңын тəрбияли, миллəт буларак менталитетын билгели. Ə милли театрның нигезе булган драматургия өлкəсендə халыкның бөек шəхеслəрен, каһарманнарын, бай тарихын, данлы үткəнен һəм бүгенгесен чагылдыру, иң беренче чиратта, халкыбызда миллəт буларак горурлык, əгəр телəсəгез, милли патриотизм хисе тəрбиялəргə тиеш. Əнə шул максаттан чыгып, драматургиябездə тарихи, тарихи-биографик əсəрлəр даими актуаль һəм республикабыз театрлары тарихи пьесаларны сəхнəлəштерү өлкəсендə системалы рəвештə эш алып барырга бурычлы. Тик практикада, кызганычка каршы, бу эш еш башкарылмый. Мона, бердəн, тарихи, тарихи-биографик жанрда язылган əсəрлəрнең җитмəве, аз язылуы комачауласа, икенчедəн, театрларның бу төр пьесаларга игътибары җитəрлек булмавы үзен сиздерə.

Ə тарихи əсəрлəрдə чынбарлык белəн сəнгати фараз мөнəсəбəтлəренə кагылсак, бу беркадəр теория өлкəсенə, язу технологиясенə карый торган сорауга һəр драматург, үз алдына куйган максаттан чыгып, эш процессында үзенчə җавап бирə, якын

килә, үзенчә хәл итә. Драма әсәренә менә бу кадәр тарихи чынбарлык кертим дә менә бу кадәр үз фантазиямне өстим дип үлчәп язып булмый торгандыр. Әлеге компонентларның беренчесе өстенлек аламы, әллә икенчесеме — бу һәрбер автор, һәр әсәр өчен индивидуаль дәрәҗәдә. Ә менә әсәрдә сурәтләнәчәк тарихи вакыйгаларны, фактларны, образларны, алар турында сөйләүче тарихи документларны чын тарихчы-галим дәрәҗәсендә өйрәнү, белү мәҗбүри. Бу очракта инде язучы, драматург хезмәте тарихчы-галим хезмәте белән тиңләшә ала. Архив фондларын, әлеге темага язылган фәнни хезмәтләрне һәм башка төр материалларны өйрәнү эше җиңелләрдән түгел. Бәлки шуңа күрә дә бу пландагы әсәрләр бик күп түгелдер.

Русның бөек тәнкыйтьчесе В.Г.Белинский: «...верное воспроизведение фактов не возможно при помощи одной эрудиции, а нужна еще фантазия. Исторические факты, содержащиеся в источниках, не более как камни и кирпичи, только художник может воздвигнуть из этого материала изящное здание», — дип яза. Күренгәнчә, тәнкыйтьче тарихилыкка да, язучы фантазиясенә дә бердәй тигез, югары бәя бирә.

**Р.Ханнанов:**



— Билгеле, шулай. Әдәбият-сәнгать белеме, теория белән таныш һәркемгә мәгълүм: аеруча да сүз һәм сәхнә сәнгатендә шартлылык төшенчәсе мөһим вазифа үти. Хәтта беренчел чыганакларга нигезләнеп язылган документаль әсәрдә дә чынбарлык йөз процент була алмый, ягъни әдәби образ реаль объектка тәңгәл түгел. Без әдәбият-сәнгать белемендә шартлылыкны ике төргә бүлеп өйрәнәбез: беренчел һәм икенчел. Беренчел шартлылыкка кертеп каралган образ, үзе турында кычкырып тормаса да, сәнгать ягыннан дөреслеккә туры килә. Табигый, фальш-ялгансыз күренеш буларак кабул ителгән әлеге шартлылык пьеса һәм спектакльләрдә әһәмиятле роль уйный: төрле каршылык-проблемаларга барып тоташкан, чәчелгән вакыйгаларны бер үзәккә туплауда, ялыктыргыч киеренкелектән котылуда, персонажларның рухи халәтен ачык гәүдәләндерүдә алыштыргысыз принцип булып тора. Ягъни, ничек кенә булмасын, автор да, режиссёр да беренчел шартлылыктан әсәрне йолып кала алмый, чөнки шунсыз әсәр таралыр иде. Ә менә икенчел шартлылык инде тарихи чынбарлыкны ачып бирү вазифасы йөкләтелгән матур әдәбият һәм сәнгать әсәрләрендә шактый сак якын килүне сорый. Гомумән, бу очракта ул урынлы түгел дип саныйм, ник дигәндә, икенчел шартлылык — демонстратив, аңлы рәвештә әсәрнең чынбарлыкка тәңгәллеген бозуга корыла. Әлеге принципка нигезләнеп, авторлар әсәрнең төп сюжет тукымасына еш кына миф, легенда, булуы фаразга тиң вакыйгаларны кертеп җибәрә. Бу инде тарихи дөреслекне зәгыйфьләүгә, уйдырма, шартлы дөньяның бик күпкә өстенлек итүенә китерә.

**И.Заһидуллин:**



— Камил әдәби әсәр тусын өчен, аның тарихи чынбарлыкка нигезләнүе мәҗбүри түгел. Тулысы белән сәнгати уйдырмага корылган әдәби әсәрләр дөнья мәдәниятендә зур күпчелекне тәшкил итә. Шул ук вакытта тарихи чынбарлыкка корылган әсәрләр дә аз түгел, ләкин бу очракта тарихи чынбарлыкның сәнгатьлелеккә зыян китермәве шарт. Әгәр әсәр текстында тарихи чынбарлык (фактлар, документлар һ.б.) зур күпчелекне алып тора икән, ул текст әдәби әсәр булудан туктый.

Әгәр язучы тарихи чынбарлыкка мөрәҗәгать итә икән, аның бозылмавы шарт. Тарихи чынбарлык рәвешендә тулысынча сәнгати уйланма тәкъдим итү очраклары да юк түгел. Ләкин мондый текстлар укучыда ялгыш караш тудыра. Мәсәлән, мин мәктәптә укыганда, Валентин Пикульнең Рәсәй тарихына кагылышлы әсәрләре белән мавыгып алдым. Хәзер, аларда чагылыш тапкан вакыйгаларның иркен һәм дөреслектән шактый тайпылып шәрехләнүен аңлагач, сак карыйм.

Аерым бер халык-милләтләрдә әлеге үзенчәлекне үз тарихларын мифлаштыру,

бизәү өчен дә файдаланалар. Бу яхшымы? Юк, чөнки ул үсеп килүче яшь буын укучыны тарихи хакыйкать шушы икән дигән ялган дөньясына алып керә.

Тарихчы буларак, мин, гомумән, тарихи темаларга язылган әдәби әсәрләрне укымаска тырышам, чөнки сәнгатьлелек көче аны хәтергә сала, ялгыш күзаллауларга алып килә. Шулар фәнгә дә күчәргә мөмкин.

Инде бер унай мисал китерәсем килә. Нурихан Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романы берничә буын татар укучысын этник тарихыбызның ерак тамырлары белән таныштырды. Әлеге әсәр язылган 1970-1980 еллар чигендә бу чорларга караган чыганаклар бик тар даирә галимнәргә генә мәгълүм иде. Әдип, Сыма Цянь кебек кытай елъязмачыларының хуннар турындагы язмаларына таянып, безнең ерак тарихыбызны реконструкцияләде. Китапның тарихи хакыйкатьтән ераклашмавы аның кыйммәтен билгеләүче үрнәк сыйфат булып кала. Моны бүгенге әдипләребез, яшьләребез һәрчак исендә тотсын иде.

**З.Хәким:**



– Әлбәттә, тарихи әсәр язарга әзерлексез тотынып булмый. Шәхсән үзем «Кайда син, Аттила?!.» театраль романын язар алдыннан ике ел буена махсус рәвештә шул чорның тарихын өйрәндем, шул бөек шәхескә багышланган бөтендөнья әсәрләрен укыдым, тарихи чыганакларда, хәтта Аттиланың үзен күргән Приск Паннийскийның да латинчадан тәрҗемә ителгән язмаларында казындым. Тарихи чынбарлык һәм сәнгати фаразларга килгәндә, язучы тарафыннан фальш җибәрмәү — аның бурычы һәм аның ни дәрәҗәдә укымышлы икәнен, милләт тарихына ихтирамын, киләчәге өчен борчылуын күрсәтә торган гаять әһәмиятле фактор һәм, ниһаять, халкының тарихын тирәнтен яраткан, ихтирам иткән суратта генә әсәрең ышандырырлык булачак. Әсәр иҗат иткәндә, тарихи дөреслектән чалыш юлга кермичә генә дә фантазиягә урын күп. Вәләкин тарихи дөреслек кысаларында иҗат итү бер хәл, ә шуны ташка бастыру, театр сәхнәсендә куйдыру яки башка юл белән якты дөньяга чыгару язучының теләгеннән, мөмкинлегеннән һәм хәленнән генә килә торган нәрсә түгел, ә бәлки иҗатчының нинди парадигмада яшәвенә бәйле, хәтта алшарт булып тора. Ничек кенә боргалансан да, нинди генә таләпләр куйсаң да, төрле сәбәпләр табып аклансаң да, телисеңме-юкмы, сәясәт дигән бер төп сәбәпкә килеп төртеләсең. Үз дәүләтең булса гына, аның чын тарихын язу мөмкин. Хәтта Федерация дип аталган зур бер империядә үзеннең тарихыңны нинди күзлектән карап һәм кем пышылдаганга колак салып язарга икәнне тарихчы галимнәребез яхшы беләләрдер. Тарихи чынбарлыкны без — язучылар язабыз һәм язачакбыз. Ләкин бу илдә сәяси юнәлеш безнең милләт мәнфәгатьләреннән чыгып хәл ителми бит. Шуна күрә бездә җан таләбе, күңел ихтыяҗы белән язылган милли рухлы әсәрләрне күрмәмешкә салышу бар. Режиссёрлар исә, Мәскәү тәнкыйтьчеләре ни әйтер икән, дип көн-төн уйлаганга күрә, халкыбыз тарихына, аның геройларына илтифатсыз мөнәсәбәттә калалар. Минем үземнең унсигез әсәрем дөнья күрмичә шкафымда саклана, чөнки аларны сәхнәләштереп, Мәскәүдән килгән яһүдләргә ярап булмый, фестивальләрдә татар язмышына багышланган әсәрләр белән дан казану мөмкин түгел. Үз дәүләтебез булмагач, режиссёрлар танылуны, бәяләмәне читтән көтәләр. Аларны гаепләп тә булмый, чөнки безнең түрәләр иҗатчының Мәскәүдә яки тагын да арырак тарафларда танылуыннан чыгып «күрәләр» һәм ихтирам итәләр.

**Ф.Хуҗин:**

– «Казан утлары» бик мөһим проблема күтәрә. Глобальләшү шартларында — дөньякүләм масштабында мондый процесс бара һәм аннан беркая качып котыла алмыйсың — халкыбызның киләчәктә милләт буларак сакланып калу-калмау мәсьәләсе күпләрне чын-чынлап борчый башлады. Татар моңы яшәгәндә, шаулатып сабантуйлар үткәреп торганда, милләтебез яшәячәк әле дип күңелләребезне юатабыз да бит (оптимизм, әлбәттә, кирәк нәрсә!), чынбарлык исә күпкә катлаулырак. Туган телебездә иркен аралашучы яшьләребез азая бара. Республикабыз мәктәпләрендә, югары уку йортларында милли тарихыбызны укыту дәрәҗәсе бик түбән, Россия төбәкләрендәгесен әйтеп тә тормыйм инде. Милләтебез яшәсен дисәк, кул кушырып утыру ярамый, эшләргә кирәк. Шунысы куанычлы: милләт язмышын кайгыртып



кылган гамәлләребез көннән-көн арта, эшләребез күзгә күренеп җанлана бара. Әдәбият һәм сәнгать дөньясын гына алып карыйк. Соңгы елларда В.Имамов, Ф.Сафин, Р.Батулла, Ф.Бәйрәмова, С.Шәмси, М.Әмирханов, Р.Зәйдулла кебек язучыларның менә дигән тарихи әсәрләре — роман-повестьлары дөнья күрде. Олы сәхнәләрдә Р.Ахиярованың «Шагыйрь мәхәббәте», «Ак бүре» опералары, «Алтын Урда» балеты, Э.Низамовның «Кара пулат» операсы куелды, М.Шәмсетдинованың «Дастан», «Ибн Фадлан», «Чыңгыз хан» симфонияләре, Р.Мөхетдинованың «Тамырлар», «Изге Болгар», «Иске Казан» «Идел-йорт» кантата-ораторияләре яңгырады. Ф.Халиков, Р.Вахитов, Р.Хужин, Б.Гыйлванов һәм башка күренекле рәссамнарыбызның тарихи темаларга язылган картиналары күпләребезгә таныштыр.

«Татар театрында татар тарихы» темасына якынрак килик. Әлбәттә, яхшы спектакль тудыру өчен яхшы пьеса кирәк. Иҗатка керешкәнче үк, язучы алдына тарихи чынбарлык һәм сәнгати фараз проблемасы килеп баса. Аларның нисбәте ничек булырга тиеш? Менемчә, җиңел генә хәл ителә торган мәсьәлә түгел бу. Мисалга театр сәхнәләрендә тудырган Габдулла Тукай (Т.Миннуллин. «Без китәбез, сез каласыз»), Муса Җәлил (Т.Миннуллин. «Моңлы бер җыр») һәм Кол Гали (Н.Фәттах. «Кол Гали») образларын алып карыйк. Тукай һәм Җәлилнең иҗатларын гына түгел, тормыш юлларын да нечкәлекләренә кадәр беләбез. Ә менә Кол Гали турында тарихи чыганаклар бөтенләй юк. Ул — халкыбызның бөек шәхесе, горурлыгыбыз, әле уңөченче йөз башында ук, монголлар явына кадәр, мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасын иҗат иткән шагыйрь. «Кол Гали» трагедиясе авторы Нурихан Фәттах чынбарлык һәм сәнгати фараз проблемасын ничек хәл иткән соң? Бу хакта Илдус Котдус улы инде «Сызгыра торган уклар» романын мисалга әйтеп үтте. Әлеге очракта да ул, галимнәр тарафыннан тупланган документаль материаллар нигезендә, шагыйрь яшәгән чорны, мохитне өйрәнгән һәм Кол Галине шул заманнарда булып узган тарихи һәм уйлап чыгарылган вакыйгаларда катнашырга «мәҗбүр иткән». Менемчә, болгар шагыйре образын тамашачыны (укучыны) ышандырырлык итеп ачып бирүдә иң дөрес юл бу.

**И.Ибраһимов:**

*– Милли тарихыбыз меңнәрчә еллар, дистәләрчә гасырлар белән исәпләнсә дә, милли каһарманнарыбызның сәнгати образлары бик аз тудырылды. Идегәй, Кол Гали, Кол Шәриф, Муса Җәлил... Монда ике юнәлеш бар: халкыбыз иҗат иткән дастаннар, эпослар һәм профессиональ тарихчылар, әдипләр язган әсәрләр. Ни өчен милли театрларыбыз сәхнәсендә милли геройларыбыз юк бүген?*

**Г.Арсланов:**

– Әйе, халкыбыз күренекле шәхесләргә гаять бай. Әйтүләренә караганда, «Җыен» фондында мәрхүм М.Госманов җитәкчелегендә төзелгән исемлектә биш йөзләп бөек милләттәшебез теркәлгән. Кызганычка каршы, аларның бик азларының гына образлары әдәбият, сәнгать әсәрләрендә мәңгеләштерелгән. Әмма милли театрларыбыз сәхнәләрендә бөек милли геройларыбыз бөтенләй юк дип әйтү дөреслеккә туры килмәс. Мисал өчен, Г.Камал исемендәге театрда каһарман милләттәшебез Мөхлисә Бубига багышланган драма уңыш белән бара. Алдарак Идегәй образы сәхнәгә күтәрелгән иде. Театр тарихына күз салсак, үз вакытында Г.Камал исемендәге театрда гына да Туктамыш хан, Сөембикә, Тукай, Идегәй, Сәхипҗамал Волжская, Каюм Насыйри, Мулланур Вахитов, Бәхтияр Канкаев кебек күренекле шәхесләребез турындагы спектакльләр репертуарга алына. (Сорауда телгә алынган Муса Җәлил, Кол Галиләрне кабатлап тормыйм.) Алар бар, ләкин сирәк. Проблема менә шунда. «Ни өчен?» — дигән авыр сорауга килсәк, җавап алдарак бирелде кебек. Әдәбиятка һәм бер үк вакытта театрга хезмәт итә торган бу төр әсәрләрне язу драматургтан зур интеллект, эрудиция, тырышлык өстенә, шундый ук күләмдә милләтпәрвәрлек, талант, теләк сорый. Күрәмсен, әлеге катлаулы синтез бөтен драматургларыбызда да юк әлегә.

**И.Заһидуллин:**

– Минем фикеремчә, дастан геройларын сәхнәгә менгерү кирәк. Бигрәк тә соңгы 10-15 елда күп милли театрлар шушы юнәлештә күтәрелеш кичерә. Чөнки дастан геройларының тәрбияви тәэсир көче зур, ул милли үзаң үстерүгә хезмәт итә ала. Ләкин монда чама хисе булырга тиеш.

Инде тарихчылар язган текстларга килсәк, мин аларны әдәби әсәр язу өчен чыганак, этәргеч кебегрәк күзаллыйм. Тарихи чыганакны укып кына, аны тәнкыйди караштан анализларга хәзерлеге булмаган язучы вакыйгаларны дөрес шәрехли һәм бәяли алмаска мөмкин. Бу очракта тарихи чыганакка нигезләнеп язылган фәнни хезмәтнең язучы тарафыннан файдаланылуы отышлы. Шундый уңышлы хезмәттәшлекнең үрнәк бер мисалы дип күренекле татар тарихчысы Сәлам Алишевның «Татары Среднего Поволжья в Пугачёвском восстании» китабындагы милли каһарманнарның берсе Канкай углы Бәхтиярның күренекле драматург Туфан Миңнуллин иҗатында тергезелүен әйтер идем. Бу һәм башка әсәрләргә кабаттан әйләнеп кайт һәм бүгенге көн тамашачысына тәкъдим итү кирәктер.

**З.Хәким:**

– Минемчә, бу сорауны, иң беренче чиратта, театрыбызда эшләүче режиссёрларга юнәлтү мәслихәт. Милли геройларыбызны сурәтләгән әсәрләр бар һәм хәзер дә языла тора. Милли җанлы режиссёр булса, ул хәтта үзе, милләтебезнең берәр бөек шәхесен сәхнәгә менгерер өчен, нәрсәдер яза башлар иде йә драматургка кинәш-заказ бирер иде. Шул ук вакытта мондый фикерем дә бар: тарихта эз калдырган бөек шәхесләрне сәхнә әсәре белән халыкка тәкъдим итү мисалларын беләбез, әмма аларның күбесе шактый уңышсыз килеп чыкты һәм тамашачыны тетрәндерә дә, өметле итә дә алмады. Бәлки тарихта уелып калган бөек шәхесләребезне театрдан күрсәтергә маташуның кирәге дә юктыр. Бит тарихта урын алган бөек шәхесне тасвирлар өчен, шулай ук бөек талантка ия кешеләр кирәк. Кайвакыт легендар шәхесне сәхнәдән яки экраннан күрсәтеп, аны түбәнсетәләр шикелле тоела. Монда да тарихи чынбарлык дигән төшенчәне искә аласы килә. Тарихка кереп калган шәхес — ул инде болай да даһи шәхес. Халык хәтерендә сакланасы кеше пропагандалауга мохтаҗ түгел. Күп очракта, киресенчә, шул бөек шәхес турында әсәр язып, спектакль куеп, фильм төшереп үзләрен күтәрергә һәм үзләрен тарихка кертергә маташучылар күбрәк күзгә чалына.

**Ф.Хуҗин:**

– Бүгенге көндә милли театрларыбыз сәхнәсендә милли геройларыбызның булмавы безне борчырга тиеш, әлбәттә. Бу хәлнең сәбәпләре төрледер, дип уйлыйм. Минем күзәтүләрем дөресмедер-юкмы, әйтә алмыйм, әмма халкыбыз тарихын, милли каһарманнарыбыз язмышын яктыртуга багышланган спектакльләргә халык бик үк ашкынып йөрми кебек. Шунлыктан алар театр репертуарларыннан тиз төшеп кала. Тагын шуңа игътибарыгызны юнәлтәсем килә: менә ничә еллар инде К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е белән театр сезоны ачыла, ничә еллар Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәре» сәхнәдән төшмичә уйналды. Сәбәбе нәрсәдә? Талантлы әсәрләр алар! Халкыбызның күркәм гореф-гадәтләрен, милли психологиясен, чорның рухын дөрес чагылдыру җәһәтеннән караганда, мин нәкъ менә шуларны («Беренче театр», «Галиябану» һәм «Сүнгән йолдызлар»ны да кушып) чын тарихи әсәрләр рәтенә кертер идем. Тагын бер нәрсә: театрның үзеннән заказ, ә хөкүмәтебездән матди ярдәм булмый торып, язучыларыбыздан милли герой тудыруларын көтеп яту дөрес түгел. Заман башка хәзер.

**И.Ибраһимов:**

*– Әйдәгез әле, милли дәүләтчелегебезнең язмышы хәл ителгән Казан ханлыгы дәверен алыйк. Аның күпме ханы булган. Әмма халык телендә 3-4 шәхес: Олуг Мөхәммәд, Сөембикә ханбикә, Шаһгали, Кол Шәриф кебек шәхесләре күбрәк телгә алына. Аларның тарихтагы роле, кылган олы эшләре, фаҗигаләре нидә? Милли драматургиябездә әлеге образлар ничек тудырылды? Бу очракта Мәдинә Маликованың «Соңгы риваять», Ркаил Зәйдулланың «Соңгы татар» пьесаларына аеруча игътибар итүегезне сорар идем. Аларда — өч тарихи шәхес. Сөембикә, Кол Шәриф, Шаһгали образлары берьюлы чагыла бит...*

**И.Заһидуллин:**

— Безнен тарихыбызда берничә гомуммилли фажига дәрәҗәсендәге тема бар. Тукай темасы, Казан ханлыгынын егылуы шундыйлардан... Мондый темаларга мөрәҗәгать итү язучыдан билгеле бер дәрәҗәдә батырлык таләп итә. Чөнки ул, шушы вакыйгаларны сурәтләүче буларак, үз өстенә зур җаваплылык ала: яки милли үзанда яшәүче мифны үзгәртә һәм баета, яки җимерә башлый.

Еш кына чыганакларнын аз булуы һәм тарихчылар арасында фикер төрлелеге яшәү язучыны кыен хәлгә куя. Бер үк вакытта шушы ук факторлар язучы фантазиясенә киң мөмкинлекләр ача.

Ркаил Зәйдулланын «Соңгы татар» пьесасы татар дәүләтчелегенен иң фаҗигале битләрен тасвирлый. Андагы һәр сүз, һәр сурәт татар язмышына битараф булмаган кешенең күнеленә тиярлек итеп уйланылган. Шул ук вакытта әсәрдә сүз барган вакыйгалар хакында тарих фәнендә мәгълүматлар бик аз: алар, нигездә, ниндидер фактларны хәбәр итү рәвешендә генә. Драматург исә үз уйланмасы ярдәмендә тулысынча яңа дөнья тудырган. Нәтиҗәдә, мәсәлән, Кол Шәрифнен, хатыны үлгәч, аның апасына өйләнүе, хатынның руслар белән яшерен рәвештә язышуы, Кол Шәрифнен кызын, иренә әйтмичә, руска кияүгә бирен җибәрүе кебек чынбарлык белән ярашмый торган мотивлар пәйда була. Бу мотивлар Кол Шәрифнен тарихи мәгълүматлардан билгеле образы (шагыйрь, дәүләт эшлеклесе, ислам дине институтлары башлыгы, дәрәҗәле суфи, мәдрәсә җитәкчесе һәм мөдәррисе, шәкертләре белән бергәләп Казанны яклаганда шәһит киткән мөселман) белән дә, җәмгыятьтәге шәригать кануннары белән дә каршылыкка керә.

**И.Ибраһимов:**

*— Казан ханлыгында Сәет дәрәҗәсендәге шәхес ил-көн күзендә. Аның хатынының иреннән яшертен эшләре барыбер дә инкарь ителер иде. Сәет кадәр Сәетнең үз йортында тәртип сала алмавына ишарә түгелме бу: үз йортында тәртип сала алмаган, ил-йортында ничек тәртип салсын, янәсе?..*

*Бүген бөтен татарның мәркәзе Казанда мәһабәт Кол Шәриф мәчете — Казан ханлыгының бөек Сәетенә, Шагыйренә, Яугиренә куелган һәйкәл түгелме әллә?*

*Казанның алынуы, тарих күзлегеннән карaганда, кичәге көн генә, дидек. Халык хәтерендә һәм тарих фәнендә Казанның алынуы Сәетнең гаиләсендә тәртип булмаудан түгел, ә татарның чуарлыгыннан, бер-берсенә терәк-туган булмаудан, ханнары-морзаларының сәяси сукырлыгыннан, кайбер ыру-кавемнәрнең хыянәте — Мәскәүгә сатылуыннан дип бәяләнә. «Соңгы татар» авторы боларны инде күптән белә булыр.*

**И.Заһидуллин:**

— Әйе, бу пьесаны укыганда, мин тарихи әсәрләргә куела торган тагын бер шартны искәрдем. Язучы, тарихи чынбарлыкка таяна икән, шул чор мохитен, шул чор кешеләре менталитетын күңеле аша уздырып язарга тиеш. Мәсәлән, Казан алынмаган вакытта ук фаталистик мотивлаштыру (мәсәлән, Сөембикәнең Казан белән саубуллашуы, дошманга бирелергә җыенмаган шәһәрне кызгануы, аның аянычы киләчәген фаразлавы) очраклары тарихи чынбарлыктан бөтенләй читкә китә. Әсәр ахырына мина Кол Шәриф түгел, автор үзе соңгы татар кебек тоела башлады.

**Р.Ханнанов:**

— Сорауда телгә алынган ике әсәр дә, бер уйласаң, ерак тарихыбызга (шулай әйтергә ярыйдыр) карамый. Моннан биш-алты гасыр элек булган чор тарих өчен кичәге көн генә. Шуңа ул чор сулышын һәр язучы да бар тулылыгында бирә алырга тиеш. Бу урында мин Мәдинә Маликованың «Соңгы риваять» трагедиясенә тукталып идем. Казан ханлыгы чорында хакимият тирәсендәге вазгыятьне, икейөзлелекне, хыянәтне ачып бирүдә, зирәк, кыю, татарның азатлык символы булган Сөембикә образын, ватанына, халкына, ханбикәсенә тугры Колшәрифне сурәтләүдә ул әдәби камиллеккә ирешә.

Драматург Ризван Хәмиднең 1995 елда язылган «Хан кызы» тарихи драмасы турында да әйтми китү мөмкин түгел. Казан ханлыгын коткарып калу өчен кулыннан килгәннең барын да эшләгән Сөембикә әсәрдә милли эстетик идеал, милләт анасы, матурлык, зыялылыкның гәүдәләнеше буларак тасвирлана.

Халкыбыз язмышы хәл ителгән дәверне, хак тарихыбызны ачып биргән бу әсәрләрнең милли драматургиядә, һичшиксез, үз урыны бар.

Янарак тарихка бәйле пьеса-спектакльләр, әлбәттә, чынбарлыкка якын булуы белән алдыра. Игътибар итегез: «Соңгы татар» пьесасы авторы Ркаил Зәйдулланың Мөхлисә Бубига багышланган «Үлеп яратты» әсәре нинди зур яңгыраш алды. Язучы мәгърифәтче милләт анасын иң биек сәнгать күгенә күтәрде. Туган халкы, дине хакына үлем белән күзгә-күз очрашканда да сынмый калган хатын-кыз шәхесен, психологиясен камил ача алу әдәбиятыбыз тарихында Гаяз Исхакыйның «Зөләйха»сыннан соң юк иде бит. Моның өчен рәхмәт Ркаил абыйга. Ә менә «Соңгы татар»ы чын-чынлап каршылыклы сораулар тудыра. Андый каршылыклы сорау Кол Шәриф һәм Сөембикә ханбикә арасындагы мөнәсәбәтләргә кагыла. М.Маликова драмасында Кол Шәриф — дин башлыгы булу белән бергә, сәясәтче, илче дә. Ул Сөембикәгә теләктәшлектә. Хәтта Сөембикәне Мәскәүгә озатыр алдыннан, алар арасында житди сөйләшү булуга карамастан, Сөембикә Кол Шәрифне үзенең төп тарафдары итеп танудан чигенми.

«Соңгы татар»да исә, киресенчә, Сөембикә ханбикә Кол Шәрифкә сәяси гаепләр ташлый, ана әрнеп рәнжи. Нәрсә, Казан фажигасендә Сөембикә белән Кол Шәриф төп сәбәпче булып чыгамыни инде? Бу инде фантазиядән узган, минемчә...

**Г.Арсланов:**

— Әйе, мине дә Сөембикә, Кол Шәриф кебек бөек шәхесләребезнең образына житди куләгә, тап төшерә торган эпизодларның драма әсәрләренә кертелүе борчый. Әйтик, Р.Зәйдулланың «Соңгы татар» пьесасында Сөембикәнең һәм Кол Шәрифнең хәләл жефетенең капма-каршы женес вәкилләренә мөнәсәбәттә беркадәр жинел карашын, тәртибен күрсәткән аерым күренешләр бар. Аларны укыгач, ниндидер канәгатьсезлек хисе кала. Изге дип саналган кешенең бик үк лаек булмаган гамәлен күрү күңелне кайтара, мөнәсәбәтне боза. Кайбер рус елъязмасы чыганакларында Сөембикәгә мөнәсәбәтле шундыйрак ишарәләр чагылып китә. Ләкин, бердән, аларның дөреслеге шик уятса, икенчедән, бөтен тормыш материалын да әдәбиятка кертергә, сәхнәгә күтәрергә кирәк микән? Бигрәк тә, бүгенге термин белән әйтсәк, татар халкының «бренды» саналган шәхесләрне гәүдәләндергәндә. Юктыр, монда икенче принцип, куелган максатлардан чыгып, хак тарихи материалны сайлап алу зарурилыгы өстенлек алырга тиештер. Әгәр «кыздырылган» фактлар кулланып, арзанлы популярлык казану, ясалма рәвештә кызыксындыру уяту, скандал кубарып танылу максаты куелмаса.

Р.Зәйдулланың «Соңгы татар»ы икенче исем белән «Яңа татар пьесасы» конкурсына тәкъдим ителгән иде. Ул чакта жюри әгъзаләре М.Госманов, И.Ибраһимов, И.Хәйруллин һәм мин фәкыйрегез бу пьесаның фажига дәрәжәсендә булып житмәве, тарихи вакыйгаларның чишелешендә ханлык Сәетенең гаиләсендәге «тәртипсезлек» сәбәп итеп алынуы тәнкыйтьләнеп, ул конкурстан алынган иде. Китап вариантында автор күп үзгәрешләр керткән: фажига-трагедия таләпләренә жавап бирерлек сюжет корган, фәлсәфи өслүбен тапкан. Әмма Евразиядәге иң куәтле ханлык язмышы аның дини лидерының хатынының астыртын эшләренә кайтып кала. Ил-көндә тәртип салырга теләгән олуг Сәет үз өендә ни булганын белмәсен, имеш?.. Мин үзем дә бүген Кол Шәрифтән идол ясау ягында түгел. Әмма аны бу кадәр мескенлеккә төшерү белән дә килешә алмыйм. Әсәрдә Кол Шәрифнең сугыштагы каһарманлыгы да бик саран күрсәтелә. Бу хакта тарихи чыганаклар бар бит инде югыйсә. Әнә, Ф.Хужин исемнәрен атап үткән рәссамнарыбызның полотноларына бер карау да житә...

**З.Хәким:**

— Бу өч тарихи шәхес турында иң элек тарихчы галимнәр тарафыннан анык һәм тирән анлатулы документаль әсәрләр кирәк. Тарихчылар аларның кылган олы эшләрен дә, фажигаләрен дә, яхшы якларын да, яман өлешләрен дә мавыктырырлык итеп язсыннар иде. Шуларга таянып, яңа идеяләр дә туар, көчле әдәби әсәрләр дә ижат ителер. Мин дә кайбер каләмдәшләремне нахак сүз сөйләүдән сакланырга чакырыр идем, чөнки бу бик зур гөнаһ. Ә инде тарихи шәхесләрнең кайсысыннан уйдырма рәвештә нахакка тискәре образ ясау, кайберсен үзе теләгәнчә явыз итеп күрсәтү икеләтә гөнаһтыр. Әлбәттә, ижатчының гоманларга хакы бар, ләкин чама дигән нәрсәне онытмаска кирәк. Борынгы греклар дөньядагы барлык фажигаләрнең

сәбәбен чаманы белмәүдә күргәннәр. Уйлавымча, бу тарихка да кагыладыр — тарихны чамасыз бозсаң, киләчәген дә төзек булмаячак. Аннары шунысы да бар: тере кешене генә түгел, бу дөньядан киткәннәрне дә рәнҗетергә ярамый. Без бит әле бүгенге көнгә кадәр яшәгән дөньябызның аргы ягында нәрсә икәнне белмибез. Әгәр моннан күп гасырлар элек яшәгән кешеләр безне күзәтеп торса, язучы фантазиясе белән ямьсезләнеп күрсәтелгән тарихи шәхес алдында ничек акланырсың һәм ничекләр юынырсың?.. Син бит персонажың турында бер кешегә генә сөйләмисең, әсәрең белән аның образын бөтен дөньяга чыгарып селкисең. Тарих галимнәре мондый очракларда сүзсез калмасын иде — алга таба тарихи әсәрләр язучы кеше тарих океанында унга-сулга карап йөзсен һәм кирәк чакта тарихчылар белән киңәшләшсен өчен.

**Ф.Хуҗин:**

– Казан тәхетендә 13 хан утырган (кайберләре ике-өч мәртәбә). Бу исемлеккә Олуг Мөхәммәдне кертмим, аның Казанда булу-булмавы мәгълүм түгел. Әмма ханлыкның оешуында аның роле искиткеч зур. Сөембикә язмышы — фаҗигале. Шаһгали — бик катлаулы шәхес, бездә аны башлыча сатлыкҗан сыйфатында гына күрсәтеп килделәр. Бу, минемчә, бик үк дөрес түгел. Кол Шәриф, киресенчә, изгеләштерелгән. Әле безнең Мөхәммәд Әмин, Сафагәрәй кебек ханнарыбыз да булган. Ханлык чорының иң атаклы шәхесләреннән саналган Нурсолтан, нишләптер, язучылар игътибарыннан гел читтә кала бирә. Югыйсә бит ул, Нугай морзалары нәселеннән чыккан кыз, — Казан ханнары Хәлилнең, аның үлеменнән соң Ибраһимның, аннан соң Кырым ханы Миңлегәрәйнең хатыны, Ибраһимнан туган һәм хан тәхетен биләп торган Мөхәммәд Әмин һәм Абдуллатыйф ханнарның әнисе. Кырым, Казан ханлыклары белән Мәскәү дәүләте арасында дипломат вазифаларын үтәгән акыллы сәясәтче дә.

**И.Рәмиева:**



– Сезнең белән килешкән сурәттә, минем бер мөһим фактка игътибар итәсем килә: Казан ханлыгы чоры белән бәйле тарихи шәхесләр образларын гомумәдәби яссылыкта карау да әһәмияткә ия. Бу геройлар арасында иң популяры, әлбәттә, Сөембикә. XVI-XX гасырлар дәвамында, мәсәлән, татар әдипләреннән кала рус һәм төрек язучылары ана багышлап шактый әсәрләр иҗат итә. Кызганыч, Совет чорында СССРда яшәгән татар язучылары үзләрен борчыган милли тарих, татар дәүләтчелеге белән бәйле темаларга язу мөмкинлегеннән мәхрүм иде. Төркиядә яшәгән һәм иҗат иткән милләттәшләребез генә халкыбызның дәүләтчелеген кайтару мәсьәләсен Сөембикә ханбикә образына мөнәсәбәттә ачыктан-ачык көн тәртибенә куя алды.

Төрек жирлегендә Сөембикә турында милли рух белән сугарылган әсәрләрнең барлыкка килүе, бер яктан, диаспорада яшәүче татарлар арасында милли идеянең каннарына сеңүе, икенче яктан, 40-60 нчы еллар төрек әдәбиятының үзендә дә тарихи тематиканың бик актуальләшеп китүе белән аңлатылырга мөмкин.

Төркия жирлегендә иҗат ителгән Сөембикә ханбикә образы гомумтөрки тарихның бөек каһарманы булып формалаша. Аның мөкатдәс образы, татар халкының милли тарихындагы иң фаҗигале мизгелләр хатирәсе буларак, изге ана, милли азатлык өчен көрәш-тартыш символы рәвешен ала. Төрки халыклар өчен Сөембикә ханбикә шәхесе гомумтөрки бердәмлек идеяләрен үзендә гәүдәләндергән тирән символик мәгънәгә ия мәһабәт образ рәвешендә калкып чыга.

**И.Ибраһимов:**

*– Милли театрларыбызда лирик, проза әсәрләрен сәхнәләштерү тәҗрибәсе дә бар. Шул ук «Идегәй» һ.б., һ.б. Флүс Латыйфиның «Хыянәт» романы заманында бик зур резонанс тудырган иде. Нурихан Фәттах, Рабит Батулла, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Марат Әмирханов, Фәүзия Бәйрамова, Вахит Имамов әсәрләре... Аларны сәхнәләштерү, дөресрәге алардан файдалану, сәхнәдә милли каһарман образлары тудыру мөмкинме?*

**Г.Арсланов:**

– Аллага шөкер, бүгенге көнгә тарихи повесть-романнарыбыз шактый күп язылган. Аларны сәхнәгә күтәрү тәҗрибәсе дә бар. Бар, ләкин җитәрлек түгел. Сүз уңаеннан,

соңгы елларда сәхнәләштерелгән проза әсәрләренең иң уңышлылары итеп Г.Исхакый әсәрләре буенча куелган «Көз» (Уфа, «Нур» театры), «Курчак туе» (Г.Камал исемендәге театр), М.Галәү дилогиясе буенча эшләнгән «Мөһаҗирләр» (С.Өметбаев исемендәге Минзәлә театры) спектакльләрен атап була. Бу спектакльләрнең уңышында төп нигез — Ф.Бикчәнтаев, Р.Әюповларның актив режиссурасы. «Актив» сүзенә аерым акцент ясарга кирәк, чөнки бүгенге көндә проза әсәрен сайлап алу, аны тулы канлы сәхнә әсәре итеп эшләүне бары актив режиссура вәкилләре генә булдыра ала. Ә сорауда саналган язучыларның прозасы, әлбәттә, сәхнә әсәрләренең нигезе була ала. Театрларга җитәкчелек иткән режиссёрларның кызыксынуы, ныклы ихтыяры кирәк.

**И.Заһидуллин:**

— Әмма мондый әсәрләр язу яки сәхнәләштерү массачыл төс алырга тиеш түгел. Бүген, театрдан бигрәк, әлеге әсәрләр буенча сценарийлар язып, кинофильмнар төшерү кирәк. Хәтта мультфильмнар, комикслар кебек формалар да гаять нәтиҗәле.

**З.Хәким:**

— «Каһарманлык» эзләүдә, аларның образларын тудыруда да чаманы белергә кирәк, минемчә. Монда да бер чыганакта күрсәтелгәнчә генә фикерләргә ярамый. Тарихка кереп калган олы шәхесне идеальләштереп, хәтта әүлия сыйфатларын тагып күрсәтергә тырышуның да фәтвасы юктыр. Шәхес, нинди генә легендар булмасын, укучыга яки тамашачыга ул «гади кеше»гә хас яклары, ялгышулары, үз заманын аңлап бетермәве, хәтта холкының кайбер җанбиздергеч сыйфатлары белән дә кызыклы була ала. Тарихи шәхесләр арасында изге кешеләр дә булган, әмма алар турында дини китапларда инде күптән язылган.

**Ф.Хуҗин:**

— Флүс Латыйфиның «Хыянәт» романы нәфис фильмның сценариесенә дә, опера либреттосына да, драма әсәренә дә менә дигән нигез була ала. Вахит Имамовның «Утлы даласы»ннан нәфис фильм төшерергә, Кол Гали белән бәйле сюжетны аерып алып (әлбәттә, ул фантазиягә корылган!), мөстәкыйль сәхнә әсәре язарга мөмкин. Факил Сафинның «Саташып аткан таң» исемле роман-трилогиясе герое, тарихи шәхес Әхмәтсафа Дәүләтьяров, сәхнәгә атлыгып тора. Гомумән, кылган гамәлләре белән халкыбызда милли аң тәрбияләрлек, сәхнә герое булырга лаек каһарманнарыбыз күп безнең. Язучылар арасында талантлы яшьләребез дә бар. Тәвәккәлләп эшкә башларга гына кирәк.

**И.Ибраһимов:**

*— Һәм иң җитди сорау... Безгә алга таба нишләргә? Бу эшкә дәүләти, сәяси бурыч дип карап, дәүләт заказлары дәрәҗәсендә аерым әдипләребезгә мөрәҗәгать итәргәдер, бәлки. Әнә, мөрәҗәгать итмәсәк тә, рус язучысы Анатолий Егин «Үзбәк хан» романын язды, без тәрҗемә иттереп бастырдык бит әле... Милли каһарманнарыбыз турында язылган һәр әсәр, һәр тамаша бүгенге көнебезгә килеп тоташырга, бүгенге укучыны, тамашачыны уятырга тиештер бит?*

**Г.Арсланов:**

— Алга таба тарихи, тарихи-биографик әсәрләрнең аерым әһәмиятен аңлап, Мәдәният министрлыгы, Язучылар берлеге, театрларыбыз бер юнәлештә системалы эш алып барырга тиешләрдер. Системалы дидем, чөнки бу очракта гадәти компаниячелек тиешле нәтиҗәне бирә алмый. Эш төрле формада — төрле конкурслар, дәүләт заказлары, турыдан-туры аерым мөрәҗәгатьләр, фестивальләр формасында булырга мөмкин. Бары шул юнәлештә даими эш алып барылганда гына уңай нәтиҗәләр күтәп булачак.

**И.Заһидуллин:**

— Күчем хан, Гаяз Исхакый кебек каһарманнар татар язучыларын матур әсәрләр язарга рухландырмасلармы? Укучыны уңай мисаллар ярдәмендә тәрбияләү мөһим. Мондый шәхесләрнең үз гомерләрен милләт өчен көрәшкә багышлавы шундый мисал булып тора.

Безнең тарихта югалтулар күп. Бер үк вакытта ирешкән казанышларыбыз да күп. Минем фикеремчә, югалтулар турында гына түгел, бәлки, казанышлар турында язарга кирәк.



*Н.Исәнбәт. «Идегәй». Туктамыш хан роленда — Шәукәт Биктимеров, Җанбай роленда — Илдар Хәйруллин.*



*Н.Фәттах. «Кол Гали». Кол Гали роленда — Габдулла Шамуков.*



*М.Маликова. «Соңгы риваять». Сөембикә роленда — Гүзәл Гайнуллина, Фатыйма — Гөлназ Нәүмәтова.*



*Т.Миңнуллин. «Канкай углы Бәхтияр». Бәхтияр Канкаев роленда — Шәукәт Биктимеров, Әбүбәкер Теләчев роленда — Ринат Таҗетдин.*

**Ф.Хуҗин:**

– Күреп торабыз: соңгы елларда милли хәрәкәт сүлпәнләнде. Глобальләшү дәверендә милли проблемалар турында сүз алып бару актуальлелеген югалтты, диючеләр бар хәтта. Ялгыш фикер бу. Без, милләт буларак, үз йөзебезне югалтмаска тиешбез. Менә шуның өчен кирәк ул милли театрда милли тарих.

**И.Рәмиева:**

– Әлеге эшне җитди бер бурыч, максат итеп кую үзен аклый. Бу очракта безнең өчен якын, тугандаш төрки дөньядан — Төркия мисалында берничә сүз әйтеп китәсем килә. Бүгенге көндә анда дәүләтнең эчке һәм тышкы сәясәте Сәлҗүкләр һәм Госманлы империясе алып барган уңышлы сәясәтнең дәвамы итеп карала һәм бөек тарихи традицияләр һәм казанышларның дәвамы итеп кабул ителә. Моның шулай икәнлеге соңгы вакытларда узган тарих, аның каһарманнары белән кызыксынуның артуында да, мәктәпләрдә дә факультатив рәвештә госманлыча укытыла башлауда күзәтелә. Моңа дәлил итеп 2011-2014 елларда төшерелгән, 139 кисәктән торган «Бөек гасыр, дәвер, чор» дигән сериалны атарга мөмкин. 2013 елда бу сериал дөньяның 45 илендә күрсәтелгән, 210 миллион кеше караган атаклы фильм булып танылa, Америка, Россия, Украина, Балкан, Европа, гарәп илләрендә ул аеруча зур популярлык казана. Билгеле, сериалга карата тәнкыйть фикерләре дә әйтелде. Тарихчылар анда анахронизмнарның күплеге, сериалның тарихи чынбарлыктан шактый ерак торуы турында байтак яздылар. Ләкин шулай да сериалның мәйданга чыгуы Госманлы тарихы белән бәйле романнарның барлыкка килүенә юл ачты, укучыларны бу чор тарихы, аның каһарманнары белән кызыксынуга этәрде, хәтта үзенә күрә бер «бум» рәвешен алды.

Интернеттагы китап сата торган сайтларга кереп карасаң, анда төрек укучысына 250 гә якын тарихи роман тәкъдим ителүен чамаларга мөмкин. Аларның байтагы — чит телләрдән тәрҗемә ителгән романнар. Сүз уңаеннан шуны да искәртәсе килә: бу илдә тәрҗемә эшенә дәүләти күләмдә зур игътибар бирелә (югары уку йортларында тәрҗемәчеләр әзерләү эше алып барыла, дөньякүләм китап күргәзмәләре дә еш булып тора). Шулай ук төрек әдәбиятын чит илләрдә танытуны, таратуны күздә тотып, төрле илләрдә яшәүче төрекчәдән тәрҗемәчеләрне бергә очраштыруны максат итеп куйган, башка телләргә тәрҗемә итүнең төрле мәсьәләләрен яктырткан мастер-класслар да әледән-әле оештырыла. Тәрҗемәчелеккә бәйле бу эшләрнең барысы да дәүләт ярдәме белән алып барыла, әлбәттә.

Тарихи темага язылган әсәрләрне таратуда Төркиядә аерым шәхесләрнең һәм хәйрия оешмаларының өлеше зур. Әдәби журналлар, вакыф оешмалары, төрле җәмгыятьләр тарихи романнар буенча конкурслар игълан итә. Вакыф оешмалары бу юнәлештә зур эш башкара. Мәсәлән, күренекле әдибебез Гаяз Исхакыйның мирасын Ватаныбызга кайтаруда, халкыбызга җиткерүдә аның кызы профессор Сәгадәт Чагатай төзеп калдырган вакыф җәмгыяте зур роль уйнады һәм ул бүген дә яшәвен һәм нәтиҗәле эшләвен дәвам итә. Түләй Дуран ханым җитәкләгән бу вакыф оешмасы Г.Исхакый мирасын саклау, аны татар һәм башка төрки халыкларга җиткерү буенча зур эш алып бара, үзенең фәнни китапханәсеннән дә фәнни максатларда файдалану мөмкинлеген тудыра, башка төрки җөмһүриятләрдән килгән студентларга стипендияләр белән ярдәм итә.

**З.Хәким:**

– Чернышевскийның XIX гасырда «Нишләргә?» дип соравын бүген дә кабатлыйбыз. Бу мәңгелек сорау, XXI гасырда яшәсәк тә, XIX йөз психологиясе иярләре булып калганбыз. Тормыш юнәлешебезне алга киткән илләрдән алырга тырышабыз, сәяси системабызның нигезе һәм асылы исә феодальлек чорын хәтерләтә. Ә бит әдәбият-сәнгать тормыш укладыннан шытып чыга. Ни дисәң дә, мәдәният беренчел түгел. Милләтне дә, аның мәдәниятен дә яшәү рәвеше саклый. Мин шәхсән үземә кайчак шундый сораулар куям: язучы язган әсәрләргә, театрда барган тамашаларга буй җитмәс һәм чиксез таләпләр куюның кирәге юктыр бәлки? Әдәби әсәрләр, спектакльләр белән генә кешенең үзанын, дөньяга мөнәсәбәтен үзгәртү мөмкинме соң? Укучы, тамашачы үзенең күңеленә авазадаш булган әсәрләргә тартыла. Күп еллар дәвамында гаиләдә, балалар бакчасында, мәктәптә, тирә-як

мохиттә тәрбияләнгән кешене ике сәгать эчендә генә спектакль йогынтысы белән үзгәртеп буламы икән?

Һәм капма-каршылыклы уйланулардан соң бер фикергә киләм — менә без язучылар, һичшиксез, омтылырга тиеш! Ничек кенә булмасын, заман нинди генә шартларда яшәтмәсен, без үзебезнең әсәрләребезне милләт язмышына багышларга һәм аларны югары дәрәҗәгә менгерергә бурычлыбыз. Язучының коралы — каләм. Без акылыбызны, сәләтебезне, өмет-хыялларыбызны шул корал ярдәмендә генә гамәлгә ашыра алабыз. Чын язучылар, чын драматурглар бер заманда да күп булмаганнар, аларны бармак белән генә санарлык. Әмма шул бөек каләм ияләренең әсәрләре галәмәт тәэссоратка ия.

Тарихка, халыкка, милли каһарманнарга дәүләт масштабында тарихи чынбарлыкка нигезләнгән сәяси караш булган сурәттә генә әдәбият-сәнгатьтә зур казанышларга ирешергә мөмкин дигән фикер белән бигүк килешәсе килми. Дәүләт заказлары белән әдипләргә мөрәҗәгать итү дә «кампанейщина»га әйләнә күрмәсен. Мәсәлән, милли каһарман образын иҗат итү язучы өчен үзмаксат булырга тиеш түгел ул. Халык язмышы, бүгенгесе, аның киләчәге әсәрдә алга сөрелсен өчен, язучы үзенең күңел ихтыяҗы белән иҗат итәргә тиеш, минемчә. Әйе, тарих — үткән чорларда, бүгенге заманда һәм киләчәктә яшәячәк шәхесләр союзы. Бүген телевидение белән интернет халыкка, бигрәк тә яшь буынга, галәмәт көч белән тәэсир итә һәм дә тәэссораты белән (эчтәлек, сыйфат турында түгел сүз) шундый ук куәткә ия булган әсәрләр кирәк. Укучыга, тамашачыга әсәрләрне тәкъдим итүнең яңа төрле ысулларын, заманча формаларын табу зарур.

Сүз ахырында шуны әйтәсе килә: инсаният дөньясында «яшәеш иерархиясе» дигән төшенчә бар. Үз милләтенңе өстән сикереп үтеп, планета күләмендәге иҗатчы булу мисалларын мин белмим. Гомер — иң беренче чиратта, грек язучысы, Гёте — немецныкы, Сервантес — испанныкы, Шекспир — инглиз драматургы, Мольер — французныкы, Достоевский — рус язучысы. Шуннан соң гына алар дөньякүләм масштабтагы даһилар. Бу шәхесләр Җир шарында яшәүче җиде миллиард халыкның «милке» булсалар да, алар башта үз милләтенеке. Шекспирны барыбер инглиз драматургы дияچәкләр. Моны татар язучылары да, режиссёрлары да беркайчан истән чыгармасыннар иде. Милләт — нинди дер социологик категория түгел. Милләт — тарихи категория, һәм ул бүген яшәүче буыннан гына тормый, милләт — барлык буыннарның җәмгысе. «Сәламәт» милләтнең рухы һәрвакыт бүгенге заманның үткән заманнарны юк итәргә омтылуына каршы тора. Көчле милләтнең рухы хәтта киләчәк заман тарафыннан да тарихка кизәнү булмасын тәэмин итә ала. Безнең заманда исә бу аеруча мөһим. Милләтебездән башка, нинди генә сәләткә ия булсак та, дан-шөһрәткә ирешсәк тә, без беркем түгел!

**И.Ибраһимов:**

*— Хөрмәтле галимнәребез, каләмдәшләр! Бүгенге «түгәрәк өстәл»дә катнашуыгыз, фикерләрегез белән ачыктан-ачык уртаклашканыгыз өчен сезгә зур рәхмәт. Әңгәмәбезне олы әдәбиятыбызның бер генә тармагын алып, бер «тар» темасы буенча алып баруыбыз да никадәрле җитди сораулар, чишелсе мәсьәләләрне өскә калкытып чыгарды. Яшәешебездә, фәндә, иҗатта, сәнгатьтә милләтебезне саклау, үстерү, Фаяз әфәнде кат-кат әйткәнчә, һәрчак актуаль һәм мондый сөйләшүләр даими кирәк. Бүгенге «түгәрәк өстәл»не тагы да журнал укучыларыбыз, язучылар, мөгаллимнәр, режиссёрлар, рәссамнар катнашында дәвам итәсебез килә. Хөрмәтле әдәбият сөючеләр, сезнең фикерләрегезне, кулъязмаларыгызны көтеп калабыз. Аларның һәркайсына журналыбыз битләрендә урын табылыр дип ышандырабыз. Бердәнбер теләк һәм таләп: ул кемнеңдер шәхесен түбәнсетү, нахак яла ягу гына булмасын.*

*Шулай ук алдагы саннарда әдәбиятыбыз, сәнгатебез, тарихыбыз, иҗтимагый-сәяси тормышыбызга кагылышлы нинди темалар буенча «түгәрәк өстәл»ләр, кайсы шәхесләр белән әңгәмәләр үткәрү турында теләкләрегез, тәкъдимнәрегезне көтеп калабыз.*

# «БАР ГАЕБЕҢ ИХЛАСЛЫК БУЛГАН, ШАГЫЙРЬ!»: ЯКИ МУЛЛА МӘХӘББӘТЕ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

Шагыйрь Габделҗаббар Кандалыйның исеме, иҗатының бер өлеше татар җәмәгатьчелегенә күптән мәгълүм. Шул таныш материалдан чыгып та, шагыйрьнең язу осталыгын, аның татар әдәбияты үсешенә керткән бәхәссез яналыгын танымаган кеше юктыр. Бу яналык бигрәк тә шигырь поэтикасы, мәхәббәт лирикасы өлкәсенә карый. Кандалый шигърияте нигездә авыл мулласының крестьян кызына булган җавапсыз мәхәббәтен тасвирлый.

«Ни өчен җавапсыз?» дигән сорау туа. Безгә мәгълүм әсәрләрдән чыгып әйтергә мөмкин: ул вакытта дин әһелләренең авылларда вәкаләтләре чиксез зур булган. XIX гасыр прозаигы Закир Һадиның (1863-1932) «Бәхетле кыз»ында бу мәсьәлә бигрәк тә ачык чагылган [Һади: 1957, 22-63]. Бу чорда күп кенә ата-ана үз кызын абыстай ролендә күрергә теләгән. Еш кына кызның теләге белән хисаплашмаганнар да.

Мәсьәләгә сыйнфыйлык позициясеннән якын килик. Гадәттә, дин әһелләре гаилә кора торган парны үз даирәсеннән сайлаган. Тик җиде буын нәселе муллалар булган Кандалыйга гына бу тәртип ярамаган. Аңа крестьян кызы кирәк булган. «Ни өчен?» дигән сорау туа.

Авыл мулласына ул чорда мәхәлләдә мулла, хәлфә, полиция, загс, нотариус, судья, прокурор хезмәтләре йөкләнгән. Кандалый әле шулар өстенә шагыйрь дә. Әлеге һөнәр ияләренә куелган таләпләрнең барысын да үтәп бетерә алган шәхес кенә түгел, әдәби геройлар да сирәк очрый. Билгеле, Гариф Ахуновның Кандалыйдан соң бер гасыр үткәч тудырган Габбас мулласын шундый үрнәкнең берсе итеп карап булыр. Әмма ул да фаҗига белән тәмамлана.

Димәк, Кандалыйның шагыйрь һәм мулла буларак беренче фаҗигасенең сәбәбе — татар гаиләсе традицияләрен үз мәнфәгатьләре файдасына бозуы. Дөрес, З.Һадиның «Җиһанша хәзрәт»е (1908), дини даирәдә кабул ителгән язылмаган кагыйдәдән чыгып, хатыннарының составын «төрләндерә»: бер хатыны мулла кызы булса, икенчесенә бай кызын ала [Һади: 1957, 140-186]. Кандалый да «бу тәртип»тән читтә калмагандыр дип фаразлыйк.

Җәмәгатьчелек Кандалыйны нигездә «Мулла белән абыстай» шигыре, «Сәхипҗамалга» поэмасы буенча белә [Кандалый: 1988, 388-428]. Хат стилендә язылган бу поэма лирик геройның мәгъшукасына ялваруы, яшьлегенә соклануы, кызның алдагы тормышында бердәнбер лаеклы кандидат-ир булачагы, хыялдагы планының барып чыккан очракта әкияттәгедәй киләчәге турында сөйләү белән үрелеп бара. Әмма кыз, күрәсең, күктәге торнага түгел, кулдагы күгәрченгә күбрәк ышанган булса кирәк. Кандалыйның поэмада куркыту, өркетү, крестьян ирләрен соңгы сүзләр белән хурлавын, кыскасы, шантаж юлына басуын башкача аңлатып булмый.

Кандалыйның әлеге гамәлләрен акларга да мөмкин. Бу очракта Закир Һадиның 1904 елда язылган «Бәхетле кыз» хикәясеннән бер өзек китерү кулай булыр. Хикәянең төп герое иске карашлы авыл мулласы — Ибәт абызагай. Ул алдау юлы белән, яучы аша, җитеш, бай тормышлы гаиләдән укыган, белемле, әхлаклы Хәдичә исемле кызны хатынлыкка ала. Аның хатын-кызга карашы авылның башка ирләренекеннән аерылмый. *«Бу авыл халкы хатыннарны ат, ишәк кеби хезмәт өчен яратылмыш бер хайван дип белә иде»* [Һади: 25]. Менә авыл мулласының үз фикере нинди: *«Ибәт абызагайның игътикадында (ышануында) хатыннар кәнизәк кебек ихтыярсыз (ирексез) затлар: ирләр аларны никадәр җәберләсә дә, аны җәбердән*

*санамый иде. Бәгъзе вакытларда хатыннар, ирләре бик җәбер кыйлгач, ирләренә нәсыйхәт кыйлмас микән дип, Ибәт абызагайга баралар иде. Ибәт абызагай ирләрен чакырып: «Хатыннарыгызның тезгенен каты тотыгыз! Бик сикермәсеннәр!» — дип, орышып җибәрә иде* [Һади: 24]. Кандалый үлгәннән соң, кырык еллап вакыт үткәч язылган фактлар белән танышкач, шагыйрь үз чорын алдан яшәгән, күпкә алга китеп күргән дигән фикер туа. Ярты гасыр тирәсе алданрак бару сәбәпле, Кандалый үз яшьтәшләре тарафыннан һәм үзе яшәгән даирәдә хуплау тапмагандыр.

XIX гасыр әдәбияты — ул мәгърифәтчелек әдәбияты [Гайнуллин: 1979]. Бу чор әдәбияты — дидактик әдәбият. Ул — балаларны гына түгел, өлкәннәрне дә ислам әдәбияты кануннары буенча яшәргә чакыра торган әдәбият. Мәгърифәтчеләр фикеренчә, бала ата-анасы сүзеннән чыгарга тиеш түгел, алар кушканны үтәргә, тыңларга, алар өйрәткәнчә яшәргә тиеш. Билгеле, мәгърифәтчеләр ата-ананың үзенә дә зур таләпләр куйган: әдәпле, белемле, һөнәрле, димәк, житешле гаилә булырга һәм булдырырга. Мәгърифәтчелек әдәбияты баланың мөстәкыйльлеген дә яклап чыккан. Шул ук З.Һадиның «Мәгъсум»ен (1906) искә алу да житә. Аны әнисе Хәят абыстай уникe яшендә авылларыннан шактый ерак булган кадими мәдрәсәгә укырга озата. Мәгъсум, бер дә барасы килмәсә дә, әтисе васыяте, әнисе теләге буенча үзен егерме яшькә дә житмичә кабергә китерәчәк мәдрәсәгә китеп бара.

Ә менә Кандалый кызларны ата-ана сүзен тыңлау тиеш дигән традицияне бозарга чакыра, ягъни, ата-ана сүзенә каршы барып, үзең теләгән кешегә чыгарга. Шигырьләрдән аңлашылганча, бу «үзең теләгән кеше» күбесенчә Кандалыйның үзенә кайтып кала. Онытмыйк, аның кулында шактый зур власть. Ул үгет-нәсихәтсез генә дә үзе теләгәнен кулына төшерә алган булыр иде. Шулай итеп, лирик геройның һәр кылган гамәленә ике яклап бәя бирергә була. М.Госманов юкка гына Кандалыйны ике кеше итеп карамыйдыр. Берсе — аның шагыйрь, икенчесе — дин әһеле [Кандалый: 1988].

Тарихтан билгеле, Кандалыйның аш мәжлесләрендә ачыктан-ачык хуҗа кызларына карата «әдәпсез» шигырьләр чыгаруы, үзен яшермичә азгын мулла кебек тотуы авыл халкының ачуын чыгара, ул берара муллалыгын югалтып та тора, ике еллап төрмәдә дә утырып чыга. Сәбәбен хәтта М.Госманов та әйтми. Бу очракта рухани сыйныфка куелган таләпләр, регламент кагыйдәләре үтәлмәү, билгеле бер сыйныфка куелган тәртипләрнең сакланмавы сәбәп булгандыр, дигән нәтиҗәгә киленә.

Билгеле, Кандалыйның шигырьләре бик халыкчан яңгырашлы, эмоциональ характерлы, кыскасы, җырлап тора торган. Ул чын халык шагыйре. Шул сәбәпле Кандалый халык тарафыннан яратып кабул ителгән. Кандалый әсәрләрендә күтәрелгән проблемаларның халыкчан булуы бәетләрдә дә урын ала. Мисал өчен «Әткәй бирде чи наданга» һәм «Наданга бирелгән кыз бәете»нә игътибар итик [Бәетләр: 2001, 179, 180].

*Алтын микән, көмеш микән бишмәтемнең баулары,*
*Надан ярның кочагында сызыла йөрәк майлары.*

*Наданнарның бармаклары сазда ускән тал кебек,*
*Галимнәрнең һәрбер сүзе шикәр белән бал кебек.*

Бәеттә үзе яраткан Бәхтияр исемле шәкерткә бара алмаган кызның газаплы тормышы турында сөйләнелә. Шулай ук аның үз әтисен каргавы да бәеттә урын алган. Бу бәетнең 1920 елда Рязань өлкәсе Вәрәкә авылында язып алынуы күрсәтелгән. Икенче бәеттә галимә кызның көчләп надан иргә бирелүе турында әйтелә. Бу бәет тә каргау сүзе белән тәмамлана, ләкин бу юлы каргыш ячыга юдырыла. Бәеттән аңлашылганча, белемле кеше тормыштагы бар проблеманы хәл итә ала. Киресенчә булганда, кызга эт тормышы көтелә. Әле алай гына да түгел:

*Зифа буем үсеп җиткәч, әткәй бирде наданга,*
*Надан егетләр саналыр шайтаннан да яманга.*

*Надан ятса йокыга, каткан тунын ябыныр,*
*Йокысыннан уятсаң, бусагага абыныр.*

Бу бәет 1900 елда чыгарылган дип санала. Димәк, Кандалый үлеп, 40 ел вакыт үткәч тә проблемалар үзгәрмәгән дигән нәтиҗәгә кабаттан киләбез.

XIX гасырда укый-яза белгән кешеләрнең «галим» диеп йөртелүе билгеле. Кандалыйның мәгъшукалары да хәреф таный белгәнгә охшап тора. Шагыйрь алар белән хат телендә сөйләшә, җавап та көтеп яши. Эпистоляр жанрга хас булганча, лирик герой үз хисләрен ачыктан-ачык яза, яшерми, хәтта элементар әдәп саклауны да кирәк тапмый.

Бер күрүдә һәм еш гашыйк булучан, дәртле Кандалый һәртөрле көндәшлекне кабул итмәгән дип уйларга нигез бар. Ул чорда авылда муллалар күп була алмаган, димәк, көндәшләр крестьян арасыннан гына табылган. Кандалыйның көндәшлекне кабул итә алмаганлыгы шигырьләрендә ярылып ята. Шуның өстенә әле ул «кара мажик» көндәшне генә түгел, бай көндәшне дә кабул итми. Дөрес, байга ул факт буларак кына карый, һәрхәлдә тупас зәһәрен яудырмый.

Бу дөньядан киткәненә 155 ел булган Г.Кандалый иҗаты белән бүген дә кызыксыну кимеми. Шагыйрьләр аңа тулаем уңай карашын белдерә, мәхәббәт лирикасын үзенә үрнәк өлге итеп ала.

XIX гасырда яшәп иҗат иткән татар мәгърифәтчеләренең XX йөз ахыры — XXI гасыр башы әдәбият тарихын язган галимнәргә, дин эшлеклеләренә, татар язучыларына да бернинди дәгъвасы була алмас. Бүген дә язучылар еш кына XIX гасыр әдәбиятына, бу гасырның күренекле шәхесләренә, алар калдырган хезмәтләргә мөрәҗәгать итеп яши.

Күренекле сатирик шагыйрь Гамил Афзал, XIX гасырда туган язучыларга багышлап, унлап шигырьне туплаган аерым бер цикл тудырды [Афзал: 2004, 189]. Шуларның берсе Г.Кандалыйга тәгаенләнә. Шигырь, Кандалый үлеп, йөз ел үткәч, Хатип Госман тарафыннан чыгарылган шигырьләр китабы турында [Кандалый: 1960].

*Шагыйрь юлы — кометалар юлы,*
*Ялтырый да, көмеш юл ярып,*
*Йөз ел буе әллә кайда йөри,*
*Галактикаларда югалып.*

*Шагыйрьләр дә форсат көтеп ята,*
*Җыры, эзе калган бу җиргә,*
*Онытылып беткәч тагын кайта,*
*Бер ялтырап, балкып йөрергә.*

Ә менә XX гасырның фәнни җәмәгатьчелектә дә, язучылар тарафыннан да мәхәббәт шагыйре буларак танылган халык шагыйре Рәдиф Гаташ Кандалыйга газәл багышлый [Гаташ: 2009, 52]. Газәлнең эчтәлегенә Кандалыйның хатлары, мәхәббәт лирикасы, мәңге гашыйк шагыйрьнең күңел ярасы, аңа каршы фикерләр, бүгенге җәмәгатьчелекнең аны ничек кабул итүе — барысы, барысы кереп бетә. Мисал өчен газәлнең үзенә мөрәҗәгать итик:

*Пакь яшьлегең саклый алса ялгыштан,*
*Сакласын шагыйрь яшеннән — каргыштан.*

*Гомереңә җитәр төшсә рәнҗеше –*
*Язмышыңда эз булыр, тап рәвешле...*

*Чөнки ихлас шагыйрь җаныннан аһлар –*
*Тәңресенә, шиксез, ирешер хатлар!*

*Шундый дога Кандалый хәзрәт кылды:*
*Ярга ялварганы — чын каргыш булды.*

*Гыйбрәт өчен калдырды яманатын!*
*...Юк, шагыйрьләр, фаш итмәгез яр атын.*

*Бары сезне яклый-аклый гасырлар!*
*...Сөймәсәләр, гаепләме матурлар?!*

*Сөйсә, алар — чын «фәрештә валчыгы»,*
*«Гөнаһлы» ярның да сез бит гашыйгы...*

*Аһ, саклый күр күңелеңне шул каргыштан,*
*Мәңгелек үзе таш атар язмыштан!*

Билгеле, Гаташ шигыре дидактика түгел инде. Аның лирик герое Кандалый кебек үз хисләрен мәҗбүриләп такмый. Бу газәлендә аның гашыйк кешегә психологик яктан якын килүе, мәкъшукны тирәнтен аңлавы күренә.

Кандалый иҗаты Гаташны робагый язарга да рухландыра. Әдәбиятны, аның тарихын, теориясен тирән белгән шагыйрь мәхәббәткә дә фәлсәфи планда якын килә. Шул ук вакытта аның лирик герое җавапсыз мәхәббәттән курка да булса кирәк. Бер робагые шул турыда сөйли:

*Сәхипҗамал — Кандалый даны*

*Сәхипҗамал абыстайның оныгы*
*Түгелме син? Пәрәү кызы туруны?*
*Рухи бабам, шиксез, Кандалый хәзрәт,*
*Илгә фаш булса да сөю — урынлы! —*

дип, шагыйрь тантана итә. Р.Гаташ заман татар шагыйрьләре арасында Кандалый кебек мәхәббәт шигырь-хатларын иң күп язучы булып танылды. Аның хатлары төгәл классик формаларга утыртылган, газәл, робагый, ирекле шигырь, традицион формалылары да бар. Шагыйрь үзе үк аларның адресатын да билгели.

*Ялкын тулы бу хатлар кемгә, дисәң,*
*Мирас алар дөньяга безнең хистән.*

Кандалыйның мәхәббәт хатлары зур шагыйрьләрдә һәрвакыт соклану уяткан. 1997 елда Илдар Юзеев шундый бер шигыренең исемен «Киләчәк кызына хат» дип исемли [Юзеев: 2002, 1 т., 234]. Шигырьдәге төп мотив — Кандалый кебек тик бер хат язу. Шигырьдә лирик геройның шикләнүләре дә урын ала. XIX гасыр кызлары Кандалыйның хатта язылган хисләрен кабул итмәгәч, XXI гасыр кызлары хатның үзен укып та мәшәкатьләнмәс дигән фаразын үткәрә.

*Килеп җитте Кандалыйның*
*Сөю хатлары.*
*Гашыйк кызлар шигырьләрен*
*Сөеп ятлады.*
*Күп кызларны сөю гөнаһ*
*Саналмый кебек.*
*Мин дә бик күп гашыйк булдым*
*Кандалый кебек.*
*«Җырың яшәр!» — диеп күңел*
*Алдалый кебек.*
*Хыялым — тик бер хат язу*
*Кандалый кебек.*

*Ышанам һәм өмет баглыйм*
*Шигырь-җырларга.*
*Хатым китсен сез яшәгән*
*Ерак елларга.*
*Сөю яшәр, хис тә яшәр,*
*Сизәм: алар нык!*
*Тик калырмы татар кызы*
*Мине аңларлык?*
*Җаныгызда бу хатыма*
*Табылса урын,*
*Сөенечтән сезне кочып*
*Еласын җырым...*

Бүген хәтта сәясәт һәм икътисад та XIX гасыр мәгърифәтчеләре әйтеп калдырган фикерләргә әйләнеп кайта башлады кебек. Мисал өчен, 2019 елда Казанда булачак эшче һөнәрләре чемпионатын гына алу да җитәр. Мәшһүр Парижлар белән узышып, Казан бу ярышны үзендә үткәрү хокукын яулап алды.

Әле XX гасырның 90 нчы елларында гына урта мәктәпне тәмамлаган һәр яшь кешенең югары белемгә ия булуы хуплана иде. Мәктәпләр югары уку йортына керүнең 100%лы күрсәткече белән мактана килде. Йөз үк булмаса да, мона ирешелде. Нәтиҗәдә, эш белән мәшгульлек үзәкләре югары белемле яшь белгечләр белән тулды. Шул ук вакытта эшче һөнәрләргә вакансияләр артты, дөресрәге, кул белән тотып эшли торган кеше калмады.

Әмма мәктәпләргә ЕГЭ формасын кертү, аның бары тик рус телендә генә булуы югары белем алуның массачыл тәртибен киметте. Бүгенге көндә төп мәктәпне тәмамлаган яшьләрнең яртысы, хәтта күбрәге дә һөнәр бирә торган уку йортларына бара башлады. Киләчәктә бу күрсәткечнең тагын артуы көтелә.

Болар барысы бүгенге көн өчен мәгариф системасының яңалыгы буларак кабул ителсә дә, XIX гасыр әдәбиятында яңалык түгел. Бу чорның мәгърифәтче язучылары прозада заман героеннан, беренче чиратта, белемле һәм әхлаклы булу, белем-тәрбияле тигез гаиләдә үсү, камил сәламәтлеккә ирешеп, тормыш итәр өчен практик яктан файдасы тиярлек һөнәрле булу, халык һәм җәмгать интересларын шәхси мәнфәгатьләрдән өстен куюу кебек сыйфатларны таләп иткән.

XIX йөз белән соклану хисе Флёра Тарханова шигырьләренә дә хас [Тарханова:

2005]. Аның бер шигыре «Унтугызынчы йөз кешесемен» дип атала. Шигырьдә бу чор идеаллаштырыла, итагатьле, матур сүзләр генә сөйләнгән чор итеп күрсәтелә, тел сәясәте XXI гасыр белән чагыштырыла, бүген «ана сөте белән керми калгангадыр, бик күпләрнең сөйләм, тел ватык» дигән факт китерелә. Шигырь лирик геройның XIX гасырга кайтырга теләвен әйтеп тәмамлана.

*Унтугызынчы йөз кешесемен –*
*Яшәр идем тик шул гасырда.*
*Хөсетле һәм чирле яңа чорга*
*Куркам хәтта аяк басарга, –*

дип белдерә шагыйрә.

XIX гасыр татар әдәбияты өчен игенче һөнәре аерым әһәмияткә ия. Татар крестьянының авыр хезмәте, төп геройның тормыш итү кәсебенә әверелеп, әдәби әсәрләрдә урын ала. Бу чор муллалык дәрәҗәсенең нәселдән нәселгә күчеп баруы белән аерылып тора. Мәгърифәтче әдипләр арасында атасы сәүдәгәр яки башка һөнәр иясе булганнар бик аз. Игенченең кешелекне туендыручы булганлыгы билгеле. Әмма авылда яшәп гомер иткән Кандалыйның игенче һөнәренә, хезмәтенә кимсетеп каравы мәгълүм. 17-18 яшендә үк «Иген икмәк — михнәт чикмәк», дигәндә ул, бәхәссез, хаклы. Әмма шул игенченең хезмәтеннән бер генә дә позитив чаткы күрмәвен ничек аңлатырга да белмәссең. Аның өчен игенче — «надан бер кара мажик», Кандалый аны сурәтләгәндә кара буяуларны бер дә кызганмый, күз алдына хәтта кеше түгел, тупас, пычрак табигый инстинктлары белән ниндидер исемсез хайван килеп баса. Шунысы гаҗәп: ул «хайван» Кандалыйның өстәлендә тәгам булсын өчен тырыша.

Әлеге мәсьәләдә М.Госманов фикерләренә мөрәҗәгать итик. Ул «гадәти дөнья интересларына, хуҗалык эшләренә җирәнеп карау — «фани дөнья»дан йөз чөерү — тәсауыф тәгълиматының төп идеяләренең берсе», дип язып чыга. Бу идеянең мулла Кандалыйда нәселдән нәселгә күчеп баруын гадәти күренеш дип саный. Гел акыл эше белән генә шөгыльләнү, китап уку эше генә хөрмәткә лаек, дигән тәрбиянең Кандалыйга ана сөте белән кергән булуын, аның башкача уйлый алмавын, икенче төрле әйткәндә, эгоистлыгын шуның белән анлата. М.Госманов Кандалыйның сәер гадәтләрен табигый талантка бәйли, аның укыган вакытта ук калкып чыккан акыл өстенлеген гадәти хәл итеп карый. Бу мәсьәләдә Кандалыйның беренче булмавын искәртә, чын татар шагыйре булган (Көнчыгыш түгел дип аңларга!) Г.Утыз-Имәнинең дә берничә порнографик әсәре булуын әйтә [Кандалый: 1988, 17].

XX гасыр ахырында Кандалый кебек туган җире Ульяновск җирлеге булган шагыйрь Ренат Харис «Өч үбешү» исемле үзе үк эротик дип атаган поэма язды [Харисов: 2006, 184]. Поэманың Кандалый иҗаты белән тыгыз бәйләнеше бар. Өч бүлектән гыйбарәт булган поэмага «Сәхипҗамалга»дан өч цитата куелган. Аларның эчтәлеген нәзакәтле дип атап булмас иде. Билгеле, халык шагыйре поэмада порнография дәрәҗәсенә төшми, физиология мәсьәләсен әдәби образлыкка күчерә белә, ислам дине кагыйдәләреннән чыкмый, гаилә иминлегенә кагылмыйча гына нәсел калдыруга килеп чыга, һәм шунын белән лирик персонажга карата соклану хисләре тудыруга ирешә.

Ренат Харисның Кандалый белән мавыгуын шагыйрь Роберт Миннуллин «эләктереп ала» һәм үзенең «Ренат Харис шигырь укый» исемле пародиясен багышлый [Миннуллин: 2007, 53]. Пародиядә Р.Харисның эротик поэманы каләмдәшләренә житкерү вакыты турында сөйләнелә. Шагыйрь дәртләнеп укый, фикердәшләре бик теләп тыңлый. Гомумән, шигырьнең тынлаучыга тәэсир итү көче турында җиткерелә.

*Укыганда тамагын да*
*Кырып-кырып алгалый...*
*Ренат Харис шигырь укый.*
*Укыганы — Кандалый.*

*Иң татлы урыннарында*
*Юри туктап алгалый.*
*Бу — бөтенләй башка Харис,*
*Бу — әр-яңа Кандалый.*

Соңыннан «Чыннан да бөек икән шул Габделҗаббар Кандалый!» дигән нәтиҗә ясала.

Туфан Миңнуллинның «Шагыйрьнең җанында, эчендә һәрвакыт яра булырга тиеш. Ул һәрвакыт авыртып торырга тиеш. Шул чагында гына ул әйбәт шагыйрь була ала», дигән сүзләре билгеле [Миңнуллин, 2015, 184]. Кандалыйны да Сәхипҗамалга булган җавапсыз мәхәббәт ярасы гомер буе бимазалап торган булса кирәк. М.Госманов фикеренчә, Сәхипҗамалга юнәлтелгән җырлары, еллар үткәч үзгәртелеп, Фәрхи исеменә юнәлтелә. Фәрхигә гашыйк булганнан соң, аның иң матур шигырьләрен язганы билгеле. Бу юлы теләгенә дә ирешә ул, өйләнә. Тик ахырдан барыбер аерыла. Аннан соң Хәлимәгә өйләнеп карый, әмма инде дәртле шигырьләре язылмый башлый. Безгә нәкъ менә шул Хәлимәнең Кандалый мирасын таратканы билгеле була.

Кандалыйның безгә килеп җиткән мирасы да кызыксынып укыла, диссертацияләр языла, башка шагыйрьләрнең иҗатларында телгә алына, хәтта аңа ияреп язулар да очрый. Бу инде теманың дәвамлы, иҗатның кызыклы булуы турында сөйли. Сүзебезне заман мәхәббәт шагыйре фикере белән тәмамлыйк:

*Бар гаебең ихласлык булган, шагыйрь!*
*Аңлаган җирдә сине кайсы әмир?!.*
*Кыз урлаган ирне дә аклаган мир, –*
*Без дә шул заттан, хакимнәр, белегез!*
*Мәхәббәт шагыйрен таный белегез! –*
*Сәер җаннарны танып баш иегез.*
*Мәхәббәт шагыйрен яклый белегез!*

## Әдәбият

1. Афзал Г. Сайланма әсәрләр: 3 томда. 2 том: юмор һәм сатира, лирика, публицистика. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. — 335 б.
2. Гаташ Г.К. Сайланма әсәрләр: 3 томда / Кереш сүз авт. Х.Миңнегулов, Р.Зәйдулла, Р.Ганиева. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2009.
3. Кандалый Г. Шигырьләр / Төз.Х.Госман. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1960. — 188 б.
4. Кандалый Г. Шигырьләр һәм поэмалар. Төз., текст һәм иск. хәз., кереш сүз авт. М.Госманов. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1988. — 558 б.
5. Миңнуллин Р.М. Сайланма әсәрләр: 7 томда. 2 том: шигырьләр, җырлар, эпиграммалар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2007. — 591 б.
6. Миңнуллин Р.М. Яра // Казан утлары, 2015. — №7.
7. Тарханова Ф.Г. Яшьлек эзем калган сукмаклар: шигырьләр, җырлар, поэмалар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. — 223 б.
8. Татар мәгърифәтчелек әдәбияты / Төз. М.Гайнуллин. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1979.
9. Татар эпосы. Бәетләр / Ф.Ахметова-Урманче. — Казан: Раннур, 2001. — 512 б.
10. Харисов Р.М. Сайланма әсәрләр: 7 томда. 4 том: поэмалар / Төз. һәм кереш сүз авт. Ф.Ф.Хәсәнова. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. — 367 б.
11. Һади З. Сайланма әсәрләр. — Казан: Таткнигоиздат, 1957.
12. Юзеев И. Сайланма әсәрләр: 5 томда. 1 т. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. — 383 б.

**Фәридә ХӘСӘНОВА,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г.Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм*
*сәнгать институтының*
*Әдәбият белеме бүлеге мөдире*

# БЕР КИТАП ТУДЫРГАН КҮП УЙЛАР

Мамадышта яшәп иҗат итүче шагыйрь һәм прозаик Рафаил Газизовны бүгенге көндә актив язучы һәм язганнарын вакытында китап итеп чыгара алучы аз санлы әдипләрнең берсе, дияргә буладыр. Аның «Тәрәзәләр» исемле китабына *(Татарстан китап нәшрияты, 2014)* кергән «Ак болыт» бәянында Кече Кирмән авылының сугыштагы югалтулары телгә алына. «Фашистларга каршы сугышта шәһит киткән 142 ир-ат, тылда ачка үлгән 216 авылдаш» — менә никадәр икән сугыш афәтенең гади бер авылдан алып киткән корбаннары! Бу саннарга кемнәрдер ышанмас та, әмма шул чорны үзе кичкән буын өчен ышанмаслык берни дә юк монда. Авылда ачтан үлүчеләрнең сугыш кырында шәһит киткәннәрдән күбрәк булуы да шаккатырмый безне. Исән калган балаларның ничек җан саклаганын шул балалар үзләре дә бичара әниләре генә белгәндер. Тагын ... гамьле язучы белә икән менә. Үсмер Саяфның эне-сеңелен, аларның «кояш нурында үтә күренә торган нәни бармаклары»н әнә ничек табигый сурәтли ул. Боларның һәммәсенә фашистлар һәм «ата фашист» Гитлер гына гаепле булмаганлыгын да беләбез инде без. Кече Кирмән мәктәбенең география укытучысы, бер гаепсез юк ителгән мулла улы, әле кайчан гына взвод командиры булган Мәхмүт тә үз взводында рядовой булып сугышкан полковникның сүзләрен яхшы хәтерли. Икәүдән-икәү генә калгач ул:

— Мин курыкмыйм, югалтасын югалттым, гаиләмне бетерделәр, үләсемне беләм, ләкин сиңа әйтеп үләм — барысына да халыклар атасы Сталин гаепле, шул исәптән синең әтиеңне үтерүдә дә, — дигән иде. Барысына да, шул җөмләдән, бик күп ил җитәкчеләренең теләгенә каршы килеп, Германиянең коточкыч дәрәҗәдә кораллануына да гаепле икән бит безнең «даһи». Үзләрендә халыкара дәрәҗәдә тыелган корал заводларын, ике ил арасындагы яшерен килешү нигезендә, безнең илдә эшләтеп ятканнар, хәрбиләрен бездә укытканнар, дип язалар хәзер тарихчылар. Дөньяны икесенә генә бүлмәк булган ике тиран нинди генә хәтәр килешүләргә бармас! Җаннарны сыкратырлык шундый серләр дә әкрен-әкрен ачыла барыбер. Бик затлы «Освобождение» фильмын мин иң элек Казан кинотеатрларының берсендә караган идем. Генерал Гудерианның Казанда укыганлыгы әйтелгәч, «О-о, земляк!» дигән тавышлардан тамаша залы шау итте. Чынлап та укыганмы, әллә илдәшләренең биредә ничек укыганын, ничек сугышырга өйрәнгәнен тикшергәнме, әмма Гудерианның сугышка кадәр Казанда булып китүе тарихчыларда бәхәс уятмый шикелле. Менә нилектән сугышның баштагы чорында СССРга бер ил дә ярдәм итәргә теләмәгән, теләктәшлек тә белдермәгән, ул үзе симертешкән фашизм белән бергә-бер калган! «Үзең тапкан карта, тарта-тарта аша» дигәннәрдер күңелләреннән безнең «атабыз»га. Аның халыкара дәрәҗәдәге зур гаебе миллионнарча корбан, ярты илнең җимерелүе белән «юылгач», «даһи»ыбыз, Гитлер кебек үк, бер шигырьдә әйтелгәнчә, үз б... үзе утыргач кына ачканнар Икенче фронтны да (ә безгә аның соңлап ачылуын бүтәнчә аңлатып килделәр). Гудериан, фашистлар Германиясенең баш танкисты сыйфатында, корыч армадасын, таныш юллар буйлаптыр, Иделгә кадәр китереп җиткерде. Дошман белән иң аяусыз, иң хәлиткеч бәрелеш тә нәкъ шунда булган, дип язалар белгечләр. «Ак болыт» бәянындагы Гаяз ул сугыш хакында ничегрәк сөйли әнә. «Сугышның соңгы ике елында ике Кызыл Йолдыз ордены, «За отвагу» медале бирделәр. Сталинград янындагы сугыш белән берсен дә чагыштырырлык түгел шул. Анда бит бер исән тау, бер исән агач калмады, кая ул кеше...»

Бу сугыш хакында истәлекләр һәм әдәби әсәрләр инде бик күп язылса да, Рафаил Газизов бәяны аларның берсен дә кабатламый, киресенчә, сугышны һәм анда катнашучыларны да, тылдагы тормышны да табигыйрәк сурәтләве белән, элегрәк язылган байтак «үрә-патриот» әсәрләрдән аерылып тора. Һәммәсен саф һәм нечкә хисле үсмер Саяфтан сөйләттерүе дә — авторның зур отышы. Монда олыгаеп баручы автор үсмер Саяф кичерешләрен шулай нечкә тоемлап сурәтлиме, әсәрдә тасвирланганнарны үзе үсмер чакта кичереп, күңеленә бикләп куйган да, инде һәммәсе укучы алдына түгелгәнме — болары Рафаил дустыбызның иҗат сере булып калсын әйдә. Бу әсәрне укыганда, кайберәүләр уйлаганча, Моңның һәм Кайгының бер үк нәрсә түгеллеге дә ачык күренә. Әтисе яу кырында ятып калган сугыш чоры баласының һәр сүзе, һәр кичереше мәңгелек моңга уралган, бу моң укучыны да үз эченә бөтереп ала, кайгырып түгел, моңланып елыйсыны китерә. Саяфны шул моң һәм ак өмет кенә яшәтә дә бугай.

Моңлы, дигәч тә, әсәр буена бер тапкыр да җырлаганын күрмибез Саяфның. Әмма бу бәяннан, 40-50 еллар элек булганча, радиопостановка эшләнсә, аның музыкасы, һичшиксез, радио тыңлаучыларның җанын айкарлык моңлы булыр иде. Шулай эшләнмәсә, искиткеч әсәрне әрәм итү генә килеп чыгар иде. Хәер, күңенечебезгә, андый постановкаларны әзерли алырлык иҗат төркемнәре дә, аларны эшләтеп халыкка җиткерерлек радио да юк инде, чын татар киностудиясе дә милли хыял булудан уза алмый һаман, шуна күрә никадәр талантлы әсәрләр аз тиражлы китаплардан ары беркайда кулланылмыйча әрәм ята. Татарстаныбыз бик күп өлкәдә алга китеп тә, ни сәбәпледер, бусында чигенде генә шул. Урынына берни диярлек калдырмыйча, халыкны шундый мәгънәле, ансат тыңлаешлы радиодан мәхрүм ит инде, әй!

«Ак болыт»ны уку барышында Саяф образы безнең чор укучысына шулкадәр якын, үз һәм газизгә әверелә, ирексездән, аннан аерылунын читен булачагын уйлый башлыйсың да укуынны әкренәйтәсен. Саяф кичерешләренен байтагы — безнеке дә бит инде, таныш алар безгә. Оныта язган идек тә, талантлы әдип каләме үзәкләребезне өзәрлек итеп исебезгә төшерде менә. Сөенечебезгә, ошбу китапта ук Саяфның дәвамы, аның рухи туганы кебегрәк кабул ителерлек тагын бер әдәби каһарман бар икән. Китапка да исем биргән «Тәрәзәләр» бәянындагы Зөлфәтне күз алдында тотып әйтүем. Әсәр иң элек «Казан утлары» журналында басылды. Үзара сөйләшкәндә автор аны «автобиографик бәян» дигән иде. Димәк, Зөлфәт дип укыганда, нигездә, Рафаилне күз алдында тотарга тиеш булабыз. Үз гомер юлы сурәтләнгәнгәме, Зөлфәтнең тормышы, әйтик, Саяфныкыннан җинелрәк, ә хисләргә саранрак булып тоела, әйтерсен Рафаил үзенең хис-тойгыларын тәмам ачып салырга читенсенә, шуна күрә күңел нечкәртерлек вакыйгаларны йөгертеп кенә язып үтә. Зөлфәтнең хисләре кызлар белән генә бәйле һәм алар мактану дип укылырлык дәрәҗәдә уңышлардан гына тора сыман. Барысы да Зөлфәт дип үлеп тора торган кызлар булса да булыр икән бер бәян эчендә, чак кына «шыттырып» әйтсәк, торганы бер Кече Кирмән Дон Жуаны инде. Өстәвенә, спортта да уңыш артыннан уңыш кына көткән икән Зөлфәтне. Әдәби иҗатка да шактый җиңел керешеп киткән икән ул. Башта мәктәпләрдә, аннары университетта белем алуы да бер уен кебегрәк кенә булган бугай аңа. Читтән торып университетта алты ел бергә укыган Рафаилебез белән Зөлфәтне чагыштырып карасак, бик күп охшашлык булуга карамастан, ниндидер зур аерма барлыгы, Зөлфәт образына нидер җитмәгәнлеге дә сизелә. Һәрхалдә, киләчәктә «Кичер, кичерә алсаң» исемле бәянны, «Кашыклар», «Җиңүчеләр», «Иптәш капитан», «Дөл-Дөл», «Эти» ише хикәяләрне язачак, бәхетен һәм киләчәген сугыш алган, үзе «көн дә урамнарда көмеш кыңгырау кебек чылтырап йөргән» игелек иясе Барый, өч тапкыр танк эчендә янса да, иң явыз дошманны җиңеп, Праганы, Берлинны алышкан, шунда җаны һәм акылы имгәнгән, ә өендә сыерына ашату өчен, көмәнле яшь хатынын ияртеп, язгы кар суларын ера-ера, колхоз кырыннан төенчекләп салам ташырга мәҗбүр булган, озакламый гомере фаҗига белән очланган Шәкүр, язгы юл өзегендә, гамьсез яшәгән урыс авылын үтеп, Кама арьягыннан уфалла чанасы белән чәчү орлыгы ташыган, өендә өч сабые ач утырган Мәгъсүмбикә, «Алтын баганам» хикәясендәге Сәлималәрне шушының кадәр җаннарны айкарлык итеп җанландыра алачак әдипнең туып килүе яшь Зөлфәт образында ачык күренми кебек әле. Бәлки болары бәяннын икенче кисәгендә язылгадыр? Хәер, алты ел буе университетта җәен-кышын бергә имтиханнар биреп, без, аның сабакташлары, Рафаил Газизовнын менә-менә әйбәт шагыйрь һәм тагын да әйбәтрәк проза остасы булачагын, аның иҗаты турында Гариф Ахунов, шагыйрь Зөлфәт, Вахит Имамов, Айдар Халим кебек талантлы әдип вә шагыйрьләрнең сокланып язачагын күз алдына китермәдек, Рафаил каләме аша үзебезнең бәянга һәм китапларга керәсебезне дә белмәдек. Читтән торып укучылар, имтихан, зачёт хәсрәтләре белән, үзара ныклап танышырга да өлгерми, кая бер-береннең киләчәген чамалау?! Рафаил-Зөлфәт арабызда имтиханын иң җиңел тапшыручы иде, анысы хак. Алган әдәби белеме белән, үргә иң биек күтәрелүче дә ул булды. Бирелә аның иң якын сабакташы Рәшит Галимов белән алар, Агылый белән Тагылый сыман, берсе портфелен селтәп, икенчесе култыгына кыстырып, университетка нәкъ вакытында гына киләләр иде дә, дәресләр тәмамланугa, юк та булалар иде. Имтихан «лимитындагы» бөтен «бишле»ләрне диярлек җыештырып (калса шул Нәйрә белән Сәкинәгә калгандыр) алалар иде. «Агылый» әдәби иҗатта уңыш казанса, «Тагылый» сәясәт баскычыннан шактый өскә үрмәләде: хезмәт юлын Чүпрәле газетасында башлаган Рәшит Галимов Балтачта ВЛКСМ райкомынын

беренче секретаре вакытында комсомолның Бөтенсоюз съездында катнашты, аннары Югары партия мәктәбен тәмамлап, Арчада район советы башкарма комитеты рәисе булып эшләде. Татарстан Президенты Аппаратында җаваплы вазифа башкарды, аннары РФ Социаль иминият фондының Татарстан бүлегенә җитәкчелек итте.

Гариф Ахунов Рафаил Газизовны, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Василий Шукшин кебек авыл җырчысы дип атый, хәтта «мин Рафаил белгән кадәр белмим икән авылны» дип, беркадәр үкенеч белдергәндәй яза. Әмма үзенә бик таныш авыл тормышын, аның кешеләрен — бала чакларыннан бергә үскән Дөлкәфилне, хыялый Саяфны, көрәшче Тәхиятулла, моңлы Барый күршеләрен, «мичтән ипи ала торган көрәк кадәр» куллы Точка Хуҗасын... әйбәт белү бер нәрсә, бу кешеләрне нәкъ үзләренчә, үз холык-фигыльләре, килеш-килбәтләре, сөйләшү рәвешләре, җорлыклары белән укучы күз алдына килерлек итеп җанландыру бөтенләй башкадыр, мөгаен. Әнә шундый сурәтләү осталыгында Рафаил Газизов белән тиңләшерлек әдипләр бүгенге көндә... булса да данәләп кенә санарлыктыр (бер «данәсе» Камил Кәримов, әлбәттә). Әгәр Рафаилебез үзенең шул үзенчәлеген — сирәкләрнең берсе булуын белсә иде, мондый талантның чишмә башын «Тәрәзәләр» бәянындагы Зөлфәт аша ачып та биргән булыр иде, бәлки. Булганын бүтәннәр белән бүлешергә, пионерлар кебек, һәрвакыт әзер бит ул. Ничә дустының беләгендә Рафаил бүләк иткән сәгать йөри! Осталыкка килгәндә, ихтимал, иң элек зур тарихлы туган ягыннан, аның бай табигатеннән, җор телле кешеләреннән алгандыр ул әдәби осталык дәресләрен. Кече Кирмән күршесендәге Арташ авылы кызы Нәзифә Кәримова әсәрләренең йөгерек теленә, персонажлары — Арташ апаларының берсеннән-берсе көттәрәк җорлыгына сокланганыбыз хәтердә әле. Күркәм холыклы, бик ярдәмчел һәм дуслыкка тугры сабакташыбыз, эзтабар-язучы Шаһинур Мостафинның да Арташта туып-үсүен истә тотсак (әмма Шаһинур исеме бәянга кермәгән әле, чөнки ул безнең төркемгә, көндезге бүлектән күчеп, соңрак кушылды), биредә туган туфрак һәм якташлар йогынтысының буш сүз булмавына төшенербез. Әлбәттә, Рафаил дус университеттагы укытучыларыбыз Хатыйп Госман, Мөхәммәт Мәһдиев, Ибраһим Нуруллин, Зәет Мәҗитов кебекләрдән дә безнең һәркайсыбызга караганда күбрәкне алган. Сабый чагыннан үз ишләренең уены, шуклыгы һәм балаларча гына «бурлыгы» уртасында булу (тиз аралашучанлыгы әнисе Хөснурыйның гел халык арасында — авыл советында эшләвеннән дә киләдер), аннары озак еллар мәктәптә укыту, директорлык итү дә аның күзәтүчәнлеген, тормыш тәҗрибәсен көннән-көн арттыргандыр. Әле дә, төпкә җигелеп, Мамадышта күп төрле җәмәгать эшләре алып бара.

«Тәрәзәләр» бәянында Рафаил Шәкүр улы авыл тормышын «Гариф Ахуновтан яхшырак белүен» тагын бер раслап кына калмый, авыл кешеләрен төрле хаксызлыктан араларга да омтыла. «Авыл кешесе эшкә ничек түзә диген син. Анысына да түзәрсең, әле шәһәрләр мыскыл итә: «Сездә бөтенесе дә бушка, нишләп бай яшәмәскә сезгә?» — дигән була. Бер нәрсәне дә сатып алмыйсыз, янәсе. Акчаң булмагач алып булмый инде аны. Ә үзләре авылдан чыгып киткәч, кире әйләнеп кайтмый. Кайтарырсың, ферма ишегалдында тирес ерган эрҗинкә итеген салган, эт тә иснәмәс фуфайкасын чүплеккә ыргытып качкан кешеләрне!» Менә шулай яза Рафаил. «Авыл кешесе, зиратка илтеп күмелгәч тә, ун-унбиш ел ишетеп ята икән үгез сорап кычкырган сыеры тавышын», — дип тә өсти әле. Тик менә сыерлар үгез сорамый, туган бозаулар үлә, әле бераүнең, әле икенченең сыеры да «аяк суза» башлады бит, сабакташ. Сәбәбен мал табиблары да ачык әйтә алмый. Ә авыл халкы аны галәмәт күбәйгән каланчалардан күрә. Чын дөресен киләчәк Рафаилләре язар язуын... Без шул бүгенгебез борынгыга әверелгәч кенә язарга өйрәтелгән. Бүгенгене бүген язучылар (тагын Камил Кәримов һәм дә Флүс Латыйфи искә төшә) бәяләнмәгәннәр генә түгел, тарих буена эзәрлекләнгәннәр иле бу.

...Авылыбыз китапханәсенә соңгы керүемдә анда эшләүче Фирдания ханым, яңа кайткан басмалар арасыннан сайлап, миңа... Рафаил Газизовның югарыда сүз барган китабын тәкъдим итте. «Үзе кызганыч, үзе шундый җиңел укыла, бер башлагач, хикәядән хикәягә күчеп, аерыла да алмыйсың, үзләре шундый мәгънәләләр», — диде ул. Бүтән китапханәчеләр дә үз укучыларына шулай зурлап тәкъдим итсәләр, бу тупланма, һичшиксез, илнең иң күп укылган китаплары арасында булыр иде. Аның «Кичер, кичерә алсаң» бәяны вакытында үз бәясен алып, Фатих Хөсни исемендәге әдәби бүләккә ия булды үзе, ләкин Рафаил дустыбызның әсәрләре кат-кат танылуга да бик лаек.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

# БЕР КӘЛИМӘ, ИКЕ СҮЗ

***Анатолий Егинның «Үзбәк хан» исемле әсәре «Казан утлары» журналының 9-10нчы саннарында басылып чыкты (2014). Тәрҗемә язучы Рөстәм Галиуллин каләме белән эшләнгән.***

Башка милләт язучыларының әсәрләрен матбугатыбызда татар телендә бастырып чыгару ул — кирәк эш, бигрәк тә тарихыбызга кагылышлы әсәрләр булганда.

«Үзбәк хан» әсәре Алтын Урда солтанатында Ислам диненең рәсми рәвештә кабул ителүе һәм шушы мәсьәләдә тәхет тирәсендә булган астыртын эшләр, фажигаләр турында.

Тукымасына кермәстән, бары тик әсәрнең Ана телебезгә тәрҗемәсе турында гына бер-ике сүз әйтәсем килә. Яшь каләмдәшебезнең иҗаты күз алдыбызда, чәчмә әсәрләр мәйданында бик үҗәт эшләве дә, язмаларының теле дә күпләрнең күңеленә хуш килә. Кыскасы, бу тәрҗемәсендә дә Рөстәмнең теле һәйбәт. Киләчәктә Рөстәмнең тәрҗемә белән бик җитди шөгыльләнәчәген һәм аның оста тәрҗемәче булып, дәрәҗәләргә ирешәчәгенә ышанычым булганга күрә, сүзсез калалмыйм. Чөнки тәрҗемәдә төгәл кулланылмаган кайбер сүзләрнең Рөстәм иҗатының буеннан-буена ияреп баруы бар. Үз вакытында әйтеп калуны кирәк таптым. Аннан соң әлеге тәрҗемә әсәрнең китап булып чыгуы да күз уңында тора бугай, бу хаталар китапка да ияреп кермәсен иде.

**«Алар көймәгә күтәрелделәр»** (9 бит). «Алар көймәгә менде» булырга тиеш. Алар китте, алар менде, дип сөйлибез бит... «Күтәрелделәр» булса да, баш Себер китәрлек хата юк югын, тик күнегелгәнчә язсак, яхшырак булыр иде. Кунаклар кайтты. Абыйлар китте. «Абыйлар киттеләр, кунаклар кайттылар» — хата. Урысның «гости приехали, братья уехали»дан туры тәрҗемә. Кызганыч ки, бу күренеш инде телгә кереп урнашты кебек. Юкса, башлангыч сыйныфлардан ук безне өйрәтәләр иде: билгесез ияле җөмләдә күплек әйтелә: кайталар. Без кемнедер көтәбез, аларны каршы алырга тиеш кеше кычкыра: кайталар. Ә инде «абыйлар кайта, кунаклар китте» — билгеле ияле җөмләләр. Шуңа күрә, «абыйлар кайталар» була алмый. «Абыйлар кайта» гына була ала.

**«Кызылга манчылган ашкын су»** (10 бит). Сыеклыкны ничек итеп манчып була икән? Сүз кеше каны белән аралашкан су турында бит. Тукыманы маналар, каләмне язу карасына манчыйлар, койманы буйыйлар...

Борынгы вакыйгалар турында язганда, урта гасырларда урысларның үзләрендә дә булмаган сүзләрне куллану әсәрне ышандырмас итәдер кебек: **отряд** (№9, 10, 13, 24 б.), **командир** (10), **талант** (12), **план** (12), **юрта** (12), **кодекс** (16), **бассейн** (19), **бурка** (21), **дворян** (21), **тост** (22), **поднос** (26, 68), **физик күнегүләр** (28), **мускул** (28), **реформа** (65), **ставка** (66), **палуба** (67), **борт** (67), **мачта** (67), **артерия** (68), **процент** (№10, 13 б.), **архитектор** (17), **известь** (17), **планета** (51)...

Тырышканда, шушы сүзләрне алмаштырырдайларын да табып булыр иде. Әйтик, тост — алкышлау, алкыш (мәҗлестә кемнедер мактап алкышлау, бәйрәмдәр (юбиляр) хөрмәтенә тустаган, касә, кадәх, тустак күтәрү, алкышлау). Поднос — төпсә, туралган кавынны, карбызны, итне, җиләк-җимешне төпсәгә салып табынга куялар. Артерия — кан тамыры, муен тамыры. Планета — Җир җисеме, Ай җисеме. Командир — унбаш, йөзбаш, меңбаш, унменбашы — тәмәнбаш, сәрдар, сәргаскәр, субай... Кораб — көймә, каек. Известь — акбалчык. Бассейн — кауыз. Бурка — бөркәвеч, сарык, бүре тиресеннән эшләнгән, туладан (киездән) тегелгән бөркәвеч...

**«Ул, үлем хастасына сабышып...»** (11) Әсәрдә бәкләри бәк (бәкләр бәге) Нугай «авырыйм», дигән булып, туганнарын җыя. Шулай булгач, «сабышып» түгел, «салышып» булырга тиеш. Башка язучылар да шушы ике сүзне бутый. Салышып — хәйләләп. Симулянт кына чирләмәгән килеш авыруга салыша. Сабышу — авыруга сабышты, чир басты, каты хасталанды, ягъни чынлыклап авырып китте. Сабышу

— юл сабышу, бер-беренә юл бирү. «Кайгысыннан сары сагышка сабышты» булса, без чынлап фаҗигагә тарган кеше турында икәнен аңлыйбыз. «Авыруга салыша торгач, чынлап авыруга сабышты», ягъни авыруын үзе чакырып китерде. «Сабышып» сүзе белән **«салышып»**ны тәҗрибәле генә язучылар да бутап яза.

**«Тудырырга ярдәм итте»** (15) — язмаларда гел-гел очрый торган хата. Ана телебездә **«тудыру»** сүзе бик сирәк кулланыла. **«Туган авыл», «туган як», «туган ел»** кебек тәгъбирләрдә генә. Ләкин **«аның хатыны бала тудырды, минем килен олан тудырды»** кебек сүзләрне ишеткәнем дә, укыганым да булмады. Болар урысчадан туры тәрҗемә генә: **«его жена родила ребёнка, моя сноха родила мальчика»**. Песи белән эт **балалый**. Каз-үрдәк **бәпкә чыгара**. Сыер **бозаулый**. Ат **колынлый**. **«Бала тудырды»** түгел, «бәбәйләде», «бала тапты», «бәбәй алып кайтты», «бала табарга ярдәм итте» («кендек әбисе булды»). **«Бала тудыру йорты»** түгел, «бәбәй табу йорты», «бала табу йорты», «бәбәйләү өе», «бәбәйханә»...

**«Тәрбиялелек — әдәп, әхлагыбызның төп нигезе»** (17). Әгәр дә без **«-лелек»** кушымчасы белән **«төп»** сүзен алып ташласак, җөмлә кыскарыр, мәгънә көчәер иде. Чөнки «төп» белән «нигез» сүзе бу очракта бер мәгънәдә килә — «основа»! **Тәрбия — әдәп, әхлагыбызның нигезе»**.

**«Өстәлне елга буена әзерләделәр»** (22) — язмаларда еш очрый торган хата. Беренчедән, урта гасырларда далада өстәл булмаган, язу-сызу өчен алты-сигез кырлы кечкенә-тәбәнәк өстәл генә булган. Ун яки йөз кешелек өстәл була алмый. Чирәмгә, келәмгә, киезгә корылган дәстархан, табын гына була. Бу — турыдан-туры урысчадан күчермә. Татарда өстәл әзерләү — ул ватык өстәлне төзәтү, сүтелеп куелган өстәлне җыю-рәткә китерү булыр иде. Әсәрдә табын әзерләү турында сөйләнә. Димәк, дәстархан, ризык, тәгам, азык-төлек, ашамлыклар күз алдында тотыла. Кайбер бичара язучылар хәтта «өстәл капладык» дип тә яза, урысчасы — «стол накрыли». Алай язучыларның каләмнәрен сындырырга кирәк!

**«Елбаздукны патша япмасына дәштеләр»** (28). Бу җөмләне аңлавы кыен. Елбаздукны патша чатырына чакырганнармы, әллә каплаулы күчмә тәхет янынамы дәшкәннәр? Монда «дәштеләр» сүзе үз урынында кулланылмаган кебек. Дәштеләр, чакырдылар, яшьтеләр, дәгъват иттеләр. «Эндәштеләр» — шул ук мәгънәдә, ләкин «эндәшү» — ул «чакыру» түгел. Урамнан узып барган кешегә «әй, кая барасың?» дип эндәшәләр (окликнул). Әй, Габдулла, безгә кереп чык әле!» булса, чакыру, өйгә дәшү-яшү (пригласил) була.

**«Газель»** сүзе (30) аңлатмада «антилопаның бер төре» дип язылган. Дөрес, сүзлекләрдә шулай язылган, ләкин төрк телле әдәбиятта ул сүз «җәйран», «җәйлан», «кыр кәҗәсе» буларак та кулланыла.

**«Үзбәк хатынлыкка үзенең җәяне Толынбайны күрсәтте»** (№10, 19 б.). «Җәян» сүзе аңлашылмый, ул «җәгән» булырга тиеш. «Җәгән» — туганының кызы, пләмәннек кыз. «Күрсәтте» түгел — «димләде», «кодалады», «ярәштерде», «туганнан туган кыз кардәшен хатынлыкка алуын теләде».

**«Пешекчеләрнең ипи... пешерү өчен** (58). Тарихи әдәбиятта аш пешерү һөнәрендә өч сүз йөрештә була: **«пешекче»**, **«ашчы»**, **«бавырчы»**. **«Бавырчы»** (онытылган сүз) — ул олы дәрәҗә, әйтик, Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә (1383) «егетләр күреклесе бавырчылыкта» әйтеме бар, ягъни ир-ат өчен шаһ ашханәсендә бавырчы булып тору — ул мактауга лаек олы дәрәҗә булган. **«Ашчы»** да дәрәҗәле вазифа, ул бүгенге «повар» мәгънәсендә куллана. **«Пешекче»** кәлимәсе — ул суелган малны пешекләүче кара эшче, ашханәдәге иң авыр, иң пычрак эшне башкаручы, суелган тавыкны, малның башын, эчәкләрен кайнар суга батырып пешекләүче вә йонын йолкып, эчәкләрен алып, юып, ашчыга тапшыручыга карата әйтелә торган сүз. Урысчасы — «подсобник», «кара эштә ашчының ярдәмчесе».

**«Тәре йөртүчеләр»** (79). «Тәре» сүзе «тәнре» кәлимәсеннән алынган дигән фараз бар. Ягъни Тәнренең сурәте. Ихтимал, ләкин соңгы йөз ел эчендә Ана телебездә бу сүз мәгънәсен үзгәртте. Күпчелек татарлар «крест»ны «тәре» дип йөртә башладылар. Юк шул, дустым, «крест» — ул «хач», «кайчы» сүзе дә шул «хач»тан килеп чыга: «аркылы агач», «аркылы тимер». «Тәре» ул — «икона»! «Крестовые походы» гыйбарәсе «тәре походлары» дип түгел, «хач сәфәрләре», «хач яулары» дип тәрҗемә ителергә тиеш. Христианнарның муенындагысы — «хач» (крест), өй

түре почмагындагы сурәт — «тәре» («икона»). Керәшеннәр бу ике сүзне бутамый, дөрес куллана. Керәшеннәр: «кач (хач) манган көн» дип сөйлиләр. Хачны изге суга батырып-манып алалар. Тәрене суга батырсаң, ул җеби, сурәт бозыла.

**«Бар серен бүлеште»** (№10, 55 б.). «Уртаклашу» белән «бүлешү» игезәк сүзләр кебек, ләкин аларның кечтеки кенә аермасы да бар: уртак малны бүлешәләр, серне уртаклашалар, серне чишәләр, серне сөйлиләр, серне тоталар (Алиш, «Сертотмас үрдәк»), серне саталар, серне ачалар...

Әдәби әсәрләрне тәрҗемә итү — ул аерым бер һөнәр (профессия), бик җитди һөнәр. Каләм иясе борынгы телебезне, бүгенгесен яхшы белергә тиеш, шулар өстенә тәрҗемәченең тарих катламнарыннан да хәбәре булу шарт.

Соңгы илле-алтмыш ел эчендә Көнбатыш, рус әдәбияты классикларын Ана телебезгә тәрҗемә итүдә искиткеч гүзәл нәтиҗәләр булды. Михаил Шолоховның «Тын Дон» һәм «Күтәрелгән чирәм» романнары (Яхъя Халит, Гариф Ахунов), Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр» (Рәис Даутов), Александр Дюманың «Өч мушкетёр» (Яхъя Халит), Фёдор Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» (Рәис Даутов), Роберт Стивенсонның «Хәзинәләр атавы» (Саимә Ибраһимова) китаплары — тәрҗемә сәнгатенең асылташлары. Яшь тәрҗемәчеләргә менә кемнәрдән өйрәнергә кирәк.

Бу изге эшендә Рөстәм Галиуллинга яңа үрләр яулавын, яңадан-яңа уңышларга ирешүен теләп калам.

**Рабит БАТУЛЛА**

---

## Халык әйтсә, хак әйтә

- Алабута орлыгы булганчы, солының саламы бул.
- Бер яманның зарары мең яхшыга тияр.
- Ике яхшы бер сәкегә сыя, ике яман бер шәһәргә сыймый.
- Яхшы белән яман арасы — җир белән күк арасы.
- Яхшы — җанына юлдаш, яман — малына юлдаш.
- Яхшы эш үз-үзен мактый.
- Усаллык белән баланы да җинеп булмый.
- Таш атсаң, кулыңны яшермә.
- Кеше таштан каты, чәчәктән нәфис.
- Бүредән ит сорап йөрмә.

*Әлеге мәкалә – каләмдәшебез Фәнзаман Батталның безгә тәкъдим иткән соңгы язмасы. Бу елның җәй аенда ул аны «Батталдан Ханнанга хат» дигән исем астында электрон почтабызга җибәргән иде. Әдәбият һәм халкыбыз тарихында фронтовик шагыйрь Салих Баттал, җәлилче Абдулла Баттал кебек күренекле шәхесләрнең портретын тулыландырган мәкалә укучыларыбызны да кызыксындырмый калмас.*

*Тагын шунысы да мөһим: Фәнзаман ага күтәргән мәсьәләләрнең берсе уңышлы хәл ителде – октябрь аенда Казан шәһәрендәге бер урамга Бертуган Батталовлар исеме бирелде. Адашларын кайгыртып, аларның батырлыгын, иҗатын пропагандалаган язучыбыз Фәнзаман Баттал рухы да әлеге сөенечле вакыйгага шат булыр, иншалла!*

**Рамил ХАННАНОВ**

# «КҮЛӘГӘДӘГЕ» БАТТАЛ

САЛИХ БАТТАЛНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

*Терелләр үлгәннәрнең күзен йомдыра,*
*үлгәннәр исә терелләрнең күзен ача.*

## Язмас борын... бер искәрмә

Сизеп торам, укучым сәерсенеп куйды: авторы да Баттал, язманың исемендә дә «Баттал»...

Яшүсмер чагымнан — республика матбугатында тәүге шигырьләрем, парчаларым күренгәли башлаган еллардан бирле бер сорау биреп йодәтәләр:

— Салих Батталның улы яки кардәше түгелме син?

Исемемнең үзе исән чакта ук легендар шәхескә әверелгән могътәбәр зат исеме белән янәшә яңгыраштыруы күнелгә рәхәт тоелса да, дөресен әйтергә туры килә иде. Тел чарлау дәрте дөрләп торган яшьлектә болайрак була иде җавап:

— Капка баганаларыбыз да бер урманда үсмәгән, ичмасам. Үги малае булсам да, таяндырмый, ярдәм итми калмас иде әле. Минем Батталым анын Батталынын оныгы булырдай яшьтә генә шул...

Олыгайган саен җавабым кыскарып бара:

— Юк. Фамилияләребез генә бер үк.

— Рухи яктан гына туганнар.

Дөп-дөресе шулай.

...Бу юлы Салих Батталнын энесе Фуат Баттал турында язмак булам. Шул ук вакытта бу ниятемнең барып чыкмасын да алдан ук аңлап утырам. Чөнки бу шәхес (ул шундый бәягә, һичшиксез, лаек!) бөтен рухы, кылган гамәлләре белән үзенең абруйлы һәм шөһрәтле нәселенә нык береккән. Анын тормыш юлы белән нык-лап танышкач, мондыйрак фикергә дә килдем: әтиләре Вазыйх вафатыннан сон нәселнең төп таянычы, сабырлык һәм салкын акыл белән тәртипкә салып торучысы шушы Фуат булган лабаса! Әледән-әле кайнарланып, дуамалланып китүче Салих Батталны, «тәртәдән» чыккалап торучы танылган гобойчы Мөбарәк Батталны нәкъ шушы кеше суытып, эзгә кертеп яшәгән икән. Фәкыйрь вакытларында ашаткан, ялгышкан чакларында кисәткән, елаган-кайгырган чакларында күз яшьләрен сөрткән, күнел төшенкелегенә бирелгән көннәрендә рух өстәп торган. Алай гына да түгел, һәркайсынын иненә кунып, гөнаһ вә савапларын теркәп баручы «фәрештә» вазифасын да бик әзлекле башкарган ул — нәселенең гадел елъязмачысы булган. Ошбу җәһәттән

караганда, язучы һәм шагыйрьләр арасында иң бәхетле әдип Салих Баттал түгел микән? Аның һәр уңышы, кайгы һәм шатлыклары, егылу-торулары, юаш һәм горур чаклары һәркайсы бер китап булырдай калын-калын дәфтәрләрдә чын хикәя булып саклана. Дөрес, бездә көндәлек алып баручы язучылар шактый. Ләкин, белүемчә, аларның күпләре тенденциоз, ягъни үз мәнфәгатьләрен куәтләү, үз-үзләрен хаклау, зурлау максатында язылганнар. Ә бу очракта сүз туганының гамәлләренә куана да, ачына да белгән гадел үлчәүче теркәгән тарих турында бара.

Хәер, кардәш һәм туганнарының һәркайсы кадерле булган Фуат Баттал өчен. Ана алар шагыйрь (Салих Баттал), герой (фашистлар тарафыннан җәзаланган Абдулла Баттал), күренекле музыкант (Мөбарәк Баттал) булудан бигрәк, туган булырак кадерле — көндәлекләрне укып чыкканнан соң, әнә шул фикергә киләсең.

Нәселнең кырык еллык тарихын үз эченә алган бу язмалар хәзер Фуатның улы Фәрит Батталда саклана. Фәритнең әйтүенә караганда, әтисенең иң кадерле, иң изге мирасы — шулар. Сизенүемчә, Фәрит аларны дәвам итә. Һәрхәлдә, дәвам итү генә түгел, тулыландыру да кирәктер әле. Чөнки әлеге дәфтәрләргә кермәгән, әмма шул ук Фәритнең хәтерендә сакланган кызыклы һәм гыйбрәтле истәлекләр күпме тагын!

Ниһаять, Фуат Баттал көндәлекләренең кайбер сәхифәләренә укучы белән бергә күз салырга вакыттыр. Гәрчә ана кадәр әйтеп куярга тиешмен: әгәр дә көндәлектәге сәхифәләрдән Салих Батталның тормышы һәм язмышы турындагы язмаларны күбрәк файдалана калсам, гаеп итмәгез. Вакыты-вакыты белән ачы телле, йөз кеше «урра!» кычкырып алга барганда да берүзе кирегә барырга сәләтле, үзен мактаучыларны да тәнкыйтьли белүче, хакыйкать һәм гаделлек хакына бөтен рәхәтләреннән дә ваз кичәргә әзер торучы өлкән каләмдәшемне бик тә ярата идем. Бөтен үҗәтлекләре, дуамаллыклары, ихласлыклары белән бергә ярата идем...

## Нәсел таянычы

Тарих Галиҗәнапләре каршында барыбыз да фани... Аллаһы Тәгалә өчен патша белән хәерче дә, сүз чәчеп китаплар үстерүче шагыйрь белән орлык чәчеп икмәк үстерүче игенче дә бер һәм тигез — һәркайсы сөенә-көенә яши, һәркайсы китә... Яшәгәндә озын тоелган гасыр үтеп киткәннән соң мизгел генә булып тоела...

Үткән гасырда Спас өязенең Зур Тигәнәле өязендә (хәзерге Алексеевск районында) Сәетбаттал дигән кодрәтле кеше яшәгән. Ул һәм кызларының берсенә Вазыйх дигән исем куштырган, үсә төшкәч, аны Нурдидә исемле сылуга өйләндергән. «Нәселне дә, милләтне дә көчле, сәләтле балалар белән баетыгыз», дип хәер-фатыйха биргән, имеш. Вазыйх белән Нурдидә алты бала үстергәннәр: Ләйлибәдәр, Галимҗан, Салихҗан, Мөбарәкҗан, Габдуллаҗан, Фуат... Шушы ир-егетләрнең үсеп җитүен генә көткән кебек, СССР белән Германия арасында дәһшәтле сугыш кабынып китә. Гаиләдән берьюлы биш ул яуга китә: пехота да, дингез һәм һава флоты да бертуган Батталовлар исәбенә көчәя. Бер сүз белән әйткәндә, бу нәсел җирдә дә, суда һәм күктә дә фашистларның иманын укыта. Галимҗан һөҗүмгә барганда һәлак була, Габдуллаҗан (Абдулла) исә, мәгълүм булганча, әсир төшеп, башка җәлилчеләр белән бергә җәзалап үтерелә — башы киселә... Исәннәре, күп орден-медальләргә лаек булып, илгә кайта.

...Шулай итеп, туганнар инде тыныч тормышта кайный: фикерләшәләр, бәхәсләшәләр, үпкәләшәләр, кабат татуланалар һәм... бер-берсенә хөрмәтне берчакта да югалтмыйлар. Салих Баттал барысының да игътибар үзәгендә. Батыр очучы яки танылган шагыйрь булганы өчен генә түгел, ата урынына калган иң зур абый булганы өчен дә! (Әтиләре Вазыйх сугыш алдыннан — 1940 елда вафат була.) Аны зурлыйлар, тыңлыйлар, хәтта масаеп, дорфаланып киткән чакларында да үпкәләмиләр сыман. Шунысы да бар бит әле: шактый замандашларының хәтерендә төртмә телле, башбирмәс Баттал булып сакланса да, туганнары һәм дусларының исендә ул җор телле, беркатлы һәм шаян Баттал булып та калган...

***«Кичә Салих абый, Мәдинә апа һәм мин чәй эчеп утырабыз. Абый:***

***— Мин үзем бирелә утырам һәм шул ук вакытта радиодан да чыгыш ясаячакмын. Сәгать ничә? Фуат, куй зур радионы да. Һәр бүлмәдә бер Салих сөйләп торсын, — диде. Мин йокы бүлмәсендәге «Минск — 55» приёмнигын кабыздым, Казанга***

***куйдым һәм, дөрестән дә, диктор: «Микрофон алдында — шагыйрь Салих Баттал», — дип әйтеп салды.***

***Шигырьләр укылып беткәч, эти*** (Нурфигальнең әтисе яки Фуатның бабасы. — Ф.Б.) ***Салих абый янына килде дә:***

***— Салих, син нигә «галәм» дип яздың, дөрес түгел бит, — диде.***

***— Укымышлылар, киңәшеп, «галәм» сүзен дөрес дип таптылар.***

***— Юк, дөрес түгел! «Җиһан» кирәк, — диде дә эти, үз ягына чыгып китте.***

***Абый:***

***— «Җиһан»ны рифмага җиңелрәк салып булган булыр иде, — дип куйды.***

***Соңрак, үз караватына утырган әни Нурфигальгә ниндидер йомыш белән эндәште һәм, кызының исемен әйткәнче, әллә ничә исемне теленнән уздырды. Мөхәммәт*** (Нурфигальнең абыйсы. — Ф.Б.):

***— Кызың бер генә бит. Әллә аның исеме дә онытыламы? — дип шаяртты.***

***— Ун бала үстерсәң, үз исемеңне дә онытырсың әле, — дип җавап бирде әни*** (Нурфигальнең әнисе. — Ф.Б.).

***Салих абый:***

***— Кодагый бик дөрес әйтә. Менә мин үземнән генә гыйбрәт алам. Мәдинәгә эндәшәсем булса, бөтен хатын-кызларымның да исемнәрен әйтеп бетерәм: Мәрьям, Ольга, Кадрия... Хатыннарың күп булмасын икән дөньяда!***

***Әни урынында авыз ерып утыра. Абыйның шаяртуы ошады. Алай да:***

***— Күпкә өйләнмәскә иде, — дип сүз кыстырды. Абый да аптырап калмады:***

***— Мөхәммәд галәйһиссәламнең дә хатыннары күп булган бит. Шулай булгач, нигә аңардан үрнәк алмаска?***

***9 август, 1961 ел».***

Шул ук елның җәендә бертуган Батталлар дачада ял итәләр. Дөнья хәлләре, әдәбият, сәнгать турында сөйләш-киңәшләр, кызып-кызып фикерләшүләр... Бәхәснең уттай ноктага менеп житүен сизгән туганнарның кайсы да булса берсе, эшләр яка урауга барып житмәсен тагын, дигәндәй, «атмосфераны» суыту әмәлен таба.

***«Мөбарәк абый:***

***— Бәрәңгенең дә, кәбестәнең дә борычы юк икән, — дигәч, Мәдинә апа аптырап калды:***

***— Нәрсәгә бәрәңгегә борыч?!***

***— Без борычлы бәрәңге яратабыз, — диде дә Мөбарәк абый, сумкасыннан «Перцовая»ны «колагыннан» тартып чыгарды.***

***Пикникны дәвам итү теләге белән, станциядәге кибеткә китәргә булдык. Төрлечә кыланып, берничә мәртәбә рәсемгә төштек. Кызыклы истәлек булачак».***

Гомернең фанилыгын берчакта да исеннән чыгармагандыр, ахры, инженер Фуат. Үзенчәлекле, истәлекле очрашуларны каләм белән генә түгел, әледән-әле фоторәсемнәр белән дә ныгыта, баета тора.

Кызыклы истәлек дигәннән, Салих абзыйсының хикмәтләрен сабый чактан ук күзәтеп үскән Фәриттә дә хатирәләр шактый. Әтисенең көндәлекләрен актарганда, монаеп та, кызык итеп тә сөйли.

**Фәрит Баттал:** — Салих абыйны мин исән чакта — күп мәртәбә, үлгәч бер мәртәбә таптадым... И, ярата иде мәрхүм безнең таптаганны! Безгә килсә дә, үзенә барсак та, сузылып ята иде дә, сеңлем Фәридә белән икебезне чакырып китереп, үзен таптата иде. Без — ике сабый әрле-бирле аның өстеннән йөрибез, ә ул, ләззәтләнеп аһылдый, ара-тирә «иң рәхәт, иң файдалы массаж шушы инде!» дип тәкрарлый. Әйе, үлгәч тә бер мәртәбә таптадым. Каберенә балчык сала башлаганчы, ләхет такталарын рәтләү, тигезләү өчен төшерделәр. Балчык күпләп төшкәндә кыйшаймасыннар, урыннарыннан купмасыннар өчен, өсләреннән йөреп, кабер төбендәге туфракка беректерергә туры килде.

**Фәрит Баттал:** — Әллә нинди кызыклар уйлап таба иде Салих абый... Дачасының ишеген каерып ачучылардан йөдәп беткәч, бөтенләй бикләми башлады. Сирәк-мирәк дача өстәлендә аракы һәм кабымлыклар калдыра да бер бит кәгазьгә болай дип яза: «Дорогие, многоуважаемые воры! Пейте и закусывайте. Только, прошу вас, ничего не ломайте, не воруйте. Ради бога, не трогайте мои рукописи». Шуннан соң тынычланды: ватмыйлар да, урламыйлар да... Ә бервакыт болай иткән: дача йортының өйалдысына

канга батып үлгән кешегә охшатып, муляж, ягъни карачкы ясап ташлаган. «Мәет»нен «өстендә» иске телогрейка, «аякларында» кирза итекләр, «башында» карга оясыдай сәләмә бүрек. Йөзтүбән ятканлыктан, карачкының йөзе күренми, ә муен булырга тиеш урыннан «кан» агып җәелгән. Сыек та, кызыл да вареньe инде анысы... Караклар керәләр дә, энгер-менгердәге «мәетне» күргәч, куркудан тыннары капланып, чыгып йөгерәләр. Качып күзәтүче Салих абыйның да, тавышын чыгармаска тырышып көлүдән, тыннары каплана икән... Төрле әмәлләр белән котыла иде дача басучылардан.

## «Һәр көнемне 10 тиенгә яшим...»

...Кайсы гына чорны яки системаны игътибардан үткәрмә, җанны ачындырган хакыйкатькә тап буласың: ирекле фикер йөртергә күнеккән талантлар хакимиятләрнең аяк астында тапталып изалана. Салих Батталның Батый ханга хат рәвешендә язылган, милләт язмышын ачынып тасвирлаган поэмасы обкомны кырмыска оясына таяк тыгып болгаткандай итә, ягъни: «КПСС карарлары белән рухланып коммунизм төзүче совет кешеләрендә каян килеп милли проблемалар булырга тиеш?!» Табеев яраннарының йокысы кача. Мондый бимазадан котылу юлы бер генә — «гаепләне» партиядән куу. Ә инде партиядән куылган адәм баласының хокуклары төрмә тоткыныныкыннан да таррак... КПССны демократик партия итеп күрергә өметләнгән Салих Баттал өзгәләнә, гаделлек юллый һәм, бер дә гаҗәп түгел, аракыдан да юаныч эзли. Энесенең кыска гына бер язмасы аның шул чордагы халәтен бик ачык тасвирлый.

***«...Кайтып кергәндә Салих абыйны күреп алдык. Ул, балалар белән бергәләп, «снежная баба»га күмер күзләр куеп тора иде.***

***...Мактый-мактый 0,5не берүзе бушатты. Теле чишелде. Мәскәүгә язган икән. Чөнки биредә, аңлар-аңламас, бик коры кыланганнар икән аның белән.***

***— Сезгә зур рәхмәт, чөнки һәр фикеремә таяныч табам. Дөреслекне аңлый беләсез. Һәрвакыт кунакка килегез, ишегебез ачык, күңелебез күтәренке булачак.***

***Кунаклар янында калырга димләгәч:***

***— Яшьләр һәм белмәгән кешеләр янында утырып булмас, — диде.***

***Аякларын дөрес атларга, үзен туры тотарга тырышып, кулларын артына куеп, әкрен генә чыгып китте. Да-а... абыйның күңеле төшенке. Ударны бик тирәнтен кичерә. Тимердәй рухы булмаган кеше ул кадәр кичерүдән бөгелер, авырлык астында бөкрәер һәм хәтта егылыр иде. Ә ул көрәшә, башын югары тота, дөреслекнең үз ягында икәненә нык ышана, чигенергә уйламый.***

***— Кулымдагы каләмемне тартып алып, икмәктән дә коры калдырмакчы булалар. Ачтан үлмәм... Шушындый финал көтмәгән идем, — диде.***

***6 апрель, 1963 ел».***

Батталлар нәселендә күңелсез, кара болытлы көннәр еш кабатланып тора. Артка күз салсаң, эзәрлекләүләр йончыта, унга баксаң — кемдер урын өстендә, сулга карасаң — гаделсезлек, алда исә билгесезлек. Фуат Баттал шуларның барысын да йөрәгеннән үткәрә...

***«Мәдинә апа килеп утырды.***

***— Салих командировкадан кайтты. Алтмыш еллыгына чыгарылырга тиешле җыентыгын басмаска булганнар — исемлектән сызганнар.***

***Авыр... Бик авыр! Мескен. Хәрби хезмәттән кайтканда, үзенә закон буенча тиешле пенсияне алудан баш тартты бит! Сверхчестный кеше! Хөкүмәт фондына калдырган. Ә хөкүмәт аны ничек кайгырта? Язган әсәрләрен дә бастырмый...***

***Бүген эти һуштан язган. Агарган. Димәк, бу — кисәтүче сигнал! Ашкыналар, мескеннәр, яңа квартирга чыгарга. Положим, чыгарлар. А дальше? Туфракка әйләнү...***

***3 декабрь, 64».***

Салих Баттал яшьтән үк Виктор Гюго иҗатына гашыйк булган Һәм бөек классикның исемен балаларының берсенә биргән. Әйбәт, кешелекле егет булай...

Көндәлекләрне актарган, укыган саен, шиксез фикергә киләсең: Фуат Баттал фатиры шушы ишле нәселнең төп йортына, «штабына» әверелгән. Кайгы яки шатлык булса да, кинәш-мазар кирәксә дә, шушында йөгереп киләләр.

Өстән генә фикер йөртүче укучыга Салих Батталның вакчыл һәм дорфа булып тоелуы

да бар. Әмма бу юлларда шагыйрьнең җан елавын, үксүен аңлау өчен күп кирәкми.

***«Эштән кайтып кына кердем, Салих абый килеп җитте. Соңрак Нурфигаль белән Рауза (Фуатның балдызы. — Ф.Б.) кайтып керделәр. Өстәл әзерләнде. Өй шәрабен татыттырдым. Ошады. Һәм теле чишелде. Лучше чишелмәсен иде...***

***Абый залда иде. Рауза, кереп:***

***— Исәнмесез, Салих абый, — дип исәнләште. Абый ләм-мим. Мин:***

***— Абый, сиңа эндәште бит, — дисәм дә — молчок.***

***Рауза теге якка чыккач, абый:***

***— Һаман 25 сумны түләми, — диде.***

***— Бурычын бирмәдеме?***

***— Әйе. Счётчик өчен. 25 сумын бирде, яртысын — юк.***

***— Күбрәк сорыйсың түгелме соң бер счётчик өчен?***

***— Син алай дисең... Беләсеңме, минем 1963 елдагы гонорар 30 сум булды? Көненә 10ар тиен... Мине Мәдинә асрый. Өйгә кайтырга гына 5 тиен акчам бар. Бир миңа бер сум».***

Татар әдибенең хәле матди яктан бер генә чорда да куанырлык булмаган. Аңа башка милләт язучыларына караганда һәрвакыт аз түләгәннәр. Ул чорда Салих Батталның әсәрләрен бастыру да тыелган. Берәр мөхәррир дөньяга чыгара калсамы! Үзен дә чыгарып ташлыйлар...

Обком каршында партбилетларына тап төшерүдән куркучы күпчелек язучылар да Салих Батталдан ераграк булырга тырышалар бу айларда. Аның белән бергә йөрүдән, әңгәмәдәш булудан Алла сакласын! Бер залда утыруның да гафу ителмәве мөмкин...

***«Кичәге язучылар съездына Салих абый нигәдер бармаган. Хәбәрләрне Локман*** (Локман Бадыйкшан күздә тотыладыр. — Ф.Б.) ***гына кереп сөйләгән абыйга».***

Съездддан соң, ягъни 1965 елның 13 гыйнварында Фуат үз көндәлегенә әнә шундый җөмләне дә теркәп куйган. Күрәмсең, аннан алдагы көннәрдә ул абыйсы белән очрашмаган булгандыр, шуңа күрә көндәлегенә «нигәдер» дигән икеләнү кергәндер... Ул елларда, колактан-колакка йөри торгач, безгә дә — Минзәләгә килеп ирешкән хәбәрне, һәрхәлдә, бездән иртәрәк ишеткәндер Фуат, шагыйрьнең ул съездда нилектән катнашмавын да тиз аңлагандыр. Сәбәбе бер җөмләгә сыеп бетә: партиядән чыгарылган кеше сөргеннән кайткан Жан Вальжаннан да хокуксызрак. Аны читкә тибәрү генә түгел, күмәкләшеп типкәләсән дә бик хуп — обком «одобряем!» дип кенә торачак.

## Бәла юлдашы – каза

Монын ише чакта, ни хикмәттер, нәселгә килгән бәла үз артыннан казасын да ияртеп килүчән. Әнә, Ләйлибәдәр апалары хастаханәдә операция кәтеп ята, шуның эзеннән диярлек болай да кара кайгыдагы Салихның хатыны Мәдинәне дә ашыгыч ярдәм машинасына салып киткәннәр. Температурасы бик тә югары икән... Кайсы тарафка күз салса да, Фуат караңгылыкка юлыга...

***«Авыру, һәркайсыбызның үкчәсенә баса-баса, сагалап йөри... 3 февраль, 1963 ел».***

***«Дәү эти ураза тотып, хәлдән таеп урында ята. Салих абый исереп килеп керде. Өстәтмәде Мәдинә апа. Чәй генә эчердек. Аннары ул ятып торды. Кичке тугызда гына киттеләр. Сөйләшеп утырып булмады... 17 февраль, 65».***

Ләкин, үзебез белгәнгә энесенең дә сүзләрен кушып әйтсәк, көчле рухлы һәм корычтай сәламәт Салих шушындый бәхетсез көннәрендә дә аракы белән артык мавыкмый. Обкомда тапмаган таянычын ЦКдан эзли, хатлар яза, Мәскәү Кремленә барырга да күп сорамый — үзенекен итмичә туктый торган шәхес түгел! Әледән-әле Фуат янына килеп чыгуы да тикмәгә түгел — ошбу энесенең аналитик фикерле, тирән белемле, төпле кинәшләргә бай икәнлегенә кырыкмаса-кырык тапкыр иман китергән. Ниһаять!..

***«...Мәдинә апа килде. Ул да зур шатлыклы хәбәр алып килде — Салих абыйны партиягә восстановить иткәннәр! Чын күңелемнән котлыйм, абый, зур җиңүең белән! Шушылай эшләргә кирәк головотяплар белән. Молодец!»***

Ләкин өч-дүрт көн үтүгә, кабат борчулар сарыла...

***«Язның беренче ае узып та бара. Аның белән бергә гомерем язының да күптән узганлыгы чатнап күзгә бәрелә. Мыштым гына салкын картлык үрмәләп якынлаша...»***

Тиктомалга монаймый Фуат. Көндәлекләренең кайберләре әнә шундый

фәлсәфәләр белән башлана икән, димәк, сәбәбе бар... Менә бу юлы да көтелмәгән хәл: абыйсы Салихны төнге өчтә «скорый» белән шәһәрнең 12 нче хастаханәсенә алып киткәннәр.

***«3-30-29га — приёмныйга шалтыраттым. Приступы жиңеләйде, әлегә йоклый, дип җавап бирделәр».***

Көндәлек дәфтәрләргә тирәнрәк чумган саен, Фуат Батталның кемлеге уйландыра: бер карауга, ул үз нәселенең юаш һәм тугры хезмәтчеседер сыман, ә инде икенче карауга, таләпчән хөкемдары шикелле. Тегеләр авырса яки берәр бәлагә юлыкса, уйга батып, башын иеп, хастаханәләргә ризык, кирәк-ярак ташый, кыен хәлдән коткару юлларын эзли, әгәр дә инде «тәртәдән чыга» башласалар, сабырлыгына таләпчәнлеген төенләп, бөтенләй башка Фуатка әверелә. Һәркайсы очракта йөрәге талпынып та, талкынып та тора. Мәгълүм ки, Салих Баттал фани дөньядан туксанын тутырыр-тутырмас китеп барды. (Ут чыкмаган, янып үлмәгән булса, йөзгә үк тә тарткан булыр иде, бәлкем, — әле һаман да нык иде, фатирын да чипчиста тотып, тәмле-тәмле ризыклар пешереп, көндәлек матбугатны укып баручы, яна шигырьләрен дә бастыргалап яшәүче нык буынлы карт иде.) Фуатның икенче абыйсы Мөбарәк Баттал да озын гомерле булды — 94 яшен тутыра язып китте оҗмахына. Монысы да безнең өчен зур куаныч. Димәк, ныклы, сәламәт нәселле булганнар! Ә Фуат үзе житмештән генә уза алды — абыйларыннан бик иртә үлде. Шул хакта уйланган чакларымда мондый сорауга тап булам: абыйлары өчен җан атып, аларның көенечләрен, гамьнәрен йөрәгә аша үткәреп яшәү китермәде микән бу иртә вафатны? Бәлки ялгышамдыр да. Әмма күпкә түгелдер...

Хәер, исән чагына кайтыйк.

Нәрсәгә генә игътибары житмәде икән Фуатның? Кызу көннәрдән соң коеп янгыр яуса, Казанның нәкъ уртасында кыр-басуларда эшләүче игенчеләр өчен сөенеп ята, Жир шарында 9 миллион тома сукыр барлыгын да дәфтәренә теркәп куя, Галимҗан Ибраһимов җәсәденең кайдалыгын да бик беләсе килә. Дәфтәрләрендә мондый мәгълүмат бар: Г.Ибраһимов хатыны Хәдичәнең әйтүенә караганда, «братская могила»ны тикшерергә рөхсәт итсәләр, Галимҗанны сөякләреннән тану кыен булмаячак икән, чөнки сул ягында ике кабыргасы юк...

Юк, нәсел язмышы гына түгел бу дәфтәрләрдә! Үзенең бөтен матавыклары, гаделсезлекләре һәм әледән-әле елмайткалап торучы сөенечләре белән бөтен чор сыйган аларга.

***«10.06.65. Йорттагы кайбер малайлар Фәритне рәнҗетәләр, татар булганы өчен. Суккалыйлар. Туры китереп, колакларын борасы бар әле».***

***«11.07.65. Уфа. Рус белән тулган шәһәр. Тарихи урыннарны белмиләр. Типичный башкорт очрамады. Ашханәләр күп, ләкин ашлары боз кебек, кыйммәт, тәмсез. Ашый алмыйча ташлап киттек. Гомерне пристаньдә уздырдык. Арыдык. Туйдык...»***

***«11.08.65. Трагедия. Әдипкә (Салих Батталга. — Ф.Б.) — 60. Ә бер коллегасы да дикъкать күрсәтмәде... Полное забвение...»***

***«25.08.65. Чәршәмбе. Урра! Мне присвоено звание инженера-конструктора третьей категории. Перспективно! Дерзай, твори, старайся, трудись!»***

Бер чорда Батталлар нәселе уңышка, күтәрелешкә илтүче дулкынга эләгә. Фуат ул көннәрнең барысын да тарихка кертергә ашыга.

***«5 май, 66. Бүген радиодан «Мөбарәк Батталның иҗади портреты»н тыңладык. Җәүдәт Фәйзи әзерләгән. 45 минут барды. Радиокомитетның музыка бүлеге башлыгы Рафаэль Ильясов (абыйның шәкерте) записьнең копиясен миңа бирергә булды».***

***«11.10.65. Салих абыйның романы (в стихах) «Казан утлары»ның 10 нчы санында басыла башлаячак. Зур шатлык! Кичә аларда ванна кереп кайттык. Кичен Мөбарәк абый килде. Ул Мәдинә апа белән ачуланышкан икән. «Анда бүтән бармыйм», ди».***

***«24 ноябрь, 65. Салих абыйның китабы басылып чыкты (бүген телефоннан үзе шалтыратып әйтте). М.Җәлил көрәштәшләренең рәсемнәрен музей җыя икән. Бу арада Габдулла Батталның карточкасын печатать итеп бирергә, диләр».***

***«7 февраль, 67. Салих абыйны машина бәреп еккан. Алтынчы больницада ята. Мәдинә апа килеп керде. Абыйның хәле авыр икән. Кичә үзем дә Микоян тыкрыгында чак кына машина астында калмадым».***

## Аермаска иде аларны!

Әнә шундый житди язмалар арасына ул, тиктомалга дигәндәй, теләсә нинди «ачышын», ишеткән, үз башына килгән фикерне яки афоризмны да теркәп куярга онытмый. Сүз унаенда әйтеп үтим, бу язмага эпиграф итеп куелган гыйбарә дә Фуат Баттал дәфтәреннән алынды. Үз фикереме ул, әллә каяндыр ишеткәнме яки күчереп алганмы — анысы мәгълүм түгел. Әмма шунысы хак: аны үз нәселе генә түгел, дөньяның һәр яналыгы, бизәге, кызыгы-кызганычы, шатлыгы-кайгысы кызыксындыра. Шуңа күрә бу көндәлек дәфтәрләр борын төбендәге хәл-әхвәлләр теркәлеше генә булудан ерак торалар. Алар — шул чорның бөтен чуарлыгын туплаган кадерле елъязма буларак, тарихчыларга һәм әдәбият галимнәренә генә түгел, дөньяны кинрәк танып белергә омтылучы бик күп ул-кызларыбызга, оныкларыбызга кирәк булачак әле. Шикләнми әйтә алам, киләчәкнең кайсыдыр әдибе мәртәбәле, талантлы, гаҗәп язмышлы бу нәсел турында документаль әсәр дә язачак. Материалларны күктән-түшәмнән эзлисе яки бармактан суырасы түгел, алар — кул астында. Ул чорда бу елъязмалар Фәрит Баттал кулында булырлармы, нәселнең бүтән кешесендәме — изге ниятле каләм иясеннән яшермәсләр, кадерле сандыкны киереп ачарлар...

Язмамны түгәрәкләр алдыннан, тагын бер сүзем бар. Язучыларның шактые һәм әдәбият сөючеләр Казанның бер урамына Салих Баттал исемен кушуны куәтлиләр. Минем уйлавымча, бу нәселдән бер шәхесне генә аерып алып хөрмәтләү, зурлау гадел булып бетмәс. Киләчәктә сүз «Батталовлар урамы» яки «Батталлар урамы» турында барсын һәм шулай гамәлгә ашсын иде, чөнки бу нәселдәге күп шәхесләр милләтнең мәңгелек хөрмәтенә лаек һәм алар, тормышта бердәм булган кебек, һәйкәли истәлекләрдә дә бергә булсыннар иде. Аермаска иде аларны, аермаска иде!..

Июнь, 1997 ел.

## Аккан сулар кире кайтмый...

Әйе, моннан унсигез ел элек язган, әзерләп куйган ошбу язмамны шәхси архивымнан күтәреп алгач һәм укып чыккач, әнә шул җыр янгырый башлады күнелдә:

*Аккан сулар кире кайтмый,*
*Яшь гомерләр дә шулай...*

Кая монда яшь гомерләр генә, хәтта тулы гомерләр дә кире кайтмас өчен үтеп китә һәм хәтерләрне янартып тормасаң, тарих чонгылына төшеп югала. Менә сез олуг шагыйрь Салих Баттал турында истәлекләр укыдыгыз... Әле кайчан гына арабызда иде кебек бит... Инде менә анын тууына быел − 110 ел...

Дөресен әйтим, Салих абыйның үзе белән сирәк очраштым мин икәүдән-икәү генә калып... Монын сәбәпләре дә булды сыман. Мәсәлән, мәктәп елларымда ук анын да шигырьләрен еш укый идем. Хәтта «Олы юл буйлап» дигән поэтик романын укып чыгарга да сабырлыгым житте бала башым белән. Ә инде бер шигырендәге:

*Баттал икәнемне онытсам да,*
*Постта икәнемне онытмам! −*

дигән юлларын укыгач, күкрәгем киерелеп киткәндәй булды. Әнә бит, минем фамилиямне дә нинди горурлык белән янгыраткан, янәсе!

Әйе, мин туып үскән Минзәләгә Казаннан килүче әдипләр дә анын горур холыклы шагыйрь икәнлеген сөйлиләр.

Кайберләре, безнен чор язучылары кебек, агулы яки көнчелекле елмаеп, авыз чалшайта:

− Эре кыйлана инде... Сөйләшкән чакта авызыннан урысча сүз чыкса да: «Тәржемәсе болай анын», − дип төрттереп китеп бара... Кире кеше!

Ә инде якташ шагыйребез Рәшит Гәрәй белән сокландыргыч хикәяләр остасы Габделхәй Сабитов мондый кыйсса да сөйләп көлдерделәр...

СССРнын Югары Советына ничәнчедер сайлаулар алдыннан сайлаучыларны

барлап-теркәп өйдән-өйгә, фатирдан-фатирга йөрүче агитаторлар була иде. Шул җәһәттән Салих Баттал фатирына әзерләгән кәгазьләрен тоткан, култык астына папка кыстырган маржа килеп керә дә, берничә кәгазен өстәлгә җәеп салып, кайбер мәгълүматлар турында сораштыра башлый. Теге сүз башлауга ук Баттал:

– Русча белмим, татарча сора. Мин – татар! – дип куя салкын гына. Ә агитатор марҗаның гаҗәпләнүдән күзләре түгәрәкләнә:

– Как-так «бельмимь»? Вы ведь фронтовик?! Всю войну прошли!

– Белмим! – дип кистерә дә Баттал, урыныннан кузгала... Аптырашта калган хатын кабаланып чыгып китә дә урамнан бер татар кызын әләктереп керә. Тәрҗемә итәчәк, имеш... Ә «кире» Баттал әйтә кызга:

– Син, сеңлем, бу апана: «Татар агитаторы килсә генә җавап бирәм, дип әйтте бу абый», – диген дә чыгып кит. Бер марҗа алдында ике татарның тылмачлыгы килешми ул... Әнә бит, Татарстан дигән татар илендә яшәп тә безнең телне санга сукмаган ул...

Йә, укучыларым, сәерме? Сәер генә түгел, Хрущёв бабагыз «егерме елдан коммунизмда яши башлыйбыз!» дип бөтен дөнья алдында шапырынган заманда сәер генә түгел, коточкыч хәл бу!

...Ә инде шуннан соңрак Казаннан әдәби очрашуларга килгән язучылар миңа – 24 яшьлек егеткә тагын да хәтәррәк хәбәр әйттеләр:

– Бетте адаш абзаң! Партиядән дә кудылар! Үзен үзе харап итте!

Һе, урыс кавемендә гасырлар буе онытa алмаслык батырлыклар кылган Батыйхан турында «Батыйханга хат» дигән поэма язган икән дә Язучылар союзы съездының трибунасыннан шул әсәрен укый башлаган, имеш. Обкомнан килгән вәкилләр, корт иләнә әләккәндәй дәррәү кузгалышып, авызын яптырганнар шагыйрьнең...

...Моннан утыз бер ел элек, Казанга күченеп килгәч, республика радиосында эшли башладым. Салих Баттал, берничә тапшыруымны тыңлагач, радио башлыгы Фәтхи Фазылҗановка шалтыратып:

– Фәнзаман Баттал сездә эшли башлаган икән. «Баттал» исемен түбәнәйтмәс микән? Чорга яраклашучы булмас микән? – дип белешкән.

– Андый гадәте сизелми, фикерләрен турыга яра, – дигән Фәтхи агай.

– Ярый алайса, тынычлап йоклармын, болай булгач, – дип, сүзен бетергән.

Ләкин... язып торуның кирәге бар микән... тагын бер кызык истә калды шул ук чордан...

Бер-ике ай элек кенә ил башына К.У.Черненко утырган иде мин күченгән чакта. Әзерләнгән чираттагы тапшыруым белән таныштыру өчен, баш редактор Роберт абый Гатауллин янына кердем. Күз йөртеп чыкты да язганыма, сер әйткәндәй генә кинәш бирде:

– Карале, Фәнзаман, гаеп итмә, бу язмаңнан унайлы урын сайлап, бер-ике җөмлә өстәү чарасын тап әле, яме... «КПССның Генеральный секретаре Черненконың зирәк җитәкчелеге белән рухланып, бу район хезмәтчәннәре планнарын уңышлы үтәп баралар» кебегрәк җөмлә инде ул...

Шулчак, сәерсенеп күлдем дә күзенә карадым. Ул да, күземә карап көлгәч, әйтте:

– Обкомда әйтеп җибәрделәр миңа шулай кирәклеген... Үзең дә сизәсеңдер, Константин агайның калган гомере елдан да артмас сыман... Ул да, башка генеральныйлар кебек, үз исемен мактаудан рухланып җан асрый икән...

Тагын да көлешкәч, тегенди җөмләне тыктым да текстка, дикторга кертеп бирдем: кем әйтмешли, рәҗе җалке бер җөмлә үзем хөрмәт иткән гадел редакторым хакына! Минем дә, аның да радиосы түгел ләбаса бу – нәкъ менә КПСС үзен пропагандлау өчен финанслап тора бит аны!

Монысын, шөкер, өлкән Баттал ишетмәде сыман – кайтавазы ишетелмәде...

Бервакыт, республика гәҗитенә чираттагы язмамны тапшырып коридорга чыксам, ни күрим, шул ук редакцияне әле – бер, әле – икенче, өченче... ишекләрен ачкалап йөрүче Салих Батталны күреп алдым. Ярсыган да, өтәләнгән дә кебек теге. Шулай да тыныч кына каршысына бастым, тавышымны да йомшартырга тырышып сорыйм:

– Әллә яңа әсәр китердеңме, Салих абый?

– Әйе, исәр турында әсәр яздым. Мә, укып кара!

Укыдым өч-дүрт кенә строфалы шигырен... Тик ике юлы гына истә калды. Болайрак иде ул юллар:

*Файдасыз бәндә син, Ельцин.*
*Дөнья сасыткан җил син!*

Бастырдылар микән ул шигырьне гомер-бакый түрәләр көен генә көйләп яшәүче ул гәҗиттә — белмим. Әгәр дә ул шигырь исән калган булса, аны укыган замандашларым гаеп итмәсеннәр мине: каршымда үрсәләнеп торган 88 яшьлек әдипнең нервысы кайнавын сизгән халәттә тәгәл истә калдыра алмадым мин ул юлларны...

Ә инде кабат бер елдан соң, Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшләгәндә, Салих Батталның «Сигезенчесе кем?» дигән повестен тоттырдылар кулыма, редакцияләү өчен.

— Бәй, аның бу китабын күптән укыган идем бит инде... — дип сүз башлавыма ук авызымны яптырдылар.

— Ул аны, өстәмәләр дә тыккалап, үзенчә төзәткәләп кабат әзерләгән. Быел аның 90 яшьлек юбилее. Өлгерт!

— Мажаралы, детектив кимәлдәге әсәрен редакцияләп бетергәч, шул ук папкага салынган фоторәсеменә текәлеп карап торгач, ошатмадым китапны ачуга ук укучы күзенә бәреләчәк ул рәсемне... Беренчедән, картаеп, табигый ямьсезләнеп беткәч төшерелгән рәсем бу, икенчедән, түшендә сугышта алган шыптыр-мыптыр медальләр тезелеп тора. Язучыны хәрбиләрдән генә түгел, корольләрдән дә затлырак булырга тиеш дип инанган бу бәндәгез хуплау тапмады ул фотода. Өенә сәгать чамасы алданрак шылтыраттым да янына киттем. Аскы катта гына яши икән — кердем. Сәламләштек. Шуннан соң өендәге чисталыкка, тәртипкә күз төшергәч, бернечә мизгелгә телсез калдым. Бер генә «кимчелек» шәйләдем, ятагының читендәге идәнгә бернечә гәҗит, журнал, китап коелган... Шул ук вакытта борыным сизде: фатирына тәмле ризык исе таралган.

Баксаң, һәр хәрәкәтемнең, карашымның кай тирәдә йөрүен күзәтеп торган икән картлач!

— Кемгә ничектер, минем яраткан тәртипсезлегем ул. Матбугатны яткан килеш башка сеңдереп укырга яратам мин! — дип куймасынмы!

— Бигрәкләр дә чиста яшисең икән, Салих абый. Кардәшләрең җыештырып китәләрдер инде көн саен...

Аның урынында башка кеше булса:

— Рәхмәт инде мактавына... — кебегрәк сүз ишеттергән булыр иде. Ә бу, идән уртасында бөтергәләнеп:

— Нәрсә дидең? Башкалардан җыештырту көненә калмаган әле Салих абзаң. Көн саен тузанны суыртып чыгам да лентяйкамны болгый-болгый идәнне дә юып алам. Чиста өйдә генә тыныч күңел белән иҗат итеп була чөнки!

Әйтеп кенә калмады, буш кулында лентяйка сабы бар сыман хәлдә, җилпенгәләп тә күрсәтте. Шуннан соң кайнап чыккан чәйнүгеннән чынаякларга су агыза-агыза чәй пешерде дә, духовкадан җалт кенә кәтлит, тавык ботлары чыгарып, өстәл янына әйдәде. Тик тора белмәгән телемне үземнең дә кисеп ташлыйсы килгән чакларым була. Алдына килгән ризыкны тыныч кына ашыйсы бит инде, югыйсә! Ләкин ашамлыкларын капкалап карауга ук телем чишелеп китте, каһәр.

— Бигрәк тәмле пешкән ризыкларың. Каршыңдагы «Маяк» рестораныннан алгалыйсыңдыр, туганнарың да әзерләп калдырадыр инде...

Тагын кыбырдап куйды да Салих Баттал, ике сәдәбе генә каптырылган күлмәген ике кулы белән як-якка аерып вә һәм дә күкрәгән алгарак чыгарып, тагын да усалрак ыңгырашкан сыман:

— Мин үз тамагыма ризык та әзерли белми торган кешемени?! Сугышта чакта бернечә атна бер полкны ашаткан кулинар мин, бик беләсең килсә! Әллә син мине, бер генә дә җиргә төшмичә, күктә генә очып йөргән дип беләсеңме?

Бу юлы мин түзмәдем — ихлас күңелдән көлдем. Аннары:

— Безнең кайбер осталыклар, гамәлләр бер икән бит, — дидем. — Мин дә армиядә чакта төзәүче артиллерист булдым, Украинаның Жмеринка шәһәрендә

хезмәт иттем, шул чакта полктан Житомирга җибәреп, өч ай ярым кулинарлыкка да укыттырдылар...

Шулай дустанә ун минут чамасы әңгәмә корып утыргач һәм бу картны йомшады дип фаразлагач, монда килүемнең төп сәбәбенә күчтем.

– Менә, Салих абый, кулъязманны укып чыгып, нәшриятка тапшыру әзерлегенә китердем. Бастыра башласак, юбилееңа житешер ул. Тик менә сиңа бер тәкъдимем бар... Син бит ул китапны яшь чагың турында, үзең дә шактый яшьрәк чакта язгансың. Әллә соң, мин әйтәм, китабыңның титул бите белән янәшә биткә шул чактагы фоторәсемеңне куйыйк микән дип әйтүем... Киңәшкә килдем янына...

Күрдеңме, укучым, минем сөйләү рәвешен? Кирәк чакта шундый тактлы, тыйнак, әдәпле сүзләрем белән таштай каты холыклы күп кешеләрне дә эреткән, үземнең киңәшләремне үтемле иткән кеше мин, югыйсә... Ләкин бу юлы тагын барып чыкмады теләгем.

– Йә-ә...Шулай итсәк, ни булыр-р?

– Китабың да матуррак, үз рәсемең дә чибәррәк булыр иде.

Тагын күкрәк киерде бу:

– Мин хәзер ямьсезмени?! Калсын, шул фотомны бир китабыма!

Менә шулай булды аның белән соңгы сөйләшүебез. Дөрес аңлашылсын, арабыз чак кына да суынмады. Тәмле ризыкларын ашатып, матур итеп озатып калды. Шулай да чыгарга җыенган чакта әйттем:

– Шулай да үзсүзле, фикереңнән чигенмәүче зат син, Салих абый! – дидем елмаеп, күзенә туры карап. Бәй, ул да елмайды. Ә инде ишек тоткасына кулымны куйгач, болай диде:

– Син үзең дә миннән шәбрәк түгел. Язуларыңа караганда, син дә күп кыйналырсың әле, ләкин чигенмә, үзең булып яшә!

Күземә сеңеп калган сурәте – нәкъ менә «мин хәзер ямьсезмени?!» дигән җөмләсендәге «мени» өлешен әйткәне – гомергә күз алдымнан китми... Шул чакта аның ияге һәм аскы иреннәре төште, теш казнасы төбенә кадәр күренерлек булды...

Шуннан соң ул ике ай да яши алмады кебек. Әйткәнемчә, янып үлде. Фатиры салкынаеп киткәч, ятагына кайнар һава өреп торучы электр җылыткычы куйган булган. Йокыга киткәч, одеялы шуып төшеп, әлеге җылыткычны каплаган һәм яна башлаган. Салих Баттал, шуның ялкыны өтә башлагач, торып форточканы ачарга барганда, жаны тәненнән аерылган...

Шулай, мин сезләргә олы адашымның язмышын, холык тәкәлекләрен яшермичә сөйләп бирүне кирәк санадым. Чөнки әсәрләрен яратып укыганда, без аны батыр сугышчы, үз мәсләгенә кыю баручы олы әдип икәнен генә түгел, бәлки аның холык-фигыльләрен дә, яшәү рәвешен дә күзалларга тиешбез. Чөнки зур шәхесләрне бары тик җансыз һәйкәл рәвешендә генә сурәтләп, мактап кына язучы галимнәр һәм каләмдәшләр артык күбәйде.

Соңгы ноктамны куйдым дип сөенергә дә өлгермәдем, Салих Батталның үзем редакцияләгән әлеге китабы искә төште... Ул елда мин басарга тапшырган китапны типографиядән кире алып менделәр һәм мине:

– Үлде бит инде авторы. Ашыктыручы юк бит... Җае чыккач басылыр әле, – дип юаттылар. Һәм аны... кабат ун ел үткәч, әдипнең 100 еллыгы уңаеннан чыгарганнар. Шунысын да әйттеләр нәшрияттагы эштәшләрем: аның «редакторы Фәнзаман Баттал» дигән кәлимәсен алып ташлап, аның урынына бүлек редакторы үз исем-фамилиясен куйган икән.

**Фәнзаман БАТТАЛ**
*22 февраль, 2015 ел.*

# АРЧА КЫРЫ

## ГАРИФ АХУНОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

1984 елның май аендагы кызыл бәйрәмнәре үткән иде инде. Иртәнге уннар тирәсе. Язучылар оешмасының пропаганда бүлегендә телефон тирләтеп утырам.

– Сине Гариф абый эзли! – дигән тавышка сискәнеп киттем. Ничек инде эзли?! Менә бит инде мин, дим аптырашка калып. Ярар, артык сүз көрәштерә торган чак түгел, Идарә язучыларның X съездына, ягъни отчёт һәм сайлауга әзерләнә, йомыш кушасылары бардыр.

Председатель бүлмәсендә бүз плащ кигән Сибгат Хәким белән көрән төстәге жинел курткалы Мөхәммәт Мәһдиев утыра. Урыннарыннан кузгатмыйча гына күрешеп чыктым да Гариф абый өстәле каршында үрә каттым:

– Мин иртәдән монда...

– Ә куда ты денишься, дигән иде берәү! – Шөкер, Гариф абыйның кәефе иртәдән үк шәп күренә. – Кәримов, Арчаны урап кайтабыз.

– Мин бит әле...

...Ун көн элек кенә, Арчаны аркылы-торкылы гизеп, 24 чыгыш ясап кайттым, дип Филармония оештырган лекторийда кызыл афишалар күтәреп йөргәнемне әйтмәкче идем – өлгермәдем.

– Кәримов, эшең качмас, – диде ул үзенчә фаразлап, машина аста көтә, сиңа биш минут!

Мәһдиев белән Ахунов уртасында барам. «Волга»да йөргән кешеләр хәтерлидер инде, уртадагы урынның аяк астына өрлек чаклы кардан валы туры килә. Шуңа күрә дә Арчаның дүртенче магиканы Гомәр Бәширов сәяхәт арбасына сыймагандыр. Ә минем әле 60 килолы чагым гына...

– Менә, Кәримов, без – өч якташ, туган авылларыбызны күреп кайтырга дип чыктык. Ие-е! Сибгат абыең да Арчаныкы, ул Әтнәнеке булып-булып кына ала.

– Арагызга сыйдырганыгыз өчен Питрәчемнең рәхмәте яусын сезгә! – дим. Яшермим, үземнең бүген мине нинди сынау көткәнен бик беләсем килә.

– Ә сине без, Кәримов, Әгерже кияве буларак ияртеек, – диде Гариф абый, тавышын уйнатып.

Алда утырган Сибгат абыйның йөзен күреп булмый – «Халык шофёры» Тәлгать абый кашагадагы көзгене үзенә борып куйган. Ә менә Мөхәммәт абый йөзендә кинаяле пауза саклап, шактый барды әле. Ник дигәндә, Гариф абыйның үзе дә Әгерже кияве икәнне бөтенебез беләбез.

Сагыну... юксыну... жирсү, туып-үскән нигезгә кайтып гыйбадәт кылу – еш кына зур югалту белән бәйле. Абзыйларның өчесендә дә бер үк гамь дип уйламыйм. Гариф абыйда хикмәт: Язучылар оешмасының ун еллык рәисе; ун ел буе СССР Югары Советы депутаты; нәфис фильм төшерелгән «Хәзинә»се; «Хужалар», «Габбас хәзрәт», «Идел кызы» трилогиясе авторы; драматург, публицист, тәржемәче; баскычны текә куеп, тиз арада үргә менгән авторитет; 50 яшендә дөнья шаулатып юбилей кичәләре үткәрә алган Гариф Ахунов – киту белән калу арасында.

Бүгенгеләр 50дән узгач Союзга керә генә әле. Гариф абыйның «рекордларын» башка бер генә рәис тә кабатлый алмаячак!.. Тик X съездда Партия галиҗәнаплары ни кыласын әлегә беркем дә белми.

– Докладлар әзерме? – Сибгат абыйның, иренеп кенә сөйләшкән кебек, кыска-кыска жөмләләре Ахуновны каушата торган иде.

– Менә, проза буенча докладчыбыз, яныбызда утыра, ие-е! Аягүрә басып жавап бир сорауга!

– Фәрвазга бирдем. – Мәһдиев кинәт житдиләнде. – Укып чыгасым килә, диде.

– Юзинеке күптән әзер.

– Илдарга рәхәт аңа – ул союзда зарплатага эшли. Ә минем укыту, жәмәгать эшләрем сырып алган... Кыл да сыймый.

— Күрденме, Сибгат абый, төп докладлар әзер. Инде бөтен өмет синдә: син ачасың, ябасың да син!

— Ябуы кыенрак... Бәлки тимәсләр әле.

— Мина калса, хәл ителгән инде, Сибгат абый, «пенсиягә чыгуы» формулировкасы белән...

Алар миннән тел яшерүне кирәк дип тапмадылар, Язучылар съездының иң мөһим көн тәртибе, имеш-мимеш булып, әдәби мохиткә таралган иде инде.

— Туфанны үгетлиләр икән дип ишеттем.

— Гафу ит, Сибгат абый, Туфан драматург буларак көчле дә, ну ул житәкче түгел.



*Шигырь бәйрәмендә. Сулдан уңга: Гариф Ахунов, Туфан Миңнуллин һәм Сибгат Хәким. 1984 ел, 26 апрель.*

— Ринатның да поддержкасы зур.

— Ашыкмасын. Парторг вазифасы да таман гына әле ана, шулаймы, Мәһди?

Мәһдиев, никтер, Ахуновны якларга ашыкмады:

— Мансур Хәсәновичның бер сүзе житә. Куймый кая барасың.

— Бер сүз, дип, моннан ун ел элек тә, Сибгат абыйны Союзга Табеев үзе куймакчы иде, ә халык мине сайлады.

— Анысы бүтән ситуация, — дип, аксакал нокта сукмакчы иде, Мәһдиев эләктереп алды:

— Сибгат ага, сөйләгез әле шул притчаны.

— Аны сез генә уйлап чыгардыгыз. Үзең сөйлә. Сөйлә. Халыкка таралган инде ул.

Мәһдиев машинадагы әңгәмәнең әкренләп киңәшмәгә әйләнә баруын бик өнәмәгән иде, шуңа күрә дә ялындырып тормастан, аксакалның жан тамырына төбәп сөйли дә башлады.

— Съезд алдыннан Сибгат Хәкимне Обкомның I секретаре чакыртып ала... Булдымы шул хәл?

— Табеев мине еш кабул итте... Шуннан?

— Табеев әйтә, Сибгат Тажиевич, без сезне Язучылар союзына председатель итеп куярга телибез, үзегез ничек уйлыйсыз бу хакта, ди... Белмим шул, ди Сибгат ага, кинәтрәк тәкъдим булды... Өйгә кайтып, хатыным белән киңәшеп карарга иде, ди. Ярар соң, ди секретарь, кайтыгыз, киңәшегез. Иртәгә нәкъ шушы вакытта көтәм, ди... Булдымы шул хәл, Сибгат ага?

— Бәлки булгандыр да.

— Икенче көнне Сибгат Хәким төгәл вакытка килеп житә. Табеев бик кырыс кына каршы ала моны. Йә, Сибгат Тажиевич, сез ризамы, ди. ...Мөршидә белән киңәшкәнием: ярар, куйсыннар, диде.

Табеев та жете генә жавап бирә. Мин дә өйгә кайткач хатыным белән киңәшеп карадым, ә ул: куйма син аны председатель итеп, диде...

— Даһилар хакында мәзәк күп чыга инде ул. Халык авыз ижатына кертүегез өчен рәхмәт кенә... Ну мин үзем ризалашмаган идем ул чакны.

— Ә мин халыкка ышанам, Сибгат ага Мөршидәсе белән киңәшмичә тын да алмый, диләр бит.

— Ә син үзең соң, минут саен яулыгың белән киңәшер өчен Шаһиданы ун ел буе Союз китапханәсендә бикләп тоттың.

— Әгерже хатыннары көнчел бит алар, әйеме, Кәримов? — дип Гариф абый мине калак сөягемнән «шап-шап» итеп сөеп алды.

Беркавым тынлык урнашты, тик бу тынлыкта Сибгат аганың үпкәләп баруы сизелә иде. Мин, батыраеп, Гариф абый турындагысын сөйләп киттем.

— Гариф Ахунов белән Нәби Дәүли Обком бүлнисендә икесе бер палатага туры килгәннәр ди. Нәби Дәүлинең хәлен белеп йөрүчеләр бик юк ди, ә Гариф абый янына көн саен тәм-том күтәреп Гөлшаһидә апа килеп йөри ди. Нәби Дәүлинең эче поша моңа. Шулай беркөнне Шаһидә апа кайнар өчпочмакларны ашъяулыкка төреп алып килә. Кемең бу, Гарифҗан, дип сорый Нәби Дәүли, танымаганга сабышып. Ничек инде кем, Гөлшаһидә, күрмисеңмени — хатыным бит... дип өзгәләнә Гариф абый. Нәби Дәүли, исе китмичә генә, хатынның, ә кичә пилмән пешереп алып килгәне кем иде, ди. Шаһидә кайнар шулпалы өчпочмакларны Гариф Ахуновка каплый да, ах, оятсызлар, сез әле монда гыйшык-мыйшык уйнап ятасызмы, дип, пырылдап чыгып китә.

— Шәп мәзәк! Ишеткәнем югые әле, — дип, Ахунов тагын аркамнан сөйде.

Сибгат аганың да ике иңбашы тигез дерелди — тавыш-тынсыз гына көлүе...

Әйткәнемчә, «язучы хатыны» дигән, ифрат дәрәҗәдә четерекле һәм дә мәртәбәле профессия бар. Һөнәр түгел, һөнәргә укытып була.

Арча кырына бер кергәч инде... Гомәр Бәшировның туына 110 ел тулу уңаеннан үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдә унбиш секундлык кына күренеш бар иде. Гомәр ага ролендә — Инсаф Абдулла — язу өстәле артында утыра. Нәкъ шул чакны, язучының хатыны Кәримә ролендә, Гөлчәчәк Хафизова бер касә чәй чыгарды... Шушы күренешкә К.Тинчурин исемендәге театр залын шыплап тутырган тамашачы, аягүрә басып, озаклап кул чапты. Алкышлар Гомәр аганың хатыны Кәримәгә, ягъни Мәһдиевнең хатыны — Лилиянең сөекле әнисенә, шулай булгач, бүгенге Гәүһәр Хәсәнова-Мәһдиеваның дәү әнисенә дигән сүз! Барысына да берьюлы!

Гариф Ахунов чорында Язучылар оешмасының штатында 23 кеше иде, «Яңа ел», «8 март», «9 май», «7 ноябрь» кебек олуг бәйрәмнәрдә зурлап табын кору матур традициягә әверелгән иде. Гадәттә, мәҗлесләр Илдар Юзеев утырган әдәби консультация бүлмәсендә уза. Тостлар күпләп-шәпләп әйтелә. Кагыйдә буларак, йомгаклау сүзе «Беренче Ледига» бирелә. Һәм банкет гаилә табынына әйләнеп куя иде. Әйе, ир белән хатын икесе бер җирдә эшләсә, эш урыны барыбер гаилә учагына әверелә инде ул...

«Телогрейка киеп, тегеннән кайтып кергән көннәреңне хәтерлисеңме, Гарифҗан?!»

«Әйе, әнкәсе, әйе, хәтерлим...»

«Мин, үземнең талантымны корбан итеп, сине зур язучы иттемме?!»

«Әйе, әнкәсе, рәхмәт сиңа шуның өчен!»

Чынлап та: хатын ирен «солдат» та итә ала, «сенат» та итә ала, ди халык. Бу яктан килгәндә, Шаһидә Максудова — Гариф Ахуновның багалмасы һәм таянычы.

Хатын-кызлар димәктән, Ахунов чорында 172 язучының 16сы гына иде алар, шуна күрәдерме, хатын-кыз иҗаты татар әдәбиятының авангарды була алмады. Әгәр, 2-39-52 номеры белән, берәр ханым Илдар Юзеевка: «Але», әдәби консультация бүлегеме бу?» — дип шалтыратса, Илдар Юзеев еш кына: «Эһе! Женская консультация бүлеге тыңлый», — дип җавап бирә торган иде...

Бүгенге көндә кызыл билетлы ханым вә туташларыбызның саны йөздән артып китте. Әлбәттә, аларның күбесе язучылы гаиләдән, калганнары укытучылар-тәрбиячеләр булыр — бу бик табигый күренеш.

Сүз уңаеннан, 2009 елны үткәрелгән «Иделем акчарлагы» конкурсында катнашкан 37 авторның тик берәве генә малай кеше (Михаил Шишкин) иде, калганнары гел кызлар. Ирексездән Илдар Юзеевның шаяртуында әүлиялык чалымнары булган диярсең.

Гүзәл затларыбызны иҗат газабына дучар иткән сәбәпләр күп, әлбәттә: эшсезлек, кризислар, дефолт, инфляция, депрессия, илләр арасындагы конфликтлар, киләчәкнең билгесезлеге h.б. Бу нисбәттән — ирләр гамьсезрәк... Гамьле кызларның күмәртәләп иҗатка ябырылуы могҗиза түгелдер, ул — фаҗигадыр...

Ни өчен соң без Гариф Ахунов чорын шул тиклем сагынабыз? Чөнки безгә соцзащита, соципотека, соцслужба, соцпакет кебегрәк сүзләр бик якын. Ахунов чорында иҗатыбыз соцәдәбият иде. Һәр яңа әсәр кульязма хәлендә үк бәяләнә, «Казан утлары» журналында басылган роман һәм повестьлар ачык партия җыелышларында анализлана, шуннан соң гына китап нәшриятына тәкъдим ителә иде. Тыйнаклык, гаделлек, иҗади

активлык, яшәү-эшләү һәм түләү ягыннан даими гарантияле (торгынлык түгел) чор булган ул. Без Гариф Ахунов чорын социализмны сагынган кебек сагынабыз...

Ни кызганыч, бүген без житәкчеләрне эш бирүче һәм акча бүлүче «работодательләр» буларак кына хөрмәт итәбез. Гариф Ахунов чорында житәкчелек үзенең эшчесен, безнең очракта язучысын, яклый ала торган ышаныч иде. Гариза язарга иренмәгән язучы теләгән вакытта уч тутырып матди ярдәм алды. Пицунда, Цхалтубо, Дубулты, Малеевка кебек ижат йортларына путёвкалы булды. Китап нәшриятының Язучылар идарәсе белән берлектә төзелгән тематик планы Мәскәүдән үзгәрешсез расланып кайта да 15-17 табаклы проза йә 5-6 табаклы шигырь китабы чыгарган автор бер «Жигули»га житәрлек гонорар ала торган иде.

1974-1984 еллар эчендә 172 язучының 120се яңа фатирга күчкән йә искесен яңарткан. Ә фатир артыннан йөреп, түрәләрне ышандыра алган төп кайгыртучы Гариф абый үзе гел Новаторлар урамындагы иске фатирында яшәп калды. Бүгенге чиновникларның төшенә дә кермәслек тыйнаклык бу!

1974 елны язучыларның VIII съезды сайлаган идарә составын аерым санап үтәсем килә[1]: Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин, Мирсәй Әмир, Азат Әхмәдуллин, Гомәр Бәширов, Әхсән Баянов, Марсель Зарипов, Мәдинә Маликова, Әдип Маликов, Туфан Миңнуллин, Зәки Нури, Вакыйф Нуруллин, Геннадий Паушкин, Атилла Расих, Шамил Рәкыйпов, Гәрәй Рәхим, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Марс Шабаев, Илдар Юзеев... Юк, мин бу исемлекне бүгенге идарә составы белән чагыштырыр өчен язмыйм, Гариф Ахунов, яңа рәис буларак, менә нинди команда белән килде, дип кенә әйтергә телим. Шуна күрә дә элек идарә ни карар кабул итсә — шул тормышка ашкан.

Үз жәрәхәтемә үзем тоз сибеп булса да, фикеремне дәвам итим. Элек Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә Идарә тарафыннан бирәр автор күрсәтелә икән (әлбәттә, КПССның Өлкә комитеты белән киңәшеп), ул, һичшиксез, олуг бүләккә лаек була иде, ә инде Ә.Еники, Г.Бәширов, М.Мәһдиев исемнәре бераз читерелеп килгән икән, Идарәне генә гаепләргә ашыкмагыз.

Ул чакта Тукай премиясе турындагы положениедә «широкое обсуждение» дигән кагыйдә булмаган да ахрысы. Мәкалә язып фикер алышу беренче тапкыр 1997 елда гына, ягъни Ренат Харисов ижаты тәкъдим ителгәч кенә башлана: «Мәдәни жомга» газетасында бер-бер артлы өч мәкалә басылып чыга (авторлары: Т.Галиуллин, М.Кәрим, Р.Шаһиева). Шуннан мәкалә ярышы азына да инде. 1998 елда Роберт Миңнуллин кандидатурасын яклап, шул ук «Мәдәни жомга»да 5 (биш) язма тәкъдим ителә. Шулай итеп, бу ярыш модага кереп китә. Хәзер исә «широкое обсуждение»ләр интернет челтәре аша яшерен тавышлар иленең гайбәт репрессиясенә әверелде...

Шактый гына читкәрәк кителде. Шагыйрь әйтмешли, сүз башым бит Шүрәле...

«Волга»быз Гариф Ахуновның туган авылы, дип килеп туктады. Моннан Күлле Кимегә, кайтышлый Гөберчәккә дигәннәр иде.

— Шүрәле каргаган Өчиле авылы шушында иде инде. Менә, менә... монда түбәнәй иде... Нигезебез урыны да беленеп тора, менә, карагыз... Әле капка баганабызның төпләре дә исән, имән бирешми шул...

Баштарак Гариф абый тавышында югалган уенчыгын эзләп тапкан сабыйлар сөенече бар иде. Ишелгән баз, нигез чүбе, кычытканлы түмгәкләр арасында бәргәләнә торгач, ул сөенеч өзгәләнүгә һәм әкренләп сыктануга әверелде... Кульяулыгы белән күз төпләрен корытканда, самими жанның сынганын күрмәс өчен, читкәрәк китеп бастык...

— Минем авылга кайтып тормабыз ахрысы. Башка вакытта... — диде Сибгат ага, бик төшенке тавыш белән генә.

— Алайса кире борылабыз. Гөберчәккә!

Гариф абыйның әмерен Мәһдиев «ә?» — дип тә, «жә!» — дип тә жөпләмәде, көчәнебрәк елмаюы үзе бер жавап иде бугай.

Өчиле туфрагыннан ерагайгач, Гариф абый, куен кесәсеннән уртага бөкләнгән дәфтәр чыгарып, нидер язып куйды. Яшереп түгел, дәфтәрне тезенә куеп, укырга рөхсәт иткән кебек, ачылып язды: «Өчебез дә шушында кайтып тупләнсәк, тагын Өчиле була...» Ул бу сүзне бая гына Сибгат агага әйткән иде.

[1] Исемлек Равил Фәйзуллинның «Гыйбрәтләр алырлык үткән юл» китабыннан *(Казан: Идел-Пресс, 2006)*.

Гариф Ахунов үзенең авторитеты белән президиумнарга даими сайланган житәкче иде. Тик утырмас, кызыл постау өстенә дермантин тышлы калын дәфтәрен жәеп, туктаусыз яза торыр: кемнең кайда ни кызык әйткәнен; залдан ишетелгән репликаларны; өлкәнрәкләр чыгышындагы өземтәләрне, авторын атап, чәчми-түкми теркәп бара. Ул дәфтәрләрнең берсендә минем исемем дә сакланган булырга тиеш...

1989 елның августында, Ринат Мөхәммәдиев житәкчелегендә, язучыларның зур төркеме, урып-жыю барышын күрергә дип, Әгерже районына килеп төштек, Тирсә, Тәбәрле, Салагыш якларын айкап, кичен Әгерженең мәдәният сараенда иркенләп әдәби кичә үткәрдек. Әгерже хакимияте чыгыш ясаган һәр язучыга сөяннән кырдырып эшләнгән бизәкле, капкачлы чүлмәк бүләк итте — эче тулы шифалы юкә балы! Делегациябез житәкчесенә, шулай ук Туфан Миңнуллин, Гариф Ахуновларга бер литрлы чүлмәкләр эләкте, соныннан чыгыш ясаучыларга, шул исәптән миңа да күчтәнәчнең майонез банкасы чаклысын гына бирделәр. Әгерже кияве буларак, батыраеп, микрофонга якынрак килдем дә:

— Әдәби кичәбез ахырына якынлаша бугай, чүлмәкләр вагая башлады... — дидем.

Ике сәгать буе акыллы сүз тыңлап алжыган зал шушы жөмләдән дә рәхәтләнеп көлеп алды. Шулчак Гариф абый президиумның икенче рәтендә утырган Рашат Низамиев белән Шаһинур Мостафинны өтәләде: «Нәрсә диде, Кәримов?! Халык нидән көлде, ишетми калдым?»

Күршеләре кайтарып әйткәч, Гариф абый аны дәфтәренә теркәп куйды.

Көндәлек алып бару — язучы ирләр эше, бу шөгыль инде хәзер аерым жанр буларак та формалашты. Кызлар исә егет сөяр яшьтә генә көндәлек язгалап ала. Ә ирләр — прогматиклар — үз биографиянне башкаларга язарга калдырма — йә су кушарлар, йә артык чынын ачып салырлар, дигән караш белән картая. «Йолдызлар калка» китабында Гариф Ахуновның биографиясенә Г.Әпсәләмов, И.Гази, Х.Туфан, Ш.Маннур, С.Хәким, Г.Кашшаф, Г.Бәшировларның олпатлыгы; Т.Миңнуллин, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, М.Әгъләмов, Зөлфәт, Г.Рәхимнәрнең егәрлеге; Р.Вәлиев, Р.Миңнуллин, М.Галиев һәм Ф.Сафиннарның яшьлеге сыйган...

Мөхәммәт Мәһдиев Гөберчәккә бик ашыктырмады, Сеҗе турысына житәрәк, юл өстендәге кибеткә туктатты. Казаннан ике кулын гына селкеп чыккан язучы берәр күчтәнәч алырга уйлады булса кирәк. Үч иткәндәй, сатучы кыз яшь һәм чамасыз чибәр иде — Сикертән авылында туып үскәнен дә белдек. Мәһдиев, кызга тел ачкычы эзләп, тиз генә танышу йоласы үткәреп алды.

— Менә, сеңлем, синең алда бөек шагыйребез Сибгат Хәким басып тора.

— Ы-ы... — дип жөпләп бара теге кыз.

— Менә, Гариф абыең Ахунов, үзе килде.

— Ы-ы...

— Мине беләсең инде, күрше авылында туып үскән Мөхәммәт Мәһдиев булам.

— Ы-ы...

— Ә бу кеше — Камил Кәримов дигән яшь язучы...

— И, беләбез, беләбез! Камил Кәримов безнең белән яңа гына очрашып китте!..

Якташ абыйларның исеменә ияләнеп үскән сатучы кыз мине бераз сөенебрәк әйттеме, әллә Гөберчәктә үзенең хан сараедай йорт-жирен күрсәтсә, өлешсез калган агайлар алдында мактану булып аңлашылыр дидеме — Мәһдиев уң кулы белән дирижёрларча кагынып алды да:

— Монда безгә делать ничу икән! Әйдәгез, шәкертләр, киттек Казанга! — диде.

Тимер юл астындагы Чыпчык кибетенә сугылып, Биектау урманының Өчиледәге Ахунжан нигезе чаклы гына аланында тукталыш ясап алдык... Ә үзебез ләм-мим!

Гариф Ахунов чорының китеп барышы, һәм зур югалтулары белән үргә менгән татар әдәбиятының әкрен-әкрен генә фанилыкка якынаюы иде бу...

Аңлашылса кирәк, бу язмада мин Гариф Ахуновның әдәби мирасын анализлауны максат итеп куймадым, аның ижаты халык күңелендә үз урынын алган инде. Ә менә ул эшләгән чорны — татар совет әдәбиятының Алтын чоры дип күкрәк киереп әйтергә хакым бар.

**Камил КӘРИМОВ**

# «НИНДИ ДӘРТ БЕРЛӘ КАЛӘМ СЫЗСАМ ДА...»

*Сүз сәнгатенең тарихын өзлексез барыш сыйфатында тасвирлауда һәм андагы теге яки бу күренешләрнең сәбәп-шартларын ачыклауда күчемлелек проблемасын хәл итү мөһим. Әдәби берәмлекне, шул исәптән нәфис текстны бөтен тирәнлегендә аңлатканда, традиция һәм новаторлык төшенчәләре ярдәмгә килә. Галимнәр карашынча, традицияләр узганның бүгенгегә үтеп керүе, шулай икән, аларның яңачалык белән дә тыгыз бәйләнеше бар.*

*Узган гасыр уртасында, үзенчәлекле поэтик иҗеге белән аерылып торган талантлы яшьләр поэзия мәйданына килгәч, укучыларның бер өлеше аларның форма экспериментларын кабул итми, тәнкыйть сүзләре дә еш яңгырый. Башта алтмышынчы елгылар иҗатына гомуми бәяләр рәвешендә белдерелгән мөнәсәбәт тора-бара вакытлы матбугат битләренә дә үтеп керә — каләм ияләре татар әдәбиятында традицияләлек-новаторлык мәсьәләсен күтәреп чыга. Гасырлар дәвамында тупланган әдәби алымнарны, калыпларны, сурәтләү чаралары байлыгын саклау кирәклеге турындагы карашларын тәнкыйтьчеләр теге яки бу мираслар җирлегендә ачарга, аңлатырга омтыла, шул сәбәпле татар әдәбиятында Тукай, Җәлил традицияләре дигән темага юл ачыла. Үзәк матбугатта әлеге исем астында куерган бәхәсләр мәйданына Х.Госман, И.Нуруллин, Н.Фәттах, М.Мәһдиев, Ф.Мусин кебек галимнәр тартыла. Ахыр чиктә яңачалыкның да буш урында барлыкка килмәве, хәтта сүз сәнгатебезнең чишмә башына ук барып тоташуы ачыклана.*

*Әдәби бәхәснең татар шигъриятенең төп көчләре тирәсендә куерүы аңлашыла да. Әлеге шагыйрьләрнең аның үсешенә керткән өлешләре зур. Тукай да, Җәлил дә әдәбият тарихының теге яки бу этапларында калку фигуралар булып тора һәм иҗатларында татар шигърияте ирешкән уңышларны бергә җыя, алга таба үстерә. Бигрәк тә Тукайда борынгы һәм урта гасырларның тел-сурәтләү байлыгы, алымнары, формалары мулдан кулланыла, шул ук вакытта ул үзе дә татар әдәбиятында реформатор санала. Сүз сәнгатебезне халык әдәбияты белән тыгыз бәйләү, анда татар сүзләрен, гади халык сөйләмен активлаштыру, шигърияткә чор сурәтен бөтен тулылыгында кертергә омтылу, шул сәбәпле китаби образлар янәшәсенә автор табышларын китереп кушу, тасвирлау объектына һәм гомумән дә автор мөнәсәбәтенең ачыклыгы, формалар байлыгы, аларның һәм язма, һәм сөйләм поэзиясе белән тыгыз бәйләнеше, көнчыгыш һәм көнбатыш шигърияте ирешкән уңышларны синтезлау омтылышы һ.б. – болар барысы да Тукай иҗатының сыйфатларыдыр.*

*Тукай юбилеена мөнәсәбәттә һәм аның энциклопедиясен язу барышында галимнәребез яңадан татар әдәбиятында Тукайчалык темасына әйләнеп кайтты. Әлбәттә, белешмәлектә аны киң планда яктыртып булмый, шунлыктан журналыбыз Тукай һәм башка каләм ияләре язганнар арасындагы бәйләнешләрне ачкан язмалар белән укучыларын таныштыруны кирәкле бер гамәл дип саный. Дәрестә нинди дә булса әсәрне аңлаткан укытучы әдәби традицияләлек һәм яңачалык проблемасын читләп уза алмаган кебек, каләмен чарлый гына башлаган яшь иҗатчы да, Тукай мирасын, шәхесен әдәби-рухи маяк иткән һәркем торып-торып Тукайга килә.*

*Без галимнәрне генә түгел, мөгаллимнәрне дә Тукай һәм татар әдәбияты турында уйланулары яисә фәнни эзләнүләре белән уртаклашырга чакырабыз. Тукайның «дәрт берлә каләм сызган иҗаты»н бер генә каләм иясе дә әйләнеп үтмәгән, әнә шунлыктан әдәбият белемебездә аларның язганнарын Тукайныкы янәшәсенә куеп карау бик мөһим.*

# ЧЫН ТУКАЙ ӨЧЕН КӨРӘШЕП...

Тукайчы диденме, һичбер башка кеше түгел, күңелгә иң тәүдә остазым Ибраһим Зиннәт улы Нуруллин килә. Аның бөтен гомер юлы халкыбызның онытылмас талант иясен аңлау һәм аңлаганын халыкка ирештерү, шагыйрьне күңелләребездә мәңге яшәтү уе белән үткән икән. Тукайга бәйле нинди генә сүз чыкмасын, Ибраһим ага, бәхәсләр вакытында үзендә уяна торган кайнарлык белән, аның хакында сөйләргә тотына иде. Башкалар күңелләрендә нинди уй яшәсә, дәлилсез-нисез генә шуны ирештергәндә, олы галимебез һәр фикерен фактлар белән раслап, теоретик яссылыкка салып шәрехләп бирәчәк.

Ибраһим абый, гомумән, дәлилсез бәхәсләшә дә белми, үз әйткәнендә нык тора, юк кына мәсьәләләрдә дә иманына хилафлык кылмый. Бу дәрәҗәдәге принципиальлек кайбер кешеләргә аның үҗәтлеге, хәтта кирелеге, катылыгы кебек күренә. Ә бит ул асылда үтә йомшак күңелле, читләр кайгысын да үзенеке кебек кабул иткән, гүзәллектән бик хисләнүчән, татлы телле, әдәпле сөйләмле кеше иде. Күпме хатын-кызның гомере андый затлы ир-атларны эзләп, көтеп ялгызлыкта үтә. Фәнебез дә шундый затлылыкка, Ибраһим агадагы тирән белемгә ия әдәбиятчыларга мохтаҗ. Ул мохтаҗлык бүген үзен тагын да ныграк сиздерә башлады.

Инкыйлаблар чорыннан соң (1923) дөньяга килгән Ибраһим ага шул чор тәрбияләгән, шул ук вакытта совет фәне мәктәбен дә узган язучы-прозаик, әдәбият галиме, тәнкыйтьче иде. Татарлар арасында зур гыйльми дәрәҗәләр алырга авыр бер вакытта ул фән докторы, мәртәбәле профессор булды. Әдәби җәмәгатьчелектә шәхесенә булган хөрмәт Ибраһим аганың Тукай иҗатын, заман биеклегеннән торып, фәнни дәрәҗәдә, комплекслы, тирәнтен тикшерүенә; тәрҗемәи хәлен, тирәлек-даирәсен, нәсел-нәсәбен максатчан өйрәнүенә; шагыйрьгә кагылышлы һәр фактны бөртекләп барлап, объектив шәрехләргә тырышуына да барып тоташты дип уйларга кирәк. Ибраһим Нуруллин, шушы төр эшчәнлек нәтиҗәсендә, фәндә дә, матур әдәбиятта да Тукай шәхесен, иҗатын булдыра алганча тормышчан чагылдырган күпсанлы фундаменталь хезмәтләр калдырды.

Ибраһим ага Тукай фәненә әдәби иҗат тәҗрибәләре, кече күләмле гыйльми мәкаләләре аша килә. «Томаннарга еллар күмелде» язмасында хәләл җефете Розалина ханым болай ди: «Ибраһим өчен 1955-1962 еллар арасы, иҗади шатлык-омтылышлар белән бергә, икеләнүләр, эзләнүләр чоры булды. Нәфис иҗат һәм фән арасында калып, кайсысына өстенлек бирергә икәнен аныклый алмый изаланды.

...Ибраһимның җаны әдәби әсәрләр язу ягында. Пьесалары өстенә, ул Тукай турында хикәяләр циклын башлап җибәрде. «Язгы үрләр» исемле повесть өстендә эшләде. Тик бу өлкәдә уңышсызлыклар еш кабатлана башлады. «Аның йолдызы»н Галиәсгар Камал исемендәге академия театры кабул итте — куелмады. Аны сәхнәләштерергә тиешле Ширияздан ага Сарымсаков театрдан китәргә мәҗбүр булды. Соныннан ул пьесадагы төп эпизод Шәриф Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы»нда кабатланды. Ә Ибраһимның әсәре халык театрында гына куелды. Урицкий исемендәге клубта куелганда, халык күп җыелган иде үзе».

Шулай да Тукай образын сәхнәгә менгерү юлында Ибраһим ага аерым уңышларга да ирешә. Аның «Тукай Петербургта» пьесасы рус телендә телевизион спектакль рәвешендә телестудиядән күрсәтелә һәм халык күңелендә бик җылы хисләр калдыра. Руслар да күтәреп алган пьесаны татар режиссёрлары сәхнәләштерергә теләми. Ахыр чиктә ул университетның драма түгәрәге көче белән академия театрының элеккеге бинасында куела. Рольләрне соңрак бөтен татар дөньясына танылачак каләм ияләре башкара: Миркасыйм Госманов, Кояш Тимбикова, Рим Кәримов...

И.Нуруллинның Тукай хакындагы пьесасы тамашачы күңелен яуламый, диючеләр дә бар. Һөнәри артистлар тарафыннан зур сәхнәдә куелмаган әсәр хакында мондый ашыгыч нәтиҗә ясау бик үк яхшы түгелдер. Икенче яктан, бәлки, спектакль, чынлыкта да, Камал театрында озак бара алмас иде, чөнки ул фикер драмасы була, ә андый әсәрләр ул чакта да, хәзергедә кебек, татар тамашачысы

арасында популярлашмый. Моны, нигездә, Р.Мингалимовның фикер драмалары булган әсәрләренең дә кайчандыр, залга кеше жыя алмыйча, куелудан туктатылулары раслап тора.

«Тукай Петербургта» – уйланылып, конфликтлары дөрес табылып язылган әсәр. Аның конфликты көчле, чөнки үзәк герой өстенә килгән авырлык-кыенлыклар бихисап, ә ул аларның һәрберсен жинә. Гадәттә, драматурглар, тамашачыны әсәр тартып торсын өчен, сюжетта мәхәббәт вакыйгаларын да файдаланмый калмый. И.Нуруллин да аны таба, әмма егет-кыз арасындагы мөнәсәбәтләрне үстерми, чөнки шагыйрь биографиясенә ялган кертергә теләми. Әсәрдә аның кызлар белән очрашуы, аларга атап шигырьләр язуы, фоторәсемнәр алышуы турында урыннар бар. Без Тукайның, чыннан да, Зәйтүнә Мәүлүдова һәм башка берничә кыз белән очрашканын, кичәләрдән соң алдынгы карашлы туташлар белән аралашканын беләбез, әмма ул мөнәсәбәтләрен артык тирәнәйтергә теләми. Автор да вакыйга-күренешләр аша шуны житкерәдер шикелле.

Күрәбез, И.Нуруллин, бүгенге каләм ияләребез кебек, шагыйрь тормышында, бәлки, гадәти генә булган вакыйгаларны, очраклы мөнәсәбәтләрне күпертү, гап-гади дуслык хисләрен мәхәббәт дәрәжәсендә чагылдыру ягында түгел. Безнең кайсыбыз кемгә атап шигырьләр язмаган, йә әйтегез? Без шул адресатларның барысына да ихластан гашыйкмы, хәтта өйләнер, кияүгә чыгар дәрәжәдә ярапканбызмы? Чын каләм иясе теләсә нинди темага жинел яза, моның өчен үтә гашыйклыкның һич кирәге юк. Гашыйклык хисе – болай да шагыйрьнең гомерлек юлдашы, синең хәтта яраткан кешең булмаса да, ул тойгы күңелеңдә яши, жае килеп чыкканда, ташый да китә...

Инде кабат Ибраһим ага алып барган икенче юнәлешкә – Тукай фәненә килик. Галим шөгыльләнгән проблемаларга охшашлары, шул исәптән Тукайга кагылышлылары белән философлар да, тарихчылар да кызыксына. Алар инде нәфис текстларга әдәбиятчылар кебек якын килми, «өлкән милләт» сызган тарих фәне яссылыгында бәяли, үзенә кирәк фактларны аралап таба, рәсми идеология кушканча шәрехли. Ибраһим абый белән тарихчы-тукайчылар арасындагы карашлар каршылыгы шуна барып тоташа дип уйлыйм. Бу факт һәм аның үз карашларында фәнгә аяк басканда ук үтә принципиальлеге, холкына хас кыюлык, Тукайча турылык шәхси тормышында да бик зур киртәләр торгызылуга сәбәп була. Илленче еллар ахырында партия билетларын алмаштыру башлангач, социаль хәлен дөрес күрсәтүе, ягъни мәдрәсә белеме алганлыгына ишарә аркасында, башта коммуна, аннан колхоз оештырган совет мәктәбендә укыткан Зиннәт аганы – кулак, ә улы Ибраһимны кулак баласы итеп күрсәтергә тырышу, партиядән чыгарып ташлау хәрәкәте кузгала, тик кара эчле коллегалары үз дигәннәренә ирешми.

Әнә шулай нәфис ижат юлы зур каршылыклар белән башланган И.Нуруллинны фән дә кочак жәеп каршы алмый, чөнки ул монда да кысаларга сыешмый, гел үзенчә булып кала, гел дөреслеккә омтыла, күзаллаулары еш кына чор идеологиясе кысаларыннан чыгып китә, ә үзе кәнәфидә утырган галимнәр сүзен кабатламый, югарыда кушкан боерыкларны үтәми. Шулай да, ныклап торып уйлаганда, нинди генә авырлыклар кичәргә туры килмәсен, Ибраһим ага барысыннан жиңүче сыйфатында чыга, һәрвакыт ахыр чиктә аның хаклылыгы раслана. Ул сугыштан да исән кайта, нәфис әдәбиятта да танылa, бүгенге көндә аны хәтта чит ил галимнәре дә Тукайны яктыртуда иң объектив тикшеренүче сыйфатында бәяли.

**Рифә РАХМАН**

*(Дәвамы алдагы санда)*

# ЯШӘВЕНЕҢ ГАМЕ ДӘ, ЯМЕ ДӘ — ТЕАТР

НАИЛӘ ГӘРӘЕВАГА 75 ЯШЬ



*Аның биеклеге – сәнгать күге. Табынганы – сәхнә. Яшәвенең гаме дә, яме дә – театр. Хәтта фани тормышының ахыргы ноктасын да сәхнәдә куярга тели ул. «Бөтен язмышы театр белән бәйле кешегә шуннан да зуррак бәхет була аламы?» – дигән сорау да куя. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Наилә Гәрәева быел үзенең 75 яшьлек юбилеен каршылый. Тамашачы күңелендә бүген дә Рәхилә, Зөбәйдә, Диләфруз, Әсәл, Миләүшә булып яшәгән актриса рольләре турында сәгатьләр буе сөйләргә әзер. Бу аңлашыла да. Әлеге һәм башка образлар аның иҗат биографиясендә генә түгел, татар театры тарихы елъязмасында да мөһим урын алып тора. Рольләр белән очрашу, иҗат газаплары, сәнгатькә бирелгәнлек – гомеренең төп һәм мәгънәле өлеше. Әңгәмәбез дә, нигездә, шул хакта.*

***– Наилә апа, бүгенге Наилә Гәрәеваны гәүдәләндергән пьеса язарга кушсалар, автор ремаркасында аңа нинди характеристика бирер идегез?***

– Наилә Гәрәева – Камал театры артисты, язмышына рәхмәтле актриса, 75 яшьтә. Нәкъ менә актриса буларак бәхетле булуыма басым ясар идем. Бер кеше дә тулаем бәхетле була алмыйдыр ул, минемчә, бәхет мизгелләрдән тора. Театр миңа әнә шундый мизгелләрне күп бүләк итте, сайлаган юлыма тугрылыклы булдым, халык та мине яратты. Дөньяда шундый зур талантлар бар: нинди дер мөһим гамәлләр кылалар, фәнни ачышлар ясыйлар, алар белән чагыштырганда, мин беркем түгел. Бары үз теләгемне тормышка ашыра алган канәгать кеше.

***– 75 яшьтә, дидегез, бу ремаркада башка яшь күрсәтелергә дә мөмкин. Мәсәлән, үзегезне ничә яшьтә хис итәсез, шул яшь...***

– Ничә яшь булса, мин төгәл үземне шулай хис итәм. «Күңелем белән 18дә», дип очынган кешеләрне анламыйм. Үземнең яшемнән канәгать, Ходайга шөкер кылам! Чын яшем турында бер көнгә дә онытмыйм, аның белән килешеп яшим.

***– Раневскаядан: «Ни өчен театрдагы язмышыгыз турында китап язмыйсыз?» – дип сорагач, «Язмыйм, чөнки ул зар китабы булыр иде», – дип җавап бирә. Юбилей уңаеннан «Язмышыма рәхмәтле» дигән китабыгыз чыгуын беләбез. Сезнең китабыгыз нинди рухта? Анда төп фикер нинди?***

– Бүгенге көнгә кадәр уңайсызланам. Китап чыгару – зур җаваплылык. Ләкин театр тәкъдим иткәч, әлеге эшкә алындым. Төп фикер исә – язмышымны хәл иткән кешеләргә рәхмәтле булу. Алар тормышымда күп очрады. Мин – рус мохитендә үскән кеше. Гаиләдә әбием татарча тәрбияләсә дә, әни заман кешесе иде, ул мине рус мохитенә тартты. Рус мәктәбендә укыдым, рус дөньясында формалаштым. Шуңа да Качалов театры каршында ачылган татар-рус студиясенә имтиханнарны рус

группасына тапшырдым. Инде сынауларны унышлы узгач, бер кеше, янымa килеп: «Син татар кызымы?» – дип эндәште. Ризалашып баш каккач, ни өчен рус бүлеген сайлавым белән кызыксынды. Мин аңа үземнең татарча начар белүемне аңлаттым. Ул, икеләнергә урын калдырмыйча: «Өйрәнерсең! Син талантлы кыз, синең киләчәгең татар театрында», – диде. Бүген дә уйланам. Нәрсә бу? Күрәзәчелекме, интуициягме, әллә милләтенә тугрылыкмы? Ни дәрәҗәдә кирәкле вакытта әйтелгән сүзләр! Мин ул кешенең кем икәнлеген соңрак белдем – Ширияздан Сарымсаков булып чыкты, ул вакытта Г.Камал театрының баш режиссёры. Аның сүзен тыңлап, мин татар группасына керергә әзерләнә башладым. Муса Җәлилнең әле яңа гына кайтып ирешкән «Моабит дәфтәрләре»ннән «Вәхшәт»не русча, аннан татарча өйрәндем. Укый башлагач та, Ширияздан абый мине «Таһир-Зөһрә», «Ай тотылган төндә» һәм башка спектакльләрдә күмәк сәхнәләрдә катнаштырды. Китапта әнә шул зур шәхесләр, кадерле кешеләр турында тәфсилләп язылган.

***– Ул вакытта рус төркеменә укырга кергән булса, бүген Наилә Гәрәева нинди актриса булыр иде икән?***

– Беркем булмас идем, бер почмакта елап утырыр идем кебек. Язмышым – татар театры, ул миңа буыннарымда татар каны агуын, нәселемнең татар булуын һәм шуның белән горурланырга кирәклеген аңларга этәрде. «Татар бәхте өчен мин җан атармын: татар бит мин, үзем дә чын татармын», – дип бүген кыюланып әйтә алам.

***– 70 яшьлек юбилеегызда Разил Вәлиев: «Әгәр музыка сәнгатенә шәһәр мәдәниятен Рөстәм Яхин алып килгән булса, театрга аны Наилә Гәрәева алып килде!» – дигән сүзләр әйткән иде...***

– Әйе, ул сүзләрне яхшы хәтерлим, алар миңа бик тәэсир итте. Шәһәрдә туунын кимчелек түгел икәнен аңлау соң килде миңа. Заманында «шәһәрлек» белән төрттерүчеләр дә шактый булды, бу нәрсә күңелгә заманында бик тиде. Хәзер аңлыйм: шәһәрдә үсү – кимсенә торган нәрсә түгел, ул мине баетты гына. Икенче курста, мәсәлән, Рәфкать Бикчәнтәев мине Хәй Вахит әсәрендә Рәхилә роленә билгеләде. Бөтен театр дәррәү купты: «Ничек инде төп рольгә татар телен дә юньләп белмәгән студент кызны билгелисез?» Ләкин ул вакытта театрда яшьләр юк иде, щепкинчылар әле кайтып җитмәгән, Рәфкатьнең башка чарасы да булмагандыр. «Беренче мәхәббәт» – Хәй Вахитның театрда куелган беренче әсәре, Рәфкатьнең беренче спектакле, минем тәүге баш ролем. Рәхиләдән халык мине таный башлады. Чыннан да, татар телен белүем начаррак булгандыр, ләкин шул ук хәл еллар узгач, Марсель Сәлимҗанов «Әни килде»дә Әни ролен биргәч кабатланды. «Ничек инде Наилә Гәрәева Әнине уйный, шәһәр кызы бит ул, Шәриф Хөсәеннең «Әни»се – авыл кешесе», – дип шаулаштылар. Бу юлы мин дә каршы чыктым: «Минем хакым бар, мин – ана. Ана авыл һәм шәһәр кешесенә бүленәмени? Ана хисләре – бертөсле», – дидем. Ләкин эчтән үземнең дә куркуым бар иде. Галимә апа Ибраһимова уйнаган роль бит! Премьера көнне беренче пәрдәдән соң сәхнә артына чыктым да калтырап төштем, Фәрит (Фәрит Бикчәнтәев – *Г.С.*): «Нишлисең син, ник алай дулкынланасың?», – ди. «Кабул итмиләр, кабул итмиләр», – дип такрарладым, тик үземне кулга алып, спектакльне уйнап бетердем, соңгы пәрдәдә генә халык мине кабул итте. Бүген бу рольне иҗатымның югары ноктасы дип саныйм.

***– Иҗатыгызның әле башлангыч чорында, шулай ук Шәриф Хөсәеновның әсәре буенча Хөсәен Уразиков куйган «Зөбәйдә – адәм баласы»ндагы Зөбәйдә ролегез бар. Зөбәйдәнең өлкәнәюе, җитдиләнүе Булатка гашыйк булудан башлана. Сез үзегезнең «яшьлегегез-юләрлегегез» белән кайчан саубуллаштыгыз?***

– Рәфкатькә кияүгә чыккач, кинәт өлкәнәйдем, чөнки ул шактый олы яшьтә иде – тормышка карашы, фикерләве бөтенләй башка, аралашу даирәсе дә икенче. Ләкин мин үземне кияүгә чыкканчы юләр булдым дип әйтә алмыйм, нәкъ менә аңа кияүгә чыгуны юләрлек дисәм генә (көлә). Юк, юк, ул алымым минем акыл

белән хәл ителгән иде. Рәфкать ялгыз кебек тоелды, аны яклыйсы, саклыйсы килү теләге уянды. Барыбер ул вакытта яшь булганмын әле, күп нәрсәләрне аңлап бетермәгәнмен. Рәфкать минем өчен укылып бетелмәгән китап булып калды. Аның язмышы бәхетсез, кадерсез булды. Талантлы иде ул, күпме эшләр башкара алыр иде! Бу уңайдан үземне дә гаепле сизәм. Әтисе тормышка ашыра алмаган хыялларны бүген театрда Фәрит ашыра. Бу Ходай Тәгаләнең рәхмәте белән, беренче чиратта, аның рухын шатландыру өчендер дип уйлыйм.

***– Сезнең язмышыгызны бераз башкачарак күзалдына китерсәк... Мәсәлән, «Мәхәббәт турында сөйләшик» геройлары кебек бергә картайган парларны... Сез алай яши алыр идегезме?***

– Яши алыр идем. Мин, кешегә бирелеп, ирне ир итеп яши алам, хәтта үземне онытырга да мөмкинмен. Олыгайган саен ялгызлыкны ныграк тоясың. Яныңда башыңны җилкәсенә куеп утырырлык кеше булса, бөтенләй икенче төрле булыр иде. Кешене яратсам, чын мәгънәсендә, бөтен булмышым белән аңа бирелəм. Ул нәрсә каян килгәндер? Бәлки, үземне бөтенләй юк югалтмас өчен шундый язмыш насыйп булгандыр, кем белә?!

***– Артист язмышы да рольләрсез ялгызлыкта үтәргә мөмкин. Әлеге тынлыш Сезне дә читләп узмаган. Җиде ел рольләрсез яшәгәнсез. Җиде ел – ул шулкадәр зур вакыт аралыгы. Бер ай эшсез, билгесезлектә булу да ярты картайта...***

– Әйе, җиде ел... Әйтүе генә җиңел, ләкин хәзер аңлыйм: бу табигый нәрсә, һәрбер актёр иртәме-соңмы әлеге чынбарлык белән очраша. Русларда шундый сүз дә бар: «В театре должна быть культура страдания». Әмма, башкалар белән чагыштырганда, мин бу чорны җиңелрәк уздым. Башта Марсель Сәлимҗанов мине үзенә ярдәмче итеп театр училищесына актёрлык осталыгы дәресләрен укытырга алды, бер курсны чыгаргач, мине хәзерге Мәдәният һәм сәнгать университетына чакырдылар. Ул вакытта педагогикага китмәсәм, актёр буларак та югалыр идем, чөнки актёр һәрдаим укырга, кызыксынырга тиеш. Театрга Дамир Сираҗиев килгәч, рольгә сусавымны белеп, үзе куйган спектакльләргә («Көйсез сәфәр», «Ләйсән ире Хәсән», «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз», «Ахырзаман») ала башлады. Бу рольләр миңа, актриса буларак аерым уңыш китермәсәләр дә, Дамирның тормышымның торгынлык чорында килеп чыгуы бар яклап та яшәргә көч бирде. 1989 елда театрга Фәрит килде. Диплом эше буларак куелган «Бичура» спектаклендә миңа Күршекәй роле эләкте. Карчыклар образына күчүем нәкъ менә шул спектакльдән башланды.

***– Тирән, яхшы роль тиз генә ачылмый, актёр белән качышлы уйный, диләр. Наилә Гәрәеваһа кайсы роленең эзенә төшү иң катлаулысы булды?***

– Туфан Миңнуллинның «Шәҗәрә» әсәрендәге Сәлимә роле шундыйлардан. ГУЛАГны үткән, фаҗигале язмыш кичергән, әмма иманына тугры калган татар хатыны. Үзе эчә дә, тәмәке дә тарта. Аның белән танышкач, бөтенләй минем роль кебек тоелмады, шуңа өстәп, спектакльгә алынган чор нәкъ ураза вакыты иде, мин инде намазга да баскан кеше буларак: «Фәрит, булдыра алмам, башка артистка тап», – дидем. Ул катгый рәвештә: «Юк, әни, син уйныйсың. Син әле үзеңне белеп бетермисең», – диде. Эшләве бик авыр булды, Фәрит тә һәрдаим: «Ышанмыйм, ышанмыйм», – дип кисәтеп торды. Ләкин җиңдек, Аллага шөкер. Бу – минем дә, Фәритнең дә уңышы. Мин яңа яктан ачылдым, үземә ышанычым артты. Зур газап белән тудыргангамы, хәзер ул минем иң яраткан рольләремнең берсе. Нәкъ шушы рольдән соң мине сәхнәдәшләрем актриса буларак кабат таныды. Бу исә минем өчен бик мөһим.

***– Фәрит Бикчәнтәев бер әңгәмәсендә: «Камал театрының үзенчәлеге – театрда артистлар ансамбленең булуы», – дигән иде.***

– Театрда ансамбль иң кирәк нәрсә, һәрбер спектакльнең төп уңышы – ансамбль.

Оркестрдагы һәрбер уен коралы мөһим булган кебек, театрда да бер генә кеше бернәрсә дә эшли алмый. Әгәр бүген дә мина «Диләфрүз» дип дәшәләр икән, анда Равил Шәрәфиев, Ринат Тажетдинов, Хәлим Җәләлов, Дилүс Ильясовнын өлеше әйтеп бетергесез. Чыңгыз Айтматов әсәре буенча куелган «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә минем Әсәл югары бәяләнде. Бүген үткәннәргә борылып карагач, бу — безнен уртак җинүебез, ансамбльнен җиңүе дигән фикергә киләм. 1967 елда әлеге спектакль белән Тукай премиясенә лаек булу да нәкъ шул турыда сөйли. Бер-беребезне күз карашыннан аңлап, бер-беребезгә ярдәм итеп эшләү — бәхет.



*Х.Вахит. «Беренче мәхәббәт». Рәхилә ролендә — Наилә Гәрәева. Тәлгать — Шәүкәт Биктимеров.*

***– Роль белән беренче очрашу гадәттә ничек уза? Рольне әзерләгәндә, эчке оппонентыгыз кем? Сез кем беләндер бәхәсләшәсез, киңәшәсезме?***

– Үзем белән бәхәсләшәм. Артык төпченергә, үз-үземдә казынырга яратам. Бу сыйфатымнан арынырга телим, ләкин булмый. Уянам да барыбер шул кысаларга керәм. Чехов әйткәнчә: «Всю жизнь хотел выдавить из себя раба». Кеше кимчелекләреннән арына алмаган кебек, артист тормышын да үзгәреп булмый икән. Рольгә гел курку белән алынам. «Бабайлар чуагында» биш ел уйныйм, һаман үземнән канәгать түгел. Ләкин, икенче яклап, бу бик кирәк сыйфат. Артист үзеннән канәгать булса, ул бетә. Бу яшьтә сирәк уйныйсын бит, сирәк уйнагач, ныграк та куркыта. Һәр спектакль — сынау. Әмма сәхнәгә чыккач, курку да, дулкынлану да, анализ да вакытлыча онытыла, син инде шул геройның тормышы белән яши башлыйсың. Хәтта авырулар, күнел төшенкелеге дә кул белән сыпырып алган кебек була. Спектакль тәмамланганнан соң да, озак вакыт аннан арына алмыйча йөрисен. Беркадәр вакыттан тагын шул анализ башлана.

***– «Актёрның рольне мөстәкыйль өйрәнүе» темасы Станиславский хезмәтләрендә зур урын алып тора. Бүген дә сәнгать белгечләре «актёр рольне үзе сүтеп җыйса гына, ул аның авторы була ала», дигән фикердә. Мөстәкыйль эшкә Сез күпме вакытыгызны бүләсез?***

– Безнең фаҗигамы, бәхетме: рольле булсак, башыбызда гел шул персонаж. Ятсак та, торсак та, кунакта утырсак та, урамда йөрсәк тә. Яшьрәк вакытта әнигә күршеләр: «Сезнең кызыгыз бераз сәеррәк, узалдына сөйләшеп тик йөри», – дип әйтәләр икән. Шуннан үземне бераз контрольдә тота башладым, ләкин барыбер уйда, хыялда рольләр. Әнә шулай без гомер буе ялган тормышта яшәгәнбез, чын тормыш читтән параллель барган, аңа көч җитмәгән. Бер актриса: «Ник театр юлын сайладыгыз?» – дигән сорауга болай дип җавап биргән: «Мин реаль тормышта яши алмаячагымны аңладым». Сәхнәдә ничә тапкыр сөйдек-сөелдек, аерылдык, үлдек, тормышта чынга аша алмаган хыялларны тормышка ашырдык. Уйнамаган чорларымда мин чынбарлыкта яшәп алдым. Ул вакытта көчемне Фәриткә, соңрак улыгым Йосыфка бирдем. Рольләрем булганда, минем яшәргә вакытым да, энергиям дә булмады.

***– «Безнең буынга заман режиссёрлары белән эшләү катлаулырак. Хәзер театр башка», – дисез әңгәмәләрегездә...***

– Без – психологик театр рухында тәрбияләнгән кешеләр, ә хәзер күп нәрсә



*Т.Миңнуллин. «Хушыгыз». Миләүшә ролендә — Наилә Гәрәева. Галимулла — Ринат Таҗетдин.*

уенга корыла. Безнең буын сәхнәдә Станиславскийның «я в предлагаемых обстоятельствах» ысулы белән яшәде. Фәрит мина: «Гел үзеңне уйныйсың, персонажны уйнарга кирәк», — ди. Әйе, театр — уен, ләкин алтын урталык булырга тиеш. Марсель Сәлимжановның шундый сүзләре бар иде: «Башыңда торсаң тор, ләкин мин синең ни өчен башыңда торуыңны аңларга тиеш». Ягъни форма белән эчтәлек бергә барырга тиеш. Хәзер күпләр шаккатыру белән шөгыльләнә башлады, тик шаккатыруда да мәгънә сакланырга тиеш. Безнең театрның кече сәхнәсендә барган «Җәйнең бер көнендә» спектаклен психологик уен дип әйтеп булмыймы? Театр төрлечә яшәп карар да барыбер кире үз юлына кайтыр дип уйлыйм.

***– Күптән түгел Юрий Альшицның «Рольгә 45 сорау» дигән китабы кулга керде. Анда ул: «Укытучы вакытны, сәнгатьне алдан тоярга тиеш. Киләчәк театры турында сүз йөрткән педагог кына нәрсәгәдер ирешә ала», – дип яза...***

– Дөрес фикер. Яңадан педагогикага алынмас идем, хәзер инде миндә Сез әйткән заманча тоемлау юк. Яшьләргә бүген нинди дә булса яңа әйбер җиткерә алмыйм кебек. Мин аның булырга тиешлеген сизәм, ләкин һаман да психологик алым белән эшлим. Бер генә мисал: берничә ел элек курс белән Туфан Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» спектакленнән өзек сәхнәләштердем, шул ук чорда Фәритнең укучысы Лилия Әхмәтова нәкъ әлеге пьеса буенча диплом эшен тапшырды. Ул бөтенләй башка формада иде. Спектакльдән соң бер укучым: «Наилә апа, карагыз алар ничек уйный, ә без һаман да психологик алымнар белән баш ватабыз», – диде. Бу сүзләр, спектакль турында бер атна уйланып йөрдем һәм башка укытуга алынмаска карар кылдым, ләкин, җитәкчелек бик үтенгәч, яңа курска тотындым. Ул соңгы курсым булыр дип уйлыйм. Әлбәттә, мин биргән психологик мәктәп – театрның нигезе, ул кирәк, аларга ул эштә комачауламас, әмма бүгенге театр икенче, моны аңлыйм һәм укытучы буларак үземә объектив бәя бирәм.

***– Сезнең өчен яшьләрдә техника мөһимрәкме, әллә актёрның сөйкемле сөягеме? Русларда аның төгәл сүзе бар – обаяние. Мәсәлән, Олег Табаков педагог, режиссёр буларак нәкъ менә сөйкемлелеккә ставка ясавын әйтә һәм ул тәрбияләгән актёрлар аша моның чыннан да шулай булуы ачык чагыла.***

– Бар нәрсә бөтен булырга тиеш. Сөйкемлелек – Ходай тарафыннан бирелгән бүләк, ләкин бер сөйкемлелек белән генә ерак китеп булмый. Русларда бер сүз бар: «Поэтом можешь ты не быть, но гражданином быть обязан». Бу актёрларга да карый. Актёр илдәге вазгыять, вакыйгалар белән кызыксынырга, битараф булмаска тиеш, үз уе белән дөньяда кайнарга бурычлы. Әлеге сыйфат бар икән, артистның уйнаган роленә үз мөнәсәбәте дә бар. Бу бик мөһим, чөнки сәхнәдә бар нәрсә дә зурайтылган көзгедәге кебек ачык күренә. Рифкать «Беренче мәхәббәт» спектакленнән соң миңа бүләк иткән альбомында шундый сүзләр язган: «Булачак акыллы артисткага». Талантлы димәгән, «акыллы» дип ассызыклаган. «Булачак» дигән сүз исә киләчәккә ышаныч, өмет белдерү.

***– Соңгы елларда режиссёрлар «драматургия – театрның нигезе», дигән фикерне шик астына куя. Бу турыда матбугатта да шактый бәхәсләр барды. Сезнең катнашлыктагы спектакльләрнең әдәби материалы төрле. Бүгенге драматургия, драматурглар белән мөнәсәбәтләр ничек?***

– Драматургия – театрның нигезе, бу бәхәссез. Хәзер күп режиссёрлар инсценировкалар белән мавыга. Мәсәлән, безнең театрда барган «Минем исемем Кызыл» спектакле Орхан Памук әсәре буенча эшләнгән. Сәхнә бизәлеше, заман технологияләре кулланылуы, фикере, темасы белән бик үзенчәлекле спектакль, ләкин әдәби материал таркау. Инсценировканы театрны яхшы белгән кеше эшләсә генә уңышлы килеп чыга. Гомумән, драматургия өлкәсендә уңыш казанганнар – театр кешеләре. Ни өчен Туфан Миңнуллин пьесалары сәхнәдән төшми? Чөнки Туфан үзе артистлыкка укыган, ул сәхнә кануннарын яхшы аңлый, белә. Бүгенге драматургия элеккеге драматургия түгел инде, чөнки драматург сәхнә кануннарыннан тыш кешеләрне, тирә-юньдә барган вакыйгаларны аңларга, заманны бик тирән тоемларга тиеш. Бу уңайдан Илгиз Зәйниевне аерып әйтә алам. Драматургик законнарны белүдән тыш (ул да бит артистлыкка, режиссёрлыкка укыган!), аның әсәрләрендә тирән фикерләр салынган. «Мәхәббәт турында сөйләшик» пьесасын гына алыгыз, ул әле аның тәүге әсәрләренең берсе. Пьесада өч буын, өч буынның тормышка карашы, үзара мөнәсәбәте. Акыллы драматург кына дөньяны шулай сизә, төрле чор кешеләрен аңлый, алар булып сөйләшә ала.

***– Сез башка театрларга да күп йөрисез, аларның эшләрен күзәтеп барасыз. Соңгы вакытта сезгә тәэсир иткән спектакльләр бармы?***

– Күп йөрим дип әйтмәс идем. Безнең театрга килгәннәрен күзәтәм. Ләкин соңгы елларда мина тәэсир иткән спектакльләр юк дәрәҗәсендә. Мин – тәҗрибәле артист, профессионал кеше. Бәлки, моңа кадәр күп нәрсә күргәнгә шулайдыр. Товстоногов, Любимов, Захаров спектакльләреннән соң бүген миңа тәэсир итү авыррак. Үзебезнең театрда тәэсир иткән спектакль – «Кара чикмән». Онытылып, дулкынланып карадым мин аны. Форма да, эчтәлек тә бар. Хәзер спектакльләр шулкадәр күп, кайсын карарга да белмисең. Додинның башлангыч чорындагы иҗатын яратам, бигрәк тә Абрамовның инсценировкалары буенча куелган спектакльләрен. Казанга Чеховны алып килгән иделәр, ләкин мин аның «Өч сеңел»ен кабул итмәдем. Минем күңелемә үтеп керә торган иң зур нәрсә – ул актёр. Спектакль, фильм начар булырга да мөмкин, ләкин актёр тәэсирләндерә ала. Бөтен нәрсә артист аша кабул ителә. Мин хәтта кайбер спектакльләрнең режиссёрларын да, сюжетын да хәтерләмим, ә актёрлар күз алдымда! «Нәүрүз» фестивалендә дә, Туфан Миңнуллин декадасында да яңалык булырлык спектакльләр күрмәдем. Әмма соңгысында Әтнә театрының «Ай булмаса, йолдыз бар» спектакле гадилеге белән сокландырды. «Гадилектә – бөеклек» дип юкка әйтмәгәннәр бит!

***– Спектакльне кабул итү-итмәү – субъектив нәрсә. Сезнең күзаллау, фикердәшләрегез, Сез ышанган кешеләрнеке белән туры килмәсә, үзегездә шикләнә башлыйсызмы, әллә аларның профессиональлегендәме?***

– Һәрбер кеше үзенчә кабул итә. Филологлар, журналистлар – бертөрле, сәнгать белгечләре, артистлар – башкача, халык – өченче төрле. Күпчелек баш белән түгел, күз, колак белән кабул итә. «Хуҗа Насретдин» спектакленең премьерасында, мәсәлән, минем артта бер тамашачы спектакль дәвамында: «Нәрсә инде бу, нәрсә инде, бер дә көлке түгел», – дип утырды. Хуҗа Насретдин мәзәкләре тыңларга килгән ул, аны гаепләп тә булмый. Театрга күңел ачарга килүчеләр күп. Бу табигыйдер дә. Менә шул тамаша көткән халыкны без бераз гына уйланырга этәрсәк, димәк, үз вазифабызны башкарганбыз дигән сүз.

***– 16 яшьлек Наиләгә 75 яшьлек Наилә киңәш бирә алса, нинди сүзләр булыр иде ул?***

– Кызык сорау (чын күңелдән көлә). Хәзерге акыл белән яшь чактагы акылны тигезләп булмый. Олыгая-олыгая кеше күп нәрсәне аңлый, ләкин үткәннәргә кире

кайтып булмый бит. Үкенечле нәрсәләр күп. «Сәнгатькә бирелеп, шәхси бәхетең турында онытма», — дияр идем. Язмышны кеше үзе яза, бервакытта да «бу минем тәкъдирем», дип акланырга ярамый. Ходай Тәгалә мөмкинлекләрне күп бирә, тик кеше аларны вакытында аңламый.

***– Элек яшәп иҗат иткән кайсы шәхес белән Сез бүген иркенләп утырып гәп сатар идегез?***

— Аяз Гыйләҗев белән сөйләшер идем. Аны бик сагынам. Ул хәтта дәшми утырса да, мин аңардан үземә бик күп көч ала идем. Без гаилә дуслары булдык. Хәй Вахит белән очрашыр идем. Марсель Сәлимҗановны, Шамил Зиннуровичны сагынам... Аларның мөнәсәбәтләре, йогынтылары бик зур булды.

***– «Хушыгыз»дагы Миләүшәгез, вафатыннан соң, язып калдырган кассетада дусларына бер-береңне ялганлап яшәүдән аруы турында әйтә. Сез тирә-юньдәгеләр, дусларыгыз, хезмәттәшләрегез белән ни дәрәҗәдә ихлас?***

— Мин ялганлый белмим. Кечкенә генә ялганласам да, үземнән-үзем оялам. Ихлас күңелле кеше мин, уйлаганымны турыга әйтәм. Шуңа мине усал диючеләр дә бар. Һәркемнең үз дөреслеге икәнен дә аңлыйм. Бер акыл иясе болай дигән: «Все несчастья в этом нелогичном мире в том, что каждый прав по-своему». Үзеңнең дөреслегеңне беркайчан да кешегә тагарга ярамый. Мин аны беләм, аңлыйм, ләкин конкрет ситуациядә куллана алмыйм. Соңыннан гына аңлау килә. Театрда да һәрнәрсәгә игътибар итәм. Мәсәлән, баскычта яисә фойеда ут сүнгән, беркемгә кирәкми, мин барып әйтәм. Кешеләрнең битарафлыгына аптырыйм. Әле ярый Фәрит театрда җитәкче, ул булмаса, мин һәр адымда дөреслек өчен көрәшеп чәчрәп чыгар идем. Күп очракта:«Аңа кыен булмасын, зыян килмәсен, аның алдында яхшы түгел», — дип тыелып калам. Товстоноговның шундый сүзләре бар: «Театрда эшең юк икән, килеп йөрмә». Бик дөрес сүзләр. Театрда күп нәрсәне белмәсәң, ишетмәсәң — яхшырак.

***– Миләүшә шул ук язмасында Шәһит белән Нурисламга: «Мин хатыныгыз буларак, сезне бәхетле итә алмадым, ләкин сез дә бит мине бәхетле итә алмадыгыз. Бәхетсез илдә бәхетлеләр була алмый», – дигән сүзләр әйтә. Бәхетсез илдә бәхетлеләр була алмый... Бу фикер белән Сез ни дәрәҗәдә килешәсез?***

— Миләүшә — ул Туфан үзе. Нәҗибә Ихсанованың: «Миләүшәнең туган көне» трилогиясен Туфан каны белән язды. Янды, көйде, үлде, терелде. Ул чордагы бөтен кичерешләрен Миләүшә аша бирде», — дип сөйләгәне хәтердә. Минемчә, Туфан Миннуллинның бу трилогиясе — иң көчле әсәре. Аның өченче кисәген — «Хушыгыз»ны Марсель Сәлимҗанов куярга алынмады, Фәриткә тапшырды. Миләүшә — минем язмышыма да бик тәңгәл килгән роль. Спектакль яшәгән вакытта әлеге җөмләне бик ярата идем. Ул чорда бәхетне һәркем бертөрле кабул итә, кешеләр бертигез яши иде. Максатлар да бер үк — тормышта үз-үзеңне табу, гаилә кору һ.б. Хәзер бәхетне төрле кеше төрлечә аңлый. Ләкин күпчелек өчен яшәү авыр. Ил дөрес бармый. Халыкка игътибар юк, бөтен нәрсәне бер кеше хәл итә. Алай булырга тиеш түгел бит. Кешенең кадере юк, Тукайның сүзләре бүген бигрәк актуаль яңгырый: «Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадерен белү?! Без аны кайдан белик, мескен үлеп аңлатмагач?!» Сәнгать өлкәсендә дә күп нәрсәләр борчый. Казаныбызда чираттагы кинофестиваль узды, ел саен үтә торган әлеге җыенның мәгънәсе нидә? Үзебезнең киностудия бармы? Сыйфатлы киноларыбыз күпме? Ничаклы акчаны юкка туздырабыз. Универсиада, олимпиадалар уздырабыз, спорт аренаалары төзибез, ә Чаллы театрының бинасы юк. Болар ничек мине борчымасын! Татарның рухын саклый торган төп нәрсә — мәдәният, сәнгать. Шуны онытмасак иде!

*Әңгәмәдәш* — **Гүзәл СӘГЫЙТОВА.**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Ул чакта

Сентябрь ае. Бил каешы кебек ялтырап яткан асфальт юл таулар, гәрәбә сарылыкка манылган урманнар аша бара. Гариф ага Ахунов белән машинада Азнакай кинлекләрен тамаша кылырга чыкканбыз. Яна гына мул табыннан кузгалгач, кәеф шәп, мин шигырь юллары сибәм:

*Очты дөнья читлегеннән,*
*Тарсынып, күңлем кошы.*

— Тукай бөек шул. Кирәк бит шулай галәми итеп әйтергә! — дип, Гариф ага тел шартлатып куя. Гадәттә, Гариф аганың сүзне тараурак тыңлавын беләм, ә монда — машинада ул какланган кебек утырырга мәҗбүр, тыңламый хәле юк, шуна күрә яңа «патроннарны» чыгара торам.

*Үлем-китемнәрне яза күрмә,*
*Мин кайтканчы, исән торсыннар.*

— Бу кем шигыре? — дип, Гариф ага әсәренеп куя.

Мостай Кәримнең «Авылдашка хат»ы шушылай тәмамлана, дигәч: «Мостай олпат шул инде! Чынлап та шулай бит, авылына кайтасың, фәлән-фәләннәр ничек дип сорыйсың, ә кемдер күптән дөньядан киткән, ишетмәгәнсең, синең өчен ул һаман исән-сау булган. Менә бит, нинди мәгънәле шигырь...»

*Туган ягым, — ап-ак табын, –*
*Ап-ак шәлеңне ябын,*
*Ап-ак шәлеңне ябын да*
*Шәмдалләр булып кабын.*

Бу юлларга сокланып, Гариф ага тагын бер тапкыр миннән кабатлатып тыңлады да шигырьнең Айдар Хәлимнеке икәнен белгәч, һич тә ышанырга теләмәде: «Ай-һай, ялгышмыйсыңмы? Аның шигырьләре бит... йомыркасын ашыгып әрчесән, бәбкә җитлекмичә туа бит әле, — шундыйрак... Рифма, ритм ягыннан да аксак-туксак була торганые. Шаккатырдын син мине. Әйтергә кирәк әле Шаһидә апана, укып чыксын китабын. Аннары мин үз фикеремне белдерермен.

Тавышны көрәбрәк алып, мин тагын Гариф ага ягына шигъри сүз юлладым:

*Бу җаныңны чайкап алыр өчен,*
*Дөнья агымсулар яраткан.*

— Әйбәт. Бик мәгънәле әйтелгән. Бусын кемнеке дип белик?

— Хәсән Туфан.

— А-а, Туфан Туфан шул инде! — диде Гариф ага гамьле итеп, сакалы бар сыман, ияк очын сыпырып куйды.

Машина чокыр-чакырларны янтая-янтая үтеп, тигезлеккә чыккач, мин:
— Гариф ага, теге шигырь юлы Хәсән Туфанныкы түгел, минеке иде, — дидем.
Гариф ага башын артка ташлап, көлеп куйды да:
— Синеке булуына карамастан, әйбәт әйтелгән, — диде.

## Көлеп калсыннар

Күнеленә көн нуры төшкән кеше генә шаян сүзне кабул итә, үзеннән дә, бүтәннән дә рәхәтләнеп көлә белә. Шикчел, сагаюлы, сәләте чамалы бәндә, гадәттә, һәр үткен сүздән дерт итеп китә, кара коелып чыга. Язучылар арасында да көлә белү ягыннан төрледән-төрлесе бар иде: партиягә тугры житдилек битлеге киеп, Гариф Гобәй, Афзал Шамов кебек, тораташ калганнар да. Андыйлар коммунизмга барып житеп, аяк салындырып утыргач кына рәхәтләнеп бер көләргә ниятләп яшәүчеләр кавеменнән иде.

Гариф ага Ахунов елгыр акыллы, уенчак уйлы, жиде айдан туган житез кеше иде. Бернichә язучы бергә жыелдымы — ул инде үзәктә, китә шау-гөр, сүз тоягы уйнату... Гариф ага, дәрәҗәле урындыклар биләвен дә онытып, башын артка ташлап, чатнатып көлә. Шулай, кинәнеп көлгәндә, кәефе шәплегенә көч өстәп, сынар аягын да күтәреп куйса, жинел-курач гәүдәсен үз көчәре тирәсендә бер әйләндереп тә чыгарса... бу инде тапкыр сүзне ошату, көлүнең иң югары кимәленә житү билгесе.

Өлкән әдибебез Гариф ага Ахунов үзе хакындагы шаяртуларны да эчкерсез кабул итә иде.

Бервакыт Актёрлар йортында ШТМ (шаяннар, тапкырлар мәжлесе) бара. Сәхнәдә — шагыйрь Зөлфәт, шулкадәр охшатып, Гариф Ахунов булып сөйли:

— Товарышши!

Я буду говорить по-русски, потому что среди нас есть русские писатели: Рустэм Кутуй и Диас Ва-ли-ев...

Товарышши!

У нашега многонационального татарскыга наруда есть па-га-вур-ка: адин рукаф пинжәкә никагда не бывает каруче другава рукава пинжәкә, так жы и у писателей: адин члин никогда не бывает ка-ру-че другава члина... союза писателей СССР. Но сриди поэтов есть и такие — дибаширы, пьяницы и хулиганы, это — Зульфат и Мударрис Агъ-ля-мов...

Зал рәхәт чигеп көлә, конкрет кешенең исемен әйтеп юморга кертүнең татарда беренче яралгысы бит әле бу. Сибгат ага Хәким, янәшәсендәге Гариф Ахуновка төртеп:

— Син, Гарифжан, СССР Югары советы депутаты башын белән болай үзеңнән көлдермә, килешми бит, — ди.

— Яшь чакта көлеп калсыннар, — ди Гариф Ахунов. — Олыгайгач, үзләреннән көләрләр...

## Атаклы «һә—әйй!»

Гариф ага Ахунов кунакчыл, юмарт кеше иде. Унайсызланырлык байлыгы булмагач, фатирына да язучыларны алып кайтып, сүздән, табын түгәрәклегеннән, үзе әйтмешли, жәдә тәм табып утыра белә иде ул.

Бервакыт ул безне (Разил Вәлиевне, Рафаэль Сәхәбиевне һәм мине) аулак өйгә дип алып кайтты. Без аңа фатирының бик кысан икәнен, хәзер инде зур фатирларга күченү дәвере икәнен сак кына искәртеп алдык...

— Мина Арча поездларының тавышы ишетелеп тора. Моннан беркая да күченәсем килми, — диде Гариф ага.

Кичке уннарга кадәр бер-беребезне макташып утырдык. Ул табынга эләкмәгәннәр бәхетсез иде, чөнки иң акыллы, иң талантлы, иң әйбәтләр фәкать шушындагы без һәм без генә идек.

— Шаһидә апагыз дачада куна бүген, берүземә күнелсез, — дип, Гариф ага безне озата чыкты.

Жәйге жылы төнге урамнар буйлап әдәбият турында гәпләшеп шактый

йөргәнбездер. Төнге уникеләрдә мин үзем яшәгән якка баручы соңгы трамвай белән кайтып киттем.

Иртәнге сәгать сигездә телефон чылтырый. Шаһидә апа тавышы: бераз кырыс таләпчәнлек тә, шул ук вакытта борчылу төсмере дә бар сыман.

— Гарифҗан абыен бүген өйдә кунмаган. Сирәк була торган хәл. Кайда икәнен син беләсен булыр...

Мин бу көтелмәгән сораудан куркып калдым. Шаһидә апа безнең өчен әби патша кебек иде бит, аның кәефенә туры килмәү берәүне дә бизәми иде. Нидер әйткән булам, ә үзем кинәт кенә югарып калган баш миемне бораулыйм.

— Шаһидә апа, Рафаэль Сәхәбиевларда түгел микән ул? — дим, икеләнеп.

Сәхәбинең кварталдагы биниһая зур йортта торуын чама белән аңлатам. Төгәл адрес, йорт номеры, этаж минем хәтер ятьмәсенә эләгә торган балыклар түгел шул.

Минем алама гына аңлатуым да яраган, эзләп тапкан бит Шаһидә апа. Ниагара шарлавыгы кебек галәмәт озын һәм биек йорт каршында фатир номерын инде кемнән сорап карыйм икән дип, чарасыз калып торганда... йөзләрчә тәрәзәнең кайсыдыр бер форточкасыннан бик тә таныш, бик тә кадерле «Һә-әәйй» дигән тавыш очып чыкмасынмы. Гарифҗанымны бик сагынганга колагыма ишетелгән сыман гына булгандыр дип, икеләнеп, сагаеп тыңлый башлаган Шаһидә апа.

Хикмәт шунда: табын бик күркәм булып, өстәл янындагы утырдашлар да ошап китеп, кәефе иң югары кимәлгә житкән чакта Гариф ага бер жырны башкармыйча калмый иде:

*Тып-тып кына басып килә*
*Көмеш тояк тулпар атым.*

Ул аның соңгы ике юлын, шаяртып, болай дип тә тәмамлый торган иде:

*Тып-тып гына кайтып килам,*
*Кертерме дип өйгә хатын.*

Шушы жырның алдагы ике юлын кабатлаганнан соң, ул, уң кулын өскә чөеп, күзләрен рәхәт кысып, үтә бер ихлас күтәренке хис белән: «Һә-әәйй!» — дип куя, бу инде жырның иң биек ноктасы була. Хәтта Илһам Шакиров үзе дә Гариф агадан: «Шул «һәй» дигән жирен тагын бер кабатла әле, күпме өйрәнеп карадым, әмма синең кебек булдырып булмый», — дип, кат-кат жырлата иде.

Менә Шаһидә апа да икенче тапкыр «һәй»нең кабатлануын көтеп, эчтән жырны көйләп тора икән. Кирәк бит, нәкъ көтелгән жирендә тегесеннән дә көчлерәк булып, «һәй» авазы шул мәлдә тәрәзәдән бәреп чыккан лабаса! Шаһидә апа сөекле Гарифҗанының кадерле авазын дөньяга очырып жибәргән тәрәзәнең жиленче катта, уңнан санаганда, 32 нчесе икәнен чамалап өлгергән.

Усаллыгын елмаюы артына яшереп, йодрыгын күңеленнән генә йомарлап килеп кергән Шаһидә апа. Аны мул табын, хуҗаларның ачык йөзе, Гарифҗанның: «Килдеңме, матурым», — дип каршы алуы чарасыз калдырган.

Хуҗаларның эчкерсез кунакчыллыгыннан, табынның гел янарып торган нигъмәтеннән мәмнүн булып, Гариф ага белән Шаһидә апа кичке сәгать уннарда гына култыклашып кайтып киткәннәр.

Кайчакта искә төшәләр дә... Казандагы миллион тәрәзәнең берсеннән Гариф аганың әнә шул атаклы «Һә-әәйй»е яңгырап куяр сыман...

Юк шул инде. Кайтавазы гына хәтердә.

*Сахифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

# МӘКАЛЬ ӨМӘСЕ

*Кемнең кулында, шуның авызында ди. Өмә озак бармас ул. Без, журнал егетләре дә, кулда чакта тагын бер кат (үткән елның 9нчы санында мәкаль тупламабыз чыккан иде инде) мәкальләребезне биреп калыйк әле! Сез дә йоклап ятмагыз, кадерле авторларыбыз һәм укучыларыбыз. Соң булса да, уң булсын дип килеп, поездның тәтенен генә күреп калучылар күп булган ул дөньяда. Хәрәкәттә бәрәкәт, йөргән аякка — җим, чапкан каләмгә мәкаль иярсен — XXI гасыр мәкальләре! Өстәп-өстәп җибәрегез. Мәкаль капчыгыбыз, ягъни чыгасы мәкаль китабыбыз мөмкин кадәр тулырак булсын!*

***

- Җаның саклау — Аллаһыдан,
  Тәнен саклау — үзеңнән...
  Җаның сатмау — Аллаһыдан,
  Тәнен сатмау — үзеңнән.
- Җан әҗәткә бирелми.
- Чирканганга чир тиз йога.
- Астыртын астан кисәр.
- Шиген булса ачык — ишегең булсын ябык.
- Астыртынның күзе кызар, йөзе кызармас...
- Азгынның тезгене юк.
- Бур базында бар да бар...
- Сабыр сорамас, алмыйча да калмас...
- Сабыр куесын кабыр.
- Сабырның сыеры да сөзешмәс.
- Сабыр Себердә дә сабыр.
- Сабырсызның сүзе селтеле.
- Кемнедер ярату да үзеңне яратудан башлана...
- Үзен яратмаган — беркемне яратмас...
- Ришвәтенә күрә базары...

**Мөхәммәт МИРЗА**

***

- Гел өргән эткә куркак песи дә ияләнә.
- Эре җиләк үсә торыр, кечкенәсе пешә торыр.
- Сул күршенә керсәң, уң күршеңнән ерагаерсың.
- Су — чокырга, чебен кутырга җыела.
- Дусларынны мәҗлес ахырында сана.
- Яна хәбәр ялганнан арынмас.
- Икмәк белән пычак бер табында.
- Татар түрә булса, түргә туганнарын тезәр.
- Яратмаган кеше белән яшәү — ялгызлыкның бер төре.
- Дустыңның чын йөзен күрәсең килсә, сораганын бирми кара.
- Сатып алалмаса, сатылып ала.

**Камил КӘРИМОВ**

***

- Йөрәкнен яше юк.
- Авыл ахмаксыз, юллар җуләрсез булмый.
- Яшьли сөйгән ярлар яшьлектә кала.
- Игә килмәгән игелек кылмас.
- Ин кыска юл — тайгак юл.
- Һәр кәҗәнен үз мазасы[1].
- Тургайга туп атмыйлар.
- Теш бетә — баш бетми, баш бетә — эш бетми.

**Вакыйф НУРИЕВ**

***

- Нәфес белми тәнәфес.
- Иблис коды: «Өр-яңа мода!»
- Гыйбрәт алмас егылудан туктамас.
- Үзен җилфердәмә, эшен җилфердәсен.
- Синен саулыкны күршен кайгыртмас.
- Юньсез адәм — бер бәла, юньсез түрә — мен бәла.
- Татар түрәсе түргә урыс чабатасын эләр.
- Гадел сүздән курыккан журналист иблискә хезмәт итә.
- Санак[2] — гуҗ тамак: үсмерләрне йота да куя.
- Һәркемнен үз бәхет бизмәне.
- Авыр чакта җыр көйләп йөр.
- Бик авырда — ела, күз түзәр ул.
- Куаныч юкта юаныч та шәп.

**Рафикъ ЮНЫС**



Күп еллар буена авылдан авылга йөреп, мәкальләр, әйтемнәр, фразеологизмнар җыйган Нәкый ага Исәнбәтнен өч томлы, 2887 битле, 35670 мәкальле титаник хезмәте бу!

[1] Маза (*диал.*) — холык, кәеф.
[2] Санак — компьютер.

## ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең беренче президенты, галим, дәүләт эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Мансур Хәсәновның тууына 85 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция булды. Башта җәмәгатьчелек Арча кыры зиратына, аның кабере янына җыелды. Монда М.Хәсәновның бюсты (авторы – Асия Миннуллина) ачылды. Бу чараларда ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашты һәм чыгыш ясады. Ул М.Хәсәновның эш-гамәлләренә югары бәя бирде. ТР Фәннәр академиясе президенты Мәгъзүм Сәләхов, «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, галим Индус Таһиров та олуг шәхесне тирән ихтирам белән искә алдылар. Конференция кысаларында «Татар энциклопедиясе»нең рус телендә чыккан алты томы тәкъдим ителде. Юбилей уңаеннан «Временем призванный. Воспоминания о Мансуре Хасанове» дип аталган китап та дөнья күрде. Аны Мансур Хәсәновның улы Булат Хәсәнов әзерләгән.

## ҖӘЛИЛ ҺӘЙКӘЛЕ

Чиләбедә каһарман-шагыйрь, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең һәйкәлен ачу тантанасы булды. Ул шәһәр үзәгендәге «Манекен» театры скверында урнашкан. Атаклы сынчы Бакый Урманченың «Таштагы портретлар» сериясеннән алынган бу сын – Көньяк Урал башкаласына бүләк. Һәйкәлне ачу тантанасында ТР Премьер-министры Илдар Халиков катнашты һәм чыгыш ясады.

## МИЛЛИ КИТАПХАНӘГӘ – 150 ЕЛ

ТР Милли китапханәсе 150 еллык юбилеен билгеләп үтте. «Милли китапханәләр: үткәне һәм бүгенгесе» дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция булды. Анда Россиянең китапханә тармагы белгечләреннән тыш Төркия, Германия, Казакъстан, Үзбәкстаннан да вәкилләр катнашты. ТР Премьер-министрының беренче урынбасары Алексей Песошин ТР Президенты котлавын ирештерде. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән департаментының китаплар һәм архивлар бүлеге киңәшчесе Светлана Аленькова РФ мәдәният министры Владимир Мединский котлавын укыды. Директор Сөембикә Җиһаншина сүзләренә караганда, ТР Милли китапханәсе Татарстанда гына түгел, Идел буе, Россия күләмендә иң зурлардан санала. Аның фондында 3,3 миллион саклау берәмлеге исәпләнә. Конференциядә ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, ТР мәдәният министрының беренче урынбасары Ирада Әюпова катнашты.

## ТӨРКИ ШИГЪРИЯТ ФЕСТИВАЛЕ

Казанда XI төрки шигърият фестивале үткәрелде. Ул ике елга бер тапкыр уздырыла. Монарчы әлеге чара Казакъстан, Төрекмәнстан, Кипр, Франция, Кырым, Македония, Азәрбайҗан, Косово, Кыргызстан кебек мәмләкәтләрдә булды. Быелгы фестивальдә 25 илдән 100гә якын шагыйрь катнашты. Аны ачу тантанасы К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында узды. Фестивальне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов ачты. Тантанада ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, ТР мәдәният министры урынбасары Гүзәл Нигъмәтуллина катнашты. Фестиваль кысаларында шигърият хакында фәнни чыгышлар, әдәби бәйләнешләр турында сөйләшүләр, «түгәрәк өстәл», мастер-класслар булды.

## ТУФАН МИҢНУЛЛИН ДЕКАДАСЫ

Г.Камал һәм К.Тинчурин театрларында Туфан Миңнуллинның тууына 80 ел тулуга багышланган декада булды. Анда Татарстан, Башкортстан, Марий Эл, Оренбург театрлары катнашты. Декадада Т.Миңнуллин пьесалары буенча 19 спектакль күрсәтелде.

## ТЕАТРДА ТАНТАНА

Туфан Миңнуллин исемендәге Түбән Кама Татар дәүләт драма театры яңа сезонын ачты. Аны ачу тантанасы Т.Миңнуллинның тууына 80 ел тулуга багышланган иде. Шул уңайдан театрда мәшһүр драматургка бюст ачылды. Тантанада ТРның мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, Түбән Кама шәһәре башлыгы Айрат Метшин, драматургның җәмәгате Нәҗибә Ихсанова һәм кызы Әлфия ханым, сабакташы Ринат Тажетдинов, язучылар Данил Салихов, Вахит Имамов, Мансур Гыйләҗев, Гафур Каюмов, Айгөл Әхмәтгалиева, театр коллективлары катнашты.

Драматург Мансур Гыйләжевка Татарстан Язучылар берлегенен Туфан Миннуллин исемендәге яна премиясе тапшырылды.

### ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында прозаик, драматург Мәдинә Маликованың юбилей кичәсе булды. Анда ТР мәдәният министры урынбасары Гүзәл Нигъмәтуллина бәйрәмдарга ТР Дәүләт Кинәшчесе Минтимер Шәймиев котлавын житкерде. ТР Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм итү фонды житәкчесе Нурия Һашимова ТР Президенты аппараты житәкчесе Әсгать Сәфәров котлавын иректерде. Тантанада Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, Казан федераль университетының Л.Толстой исемендәге филология һәм мәдәни багланышлар институты доценты Рамил Мирзаһитов, Татарстанның халык артистлары Наил Дунаев, Дания Нурлы, Халимә Искәндәрова, «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Ләйсән Юнысова, юбилярның җәмәгате, шагыйрь Әхмәт Рәшитов, якташлары — Сарман районы вәкилләре дә изге теләкләрен әйттеләр.

### САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Әлмәттә «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте һәм Татарстан Язучылар берлегенең Саҗидә Сөләйманова премияләрен тапшыру тантанасы булды. Бу премия моннан ун ел элек булдырылган иде. Быел да тантана Әлмәт Татар дәүләт драма театры бинасында узды һәм С.Сөләйманова премиясенең барлык лауреатларын җыйды. Тантанага килгән кунаклар Саҗидә Сөләйманова бюстына чәчәкләр салды, шагыйрә исемен йөрткән китапханәдә шигъри бәйгедә катнашты.

Быел дәрәҗәле премиягә «Миһербанлык чишмәсе» китабы (Татарстан китап нәшрияты) өчен — Иҗаудан шагыйрь Ринат Баттал, «Кар юлы» китабы (Татарстан китап нәшрияты) өчен — Чаллыдан шагыйрә Сирень Якупова, «Ветер сердца» китабы (Татарстан китап нәшрияты) өчен Казаннан шагыйрә Ольга Левадная лаек булды. Лауреатларны «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары, «Рухият» янарыш фонды рәисе Рөстәм Мөхәммәдиев, Әлмәт районы башкарма комитеты житәкчесе Нажия Хәйдәрова котлады. Кызыксындыру премияләре Түбән Камадан Илдар Хәйруллинга (Татарстан китап нәшриятында басылган «Ерып чыгарбыз» дип аталган китабы өчен), Әлмәттән Нәфисә Сабиржановага («Икегә бүленгән гомер», «Рухият» нәшрияты) һәм Лениногорскидан Наил Шәрифуллинга («Кая бара бу дөнья?», Татарстан китап нәшрияты) тапшырылды. Алар бу бүләкне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов кулыннан алды. Республикабызның югары уку йортларында белем алучы, әдәби иҗат белән шөгыльләнүче 10 студентка Саҗидә Сөләйманова стипендияләре бирелде. Егетләрне һәм кызларны Саҗидә Сөләйманова белән язучы Әдип Маликовның улы Әнвәр Маликов, «Рухият» рухи янарыш фондының башкарма директоры Флюра Шәйхетдинова тәбрик итте.

### АЛИШ ПРЕМИЯСЕ ИЯСЕ

Спас районы Көек авылы мәдәният йортында Абдулла Алиш исемендәге әдәби премияне тапшыру тантанасы булды. Быел бу бүләккә «Бүләк» китабы (Татарстан китап нәшрияты) һәм балалар матбугатын үстерүгә лаеклы өлеш керткән өчен шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова лаек булды. Премияне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов тапшырды.

### ОЧРАШУЛАР

Минзәлә районында «Казан утлары» журналы көннәре булды. Анда журналның баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, бүлек мөхәррире Айгөл Әхмәтгалиева, авторлар — Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге житәкчесе Факил Сафин, шагыйрә Фәнисә Шәйдуллатова катнашты. Язучылар Минзәлә педагогика колледжы, авыл хуҗалыгы техникумы, татар гимназиясе укучылары һәм укытучылары белән очраштылар. Минзәлә муниципаль районы башлыгы Айдар Саләхов белән очрашуда әдәбиятны, мәдәниятне үстерү, милли матбугатны тарату мәсьәләләре хакында эшлекле сөйләшү булды. Бу чараларда район хакимияте башлыгы аппараты житәкчесе Роза Салдаева, район мәгариф бүлеге мөдире Наил Габдуллин һ.б. катнашты.

***

«Казан утлары» журналы редакциясе исеменнән бер төркем язучылар Марий Элнын Бәрәнге районында булып кайтты. Равил Фәйзуллин, Илфак Ибраһимов, Камил Кәримов, Радиф Сәгъди һәм Фәйрүзә Мөслимова Портянур, Куян, Бәрәнге мәктәпләрендә очрашулар үткәрделәр. Кунакларны район хакимияте башлыгы Әлфит Ибраев кабул итте.

***

«Казан утлары» журналы редакциясе вәкилләре һәм авторлары Сарман районында булдылар. Җәлил эшчеләр бистәсендә һәм Ләшәү-Тамак мәктәбендә очрашулардан соң, Сарманның Үзәк мәдәният йортында әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәдә журналның баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, аның урынбасары Рамил Ханнанов, бүлек мөхәррире Камил Кәримов, пропаганда бүлеге хезмәткәре Фәнил Гыйләҗев чыгыш ясады. Бу чараларны оештыруда район башлыгы урынбасарлары Гүзәл Гәрәева, Фәндәс Вәлиев, мәгариф, мәдәният бүлекләре, үзәкләштерелгән китапханә хезмәткәрләре актив катнашты.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: исторический роман В.ИМАМОВА «Сулейман султан»; повесть А.ХАМЗИНА «Шамкай»; стихи Р.НИЗАМИ, Р.БАШАРА, С.АХМЕТЗЯНОВОЙ; рубаи Г.МУХАМЕТШИНА.
«100-я страница»: В.ИМАМОВ. «Татары ли наши богачи?»
«Круглый стол» с участием Г.Арсланова, И.Загидуллина, И.Ибрагимова, И.Рамиевой, З.Хакима, Р.Ханнанова, Ф.Хузина.
«Литературная критика»: статья Ф.ХАСАНОВОЙ, посвящённая творчеству Г.Кандалый; статья Р.ШАРАФИЕВА, посвящённая произведениям Р.Газизова; статья Р.БАТУЛЛЫ, посвящённая особенностям перевода романа «Хан Узбек» А.Егина.
«Искусство»: беседа Г.САГИТОВОЙ с актрисой театра им.Г.Камала Н.ГАРАЕВОЙ.
«Наши юбиляры»: статья Ф.БАТТАЛА, посвящённая 110-летию со дня рождения С.Баттала; статья К.КАРИМОВА, посвящённая 90-летию со дня рождения Г.Ахунова.
«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.РАХМАН.
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Пейзаж». *Работа Айрата Гайфуллина;*
парк Кирова в Казани после реконструкции.

# IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: historical novel by V.IMAMOV «Suleiman Sultan»; story by A.KHAMZIN «Shamkay»; poems by R.NIZAMI, P.BASHAR, S.AKHMETZYANOVA; rubaie by G.MUHAMETSHINA.
«100th page»: V.IMAMOV. «Are the Tatars are our rich people?»
«Round table» with participation of G.Arslanov, I.Zagidullin, I.Ibragimov, I.Ramieva, Z.Hakim, R.Khannanov, F.Khuzin.
«Literary criticism»: article by F.KHASANOVA, devoted to creativity by G.Kandaly; article by R.SHARAFIEV, devoted to worksby R.Gazizov; article by R.BATULLA devoted to translation peculiarities of the novel «Khan Uzbek» by A.Egin.
«Art»: conversation of G. SAGITOVA with the actress of G.Kamal theatre. N.GARAEVA.
«Our jubilees»: article by F.BATTAL, dedicated to the 110th anniversary of S.Battal; article by K.KARIMOV, dedicated to 90th anniversary of G. Akhunov.
«Tukai and Tatar literature»: rubric is led by R.RAHMAN.
«Pages of humor»: rubric is led by M.GALIEV.
From photo archives of the magazine.
Diary of socio-cultural life.
On our covers: «Natural scenery». Work by Ayrat Gayfullin;
Kirov Park in Kazan after reconstruction.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Пейзаж». *Рәссам Айрат Гарифуллин эше.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Казандагы төзекләндереп яңадан ачылган Киров паркы.

# Яңа китаплар




**Разил Вәлиев.**
**МӘХӘББӘТ ҺӘМ НӘФРӘТ.**
**Разиль Валеев.**
**ЛЮБОВЬ И НЕНАВИСТЬ.**
*Шигырьләр, повестьлар, истәлекләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. — 543 б. Тиражы — 2000 данә.*

Бу китапка Татарстан Республикасының халык шагыйре Разил Вәлиевнең төрле елларда иҗат ителгән шигырьләре, повестьлары һәм мәшһүр шәхесләр турындагы истәлек-язмалары керде. Киң катлам укучылар ихтыяҗын исәпкә алып, әсәрләр татар һәм рус телләрендә тәкъдим ителә.




**Нур Әхмәдиев.**
**МӘҖНҮНЛЕКТӘ МИҢА ТИҢНӘР ЮК.**
*Шигырьләр, чәчмә әсәрләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. — 335 б. Тиражы — 2000 данә.*

Әлмәттә яшәп иҗат итүче танылган шагыйрь Нур Әхмәдиевнең әлеге җыентыгына кырык еллык иҗат дәверендә язылган шигырьләре һәм соңгы еллардагы яңа әсәрләре туплап бирелде.

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2015
Парклар һәм
Скверлар елы



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)